
ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2000





Qazanda şığer bəyrəme

# Казан утлары
# Qazan utları

*2000*

# 4

**(930)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Хәсән ТУФАН. Сүз кушасы килә талларга. *Шигырь* ..... 5
Рафаэль СИБАТ. Ялгызак. *Моңсу роман* ..... 6
Марс ШАБАЕВ. Ярты төн бәйрәме. *Поэма* ..... 80
Рахмай ХИСМӘТУЛЛА. «Оныкларым, сез бәхетлеме?» *Лирик повесть* ..... 89
Шамил МАННАП. Монсу парчалар. *Шигырьләр* ..... 133
Рифә РАХМАН. И Кешем! *Шигырьләр* ..... 147
ИДЕЛБИКӘ. Дүртьюллыклар ..... 150


ЖИҢҮНЕҢ 55 ЕЛЛЫГЫНА


Рәис САФАРОВ. Әҗәл белән янәшә ..... 139
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шигъри җанлы галим ..... 164
Илбарис НАДИРОВ. Искә төшә сугыш еллары ..... 166


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Рәдиф ГАТАШ. «Сәфәрләргә чыксаң белерсең...» ..... 152
Миләүшә ХАҖИЕВА. «Утырып уйлар уйладым» *(Рецензияләр конкурсына)* ..... 173


ПУБЛИЦИСТИКА


Нәҗибә САФИНА. Фидакарьләр вөҗдансыз булмый ..... 158


ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА


Таһир ГЫЙЛӘҖЕВ. Тукай һәм Вәлиди ..... 177


ЮМОР-САТИРА


Азиз НӘСИН. *Хикәяләр.* ..... 183
Безнең календарь ..... 186
Котлыйбыз ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. СИБАТА «Холостяк» *(начало)*, повесть Р. ХИСМАТУЛЛЫ «Счастливы ли вы, внуки мои?»; стихотворение Х. ТУФАНА, поэма М. ШАБАЕВА «Праздник полуночи», стихи Ш. МАННАПОВА, Р. РАХМАН, ИДЕЛБИКИ.
К 55-летию Победы»: воспоминания Р. САФАРОВА «Рядом со смертью»; статьи Р.ФАЙЗУЛЛИНА «Ученый с душой поэта» и И. НАДИРОВА «В памяти—годы войны».
«Литературная критика»: Р. ГАТАШ— Взгляд на творчество поэта З. Мансурова.
«На конкурс рецензий»: М. ХАЗЕЕВА рецензирует книгу Т. Миннуллина.
«Публицистика»: статья Н. САФИНОЙ «Самоотверженные».
«К истории литературы»: статья Т. ГИЛЯЗОВА «Тукай и Валиди».
«Юмор-сатира»: рассказы турецкого писателя А. НЕСИНА.
Наш календарь.
В номере отмечаются 70-летие З. Гумеровой и 60-летие артиста теарта им. Г. Камала Х.Залялова.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: «Весеннее половодье»; писатель-публицист Магсум Гараев.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": R.SIBAT 'S novel «The bachelor», R. HISMATULLA 'S storry «Are you happy, my grandchildren?»; M. SHABAEV 'S poem «The midnight holiday»; verses of H.TUFAN, SH. MANNAPOV, R. RAHMAN, IDELBIKA.
"Commemorating the 55 th anniversary of Victory": R. SAPHAROV 'S memoirs «Near the death», R. FAIZULLIN 'S article «The scientist with poet soul», I. NADIROV 'S article «War years in our memory».
"Literary criticism": R. GATASH - poet Z. Mansurov 's creative works.
"Review competition": M. HAZEEVA'S review of T. Minnullin 's book.
"Publicism": N. SAFINA 'S article «Selfless».
"History of literature"; T. GILAZOV 'S article «Tukay and Validi».
"Humour - satire": the Turkish writer A. NESIN 'S stories.
"Our calendar".
Commemorating the 70 th anniversary of Z. Gumerova and the 60 th anniversary of N. Zalalov.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «The spring flood», the writer M. Garaev.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 15.03.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-112
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066 Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

ШИГЪРИЯТ

# Xəsən Tufan

## Süz quşası kilə tallarğa

Uyğa talğan
Dərya talları...
Şundıy uyçan aulaq tannarda
Süz quşası kilə tallarğa:
—Sez beləmsez qaya barğannı,
Uyğa talğan dərya talları?

Şundıy uyçan aulaq tannarda,
Tanışların kürgən şikelle,
Tuqtıy keşe, uzıp kiteşli,
Həm baş iyə monsu tallarğa,
Şundıy uyçan aulaq tannarda.

Süz quşası kilə tallarğa, —
Əytersen, tal tatarça belə.
Belmi də bit, çiksez mənqedə
Tere xəldə oçrıy alğanda
Süz quşası kilə tallarğa:

— Sez beləmsez qaya barğannı?
Tere xəlgə kilgən bu matdə
Qayadır bit bara, əlbəttə.
Yafraq yarıp—sanap zamannı,
Sez beləmsez qaya barğannı?

Uyğa talğan dərya talları
Dəşmi genə yafraq yaralar,
Dəşmi genə qarap qalalar
Keşe qaya kitep barğannı...
Uyğa talğan
Dərya talları.

## Чәчмә әсәрләр



**Рафаэль Сибат**

# ЯЛГЫЗАК

МОҢСУ РОМАН

*Кадерле вә сөекле апам,*
*Шәйхуҗа кызы Мөнҗия Заһидуллина,*
*Сиңа багышлыйм бу әсәремне.*

Автор.

## I кисәк

Егерменче еллар ахырында гражданнар сугышы солдаты, таза тормышлы Гыйбадулланың улы Заһидулла ипле генә итеп Аяз мулла кызы Заһидәгә эндәште:

—Беләсеңме, матурым, нәрсә... Бу күмхуҗ дигәннәре җүнгә алып бармас... Авыл мужигын, барысын бергә җыеп, бер камыт кигезеп эшләтү булачак бу. Эрбәлүтсия ясап маташулар шушы камытка кайтып каласын белсәм, кызыләрмис булып сугышта да катнашмаган булыр идем мин—бичара. Ходаем шулай кушкандыр...

Алар мамык очырган карт тупыл төбендә утыралар иде...

Күккә алама болытлар каптырылган, шуңамы аның зәңгәрсу якты төсе шактый уңып, ул караңгыланып калган. Күптән түгел генә яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп, давылланып узган яңгыр дөньяга салкын өшеткеч тоем калдырып, көнбатышка юнәлгән. Кояш битенә ямаулык булып кунган сыек алама болытлар аның йөзен дөньядан яшергәнгә күрә, жир өстендә сабырсыз суыклык өстенлек итә иде...

Әмма...

Карт тупыл төбеннән челтерәп аккан чиста сулы саф чишмәгә карап утырган егерме тугыз яшьлек егет белән егерме яшьлек кызның ипле вә җыйнак кына тоташкан кулларыннан бер-берсенең тәненә вулкани

---

Рафаэль СИБАТ (Хужин) (1946)—*язучы. «Исабәт», «Атлар рәнҗеше» романнары һәм дистәләгән повесть-хикәяләр, күпсанлы поэма-шигырьләр авторы. Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында яши.*

кайнарлык илә җан җылысы да агыла иде. Тагы шунысын да өстәргә кирәк: моннан җиде ел элек егерме ике яшьлек Заһидулла Аяз мулла кызын шушы чишмә янында күреп, балигъ булып та җитмәгән унөч яшьлек кызыкайның бер күз сирпешеннән гашыйк Мәҗнүн, бичара Таһирга әйләнеп, тегесе дә беренче тапкыр төн йокысын онытып, иртәнге таң атуга, Ләйлә-Зөһрәгә әверелеп, алар бер-берсен ихлас сөя һәм Гашыйклар Чатыры астында яши башлаган иде.

Инде мәңгелеккә кавышырга дип йөргәндә генә, илдә крестьяннарның элеккечә яшәү ихтыяҗ-шәкләнә, ә аннан соң инде дин-иманга каршы кызыл, канлы, утлы көрәш башланып, бу ике яшь күңел, чынсаф гашыйклар аптырап, икеләнеп, гаҗәпләнеп калган иде. Әмма яшь йөрәкләрне замананың кара пәрдәләре генә ябып куя алмыйдыр, шуна алар өйләнешергә, гомергә бергә булырга шушы карт тупыл төбендә вәгъдәләшкәннән соң, икенче сүз итеп Заһидулла колхозлар хакындагы уен кузгатты.

—И-и-и, җаным,—диде Заһидәсе.—Син бит сәвит влачы өчен көрәштең, сугышта катнаштың, сиңа нигә куркырга ди инде ул күмхуҗлардан? Синең яшьтәшең Габдрахманнар оештыра ич аны...

—Электән үк бае булган, ярлысы... Акыллысы бар, ахмагы... Тырышы бар, ялкавы, һәр нәрсәгә җанын фида кылучылар бар, битарафлар. Карак бар, урламый яшәүчеләр... Боларның барысын да бер юрган астына җыяргамы? Юк инде, матурым!

Заһидәсе аңа елыша төште һәм челтерәп аккан чишмә тавышына кушылып болай диде:

—Ә син курыкма, Заһидулла! Без юрганны гомер буе икебез өчен генә тотарбыз...

Кызның серле вә ымсынулы тавышына дертсенеп һәм дәртсенеп киткән егет аны үз кочагына алды:

—Юрган—гашыйклар чатыры ул, матурым, аңа ике генә кеше сыя...

Алар беркавым шулай бер-берсенең йөрәк кагышын, кан агышын тыңлап утырдылар. Менә нindидер сихри көч илә Вакыт аларның тәннәренә тылсымлы бердәмлек иңдереп, йөрәкләр бер төсле кагып, кан бер үк агыш-табышка керде. Мәхәббәт импульсы иде бу!

Тик шулай да мондый ою, шушындый сәҗдәлек озакка бармады, алдагы тормыш турындагы авыр уйлар икесенең дә баш миен тоташ кимереп тора иде...

—Заһидулла, җаным, кая китеп качарга телисең бу тормыштан?—дип тынлыкны бозды гаҗиз калган Заһидә.

—Урманга, аюлар янына!

—Кешеләрдән качып урманга? Әле тагы аюлар янына? Йәле, шаяртма сана?!

—Мин хагын әйттем...

—Аюларың кешеләрдән артыкмыни?—диде кыз Заһидулланың аучы икәненә төрттереп.

—Артык...

—Кай яклары белән?

—Алар эрбәлүтсияләр ясап тормыйлар!

—Ха-ха-ха...—кыз егылып көлде.

Егет аны яратып кочагына алды.

... Болытлар тарала төшкән иде...

—Аһ, җирбитләр! Көпә-көндез кочаклашып...

Карасалар—карт тупыллар арасыннан, шома таягын күтәреп, Аяз мулла болар өстенә килә. Авызыннан күбекләрен чәчә-чәчә. Башка вакытларда Шөн халкы алдында мәгърифәтле, инсафлы, гадел мулла булып күренсә дә, ул бүген Сабир байның данлыклы кызыл үгезе кыяфәтенә кергән: күзләрен кан баскан, борын тишекләре әчтерхан чикләвеге керердәй булып кабарган, хәтта какшамас нык-калын иягендәге ак сакалы да дерелди кебек.

Яшьләр, тилгән күргән чебешләрдәй, аерылдылар, ләкин егет кызны үз яныннан җибәрмәде, бары артынарак таба гына яшерде. Менә хәзрәт авыр-саллы таягын күтәрде:

—Аһ, уйнашчылар! Картайган көнемдә якты йөземә кара китереп... Ик-ке-гез-не дә... бәр-реп үт-тер-рәмм!!

Заһидулла сак һәм чак кына кулын күтәрде:

—Бабай, матри аны! Бу сиңа теге заман түгел. Без советский власть өчен воевать иткән...

Гражданнар сугышы солдаты ачулы сөйләшкәндә, урыс сүзләрен кыстырырга ярата иде. Хәтта бер-ике «мат» белән. Бу юлы аларны иреннән очып чыгам дигәндә генә тешләп алып калды. Ни генә димә, рәттән генә сөйгән кызы, ә алдында авылның хөрмәтле мулласы, аның булачак бабасы тора ич!

Аяз мулланың саллы-усал таягы җиргә чүкте, ләкин гайрәте утлы казандагы су кебек кайнап-ташып тора иде әле:

—Нич-чек мм...—мин син-га баб-бай бул-лыйм ди-и-и?!—ачулы хәзрәтнең дә сөйләме үзенчә, ул авазларда, аларның да тартыгын үзенә нык тартып, шуларда таптанып-нитеп сөйләшә иде.

—Без Заһидә белән өйләнешергә килештек,—диде егет, мулланың күзләренә ачык вә туры карап.

—Кыз-зым дөр-рес-сме?—диде хәзрәт.

—Әйе! Дөрес, әтием...—диде Заһидә оялып кына. Аннан битен каплады.

—Ә бб...-бб...-ббезз??? Бездән... ббезз-ддән рөхсәтне кем сораган?—Аяз мулла йомшый төште.

—Бүген әтине сезгә җибәрәм,—диде Заһидулла.

—Алай булса гына...—хәзрәтнең кикриге тәмам шиңде. Менә ул, теләсәгез, чукыныгыз шунда дигәндәй, кул селкәде дә үзе килеп чыккан тал-тупыллар арасына чумды.

* * *

Болытлар таралып, күктә кояш тантана итә иде.

Нократ елгасының Ямул суы коя торган тамак урынын яңа тормыш итәр өчен сайлап алды авылдан урманга, кешеләрдән аюлар янына качкан Заһидулла.

Монда тыныч иде...

Монда рәхәт иде...

Чордашы вә әнисе ягыннан туганы Әхмәдулланың забузной каегына («заводная лодка»дан алынган) барлык булган мал-мөлкәтен салып, Идел кичеп, шул тамакка бушатынды. Әхмәдулла аның белән саубуллашып, аргы якка юл алуга, егетнең җаны да бушанды: авылмы, әллә яңа өйләнешеп кенә анда калган Заһидәсеме аны нык кына сагындыра башлады.

—Сәлам тапшыр безнекеләргә!—дип кычкырды ул, әле Әхмәдулла ярдан аерылып, көймәсе канатларын селки башлаганчы ук.

—Әй-тер-мен,—диде тегесе салмак кына.

—Ни...

—Ан-лыйм. Иң берен-чесе сә-ламнең Заһидәгә...

—Мин...

—Ку-ышын я-сап бетер-гәч, ал-мага кай-та ди-ярмен...

—Йә, жарар...—Заһидулла аңа кул болгады һәм бер кочаклык мал-мөлкәтен күтәреп куе зireклеккә кереп китте. Эчкәрәк кереп, кечерәк бер аланга чыгуга, аны бер имәнгеч күренеш көтә иде. Бүреләр өереме, әллә саташкан аюмы ботарлап ташлаган яшь кенә поши баласы гәүдәсе. Дөрес, аның тәне сөякләргә генә калган диярлек, ләкин менә башы ни сәбәптәндер бөтен булып, аның калай күзләре ир-егеткә текәлгәннәр:

—Нигә килдең монда?
—Яңа тормыш корыр өчен!—дип, уйда гына җавап бирде Заһидулла.
—Ул яңа тормышны авылыгызда коралар ич?!
—Аларныкы миңа ошамый...
—Кешеләрнеке кешегә ошамагач, син кеше түгел, димәк?
—Мин үземчә кеше, аерым кеше...
—Авыр булыр сиңа, Кеше.
—Авырлыклардан курыкмыйм мин, ирексезләүдән куркам...
—Сау бул, Иреклеҗан!
—Хуш, поши дус!!

Ир-егет үлән, куакларны ерып алга юл сарды, ә болын-аланда яткан пошиның күзен чебеннәр сырып алды.

Нинди-дер сукмакка килеп чыгуга, хуш исләр аңкытып, нарат урманы башланды. Төз һәм биек наратның юан кәүсәсендәге тукран, барабан каккандай, тукылдатып алды:

—Тук-тук! Тук-тук-тук!!

—Бу якка тукмак эзләп адәм килгән, бәхет табам дигән. Эзләр дә—табармы? Эзләр дә—табармы? Бармы ул бәхет??? Тук-тук-тук.

Заһидулла куелыкка таба юл алды. Хәзер инде хуш ис черек агачлар, иссез-нисез гөмбәләр, җирдә ятучы ботак-шатак, ылыс эңәләре коелган күркәләр өстеннән юл тотты. Бер кавым тирә-юньне күзәткәләп барган Заһидулла каршы яктан су дымын тойды. Якында гына Сарапул күле булырга тиеш. Ул бит бу якларны әйбәт белә: гражданнар сугышы вакытында күлдән ерак та түгел урнашкан тау өстендәге урыслар авылы Биектауда (Высокая Гора) аклар, ә Шөн ягында кызыллар торды. Әхмәдулла каегында бу якка разведкага чыккан кызылармисләр белән бер командирны, аклар тотып алып, асып та куйдылар. Аларны соңыннан, Шөн ягына алып кайтып, татар зиратыннан өскәрәк калкулыкка, Әби патша юлы кырыена туганнар каберенә күмделәр...

Заһидулла күл ягына китмәде, аңа язын су басмый торган үр урын, йорт һәм каралты-кура төзерлек иплe бер сырт кирәк иде. Шуңа ул җирнең түбәнәя баруын яисә күтәрелә килүен чамалап, сукмагын төньякка таба борды. Шул вакытны...

Ул чүт кенә кара еланга килеп басмады. Тегесе инде, телләрен чыгара-чыгара, чагарга дип, башын да күтәргән иде...

И котырды салмак-иплe, сабыр уйлы Заһидулла:

—Син, мать твою! Яңа җиргә килеп җитмәс борын ужалить хочешь, гадюка, черную мать твою!?

Исәрләнгән ирдән аю да читкә чиртә, шунамы кара елан, бөгәрләнә-бөгәрләнә шуып, җирдә яткан черек нарат кәүсәсе астына кереп китте. Ләкин...

Елдам ирдән елан да кача алмый шул! Заһидулла җилкәсенә алган төенчеген ташлады да, балтасын тотып агач янына килеп басты, ә елан эчкәрәк елышты. Ул балтасы белән бер күсәклек ботак чабып алды һәм җирдәге нарат кәүсәсен түнтәреп атты. Елан, тыз-быз килеп, кая качарга белми йөргән арада, аңа күсәк белән китереп сукты. Тынсыз калган җан иясе тере иде әле, ул, үз-үзен саклау инстинктына буйсынып, һаман да каядыр шуарга-качарга тырыша, ә бу исә кешене, бу урында Заһидулланы, тагы да котырта төште:

—Әле син исәнмени, гад?! Мә, сиңа! Мә, сиңа!!

Елан өстенә төшкән авыр күсәк бер үк вакытта тетрәндереп җирне дә кыйный иде.

Аның кайтавазы булып еракта ябалакмы ухылдый, бүреләрме улый, урман үземе дулый.

Заһидулла еланны кыйнаудан туктады...

Көч чыгарудан битәр, ачудан мангаена, чәч төпләренә чыккан тирне сөртеп алып, елан үләксәсен күсәк очына элде дә куе ешлыкка ыргытты.

—Уф!—диде ул аннары нигәдер һәм шундук аңлады: еланны үтергәненә ул бик нык үкенә иде инде.

—Ник үтердем мин аны?—дип уйланды ул.—Йә, әйт, аның миңа ни зыяны бар иде... Чакмады ич ул мине, чакмады... Бары куркытырга гына теләде...

Үз-үзеннән ризасызлыкмы әллә күченүнен, яңа тормышның беренче көнендә үк поши үләксәсенә очрап, тукран тукылдавын үзенчә аңлап, инде менә елан үтерүгә—үтерүгә!!!—барып житкәч, аның тынгысыз жанын тагын нииндидер бушлык биләп алды. Күңеленә күле-күле белән сагыш, болыты-болыты белән моң керде...

Бәлки ул, гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр күченеп киткәне өчен үкенгәндер. Ә бәлки?..

Бәлки нәкъ шушы минутларда туган авылын сагынгандыр. Ә бәлки...

Бәгырен кисеп Заһидәсе искә төште аның бу минутта. Югыйсәме? Югыйсә, ятасы иде хәзер менә бу әңгер-меңгердә, печән түшәлгән печәнлектә кочаклашып һәм тын гына мыдыр-мыдыр сөйләшеп. Бербереңә «матурым», «жаным» дигән сүзләрне сибеп. Ә аннан соң туйганчы назга-сөюшүгә батасы иде...

Заһидулла авыр уйлардан арынып та өлгермәде:

—Ты, че тут ходишь?!—дигән янаулы тавышка сискәнеп, башын күтәрде. Каршында ат йөзле, сыер гәүдәле, тап-таза маржа тора иде.

—А я здесь хочу новую жизнь устроить...—диде ул аңа.

—Ты, че? Шунский что-ли?

—Шунский!! Ну и что?

—Ничего... Просто так спрашиваю...

Хатын матур итеп елмайды һәм!—шундук чибәрләнеп китте. Хәйран калды Заһидулла: моның ат йөзле булуы чыраенда салкынлык, кемгәдер ачу йөрткәннән генә икән.

—Кайда кунарга жыенасың?—дип сорады ул аннан.

—Менә эзлим әле. Җайлы урын эзлим, яңа тормыш урынын,—диде Заһидулла.

—Бүгенгә киттек миңа, шалашта төн чыгарсың...

Әңгер-меңгергә сыенган ир һәм хатын төн кунарга шалашка юл алдылар.

* * *

Урман бетүгә, уйсулык башланып, ерактарак таллы-болынлы урыннар күренде. Ләкин аларга кадәр уйсулык белән болыннар арасында бер озын гына түбәсыман жир, артык биек булмаса да үр бар иде. Әлеге калкулык Нократ елгасы янынннан килеп, Биктауга таба калыная төшкән дә кире башлы чөй-үр шәклендә Сарапул ягына да үрләгән-үрмәләгән. Бу—Заһидулла эзләгән урын булып, Тамараның да шалашы аның урман ягына урнаштырылган иде.

—Ошыймы сиңа бу урыннар?—дип сорады хатын.

—Нәкъ үзе!

—Ничек «нәкъ үзе»?

—Мин эзләгән урын ич инде бу!!

—Киттек алайса минем шалашка...

Алар җәһәтрәк атлый башладылар. Заһидулла хатынга карап тагы бер шаккатты: кара аны! Бер дә сыер гәүдәле түгел бу, урман пошиемыни, һәйбәт юырта бу!! Хәер, ныклабрак караган кеше күрми калмас та иде, утыз яшьләр тирәсендәге Тамара, кирәк икән, тыгыз тәнле таза гәүдәсен агачтагы тиен кебек житез бөтереллдерә дә ала иде. Ә менә ял вакытында яисә тынычта ул тагы сабыр-акрын халәткә күчә. Бу аңа гына хас нәрсә булып, аның серен хәтта ата-аналары да белә дә, аңлый да алмый иде...

—Карының ачтымы?—дип сорады хатын.

—Ничек кенә әле. Бер бозау ашар идем,—диде ир шаяртыбрак.

—Хәзер су бозаулары пешерәбез...

—Нәрсә-нәрсә?

—Су бозаулары...

Заһидулла әнгер-меңгерне эретеп көлеп җибәрде, Тамара ана кушылды. Кинәт кенә алар әле беренче тапкыр бер-берсенә төбәп карадылар һәм анладылар: кай яктандыр ир хатынны, хатын ирне ошата башлаган иде инде.

—Ә нәрсә ул су бозаулары дисәм, көләрсең инде, бу үзе бозау икән дип, чамалавым буенча, су бозавы дип балыкны атадын бит,—диде Заһидулла.

—Синенчә әйтсәк, нәкъ үзе!

—Ах!—диде ир.—Чукынып китсен, балык яратам ич мин. Ә аны каян тотабыз?

—Аның тотылганы шалаш эчендә яшел кычытканга төрелеп ята...

—Әйдәле, карыйк әле...

—Юк инде! Товарның мин сина житлеккәнен, тәлинкә белән алдына куелганын күрсәтермен.

—Хәзер үкме?

—Түземсез!—дип тиргәгән булды хатын.—Ә хәзер приказ: чалбар-күлмәк, чабатаңны сал да, ә-нә!—күрәсен, болын уйсулыгында, таллар үскән жирдә Ямул елгасы ага, шунда юынып кил.

—Минем чабата түгел, итек ич!—дип, тагы шаяртып алды, көлә-көлә Заһидулла. Үзе дә ирләр күнитеге—гаскәри офицерларныкы!—кигән Тамара аны аягындагы итеге һәм бер кат эчке ыштаны белән барыбер су коенырга куды:

—Юкса, балык сина тю-тю!!—диде ул хатын-кызларга гына хас кирелек белән.

—Йә, жарар ла,—дип, ир күндәмлек иярене атланды, ә хатын бу урта буйлы татарны күз чите белән генә күзәтеп алырга да өлгерде:

«Таза, нык. Имән кебек бу, тәскә-биткә дә матур күренә. Эх! Ничә ел гомерем мич башындагы чирле ирне карап үтә бит. Гражданнар сугышыннан гарипләнеп кайткач, ни тернәкләнеп китмәде, ни үлмәде. Ярый әле ак офицер икәнен яшерә белде, ялган документлар төшерә алды. Аны күптән чыгарып аталар иде бит. Теге елны аклар кызылларны асып кына куйдылар ич әнә...»

Нык адымнар белән басып, Заһидулла Ямул суына юнәлде. Шактый озак юынды ул анда. Ниндидер бер сизенү ана ашыкмаска куша, әлеге хатын белән очрашуның тикмәгә түгеллеген колагына пышылдый, сабыр итәргә боера. Шуңамы ул юынып ярга чыккач та, озак кына тирә-юньне күзәтеп торды, ә соклану хисе:

—Матур монда! Сөбханалла!!—авазын янгыратты.

Акрын гына үргә күтәрелеп килгәндә, түбә-үрдәге шалаш янында дәртле учак ялкыны караңгылыкны ерып, күккә ымсынып-карап бии иде. Бу бер гажәби матур, тантаналы, тылсымлы вә сихерле күренештән Заһидулла адымнарын сагайтты. Бөтен тәне калтырап, кинәт буыннары сызлап, тез башлары чәнчеп, ул туктап ук калды...

Менә шалаштан чәчләре тузгыган, изүләре ачык пәри хатыны чыкты...

Йә Алла! Әле генә тупас киндер күлмәктән, иске яулыктан һәм ирләр итегеннән булган Тамара хәзер ак озын күлмәктән иде. Муенына нидер таккан, аякларына берни кимәгән. Ә чәчләре?!

Йә Хода! Шундый матур чәчләрне шул иске, тупас яулык ничек оялмый каплап йөри икән? Болар чәч түгел—урман, аның да ешлыгы, ин куесы. Иң матур чегән хатыны да кызыгыр бу чәчләргә. Ни өчен чегән хатынымы? Заһидулла сугыш елларында аннан соң да, чегәннәрне очратып, дөньяда иң матур чәчле кешеләр—чегәннәр дип, уйлый иде.

—Кил кызурак!—дип чакырды хатын.

—Хәзер, хәзер...—дип, мыгырданды бу күренештән һаман да айный алмаган ир.

Килсә... Учак өстенә таякка асып куелган чиләктә быгырдап балык кайный, бер читкәрәк таякка анын юылган күлмәк-чалбары эленгән. Ләкин...

Иң гаҗәбе—Тамараның әверелеше, женнән фәрештәгә әйләнеше иде. Каушаудан Заһидулла аңа борылып карарга да курыкты. Башыннан берсеннән-берсе куркыныч һәм сискәндергеч уйлар узды:

«Кем бу, чукынчык?! Әллә урман пәриеме? Кем бу, женмефәрештәме?»

Ә жен-фәрештә көлә-көлә аңа эндәште:

—Йә инде, че дуешься, утыр учак кырына, хәзер уха ашыйбыз...

Заһидулла аңа ян белән генә, зөфаф киченә кергән кәләш кебек тартынып-оялып кына утырды. Тамара аяк өсте аш бүлә башлады. Шулвакыт...

Сарапул ягыннан кинәт искән җил Тамараның өрфиядәй күлмәген җиңел генә күтәреп җибәрде һәм Заһидулла:

—Кичер, Аллам! Мин түгел, оятсыз җилең гаепле...—диде дә, хатынны, чүмече-ние белән мамык урынына күтәреп, шалашка алып кереп салды. Ирнең әкәмәт каты тәненнән, тыгыз-таза беләкләреннән күптән наз-сөю көткән хатын-кыз тәнендә кинәт учак уты кабынып, Тамара «Ах!»—диде дә, һуштан язганчы Заһидулланың муеннарыннан кочып алды...

... Хатын аңына килгәндә, алар икесе ике якта яталар иде. Икесе дә давылдан соң тынычланып калган урман хәлендә...

... Алар куыштан чыкканда, күк йөзенә ай калыккан, шулпа суынып беткән иде инде.

—Кая чүмечең?—диде ачыккан һәм сусаган Заһидулла беренче гыйшык эшеннән соң ирләр гадәте буенча хатын-кыз белән командалык итеп. Көч түгү—шундук ашауны сорый ич!

—Бүлгече—миндә, сабы—синдә!—дип, чытлыкланды Тамара, оятсыз көлеп. Хатын-кыз үзе белән йоклаган иргә ничек сөйләшсәң дә ярый дип саный бит ул...

Чүмечне куыш эченнән таптылар, ул, чыннан да, икегә аерылган иде: бүлгечкә һәм сапка. Хәер, оста куллы Заһидулла аны тиз саплады һәм әйбәтләп саплады.

Туйганчы балык ашап, уха чөмереп утырганда, кичке салкын төште. Күл бакалары сайрауларын, чикерткәләр черләүләрен туктаттылар.

Биектау ягыннан этләр өрде, яшьләрнең кычкырып көлгән тавышымы, нидер ишетелде.

Еракта бик сагышлы итеп ябалак көрсенде:

—Ух—ху! Ух-ху!!

Алар тагы куышка кереп яттылар. Тамара Заһидуллага сарылды:

—Я тебя люблю, ах! как еще люблю... Дави меня, дави, мой татарский конь!! Я этот день целую вечность ждала...

Ул төнне алар бер тән, бер җан булып кушылдылар, Куыш эчендәге хатынның аһылдау тавышын һәм кинәт түзә алмыйча кычкырып җибәрүләрен күл камышлары ишетеп торды. Ул төнне Татар Аты үз эшен шәп башкарды...

* * *

Сызылып таң атты...

Йокысыннан уянган кошлар өздереп сайрап җибәрделәр. Әкрен искән җилдә камыш сабаклары, кыштыр-кыштыр килеп, кичәге хәлне бер-берсенә бәян иттеләр. Биектау ягында яңгыратып тәүге әтәч кычкырды, аңа башкалар да кушылдылар.

—Кик-ри-кү-үк!

—Нәрсәдер кәкре күк!!

Ир вә хатын иртәнге чыклы салкыннан бераз гына тынып, шунамы бер-берсенә тагы да елышып, шалаш эченнән тышкы дөнья авазларын тын гына тыңлап яттылар.

Заһидулла, Чаян йолдызлыгы астында тугангамы, ифрат кызыксынучан кеше булырак, тагы шуның өстенә хатын-кыз белән төрле мөнәсәбәтләрдә тикшерү, танып белү, серенә төшү кебек характер билгеләренә дә ия инсан икәнлеге аркасында аны кызыксындырган берничә мәсьәлә турында сорау бирми түзә алмады:

—Тамара, син нишләп, Ямул суына коенырга куганда, мине ярым ялангач калдырдың?

—Бердән, синең күлмәк-чалбарың сазга буялган иде...

—Беләм, Вятканы кичкәндә буялды ул... Ә икенчедән?

—Икенчедән?

—Әйе...

—Икенчедәнме?—хатын аның ягына яртылаш борылып ятты һәм, гүя шалашта алар белән рәттән ун кеше бар, Заһидулланың колагына пышылдады:—Икенчедән... мин синең ирлегеңне тикшерәсем килгән иде... «Әле ачыктан-ачык сөйләшү, әле секрет-мекрет...»—дигән уй сызылды Заһидулла башыннан.

—Менә инде,—дип аптырады ир.—Соң аның өчен анадан тума шәрәтән калырга кирәк ич?! Ә син мине ыштаннан һәм күнитектән коенырга кудың... Ярый әле озынборыннар талап үтермәде...

—Юк ла! Аңламадың син...—дип бүлде Тамара.

—Нәрсәне аңламадым? Бик яхшы аңладым!!

—Минем синең тәнеңне күрәсем килде...

—Шуннан?

—Онытма: хатын-кыз иң беренче ир кешенең буй-сынына, тыгыз-таза гәүдәсенә гашыйк була. Алар өчен матурлык, ирләр матурлыгын әйтәм, ул кадәрле үк әһәмиятле түгел.

—Маймылга да кызыкмыйлар инде!

—Әлбәттә...

—Шуннан?—дип төпченде Заһидулла.

—Мин сине бер күрүдә яраттым!—дип беренче тапкырындагы кебек утлы бер аһылдау белән аның муенына сарылды Тамара...

... Шактый гына яткач, ир кеше икенче соравын да бирде:

—Ә ак күлмәк? Ул каян килде?

—«Все свое ношу с собой»,—дигән ди бер борынгы философ. Минеке дә шулай...

—Кем-кем шулай дигән?

—Биант бугай.

—Ә син аны каян беләсең?

—Соң мин революциягә кадәр үк гимназиядә укыган кыз ла! Китапларны да бик күп укыдым...

—Күренеп тора—диде Заһидулла аңа чиксез бер ышанган хәлдә.

—Ә син?—дип сорады Тамара.—Менә син русча да әйбәт кенә сөйләшәсең, фикерләвең дә көчле, логикаң да шәп—син кайда укыдың?

—Казанда, мәдрәсәдә...

—Кит әле, мәдрәсәдә дә шундый белем бирделәрмени? Ә без аны «воронье гнездо» дип, көлеп кенә йөри идек ич?!

—Күргәнеңчә...

Тамара бу тыныч-сабыр, ипле татарның күзләренә тутырып карады һәм борын очына имән бармагы белән йомшак кына басып:

—Ах, мой татарский конь!!—диде.

—Татар ат түгел, татар—ат өстендәге жайдак ул,—дип коры гына төзәтте аны Заһидулла.—Беләсең килсә, синең белән дә мин жайдак!

Шушындый тыныч кешенең эчендә бик дуамал, гайрәтле җен

утырганына төшенгән хатын, корт чаккандай, сискәнеп китте һәм эчтән:

—Тыныч күлдә—женнәр күп,—дип, үзенә акыл алды, алга таба бу татарны ярсытмаска карар кылды.

—Безнең сүз ак күлмәк иде бит...

—Әйе,—диде тынычланган Заһидулла.

—Ул—минем туй күлмәгем,—дип, моңланып куйды хатын.

—Ә муенындагы алтын чылбыр?

—Туйга әтием бүләге...

—Оһо!—дип аптырады ир.—Бай яшәгәнсез!

—Әтием купец иде...

—Ә нигә ак күлмәк белән туентауны шалашта саклыйсың? Өйдә генә калдырасы ич...

—Ирем эчә... Улмы? Ул аларны момент сатып җибәрәчәк...

Тамара, ачылып китеп, Заһидуллага үз тормышын хикәят кылды, бәян итте.

Кояш шактый күтәрелеп, үләннәрдәге елтыр чыклар берәм-берәм юкка чыккан иде инде. Бу вакытта кошлар тавышы да бер мәлгә тынып, җир өстенә талгын бер тынычлык, иплелек, көн башында була торган дәрт вә дәрман җәелгән иде.

Калган шулпаны җылытып, капкалап кына утыралар иде, авылның тау сыртыннан төшеп, өч ир боларга таба килә башлады. Ара ике чакрымлап булса да, боларны күргән Тамараның коты очты:

—Загидулла, зинһар, бар ычкын! Боларга эләксәңме, үтерәләр болар.

—Кемнәр соң алар?—дип сорасы итте ир.

—Иремнең туганнары...

—Ни кирәк аларга?

—Әтиемнең алтыннары...

—Муенсамы?

—Юк, Сарапул күленә тимер ящикта батырылган алтыннар...

Заһидулла китәргә ашыкты, ләкин шуңа карамастан, аны ниндидер бер куркусызлыкмы яисә ялгыз хатынның үзен генә калдырып китәргә теләмәүме тота иде.

«Ах, мылтыкны да аласы булган икән, ә?!»—диде ул үз-үзенә.

Шулвакыт, юләрдән сорама үзе әйтер дигәндәй, аның башына тагы бер сорау килде:

—Ә, син, көн-төн бу шалашта нигә кунып ятасың?

—Алар алтын ящик күмелгән урынны эзлә, диләр. Мин белмим, дим...

—Соң белмәгәч?!—дип ярсып китте сабыр Заһидулла.—Мать твою!!

Тамараның күзләре зур ачылды, ул тагы, әле яңа гына күргәндәй, Заһидуллага карады:

—Син нишлисең, Загидулла?

—Гафу...

—Ярар инде... Тик шулай да кит моннан! Болар сине минем белән күрсәләр, һичшиксез үтерәчәкләр...

—Алтынны бергәләп эзлиләр дипме?

—Соң бергә утырып уха ашаганнар дип түгел инде. Алар өчен балык шулпасы—нуль, аларга алтын кирәк, шуның белән теге якка, кордон артына качарга... Ә мин күлдән мурдага алтын балыклар тотып ятам, күл төбеннән алтын эзләмим...

Алар икесе дә куышның урман ягында иделәр. Уйсулыктан килүчеләрне ачык күрсәләр дә, алар безне күрмидер дип уйладылар. Тик тегеләр якынайган саен Тамараның шик-шөбһәсе арта барды, ул Заһидулланы кочаклап үпте дә, күз яшьләренә тыгылып, урман ягына этәрде. Ир кеше, өч-дүрт адым атлауга, хатын үзе үк аны туктатты:

—Тукта!

—Ни бар тагы?—диде кире борылган Заһидулла.

Тамара муенындагы алтын чылбырын салды да аның кулына төртте:

—Истәлеккә! Син минем беренче һәм соңгы чып-чын ир кешем. Рәхмәт сиңа!!

Заһидулла ешлыкка чумып, чирек сәгать тә үтмәде, усал карашлы өч ир ак күлмәкле, тузгыган чәчле хатын янына туктадылар. Хатын да ат йөзле, сыер гәүдәлегә әйләнде.

—Ах, убырлы карчык! Болай киенеп кемне көтәсең?

—Үз кияvемне!—диде хатын.

—Ирең синең өйдә...

—Ирмени ул, чир!!

—Карале, сволочь, уйнашчы, ә? Әле генә урман ешлыгына кем кереп китте?

—Минем принц!!!

—Уйнап сөйләшмә, артыннан барып ботарлап ташлыйбыз да муенына таш бәйләп күлгә атабыз бит без аны...

—Балыкчы ул...—диде дер калтыраган хатын.

Заһидулла бераз торгач, ешлыктан кире чыгыбрак шалаш ягына күз салды: аларның Гөнаһлы Мәхәббәт Чатыры тәмугъ утында яна иде...

* * *

Бер елдан соң гына аяк басты бу якларга Заһидулла. Теге вакыйгалардан соң, авылга кайтып керү белән, алар өенә Габдрахман да килеп керде:

—Син нәрсә?!—диде ул, күзләрен акайтып, Заһидуллага.—Аерым хуҗалык кору өчен Иделнең аръягында урын эзлисеңме?

—Син дә бит менә Шөндә күмхуҗ төзеп ятасың, бәлки минем дә үз күмхуҗымны төзисе киләдер,—дип кенә сылады Заһидулла.—Белемем дә синекеише генә түгел...

Авыр якка, чиргә-бөсергә төрттерде ул, белем ягы сайрак иде шул Габдрахманның, урысчасы да йомшаграк: «хлеп», «суль», «картушка», «видрә»дән аз гына өстәрәк. Ләкин...

Революцион митингларда, төрле җыелышларда комиссарларның чыгышларын тыңлап теле чарланган гражданнар сугышы солдаты Габдрахманны барыбер болай гына алдырып булмый иде инде хәзер.

—Эрбәлүтсия атларында...—дип башлады ул.

—Колхозга ничә атыңны биреп кердең, хәерче?—дип кенә туктатты аны Заһидулла, үзләренең абзарындагы өч атына төрттереп. Алар хәтта якалаша яздылар, ярый әле Заһидулланың әтисе Гыйбадулла карт сабыр акыллы кеше иде, икесен ике унайга салып, аерды ул аларны, юкса бит Габдрахман:

—Раскулачабайт итәм мин сине!!!—дип тотынган иде...

Ә Заһидулланың үз кересе:

—Чабайт итәргә мастер син, чабай давай, чабай! Син бит гражданнар сугышыннан кайткач та картлар: «Йә, Габдрахман энем, кайда булдың, ничек сугыштың?»—дигәч, кайда булганны белмим дә инде, ну, ат өстендәге Габдрахман сугышта атларны кылыч белән чабать та чабать итте инде!—дип мактангансың.

—Син,—диде Габдрахман.—Казанда мәдрәсәдә укыдың да соңыннан үзең мулла булу өчен Аяз хәзрәтнең кызына өйләндең...

—Заһидәне яраттым мин!

Һәм шунда Заһидулла кинәт кенә ярсып китте, ата-анасын да онытып русчага күчте:

—Мать твою! Әле син минем Заһидәгә тел тидерәсеңме, өзеп атармын ул елан телеңне!!

Чуендай авыр, таштай каты ике гәүдә, ике кыядай, бер-беренә килеп ябышты.

Менә шунда аларны сүзсез генә тыңлап утырган Гыйбадулла карт урыныннан торды.

—Оланнар!—диде ул.—Йә, әйтегез әле, нәрсә бүлешәсез?

—Безнең бүлешер малыбыз юк!—диделәр икесе дә.

—Соң,—дип аптырады карт.—Сез—гражданнар сугышы солдатлары, икегез дә, кызыллар ягыннан торып, акларга каршы сугыштыгыз. Ә хәзер үзара якалашып маташасыз?!

—Без бүгеннән... кан дошманнар,—диде Заһидулла.

—Әйе, кан дошманнар!—дип җөпләде Габдрахман.

—Ни сәбәптән?—дип сорады карт.

—Ул минем хатынымны хурлады,—диде Заһидулла.

—Ул колхозларга, яңа тормышка каршы дошман кешегә әйләнде, шуңа күрә мин аның кан дошманы,—дип сөйләк тотты Габдрахман.

—Мин сезнең дошманлыгыгызны бетерәм,—диде Гыйбадулла карт тыныч кына. Аннан соң ул башына сәкедә аунап яткан түбәтәен киде, кулына камчысын алды һәм ике «үгез»гә:

—Әйдәгез, минем арттан!—диде.

Коты очкан каба буе гына хатыны йомгак булып тәгәрәп килде дә:

—Әтисе...—дип сарык бәкәенекедәй дымлы-йомшак матур күзләре белән картка карады.

—Кортка...—диде Гыйбадулла яратып. Аннан дуамал бер гаярьлек белән, елан ысылдагандай әйтеп куйды:

—Ирләр эшенә кысылма!!

Кортка, тавыш-тынсыз гына кире чигенеп, тагы сәкегә чүмәште...

Өй эчен кабер тынлыгы басты. Стена ярыгыннан чыккан ялгыз кара тараканның мыегын селкетүе дә һава дулкыны белән очрашып, үзенә күрә музыкаль бер аваз чыгарып, шушы тынлыкны үтерми тота иде:

—Зин-зин...

—Зин-зин-зин...

... Бер мизгел, кызарган алма кебек, адәмнең гомер-агачыннан өзелеп төште...

—Син нәрсә, әтәй?!—диде ифрат та пошаманга төшкән Заһидулла, картның кулындагы камчыга карый-карый.—Әллә безне камчыларга телисеңме?

—Нибуч, Гыйбадулла абзый!—диде Габдрахман да куркынып.—Мин үзем сиңа, олы кешегә, кул күтәрә алмыйм, әмма дә ләкин, Аяз хәзрәт әйткәндәй, сиңа да суктыртмыйм...

—Һәй, маңкалар!—дип кинәт кенә ярсып китте Гыйбадулла.—Мин сезне болай дошманлашып йөргәнче дип, бәйгегә чакырам...

—Нинди бәйге ул?—диде икесе дә.

—Менә хәзер ишек алдына чыгасыз да сугышасыз...

—Кит әле, әти,—дип көлде Заһидулла.

—Булмаганны! Сугышып яталар ди монда,—диде Габдрахман да.

—Әһ-һә!—диде карт.—Кикригегез шиңдеме, яшь әтәчләр? Курыктыгызмы бер-берегездән?!

Шушы сораулары саен карт, камчысын еландай уйнаклатып, чажылдатып-чожылдатып алды. Заһидулланың күз алдына Нократның аръягында үзе үтергән кара елан килде, ә Габдрахман приказларын урынына җиткереп үтәмәгәне өчен үзен ике кызыл командирның камчы белән яруларын исенә төшерде. Шул уй-хатирәләрдән икесенең дә каннары кайнап китеп, баш миенә пешергеч ут өстәделәр.

—Минем Габдырдан курыкканым юк!—диде Заһидулла.

—Заһидан да курык, башкадан да. Алай булса, урамга чыгарга да куркырсың,—диде Габдрахман төксе генә.

Аңлады хәйләкәр карт яшь каннарның астында учак дөрләгәнен.

—Киттек!—дип, бер сүзле әмер бирде ул аларга.

Алар чыгуга, сөзешеп ятучы тәкәләр икесе ике якка аерылды. Күктәге кара каргалар:

—Кар-Кар!—Кар-кар-кар!!—килеп, зәңгәрлекне инләтеп алдылар. «Кара боларны, кара,—диләрме алар? Әллә каравыл кычкыраларммы, һич аңламассың...

—Басыгыз кара-каршы!—дип, боерык бирде карт.

«Үгез»ләр күзләрен алартып, йодрыкларын төйнәп, күкрәкләрен кабартып бер-берсенә текәлделәр.

—Тәртип болай,—диде Гыйбадулла.—Чиратлашып бер-берегезгә өчәр тапкыр сугасыз. Кем егыла, җиңелүче санала. Ләкин, матри аны: йөзгә, эчкә, кендектән түбән сугасы түгел! Бары күкрәккә генә. Заһидулла, син—Таң батыр, ә син, Габдрахман—Камыр батыр булырсың.

—Нигә Камыр?—дип, каршы төште шунда кинәт кенә балалык чокырына егылып киткән Габдрахман.—Улы, имеш, Таң Батыр?!

—Аңлатам,—диде карт.—Заһидулла улым минем таң атканда туды, ә синең әниеңне, Габдрахман, камыр басканда тулгак тота башлады. Синең белән йөкле иде ул. Аңлашылдымы?

—Аңлашылды...—диде Габдрахман нәүмиз генә, ә эченнән: «Әнкәй мине камыр басканда тапкан, ә үзем гомерем буе туйганчы бер ипи ашарга тилмереп яшәдем...»—дигән уйлар узды.

Читәнгә атланган әтәч, дөньяны ярып:

—Кикрикүк!—дип кычкырып куйды.

—Таң батыр, сук!—диде Гыйбадулла.

Гөрсс!

Сугуның авазы Габдрахманның киерелгән мичкәдәй күкрәгендә иңрәү вә авырту кайтавазына әйләнде.

—Камыр батыр сук!—диде карт, ә үзе эчтән генә «Чыда, улым!»—дип, Заһидулланың күзләренә карады.

Гөрсс!

Габдрахманның гөрзи-кулы дошманының күкрәгеннән «а-ах-хх!»—дигән авыр аваз тартып алды.

Әтәч тагы кычкырды...

—Сук!

Гөрсс!!.

Иманнәрме, өйләрме, җир үземе чайкалды...

Әтәч өченче кабат кычкырды...

—Сук!

Гөрсс!!!

Дөньяда хәрәкәт тукталды, вакыт бур мәче сыман ишек ярыгыннан чыгып сызды, башта уй калмады. Корышып-тырышып фикергә килергә теләү барын китермәде. Караңгыланган күз аллары яктыра төшкәч, Габдрахманның чәнчүле йөрәге, авыртулы күкрәге аша бер генә уй сызылды:

—Җиң... ел... дем... Әйе, җиңелдем! Ул мине өченче сугуда, аңсыз калдырып, аяктан екты. Торып булырмы хәзер аякка, ә, комхуҗ рәисе?!?

Шунда ул кемнеңдер зур җылылык белән сузылган нык һәм каты кулын тойды. Күзләрен ачып караса:

«Заһидулла икән! Яшьтәше... Авылдашы...»

Аңлады Габдрахман:

—Юк, комхуҗ рәисен үтермәгәннәр! Ю-у-ук! Күк тә үз урынында, җир дә убылмаган...

* * *

Бу юлы да Әхмәдулла көймәсен куе зиреклек каршына туктатты. Заһидулладан сорап та тормыйча. Аз гына өстәрәк Ямул суы Нократ белән тоташа, гүя ачыккан колын анасы биянең имчәкләренә килеп ябышкан...

—Туктале...—дип аптырады Заһидулла.—Кабат монда китердең... Әле мин сиңа зиреклеккә туктат та димәдем ич...

—Минем каек үзе килә бу ярга,—диде Әхмәдулла сузып кына һәм бернигә дә аптырамаган сыман янагына сугып алды. Урман ягыннан су буена килгән озынборын кеше битендә җан тәслим кылды.

—Ничек инде көймә үзе килсен?—диде Заһидулла Әхмәдуллага карап. Якланып сөйләшәме соң бу җик?! Мәче баласы кебек сырпанып-сыланып, йомшакланып торган җил аның кинәт кенә ярсып китүеннән мангаена чыккан ике бөртек тирен ялап алды. Ул шундук тынычланды:

—«Бу якка чыгар дидем... Чыгардымы—чыгарды... Нәрсә әле аңа ачуынны китерәсең? Аш атканга таш атмыйлар...»

—Мо-он-дая... бал-лыйк шә-эп ка-ба...—диде Әхмәдулла рәхәт елмаеп.—Ә көймә балык тутырып кайтырга ярата ул.

—Хы!—дип кенә куйды Заһидулла, ә Әхмәдулла рәхәтләнеп дәвам итте:

—Саласың кармакны, аласың тартып—бәртәс! Тагы сал-лам, тагы ал-лам—оһо-һо!!—ике гөрәнкәле корбан балыгы... Бу бит могҗиза, тылсым дөньясы. Нүжәли күпме Идел буенда яшәп шушы байлыкны күрмисең син? Көймә-каек астында гына ич ул байлык...

Заһидулланың исенә Тамара килде...

Ах, теге көнне аның белән балык ашаулар...

Алтын яшерелгән урыннан аның, алтын канатлы балык тотып, Заһидулланың ач карынын тукландыруы... Ә куыш эче? Аның шашып пышылдавы—инрәве—кычкыруы:

—Дави меня, дави, мой татарский конь!!

Заһидулла үзалдына рәхәт елмайды, моны күргән Әхмәдулла тагы да дәртләнеп сөйләп китте:

—Эх! Балык тотуның тәмен белмисең син! Син аучы бит, балыкчы түгел. Синең балыкчылыгын—балык ашауда гына. Балык тоту мо-гы-җи-за—син... белмисең син...

Әхмәдулла ялан аякларын көймә төбендәге суда чупырдатып куйды, аннан, ике баш бармагын күтәреп, аякларын йөздереп алды, гүя канатын чыгарып Нократ буйлап ике балык йөзеп бара. Заһидулла сәерсенеп үк китте:

—Балык—аяклар! Йә Алла...

... Ярга төшкәндә, ул эченнән генә «бисмилла»сын әйтте—теге вакытта онытылган иде бу изге сүз, хәтерен, мур кыргыры!

Әхмәдулла белән саубуллашып яр өстенә, зиреклек урманына күтәрелгәч, ул тагы:

—Бисмиллаһир-рахманир-рахим, әгүзе билләһи минәш-шайтан иррәжим!—диде.

Ни хикмәт, шушы сүзләрдән соң үз-үзенә, кылачак гамәлләренең дөреслегенә ышаныч туды, гүя күкләрдән аңа бетмәс-төкәнмәс көч инде.

—Юк инде!—диде Заһидулла.—Узган елдагы кебек быел йорт корырга урын эзләп йөрмәячәкмен. Пука торып торырга зиректән салынган өй дә ярар. Наратка бәйләнсәм, харап итәрләр! Халыкныкы диләр дә әнә... Бар берәрсен егып кара! Күрсәтерләр халыкныкы икәнен... Дәүләтнеке ул, сәвитнеке... Элек патшаныкы иде, байларныкы... Әнә бит тау башындагы урманның исеме үк кычкырып тора:

—Бояр урманы! Димәк, боярныкы...

Заһидулла билдән чишенеп ташлады, корыч мускулларын уйнаткалап «Гали пәкесе» кебек үткен балтасын кулына алды.

Кояш шактый кыздыра башлаган иде инде...

Нократ буеннан искән талгын, әмма салкынча җил кансыз озынборыннарны, давыл яфракларны очырткан сымак, урман эченә куалый. Әллә нигә бер узган пароходлар бакенчы Иван турына житкәч, моңсу һәм корымлы, ярсу вә тыгылган тавыш белән кычкыртып узалар. Яр буена чыгып баскан Иван аларны, генерал күргән солдат кебек, үрә катып сәламли һәм кечкенә флагын болгый-болгый:

—Юл ачык! Хәерле юл сезгә!!—дип, озатып кала.

Алны-ялны белмичә эшләде Зәһидулла.

Урман эчендәге балта тавышы, тимерчедәге чүкеч кебек, зиреклекне көне буе чүкеп торды. Бары тавышы гына «зең-зең», «чек-чек» булмыйча, балтага хас иде:

—Тук-тук!—Тук-тук-тук!

Туклыкка тавышмы бу?

Кем белсен!

Адәм баласының киләчәге һәрвакытта да өмет томаннары, язмыш бураннары, шатлык мизгелләре, хәсрәт күлләре эчендә. Кеше «Бүген» исән мин дип яши, ләкин һәрвакыт «Иртәгә»не күздә тота. «Иртәгә» юк икән—«Бүгенге»нең кыйммәте, кулдан төшеп челпәрәмә килгән бәллүр савыт сымак, шундук югала. Әнә шул «Иртәгә» өчен, өмет җуелмасынга адәм баласы һәрчак хәрәкәттә, шуннан бәрәкәт табу битарафлыкка, ялкаулыкка, үлмәс борын тере мәеткә әйләнүгә юл куймый. Инсаннарның үзләре дә белмәгән Иң Олы Бәхете дә әнә шундадыр, мөгаен, чөнки бу бәхет кемдә дә бар, хәтта иң пычрак вә хәсис адәмчекләр, бәндәчекләр дә аңа ия...

Бик күп агач екты ул.

Һәр агач кырт итеп өзелә дә «аһ!» диеп, егылыр якка китә һәм гөрселдәп җиргә ава. Урман аһылдап куя, тирә-юньдәге агачлардан кошлар күтәрелеп оча. Әллә каян килеп чыккан тиен кире куелыкка ычкына. Әнә яктылыкка адашыпмы кызыл төлке килеп чыга...

Балта тук-тук агач кыйнавын дәвам итә. Менә соңгы селтәнү: ыңгырашып нидер өзелә—агач гомерен тотучы соңгы җеп-үзәк бугай—һәм ботаклы могҗиза төлке өстенә ябырыла. Хәйләкәр ана көлтә койрыгын гына күрсәтә...

Шул арада өч-дүрт кешелек эш эшләп ташлаган Зәһидулла күлмәк җиңе белән маңгай тирен сөртә һәм үз-үзеннән бик канәгать калып, Нократ ярына су эчәргә төшә. Чишмәләр эзләп йөрергә вакыты юк аның, ят та көмеш суын Иделдән генә чөмер! Чиләге беләнме?—анысы синең эш...

Урманнан төшкән пошилар кебек, тәмләп кенә—кушучлап су эчеп утырганда, аңа кемдер дәште:

—Ә, синмени әле бу, карындаш?!

Борылып караса, яр комнарын шытырдата-шытырдата ана таба керәшен Мәкчим килә. Балыкчы һәм аучы Мәкчим. Аның белән кыш көннәрендә урманда бер генә очрашмады Зәһидулла. Хәтта, сүз куешып, уртак ауга да йөрделәр.

—Һу-һу, Мәкчим дус! Иптәш—фикердәш,—диде Зәһидулла да. Кул бирешеп күрештеләр, бер-берләренең күзләренә яратып карадылар. Авызларында, үзара ризалык, сөенеч билгесе булып, елмаю җәелде.

—Нәрсә, башладыңмы домстройны?—диде Мәкчим. Ул аның бу якта йорт салып, яңа тормышка ут тергезеп-терелтеп җибәрергә йөргәнен белә иде, ауда чакта ниләр генә сөйләнми.

Кабат яр өстенә күтәрелеп, Зәһидулла аударган агачларны карадылар.

—Бер көндә, ә?!—дип гаҗәпләнде Мәкчим.—Кемнәр булышты, әйт? Әй, кире татар! Чакырсаң, булышырга мин дә килә идем ич. Үз карындашыңа әйтмичә, Биектау урысларын чакырып йөрмәсәң, чәпчим...

—Һы!—дип кенә куйды Зәһидулла.

Мәкчим—төпченүчән, үзеген күрмичә тышкы кабыкка гына ышанып йөри торган адәм затыннан түгел иде. Шуңа ул кабат сорады:

—Кемнәр булышты, дим? Чәпчим...

—Койрыклы җеннәр!

—Ә?!

—Ие!! Чәпчим...

—Булмас ла!—керәшен шаккатты.—Бу, чәпчим...

—Күз алдыңда...—татар, менә бит дигәндәй, кулларын җәйде.

—Ай, карындаш!—диде Мәкчим.—Ат куәте бар икән үзеңдә.

Монымы? Моны Мәкчим өч көн ега. Кара әле бу төпләрне?! Кызыл төпләрне! Билләһи саный китсәң, утыз гына булмас, чәпчим...

—Утыз бер!—диде Заһидулла.

—Елы да утыз беренче ел... Зирек төпләре дә утыз бер... Утыз бер кызыл төп... Кызыл төпләр... Красные пеньки... Алда бу урынга шундый исем кушабыз: «Кызыл Төпләр». Ризамы?

—Риза,—диде Заһидулла мондый кызыклы исемгә хәйран калып һәм куанып.

—Ә хәзер, әйдә минем куышка!—диде Мәкчим.

* * *

Яр комын чабата белән сөзеп, Ямул суы тамагындагы Мәкчим куышына киттеләр.

Кояш йоклау куначасы—бату офыгына авышып бара иде инде. Тереклек көн буена күпмедер дәрәҗәдә мәлҗерәп, чабып йөрүдән туктап, телен чыгарып суыта-суыта әлсерәгән эт хәлендә иде...

Бары Идел генә ага...

Әйе, Нократ-су элеккечә ага да ага...

Мизгелләр, минутлар, сәгатьләр, тәүлекләр, айлар, еллар булып ага... Чорлар-дәверләр булып ага...

Бу агышны туктату Тәңре кодрәтендә генә...

Кеше гомере дә шулай. Туа икән инсан, Вакытның бер кисәге булып яши башлый. Әлеге Вакыт кисәге Гомер дип атала.

И, гомер агышлары!

Бу агышның үз сагышлары... Үз моңы-жыры, үз сөенечләре-көенечләре-үкенечләре. Үз кайгысы-хәсрәте, үз шатлыгы-бәхете.

Гомер агышлары...

Аны туктату Үлем кодрәтендә генә...

... Зур имән астына жәплекәле таяк-күсәкләр терәтелеп эшләнгән Мәкчим куышы авызы белән Нократка карап тора иде, гүя шуннан сулу ала, салкын жыя, дымлылык өсти, шуңамы челләдә дә куыш үз алдына жилләп тора.

Мәкчим, байлыгына куангандай, төреп куйган бер бөтен түгәрәк ипине тастымалдан алып, куыш авызына чыгарды, ниндидер сары төстәге гәжит кисәгеннән дуңгыз мае тартып алды һәм төкерекләрен йота-йота аны шытырдатып турый да башлады. Заһидулла йөзен чытып читкә карады. Хәйран хәл: Мәкчим аны арты белән дә күрә икән:

—Чытма-чытма йөзеңне! Әрмиядә ашадың син моны. Зинһар өчен ялганлап, кабып та карамадым, димә. «Голод—не тетка! Кабарсың, агайне, каптыра ул тормыш, теләмәгән нәрсәләреңне дә каптыра. Әле бит тегесен дә тоттың, иеме? Иеме, чәпчим?»

—Кайсын?—дип сораган булды Заһидулла.

—Утлы суны... сугыш вакытында дим, чәпчим...

—Самагунны әйтәсеңме?

—Тагы нәрсәне дип уйлыйсың?! Совсем чәпчим...

—Соң бозлы суны муеннан жырып чык та, дер калтырап якмаган өйдә утыр. Яксаң да, кайчан жылына әле ул? Әнә шул вакыт...

—Бер кружка тутырып саласың да мич утлары тәнеңдә дөрләгәндәй була инде!—дип элеп алды Мәкчим.

—Әйтмә инде!

—Менә шунда, Казан мәдрәсәсе шәкерте үлеп, кызыләрмис дөнжага туа да инде. Шәкерт эчкән чәй урынына мәй дигәннәре куела өстәлгә, ә? Ә, чәпчим...

—Әйтмә дә генә инде!!

Шушылай сөйләшү-килешү алар арасына инде монарчы да булган кардәшлек, якын туганлык хисләре ялкынын тагы да үстереп-үсендереп

жибәрде, инде алар, бер тән булмасалар да, бер җан булып, бер Рух уты белән кабызылып, бер-берсен якын итеп, яратып һәм олуг хөрмәтләү, игътибар җәһәтендә табынга утырдылар.

Кичке шәфәкъ нурларында Мәкчим чирекле шешәдәге аксыл суны кружкага койды:

—Тот, мөселман! Чәпчим, тот!

—Йә Ходаем, кичер...—диде Заһидулла һәм «бисмилла»сын әйтеп, утлы суны авызына койды. Тагы йөзен чытты...

—Йә, йә!—диде Мәкчим.—Ачы миләштән дә ачы түгелдер ич. Дөнҗада анысын да ашыйбыз әле... Дөнҗа—үзе ачы миләш ул. Янына киләсең, агачы матур, җимешләре күзен кызыл, күз җавынны алып тора! Алып кабасың—әче, шундый да әч-че, ирексездән йөзенне чытасың. Менә синең кебек... Чәпчим бит, ә?

Ул тагы шешәдән кружкага аксыл суны койды.

—Җәле, Мәкчим, җәле керәшен!—диде аннан үз-үзенә, тиз генә чукынып алып.—Чәпчим киттек, Мәкчим...

—Тот, чукынган!—диде бит алмалары кызарган Заһидулла, дуңгыз маен уртлап.

Мәкчим бер кабуда бер кружканы бер генә йотты. Моны күргән Заһидулла бу искитмәле хәлгә шаккатты:

—Ничек кружкасы-ние белән кереп китмәде диген, ә?!

Керәшен, «ә-ә-ә-әһ!» диеп, авызларына бармак очлары белән суккалап торды да, күзләрен челт-мелт йомып-йомгалап, умырып дуңгыз маен капты, бер телем ипине бөкләп диярлек авызына тыгып куйды.

Эчми эчкән Заһидулла чираттагы кружкадан соң лыкма исерде, юк кына сәбәп табып, Мәкчимгә бәйләнә башлады:

—Нигә син татар башың белән Биектауда урыслар арасында яшәп ятасың, ә? Кил безнең Өшенгә, мин сина менә дигән кыз табып бирәм!

—Мин өйләнгән инде,—диде Мәкчим.—Шул хатыным марҗа булганга, Биектауда урыслар арасында гомер кичерәмен. Аннан соң минем исемем дә, динем дә аларныкы ич. Нигә мина урыслар белән бергә яшәмәскә, ди?!

—Шайтан икәнсең!—диде Заһидулла.

—Алай димә,—дип каршы төште Мәкчим.—Чәпчим, алай димә...

—Йә, жарар! Шайтан түгелмени син? Тәрең муеныңда бит?

—Минем тәрем—муенымда, денем—куенымда...

—Моның белән ни әйтмәкче буласың?

—Минем бабамны мөселманча күмделәр. Үзенең васыяте буенча... Чәпчим, мөселманча...

—Һы!—дип кенә куйды Заһидулла.

—Ә менә татар...—диде керәшен.—Марҗага өйләнсен әле... Татар үз исемен генә түгел, ата-бабасының исемен дә сата. Йә, жарый инде, үз исемен үзгәртсен ди... Ә нигә ул ата белән бабасы исеменә тия?! Ни хакы бар кагылырга? Ник үзгәртә ул аларны, сатлык татар?!

—Кит әле, жукны сөйләп утырма, дустым,—дип кисте аны Заһидулла.

—Жук, дисеңме? Менә минем Казанда Ибраһим исемле танышым бар иде. Гражданнар сугышында бергә булдык. Шул, соңыннан яраланып, лазаретта эшләүче җыештыручы марҗа кызына өйләнде. Ибраһим Камалов дигән Мөхетдин улы Иван Михайловичка әйләнде дә куйды. Әле бит фамилжәсен дә хатынныныкын алган.—Собакин... Тьфу, Со-ба-кин! Фамилжәмени бу? Ә бит Камалов звучит! Идел-Кама елгасын хәтергә төшерә... Чәпчим, әйбәт фамилжә...

—Андыйлар меңгә бер генә,—диде Заһидулла аны тынычландырып.

—Юк, бүген меңгә—бер, иртәгә йөзгә—бер, алга таба унга—бер булачак әле ул. Революция бу, белдеңме? Бар халыкларны бергә укмаштырган, ботка ясаган революция. Ач күзенне, шәкерт! Дөнҗа бу, ач күзенне... Чәпчим, ач!..

—Кичәге шәкерт...

—Кичәге булсаң да, кичтә калма. Мичтә дә калма, чәпчим, мичтә калма...

Авыр тынлык урнашты...

Ни сәбәптер икесенә дә уңайсыз иде. Утлы су телләрен чиштеме, нидер күңелләрен борчый иде. Никадәр дус булсаң да, бер-береңә ачылып бетәргә ярамый ич! Кеше күңеле пыяла икән, ул тиз уала, шундук ватыла, ә аның артында шыр ялангач хакыйкать кенә кала.

Заһидулланың күкрәгенә моң инде, җаны саргайды, рух уты, сүнәм-сүнәм дигәндәй, сүрелеп алды, бәгыре кискәләнде.

—Җырла әле, Мәкчим туган,—диде.

—Җыр дисеңме? Чәпчим, җыр дисең?

—Теге озын керәшен көен җырла. «Ачы миләш»не...

Мәкчим тагы тутырып бер кружка аксыл суны койды һәм ялт итеп эчеп тә куйды. Заһидулла тагы хәйран калды. Бу юлы да авызларын бармак белән каккаласа да, «ә-ә-ә-әһ» дип торса да, Мәкчим берни дә капмады.

—Башка китсен азрак,—диде ул.—Ату, мине бер алмаса, чирегә белән дә алмый... Чәпчим, алмый...

—Җырла инде!—дип ялварды исерек Заһидулла.

—Хәзер, хәзер... Бераз гына тын җыйыйм әле, хәл алыйм. Сулыш тар була алайса... Чәпчим, тар...

Ул Себер халыклары шаманы кыяфәтендә бер кавым бер ноктага текәлеп, онытылып торды. Шулвакыт җете зәңгәр күзләренә сары төс инә башлады һәм Мәкчим гаҗәеп моңлы тавыш белән, үтергеч моңлы җырны җаныннан түгәргә тотынды:

Зәңгәр күктә болыт була,
Болында—ат көтүе.
Авыр, дуслар, ай, читен лә
Юк бәхетне көтүе...

Коелардан су алганда,
Төшеп калды чиләгем.
Дөнжа безгә—ачы миләш,
Кемнәр таба җиләген?

Бу—керәшеннәрнең «Кара урман»ы иде...

Шуның өстенә, бу—Мәкчимнең яшь чагында сүзләрен дә, көен дә үзе чыгарган бердәнбер, гомере буе җырлап йөргән җыры иде. Ул аны күз керфекләренә яшь тамчылары элеп җырлый иде...

Моңга Заһидулланың бөтен җаны айкалды, мондый моңны, бәрхет тавышны, бик сузынкы көйле сүзләрдән соң ифрат кыска бию рухындагы кушымталы көйне аның тынлаганы да, ишеткәне дә юк иде. Ә Мәкчим җырлавын дәвам итте:

Болыннарда чишмә таптым,
Тик сулары болганчык.
Җырлыйк әле, кан-кардәшкәй,
Күңелкәйләр тулганчы.

Коелардан су алганда,
Төшеп калды чиләгем.
Дөнжа безгә—ачы миләш,
Кемнәр каба җиләген?

Инде хәзер Заһидулланың яшьләре ирексездән чыктылар да тып-тып җиргә, ялангач беләкләренә тама башладылар...

Тәмам экстазга кергән, җыр рәхәтенә вә хәсрәтенә чумган, аның сагышлы-моңлы сихри ләззәтендә йөзгән Мәкчим, зәңгәр-сары күзләрен йомып, соңгы куплетны башлап җибәрде:

Тудыргансын, газиз анам,—
Жан биргән Богка рәхмәт!
Үлүләргә караганда,
Яшәүләре бик рәхәт.
Коелардан су алганда,
Төшеп калды чиләгем.
Дөнжа безгә—ачы миләш,
Кемнәр ашый җиләген?

Бу соңгы аккорд, ахыргы моң инрәве күкләр пышылдавы аша тылсыми куәткә ия булып, ирнен колагына һичтуктамый тукып торды:

—Ела, ела! Ирләр елавы юкка түгел... Ела, ела, ела! Бушанганчы, эчендәге кара ташларың эреп беткәнче, елап туйганчы ела...

Заһидулла, ике кулы белән газиз жирне төя-төя, бар жанын сыгып, күңелен агызып, бәгырен кысып, жиргә капланып, үкси-үкси елый иде...

* * *

Икенче көнне Әхмәдулла көймәсенә салып, Заһидулла өчен кибәндәй зур сөенеч, болытлардай биек шатлык алып чыкты:

—Малаең туды!

Ата булу бәхете...

Утыз яшьлек ир өчен моннан да зур бәхет бар микән?

Каушады Заһидулла, каударланды, ашыкты-сөртенде, абынып та егылды. Гүя ул сукыр иде...

Бар булган әйберләрен Әхмәдулланың көймәсенә салдылар, балта, бер кулга көйләнгән зур пычкыны—ярты пычкы!—үзе белгән урынга яшереп куйды Заһидулла, аннан соң, анадан тума чишенеп ташлады да, телсез калган Әхмәдуллага дәште:

—Бар, син атлый тор!

—Ә-ә?—дип кенә куя алды тегесе.

—Теге якка, безнен якка... Йөзә тор, дим...

—Ә си-ин?

—Мин үзем!

Шул арада үзе иртәнге томан күтәрелеп килгән Нократ суына чумды. Су өстеннән пар күтәрелә иде әле.

—Чаш-шш-кан тәре! Чашкан бу,—диде Әхмәдулла яннарына килеп туктаган Мәкчимгә.

—Шашмаган ул,—диде Мәкчим бик белдекле кыяфәттә,—түше кыза анын...

—Ә нигә түш-ше кыз-за?—дип сорады Әхмәдулла.

—Әйтик үрдәкнен түше ник кыза?—дип фәлсәфә сатты Мәкчим.— Анын бәрәнгесенә тоз күп салганнар, шуңа кыза. Ә адәмнеке ник кыза? Ул үзе салганга кыза...

—Нәрсәне?

—Утлы суны...

—Утлы су? Теге хәмерне әллә? Биектау урысларынын чөгендердән куа торган самагунымы? Заһи эчми бит ул!

—Мин дә эчә димим ич, жиффәрә генә, салып кына куя,—дип кеткелдәде керәшен.

—Әй,—дип кул селкеде Әхмәдулла.—Керәшеннең акылы, керәле дә чыгалы, ди...

—Жарый-жарый, күп сөйләшмә, бар! Әнә, Заһидулла Вятка уртасына житә инде. Смотри аны, артыннан карап кына бар. Алай-болай ул-бу булмасын тагы!

Әхмәдулланың көймәсе Нократ суын ярып теге якка үрмәли башлады.

... Суга керүгә үк, тәне өшеп китсә дә, бер ун колачлап йөзүгә, хәле киңәеп, сулышы иркенәеп киткән Заһидулла олы-олы алдырып йөзә башлады, ә йөрәге һәр тибеш саен колагына бер сүзне кага иде:

—Малай бар...

—Минем малай туган...

—Малай, малай... Минем улым...

Дәвамчы варисың, буыннарга яңа буын өстәлү—яшәешнең Иң Бөек Кануннарыннан берсе икәнен ул менә әле генә, малае-улы туу хәбәрен ишеткәч кенә тойды. Аны шулкадәр дәрт-дәрман, олуг аталык хисе, әти булу горурлыгы биләп алды ки, әгәр Нократта су түгел, ә тоташ ут акса да, ул бу елганы кичеп чыгар иде сымак...

Кеше һәм көймә ярга бергә төртелделәр. Заһидулла судан чыкты, Әхмәдулла көймәдән төште.

—Кая, җәһәтрәк бул, китер эчке ыштанны!—диде Заһидулла. Ак ыштанын аякларына эләктерүгә күлмәк-чалбарын, чабата-оекларын да кимичә, яшь тай кебек, авылга элдерде. Гүя кайдадыр янгын иде.

—Кар-ра... ин-де!—дип телсез калды Әхмәдулла. Аннан яланаяк тузан туздырып чапкан таза-сәламәт, куәтле-көчле шәрә иргә сокланып карап торды да:—Чаш-кан бу, билләһи, чашкан!—диде.

Аннан соң, каегын бәйләгәч, Заһидулланың әйберләрен култык астына кыстырып, авыл ягына юнәлде, ә үзе эченнән генә мыгырданды:

—Чашкан дими нә диярсең моны?! Көпә-көндез... шәр-рә-тән килеш... балам-улым туган дип... шакмараларыңны селкетә-селкетә чап әле син? Чаш-кан бу...

... Бакча артлап юыртты Заһидулла.

Көтү чыгып килә иде...

Сыерларның акырып мөгрәвен, сарыкларның калай тавыш белән бәтелдәвен, көтүчеләрнең «һай-һу»лап көтү куу тавышларын колагына да элмәде ул. Кычытканлы ызан буен яра-яра, артлатып лапас ягына барып төште. Аз гына сулу алып торды. Күзе билдән түбән төшсә, мәржәне, оясыннан карап яткан эт кебек, ыштан ачыклыгыннан башын тырткән иде.

—Чукынчык!—диде ул.—Ашыгычлык белән төймәләп куярга да онытылган.

Заһидулла кире мунча ягына борылды. Кара мунчадан җылы белән бергә кичтән нык парланган таш исе аңкып тора иде.

—Кичә мунча якканнар...—дип уйлады ул.—Туктале... Заһидә бер дә бәбәйләр төсле тоелмый иде бит әле... Алай дисәң дә, мулла кызы булса да, мескенләнеп, тәтиләнеп йөрергә, бигрәк тә үзен кызгандырырга бер дә яратмый ич ул!

Ир ниндидер ашыкмау-каударланмау халәтенә күчеп, сабырлык йөге астында рәхәтләнеп озак кына юынды, үзе тагы, кем беләндер сөйләшкән кебек, кычкырып:

—Их! Бер кара яндырып чабынып төшәсе иде...—диде.

Мунча өйалдысында Заһидә тарафыннан юылган ап-ак чиста ыштан, алмаш күлмәге һәм чалбары тора иде. Шунда ук аның өйдә өстерәп йөри торган чүәкләре. Әнисе үзе суккан палас идәндә аяк киеме белән йөргән кешене өнәми. Яланаяк йөрү—язык эш, мөселманга хәрәм гамәл, хәтта гөнаһ, ди. Бигрәк тә хатын-кызларга. Шуңамы әтисе Чепья базарыннан аларга читек-кәвешләр, төрле-төрле чүәкләр алып кайтты. Шулай итеп чабата бары эш киеменә генә әверелеп калды. Хәер, бу хәл авылда бары Гыйбадулла гаиләсенә һәм тагы биш-ун йортка гына хас иде. Калганнары революциягә кадәр ничек торганнар, шул шәкелдә, шул байлыкта, шул тәртиптә яши бирделәр. Бары патша—юлбашчыга, халык—сәвитнекенә, урядник—милиционерга, шәкерт—пионерга гына әйләнде. Комсомол, бигрәк тә партия дигәннәре зур көч иде. Аерым тормыш күмәккә әйләнде, аерым камыш чүлмәккә менде. «Аерым камыш»—кичәге зимагур, йортсыз-җирсез, милексез сукбай. Андыйлар бүген

секретарь да рәис, уполномоченный да комиссар...

Зәһидулла, карак мәче кебек шыпырт кына атлап, алты почмаклы ак өйләренең карлыган, шомырт агачлары үскән бакча ягына килде. Менә ул ак пәрдәле тәрәзәгә колагын куйды да тынлый башлады...

... Өйдә бала елый иде...

Рәхәтләнеп тыңлады Зәһидулла яшь жанның елавын, хәтта кечә таммый калган ике бөртек яше дә, күз кабакларын борчак бөртегедәй авырттырып чыгып, жиргә «леп-леп» кенә итеп төштеләр.

Менә бала катырак, үҗәтрәк, кызганычрак тавыш белән елый башлады. Кинәт кенә Зәһидулланың башына: «Ник елый?!»—дигән шөбһәле уй килеп керде.

—Әллә әнисе карамыймы? Әби-бабасы ташлап эшкә киткәннәрме? Әле бит... Әле бит урак өсте түгел...

Ул, гадәтенчә, кинәт кенә ярсып китте. Өйгә атылып керде дә:

—Ник елатасың, мать твою, баланы?!—дип акырды. Зәһидәсенең яшьле күзләрен күрүгә: Гафу ит, матурым...—дип аның аякларын кочаклады.

* * *

Көз килде...

Урман өстеннән йөгереп узган Алтын Болыт агачларның яфракларын сары төскә манды. Усалрак жил искәндә, алар жир өстенә күз яшьләре сыман тамдылар. Куаклардагы чикләвекләр дә, тәмам саргаеп, жиргә коелдылар. Менә беркөнне, ешлык араларын кемдер утап чыккандай, урман куелыгы шәрәлеккә алышынды. Агачлар, мунчага килгәч, беренче тапкыр киявенең шәрә тәненнән оялган ялангач кәләш кебек, бер-берсеннән читенсенеп торалар сымак... Бары...

Бары кызыл күзле баланнар гына дөньяга тутырып карый әле...

Бары ут бөртекләре янган миләшләр генә бернигә дә исе китмәгәндәй кыланалар...

Ләкин...

Көз бу...

Көз инде бу, көз...

Үзенең сары сагышлары, моң кагышлары белән тулган көз. Күкләр дә хәзер җәй көннәрендәге кебек дөбердәп-күкрәп, каты итеп яшь коеп еламый, ә тавыш-тынсыз гына, сабыр карчыклар кебек кенә балавыз сыга.

Ах, ул көзге яңгырлар!

Гомерләр үтүенә ишарә түгелме алар?

... Зиреклеккә йорт корган ялгыз Зәһидулланың башында уйлар тилерә, ул җанын кая куярга белми, тәне дә корыган кебек: берни эшлисе килми генә түгел, хәрәкәтләнергә дә иренә...

Аның Рухын кемдерме, нидерме сындырырга тели, учагындагы утлы күмерләрне казып ата, күңеленә авыр уйлар, җанына кара ташлар өя. Бәгыре телгәләнә яшь ирнең: «Мин монда йорт салып, кешеләрдән аерылып йөргән булып, туган авылымны, ата-бабаларым нигезен ташлап китеп дөрес эшләдемме? Ни кирәк миңа?! Ни җитми миңа? Яшәү бит бер генә, гомерләр, күпме сузылса да, үтәчәк бит... Миннән ниләр калыр? Көлләр генә...»

Авылдагы Зәһидәсен, кечкенә улы Галимулланы сагынудан аның күзләренә яшь тыгыла, ул йорт иДәнен сыта-сыта ишекле-түрле йөри башлый: «Ни җитми миңа?! Моңарчы да яшәгәннәр, бездән соң да яшәрләр... Шушы арага кысылган минем гомергә иң кадерлесе нәрсә соң? Ни өчен яшим мин? Кем соң мин?! Хәер, кем булсаң да—патшамы, көтүчеме—һәр яшәүнең ахыры үлем белән очлана ич... Шушы гәүдәнне җир эченә алып барып салсыннар әле... Яшәүнең ахыр максаты җирдә

черүгә әйләнеп кала түгелме соң? Алай икән—нигә яшәп торырга, ди!.. Нигә, кешеләрдән кача-кача, үзеңә ошаган аерым тормыш корырга, нигә йортлар салып җәфаланырга, нигә газапланырга, черәшергә, интегергә?.. Бетмәс-төкәнмәс кодрәткә ия кешедәй ник юкка көч түгәргә, ди? Ахыр килеп бер көнне яшәвеннең бөтен максаты өч аршын җиргә күмелеп калачак бит. Алып батыр булып таулар күчерсән дә, ахыр нокта—Үлем...

Ул бу уйлар кантарына җавап таба алмады, башын диварга бәреп ярганчы дип, ишекне тибеп ачты да тышка чыкты.

Көзге җил Нократ йөзенә җыерчыклар сибеп, аның бите әбиләрнекенә яисә шадра ямьсез кешенекенә охшап калган иде. Яр буе керәшәләре, ояларыннан чыгып, Идел өстеннән балык эзләсә дә, тегеләре су төбенә үк киткән булганлыктан, ашарларына берни тапмый кызганыч тавыш белән кире «өйләре»нә юнәләләр иде...

Бу минутларда Заһидулла үзен дөньяда бер үзе генә калган япаялгыз кеше итеп хис итте. Хәтта... Бер кавымга ул үзен дә югалтты. Әйе, әйе! Керәшәләр бар—ул юк, суда балык бар—ул юк, урман шаулый—ул ишетми, җилләр исә—ул тоймый, яңгыр сибәли—ул күрми...

Шадра битле Нократ суы, аның өстендәге елак тавышлы кызганыч керәшәләр, аның җанын тәмам айкап чыгардылар, ул ашыгыч адымнар белән текә яр читенә үк килде дә инрәп, айга карап улаган бүре тавышлары чыгарып оран салды:

—Әти-и-и, әни-и-и!

Тавыш урманда кайтаваз булып яңгырады:

—И-и-и-и-иһ...

Ул тагы ачыргаланды:

—Заһи-дәү-ү!!

Урман:

—Әү-ү-ү..—дип җавап бирде.

—Улым, Гали-и-му-ул-ла!!!

Агачлар:

—Ә-ә-әйт!—диделәр.—Улама...

Заһидулла:

—Ялгыз яши...—дип сөрән салды.—Кайда сез? Мин... ялгыз...

Нократ суы, апарасын чөмергән дуңгыз кебек, ярларга бәрелеп иренен чупылдатты, керәшәләр оя-тишекләренә чумдылар.

Заһидулла бу ярда, аваз салып чакырган кадерлеләре теге якта иделәр. Ни теләсәң дә, тирән-киң елганы ерып чыгып булмый, моның өчен юк дигәндә, Муса кебек пәйгамбәрләр кодрәте кирәк. Хәер, алар кодрәте дә Аллаһы Тәгаләдән ич...

Үзеңнекеләрдән качсаң, читләргә юл ачарсың, ди. Уйларының очына, сагышының кырына, моңнарының чигенә, фикерләренең читенә дә житә алмаган Заһидулла, ике чигәсен уч төпләре белән кысып торды да, зурэре адымнар белән, аяк астындагы юеш яфракларга, корып бетмәгән үләннәргә баса-баса, Биектауга юл алды...

... Мәкчим өйдә икән...

Үзе әйтмешли: «Чәпчим, өйдә!»—икән...

—О-оһ! Карындаш!!—дип, шатланып каршы алды ул аны. Мәкчим ау җәтмәсен ямап утыра иде.—Чәпчим, карындаш килгән...

—Хатының өйдәме?—дип сорады Заһидулла.

—Катынмы? Ниемә ул сиңа?—дип көлемсерәде хәйләкәр Мәкчим.—Дәртеңә чыдый алмасаң, биреп торам, бар апкит берничә көнгә... Чәпчим, бирәм...

—Юк ла!

—Нәрсә «юк ла»? Мин бит—всерьез... Чәпчим, всерьез...

—Салып бир әле теге утлы суыңны, чукынган тәре!

—Ә-ә?—диде Мәкчим, кинәт кенә эшеннән туктап.—Әйдә, алайса, тиз бул! Катын дуңгызлар карый, без моны карыйк. Аптырама, дуңгыз-

ларын ашаткач, биләм ягына ычкына ул. Чәпчим, биләмне ярата ул минем катын...

Берәрне салгач, жор сүзле, хәйләкәр күнелле Мәкчим «карындаш»ының юкка гына аны эзләп килмәгәнен, сары мыек очлары белән тоеп, сорап куйды:

—Йә, жарар! Монсыз дөнжа монсыз, ди. Хәзер инде төп йомышыңны сөйлә... Чәпчим, сөйлә!

—Ни әйтергә соң?

—Жаның тыныч түгел синен, Заһидулла. Чәпчим дә... тыныч түгел менә...

—Дөр-рес!—дип жөпләде ир.—Нилектән икәненә төшенмирәк торам әле...

—Ялгыз син... Шунлыктан ул... Менә мин бу карт маржага ник өйләндем димсен? Ялгызлыктан... Ул да ялгыз, мин дә... Дөнжада һәр нәрсә пар-пар туган ич: балыклар да, кошлар да, хайваннар да, кортлар да... Хәтта үләннәрнең дә ата-ана булганнары бар? Чәпчим, бар...

—Минем дә хатыным ... балам-улым бар...

—Во-во! Чәпчим, во...

—Өйне дә житкезеп бетерергә кирәк ич!

—Кайтып кил син алар янына берәр атнага...

—Эшне генә очлыйм да...

—Ә анарчы,—диде Мәкчим.—Мин сиңа яңа дуслар бүләк итәм! Чәпчим, шәп дуслар!

—Кемнәрне?

—Эт белән мәчене...—дип шаркылдады Мәкчим.—Минем мәрхүм бабай әйтә иде, йортында эт-мәче тотмаган кеше биш-ун елга иртәрәк үлә икән... Чәпчим, үлә...

«Тагы үлү...»—дип уйлап куйды Заһидулла.

—Әйдә!—диде Мәкчим.—Юл аягына тагын берне каплыйк та шылыйк... Чәпчим, шылыйк...

—Ә син кая?

—Синең белән, эт-мәчене озатып куям... Чәпчим менә...

Ул, кече яктан үсеп килә торган мәче баласын алып, Заһидулланың кулларына салды. Ә абзар астындагы оядан яңгыравыклы тавышлы, калын тәпиле, таза сыртлы көчекне тартып чыгарды. Моны күргән мәче баласы, куркыныч ысылдады, йоннарын кабартып Заһидулланың жилкәсенә үк менеп утырды. Кулын тырнап канатты...

... Берсе мәче, берсе эт тоткан татар белән керәшен тау астына ук төшеп киттеләр. Сарапул күленә житәрәк таныш жыр яңгырады:

Дөнья безгә—ачы миләш,
Кемнәр ашый жиләген?

Тавыш хәзер ике булып, бәрхет моңга басынкы мөгерәү дә кушылган иде. Шул кушынкы моңнанмы, Жир тетрәнде, Күкләр тыйнак кына елавын дәвам итте.

* * *

Вак, эчпошыргыч яңгыр ява...
Тәндә мәлжереклек. Нигәдер көне буе йокы килә. Йокы килә, йокы...

Ике тәрәзәсе Нократка, берсе көньякка караган өйнең эчен эңгер-меңгер баскан. Кайткан уңайга өреп-талашып, чинап-мияулап танышкан көчек белән мәче баласы, уртак йортта дус торудан да яхшысы юк дигәндәй, күптән инде татулашып, һәркем үз почмагын тапкан иде: песи—сәкедә, маэмай—мич артындагы аралыкта.

Заһидулла үз халәтен үзе аңламый:

—Бүген авыр көн, дөньяның үзе кадәр авыр көн, эчпошыргыч авыр көн...

Хәле юк, тәндә арганлык, көчсезлек. Авырый түгелме ул? Алай дисәң, бер җире дә чәнешми, сызланмый, бары башка кергән уйлары гына таш кебек. Хәер, берни турында да уйламый ич ул! Башына гына таш тутырганнар. Кемнәр? Койрыклы җеннәр! Шуңамы көн авыр? Өзелеп йокы килә...

—Изрәдең әле син, карындаш?!—диде аңа Мәкчим.—Чәпчим, изрәдең...

—Изрәмәдем, авыр уйлар басты мине...

—Тагы кәгеп җибәрикме бераз? Чәпчим, ә?

—Бармыни?

—Керәшендә юк әйбер дә бар ул! Чәпчим, бар...

—Чыгар... алай булгач...

Менә Мәкчим ыштан бөрмәсенә кереп китте һәм эчтәге бил каешына янлап эләктерелгән шешәне тартып чыгарды.

—Ай, хәйләкәр керәшен!—дип көлде Заһидулла.

—Татар бул да хәйләкәр булма,—диде, теш ыржайтып Мәкчим.—Чәпчим, хәйләкәр булма, имеш...

—Синең татарлыгың да телеңдә генә ич!

—Татарлык—әнә шул тел инде ул. Тел милләтнең җаны ич, ул юк—халык та юк. Чәпчим, дим, менә, совсем халык юк.

—Кайда укыдың син?

—Малмыжда... Носла керәшене ич мин!

—Беләм-беләм... Нослада—осталар!

—Һәр эшкә дә осталар!—дип мактанды керәшен. Шуна өстәп, үзе дә кукыраеп китеп, әйтеп салды:—Ә Мәкчим—осталарның остасы! Чәпчим, остасы...

—Йә, йә... Белмисең икән, белмим дияргә кирәк!

—Ә нигә?—диде керәшен кызып.—Дөрес түгелмени, Заһидулла, ә?! Мичеңне кем салып бирде? Мин! Тәрәзә борысыңны кем утыртты? Тагы мин. Рамнар ясап, тәрәзәңә кем пыяла куйды. Тагы, тагы мин... Чә-әп-чим, мин!

—Син генә инде!

—Кем сиңа сало ташый? Чәпчим мин.

—Син...

—Кем сиңа ысланган балык, ипи китерә?

—Син шул...

—Кем сиңа самагун эчерә? Чәпчим, ә?

—Чукынган тәре!—дип кычкырды Заһидулла.—Әле син минем муенга тәре дә тагарсың, ә?!

Икесе дә шаркылдап-төенеп көлеп җибәрделәр.

—Хочешь, мин сиңа Биектаудан мәткәләр табам?—диде Мәкчим, берәрне кагып алгач.—Тәрене такмыйм... Юк, такмыйм!

Тыштагы вак яңгыр, тәмам табигать музыкасына әверелеп, түбә такталарында нindidер үзенчә бер көй уйный һәм елый-елый тәрәзә пыялаларыннан агып төшә. Ләкин бу кызганулы вә рәнҗешкә тулган елау түгел, ә Заһидулланың ялгызлыгына ишарә, ничә миллиард кеше яшәгән Җир шарында, ялгыз кырмыска булып, үз түмгәгеен булдырырга теләгән көчле-куәтле, таза-нык, горур вә мин-минлекле ир-атка нindidер ым кагу иде. Шушы яңгырның, күрәсең, берәр «әфсен-төфсен»е булгандыр. Заһидулла иртәнге авыр сорауларыннан, җелегенә үткән үкенүләрдән, бигрәк тә тәмам юләрләндерә язган икеләнүләрдән тәмам арынды, аңына саф акыл килеп, инде хәмер эчүдән тәмам исереп барса да, чын мәгънәсендә башы яп-якты калып айнды. Кинәт аның җанына, язгы ташкындай, үз-үзеннән канәгатьлек, кылган гамәлләренә ризалык тула башлады һәм күңел түрендә аяк бөкләп ике тәхеттә утырган «ике мин»е тора—терәшеп тарткалашып киттеләр:

—Авылдан китеп, бу якка яна йорт салып яна тормыш корам, диденме?—Сорауны Беренче Мин бирде.

—Диден... Ләкин...

Җавапка тавыш ишетелде.

—Нәрсә ләкин?—диде Беренче Мин.

—Әле бит синең бердәнбер йортың гына бар, ә каралты-кура? Мал-туар?? Сөрер-чәчәр, урып-җыяр өчен җирең? Гел дә гел Идел балыгы ашап, йә ауга йөреп кенә тамак туйдыра алмассың ич!

—Әйе, Икенче Мин, соравың бик хаклы. Җавап бирәм, абзар-лапаслык бүрәнәләрем, такталарым бар минем. Кирәген Биектау урыслары ярып бирделәр. Әнә кайтып туган авылыңа—Өшенгә—кара! Күбесенең өй түбәләре саламнан. Йортлары иске, кыйшайган, җиде-сигез аршынлы йортларда унлап кешеле гаилә гомер кичерә. Булганнары—зур сәке, мич өстендә—сәндерә, агач өстәл, эскәмҗә и, бетте баш, калды арт утырып? Ә минем? Ә минем, дим?!

Икенче Мин, үз өенең сыртына менеп дигәндәй, әтәч кебек канат какты:

—Минем унга унике аршыннан йорт, түбәсе такталан. Ягам дисәм, утыны рәттән генә, урманга керсәң, ботак-шатагы гына аунап ятмый, ауган агач кәүсәләре дә бихисап. Ә Өшендә кышын кышлый урманнан утын ташып интегәләр. Тотам, дисәм—балыгы аяк астында гына, атам, дисәм—киеге урман тулы. Ә чәчәр жир?.. Чәчәр жирме? Бар ул! Кайдамы? Элеккеге Тамара шалашы торган урында...

Кинәт Заһидулланы хатирәләр дулкыны күмеп китте: «Ах, Тамара, Тамара...» «Дави меня, дави, мой татарский конь!»—Әлеге тавыш аның колагын ертып керде.

—Их! Тамара, Тамара! Кайда син? Ник күренмисең... Нигә миңа үз кулларың белән теге вакыттагы кебек шулпа каптырмыйсың да, балык ашатмыйсың...

—Мой татарский конь!—диде тавыш.

—Һы!—диде Заһидулла.—Ялгыз ат... Биясез калган Айгыр...

—Ишетмисеңме әллә?!—дип, аның уйларын бүлде Мәкчим.

—Нәрсә?

—Менә... Самагуннан тәмам саңгырауга әйләнде бугай бу... Чәпчим, саңгырау...

—Нәрсә дисең, мать твою?!

—Телисеңме, дим, мин сиңа Биектаудан мәткә алып килэм. Сиңа кызыгып җөри торган бер катын бар анда. Үзе менә болай, үзе менә тегеләй, үзе ирсез. Шәп нәрсә! Ашарына-эчәренә дә бар. Тик куанычы юк... Балтасы сапсыз тора. Яхшылап сапларга кирәк! Кем яхшылап саплый ала, ул ана җанын да кызганмаячак. Чәпчим, шул!!

Заһидулла тәмам зиһенен җыйды, ләкин акылын җуйды, чөнки:

—Тамара... Тамара...—дигән исем аның баш миендә сугып кертелгән кадак кебек тыкылдап, бер үк вакытта ерак болындагы ат муенына асылынган шөлдер кебек чыңлап, тимер төйгән тимерче чүкечедәй зеңләп тора иде.

—Миңа мәткәләр кирәкми!—диде татар.

—Кем кирәк, хур кызларымы?—диде керәшен.

—Миңа Тамара кирәк!

—Там-ма-ра? Чә-әп-чи-им!

—Әйе!

—Кайсысы? Тамаралар Биектауда өчәү бит...

—Купец кызы Тамара,—диде Заһидулла, күңеленә—өмет, җанына—көтү, бәгыренә—сагыну өеп.

—Боже мой!—диде Мәкчим.—Йә Алла! Чәпчим, Кодай...

—Нәрсә шаккаттың әле?

—Теге түшәк өстендә яткан, чирле Николайның катынымы? Шулмы, чәпчим?

—Гражданнар сугышында безгә каршы, кызылларга каршы, сугышкан ак офицер хатыны Тамара,—дип өзде Заһидулла.

—Вәт! Күрәсең булса, гүргә керми торырсың, ди иде минем бабам. Хак икән сүзләре! Соң, син Николайның ак офицер икәнен дә белә идеңмени? Чәпчим, беләсеңме?

—Белә идем... Тамара сөйләде...

—Белү-сөйләүләр нигә инде хәзер?—диде Мәкчим.

—Аңламадым?

—Николай үлде, Тамара югалды... Чәпчим...

* * *

Заһидулланың җанына кара кисәү тыктылармыни... Күңелендә шайтан туе иде бугай...

Күз аллары караңгыланып китте, гәүдәсе чуендай авырайды. Чигәләрендәге кан тамырлары, менә-менә шартлыйм хәзер, шартлыйм хәзер дигәндәй, бармак юанлыгында кабардылар. Йөрәге, кувалда-балта белән төелгәндәй, авыр һәм каты тибә башлады:

—Дөп-дөп! Дөп-дөп-дөп!!!

Өстәл өстендәге кулларына салган башын күтәреп, ул Мәкчимгә сызланулы хәлсез тавыш белән дәште:

—Ничек югалды?

—Шулай инде, юкка чыкты... Чәпчим, юкка чыкты...

—Мать твою!

—Минекенме? Чәпчим, минекенме?

—Юк ла! Теге заразаларны әйтәм...

—Кемнәрне?—Мәкчим әле һаман Заһидулла сүзләренә төшенеп бетми, әмма үзенең төпченүчән акылы белән эшнең кая барганын чамалый: чибәр-таза Тамара белән матур-көчле Заһидулла арасында нидер булган. Нидер булган... Юкса, ул Тамараны чакырырга теләмәс иде һәм, ниндидер алар икесе генә белгән уртак сер. Югыйсә, мондый сәер кыяфәттә, башын югалткан халәттә утырмас иде.

—Николайның ... ак офицерның зараза туганнары...

—Туганнары, дип... бер шайка инде алар, чәпчим.

—Ничек бер шайка?—дип куйды Заһидулла.

—Бандитлар!—диде ярып Мәкчим.—Әле мине дә үз араларына кертмәкчеләр... Чәпчим, кертмәкчеләр...

—Сине?

—Әйе, мине инде! Алар хәтта мине үзенеке-үзләренеке саныйлар, чәпчим.

—Һич тә аңламыйм?

—Сөйләсәң, урыслар әйтмешли, длинная история.

—Сөйлә! Вакыт бар, вакыт күп. Төн—безнеке...

—Кая,—диде Мәкчим.—Чәпчим, караңгыланды. Җиделе лампаңа ут төртик әле...

—Минем өчле генә монда, бишле, җиделесе өйдә калды.

—Икебезгә өчле дә җитәр!—дип көлде Мәкчим.—Түнтәрикме берәрне? Чәпчим, ә?

—Киттек!

Алар икесе дә аз гына утлы суны йотып куйдылар, дөресен генә әйткәндә, эчү кайгысы тәмам эреп бетеп юкка чыккан, утыруларын да алар хәзер уртак дуслык хөрмәтенә багышлап кына утыралар иде. Инде менә «озын тарих» турында сүз чыккач, Заһидулла, бер төендәй җыерылып, колакларын сагайтып, Чәпчим Мәкчимнең авызына текәлде: «Ни кош-сүзләр очып чыгар бу өстендә сары мыегы кабарган эре тешле оядан?!»

Мәкчим көттерми-нитми генә сөйләп китте:

—Чепья базарында йөри идем... Революциягә кадәр бу, чәпчим

революциягә кадәр. Шунда печән кибәнедәй дәү гәүдәле, көрәк сакаллы бер урыс дәшә мина: «Парень, как тебя звать?» Мин: «Мәкчим»,—дим. «Ну, Максим!—ди бу.—Хочешь ко мне кучером?!» Ашау такы-токы, өйдә миннән башка алты бала. Бәләкәйләре әле, чәпчим, бәләкәйләр... Киттем мин мона ялланып. Әй, мала-лай, ниләр генә күрмәде башлар бу купец Стаканов белән. Эчәргә дә мин аннан өйрәндем. Бер чиләк эчә иде ул, чәпчим, бер чиләк... Аннан бер каз белән бер йомры ипине изеп кенә ташлый. Чәпчим, изеп кенә ташлый. Аның бер боты да бер кеше кадәр бар иде. Үлчәүдә тугыз пот килә иде ул, әле үзе ун потка басарга, таныш сәүдәгәр-купецлары арасында иң авыр гәүдәле купец булырга хыяллана иде. Үзе бит билгеле бай, купец Стахеев, Балякиннар белән, чәпчим, әшнә.

—Балякиннан истәлек булып Идел уртасында Бәләкин утравы гына калды. Әйтүләренә караганда, аның бу сай урында парахуты утырган, тарттырып ала алмаганнар, шуннан, төягән товарын алып, парахутын калдырганнар да ул урында утрау калыккан. Ә Стахеевның ике тегермәненең берсе әле дә эшли безнең Шөн елгасында. Су тегермәннәре алар,—диде Нигъмәтдер Заһидулла. «Минбеләм»леген күрсәтәсе килдеме, әллә башкамы, тик шулай да ул Чәпчим Мәкчимне сөйләвеннән бүлдереп, шушы үзе белгәннәрне кыстырып китәргә тиеш санады.

—Алары икенче история,—диде Мәкчим.—Чәпчим, икенче история...

—Стакановны дәвам ит алайса...

—Юк, башта без стаканлап алыйк әле, чәпчим, тамак кипте бу Стаканов гыйбрәтен сөйләгәндә...

—Әйдә, сон... Кабып куй алайса,—диде Заһидулла.

Өчле лампа сыек сары ут белән өстәл тирәсен генә яктырта иде. Бу яктылык түшәмгә үк менеп житә алмаса да, ике ирнең дә йөзләренә үрмәләгән сары нурлары белән, аларны ниндидер ят төскә кертеп, җәнлек кыяфәтендә чагылдыра. Җылы итеп ягылган мичтән яшәү көче алган көзге чебеннәр хәлсез атлап тәрәзә янагы буйлап йөриләр, кайберләре безелдәп оча ук башлаганнар. Эт-мәче кайткач, шош-шош! килеп йөри торган кыргый керпе идән башы ярыгыннан базга шылган, энәләрен тырпайтып шунда утыра.

Янгыр явуыннан туктады...

Ләкин дөньяны болытсыз да кара баскан, төн үзенең пәрдәсен җиһанга салган иде инде. Әллә нинди авыр, металл пәрдә иде бу. Бер дә мөселман хатын-кызлары пәрәнҗәсенә охшамаган. Нигәдер Заһидулланың хәтеренә Шөн авылы төннәре килде. Пәрәнҗәле, йомшак, челтәрле төннәр иде алар. Бу яктагы куе урман арасында төннәре дә куемы? Әнә бит авылда чакта җәйге төн бер мизгелгә кара шәлен генә бөркәнеп ала иде. Аннан гүзәл кыз йөзедәй яктырып кояш чыга һәм алтын нурлары белән сине җылыта,иркәли башлый. Ә монда?..

Тәрәзәдән караган кешегә, өстәл янында сап-сары йөзле ике кеше утыра иде...

Мәкчим сүзен дәвам итте:

—Күрдем ул Стаканов белән күрмәгәннәремне. Мәтвей Григорьич җиффәрергә ярата дидем ич әле.

—Исеме Матвей Григорич идемени?—дип сорады Заһидулла кызыксынып. Ә чынында аның Тамараның әтисе йөрткән исем-атны тулысы белән беләсе килә иде.

—Бүлдермә әле, коръәненә кадалган чалма!—дип ачуланып атты аны Мәкчим.—Чәпчим, тыңлый белмисең син, татар аты!

Галлюцинацияме, әллә башкамы, Заһидулланың колагында теге исерткеч—шаштыргыч—юләрләндергеч сүзләр янә яңгырадылар:

—Мой татарский конь!

—Керәшенчәрәк әйтсәк, Матви Григорич кына түгел, Мәтби Гөргөрич була әле ул, Стаканов, чәпчим. Эш исемдәмени, хикмәт җисемдә! Төшәбез шулай Наратлыдан Лубъян базарына. Гөргөрич, сату-алу итәргә

түгел, лыкынырга төшә Лубъянга. Анда анын знакумуйлары күп! Чәпчим, күп. Шул күпләр белән, чәпчим, күп эчәләр болар. Кайтабыз кире. Карра, чәпчим, кара бур-ран чыг-га! Күз ачкысыз. Мин, атларга ышанып, дилбегәне җиффәрәм, алар каты юлдан читкә китмәячәкләр, мона, чәпчим, ышанам. Барабыз шулай. Биектау астына җитеп, Сарапул күле кырыннан гына бара идек, кинәттән атлар туктады. Чәпчим, туктады бит, әй! «Нәрсә сун бу?»—дип, ат башына йөгерсәм, икәвесе минем якадан бөтереп тә алалар. «Кашуфкада купец Стакановмы?»,—диләр. «Ие»,—мәйтәм. «Бар чакыр монда купецыңны!»—дип, сугып та егалар. Яшь чак гайрәтле чак бит, ник куркырга әле болардан дип, күтәрелмәк булам һәм күрәм: куаклар арасыннан тагы икәвесе киләләр. Дуңгыз кебек тазалар, чәпчим, менә тазалар, аналарын корт чаккыры! Яңа килгәннәрнең берсе әйтә: «Акчасы бармы Стаканның?»—ди. «Белмим, дим, күрмәдем»,—дим.— Чәпчим, акчасын күрмәдем»,—дим. «Әйт әле үзенә, килсен безнең янга»,—диләр. Эт кебек өстерәлеп хуҗа янына барам: «Мәтби Гөргөрич, дим, сезне тегендә, ат башында чакыралар»,—дим, дер-дер килеп. «Атаң башында түгелдер бит?»—дип, көлә генә бу. «Атам башында бүрек, мәйтәм, Мәтби Гөргөрич, ә болар дүртәү икебезнең дә башка җитәячәкләр»,-дим. «Кайгыргансың икән юлда дүрт чебен торганга!»—ди бу. Чәпчим, шулай ди, «дүрт чебен», ди. «Бар, ди, эндәш главарьларына. Мин анын белән, ди, күптән очрашасым килә иде инде»,—ди. Чәпчим, шулай ди бит бу. Бардым да әйттем: «Башлыгыгызны чакыра купец»,—дим. Китте бу эре генә. Купец кашуфкада утыра. Килеп басты теге: «Акчаң бармы бай?»—ди усал тамак белән. Чәпчим менә, шулай ди. Ә Мәтби Гөргөрич: «Минем авызгарак иел әле, кычкырып сөйләшә торган сүз түгел»,—ди. Теге иелгән иде, чәпчим, иелгән иде, купец моны уклау-уклау бармаклары белән, бер кулы белән буып алды да кашуфкасыннан күтәрелеп һавада асып тора башлады. Валлаһи, дим, Мәтби Гөргөричнең шашкан кыяфәтен күреп аска җибәрдем. Чәпчим, китте, чәпчим...

* * *

Шулвакыт әллә ни булды...

Гүя купец Матвей Григорьевич Стаканов теге шашкан кыяфәте белән урман як тәрәзәсеннән карап тора иде, Мәкчим бот арасын капшап алды да тышка чыгып йөгерде. Берни аңламаган Заһидулла ишегән дә ябып өлгермәгән Мәкчим артыннан шаккатып калды. Суык кермәсен дип, барып ишекне япты, капкачын алып, мичкә тәгәрәткән бәрәңгеләрне табакка җыеп куйды.

Менә ишек ачылды...

Аннан гаепле кеше төсле Мәкчим килеп керде:

—Син инде гаепләмә, карындаш—диде ул.—Шул көннән соң тотанак юк минем, аз гына күбрәк чөмерсәм, насус тотмый, әллә берәр җирдә пужар: чаптырырга гына тора... теге хәлне искә төшерсәм дә, чәпчим, тотанак бетә... Менә хәзер дә...

Чалбардан килгән сидек исенә борын җыерса да, Заһидулла аны Мәкчимгә сиздерергә тырышмады, бары татар гадәте буенча дустын кул юарга куды:

—Бәдрәфтә булгач, өйдә кул юу—бездә мәҗбүри. Хәзер бәрәңге ашыйбыз, бар тәһарәтләнеп кил. Комган белән ләгән әнә почмакта...

Мәкчимнең ысланган балыгын да аралаштырып, бик тәмләп мич бәрәңгесе ашадылар. Заһидулла өстәл өстендәге утлы суны шешәсе белән тәрәзә төбенә куйды. Балык кылчыкларын, калдык-постык ризыкларны, ипи валчыкларын иске тастымал белән сыпырып, көчек белән мәче баласына бирде. Мәкчим дә булышам дип, уч төбе һәм җиң очы белән генә өстәл сөртешә башлаган иде, аны шундук тыйды:

—Кул белән өстәл өстен сөртергә ярамый, өстәл үпкәләр, ди.

Өстенә сый-ниГъмәт килүен теләмәс, ди. Хәерчелек теләмә, яме!

Мәкчим дә аптырап калды:

—Менә, татар! Теге жарамый, бу жарамый. Коръәненә кадалган мулла! Чәпчим, бер нәрсә жарамый...

—Ә син чукынган тәре!

Тыштан бер-берсенә ачуланышкан булсалар да, бер кавем балалары булып, уртак телдә сөйләшкән ике татар—мөселман вә керәшен—чын мәгънәсендә дуслар иде. Инде өстәл өсте жыештырылып, Мәкчим мич каршына барып, тәмәке төрде. Инде чүгәләп кабызып кына жибәрим дигән иде, Заһидулланың тагы кырыс тавышы яңгырады:

—Татарлар өйдә тәмәке тартмыйлар! Чын мөселман, вупшы, тәмәке тартмый. Ул—хәрәм санала.

—Беләм,—диде монысы белән тиз генә килешеп Мәкчим.—Бабай да әтине, тарта башласа, өйдән куа иде.

Заһидулла тамаклары туйган көчек вә мәче баласы белән уйнап калды, ә Мәкчим чыгып тартып керде. Шулвакыт песи тәрәзә пәрдәсенә сикерде. Чукынчык! Юеш тәрәзә пыяласында жегәрсез күбәләк йөренә икән. Заһидулла эт белән мәчене тышка чыгарып жибәрде:

—Бар, бушатынып керегез!

Моны сизгән энәбикә баз астыннан чыкты. Шош-шош пошкыргалап һәр почмакны иснәп чыкты, көчек яткан урынга аеруча игътибар биреп, усалланып ысылдап та алды, ят итеп төчкерде һәм тагы идән башы ярыгыннан базга чумды.

Үзе белән эт-мәчене ияртеп, Мәкчим керде.

—Карале!—диде ул.—Карындаш, без бит боларга исем кушмадык. Әйдә, син—мулла кеше, укы доганны...

—Бисмиллаһи... Эткә ни исем кушабыз, Мәкчим?

—Мәкчим!—диде Мәкчим.

—Үз исемеңнеме? Юләрләнмә әле, матри аны, шаярып маташма... Бисмиллаһи. Эткә ни ат кушабыз?

—Мәкчим!—диде һаман тегесе.

—Мать твою! Кире керәшен!!

—Мин кире керәшен түгел, син киребеткән татар. Әйттем, и все: Максим кушабыз, чәпчим, Максим...

—Соң бу урыс исеме ич!?

—Ә алар этләренә татар исеме кушмый дип беләсеңме әллә? Биектауда әнә Мохтар исемле эт бар, хужасы: «Ко мне, Мухтар!»—дип кенә чакыра.

Заһидулла беравык уйга калды һәм шундук ризалашты:

—Йә, жарар. Башладык: «Бисмиллаһи... Эткә ни исем кушабыз, Мәкчим?

—Максим!—диде Мәкчим.

—Аллаһу әкбәр! Моннан соң, көчек, атың Максим булыр,—диде Заһидулла.

Чәпчим Мәкчим көчекне кулларына күтәрде дә ике колагына да аерым-аерым кычкырды:

—Максим! Исемең синең Максим!! Чәпчим, Максим.

Аннан ул эт баласын алып барып ишек тупсасына куйды һәм икәүләп чакыра башладылар:

—Максим, Максим! Максимка!! Кил монда...

Көчек бу чакыруга, ике салмыш ирнең бала-чага кебек аның белән уйнавына бик канәгать калды, рәхәтләнеп койрыгын болгап торды һәм ишек катыннан алар каршына килде дә яшелле-күкле, әле нечкә, әле калын тавыш белән чиный-чиный өрде...

Ирләр егылып көлделәр...

Шушы нәни жаннан, эт баласы дигән хайваннан аларга ниндидер күзгә күренмәс тылсым жылысымы, тереклекне чолгап алган биоэнергиямe ага иде.

Мәкчим мәче баласын кулына алды:

—Бу малайга ни ат кушабыз?—диде ул.

Заһидулла, бер мизгелгә Мәкчим белән эт-мәчедән аерылып, үзенең улын, Заһидәсен исенә төшерде, Нократ ягына урнашкан тәрәзәләргә күз салды һәм, аның бәгырен кисеп, эчке бер аваз инрәде:

—Улым... Заһидәм... Әти... Әни...

Ә Мәкчимнен үз сүзе:

—Мәчегә исемне үзен куш!

—Бисмиллаһи...—диде анга килгән Заһидулла.—Мәче малаена Караколак дигән исем кушарбыз!

—Нигә Караколак?—дип аптырады Мәкчим.

—Күрмисенмени: ике колагы да кап-кара...

—Ә үзе ак, чәпчим ак бит.

—Бер мичкә балда иң беренче ике калак дегет күренә,—диде Заһидулла.

—Җә, җарар инде...—дип куйды Мәкчим.—Синенчә булсын...

Алар кабат өстәл янына килеп утырдылар.

—Әйдә, чәй янартабыз,—диде Заһидулла, кунакны ни белән булса да сыйларга теләп. Әле бит анын пешкән баллы чөгендере дә бар. Чәй белән хәтәр үтә ул.

—Төнгә каршымы?—дип сорады Мәкчим.

—Хәер... Шулай инде...

Бер кавым тынсыз утырдылар. Заһидулланың гына күңеле тынычсыз иде: күз алдында юлбасарларның атаманын бер кулы белән буып югары күтәргән купец Матвей Григорьевич Стаканов тора...

Никадәр каршы торса да, Мәкчимгә ул алдагы хәлләрне дә бәян итәргә кушты. Дөресе, үтенде, ирләрчә ялварды һәм—күндерде.

Мәкчим, авыр сулап, мич башындагы утлы суны аз гына кружкага койды да, бу юлы да Заһидулланы шаккаттырып, озаклап йотым-йотым гына эчте һәм урман як тәрәзәгә карап сүзен дәвам итте:

—Ә, ие... Кайда калган идем сун әле?

—Купец, юлбасарын бер кулы белән буып, өскә, һавага күтәреп тора башлый...

—А-а-а!!!—дип акырды Максим.

—Ник кычкырасың? Урман шүрәлеләрен уятасың ич. Әллә җинеләйденме?—Заһидулла кинәт кенә үзе дә куркынып китте.

Җаны-тәне белән калтырап, ул рәттән генә нindидер куркыныч барын сизде. Бу турыда аңа дивар бүрәнәләре, түшәм такталары, хәтта җылы мич үзе дә пышылдыйлар сымак иде.

Мәче баласы Караколак та куркынып үзен сәке почмагына сендерде, ә көчек Мәкчим—Максим чәң-чәң килеп өрә башлады. Елый-елый, куркынып өрә иде ул.

—Ни бар?—дип сорады Заһидулла бу сәер вә серле тынлыкны өзеп. Ни кычкырам дисә дә, тавышы чыкмады, авазлар, бүре күргән сарык бәтиләре кебек бер-берсенә елышып, әмма пышылдап кына чыктылар.

Һаман йөзен урман як тәрәзәдән ала алмаган Мәкчим, акаеп киткән зәңгәр күзләре вә арыш көлтәсе кебек тырпайган сары мыеклары белән баккан Мәккәсенә ымлап күрсәтте. Борылып караса...

Тәрәзәгә йонлач гәүдәле зуп-зур нәмәрсә капланган иде...

Менә ул, дөньяда булмаган да шикелле, юкка чыкты.

—Оборотень!—дип, чукынып куйды Мәкчим.—Мәтби Гөргөрич Стакановның өрәге... О Боже! Җә Кодай!! Чәпчим бит... Өрәге...

—Аю бит ул!—диде, шундук аңына килгән Заһидулла никтер куанып.

* * *

—Мин синдә генә кунып китәм инде, малай,—диде соң дәрәҗәдә курыккан Мәкчим.—Ник мылтыкны алмадым сун?! Әй, карындаш! Чәпчим...

—Кун әйдә! Урын иркен,—дип ризалашты Заһидулла.

Мәкчимнең аю күргән күзләре, баш миен әллә нинди убыр, өрәкләр, инде күптән тәне таркалып, сөякләре генә җирдә яткан купец Стаканов образын гәүдәләндереп, ямьсез хыялы белән баетылып, мәхшәргә юлыктырган иде. Үз-үзләрен тынычландырыр өчен, алар, икәүләп чыгып өч тапкыр мылтыктан һавага аттылар. Төнге ату тыныч дөньяны һәм тынып калган урманны шул кадәр тавыш белән селкетте ки, мондагы киек-җанварларың, каз-үрдәкләрең генә түгел, җен-албастыларың да алтмыш-җитмеш чакрым ары чапканнардыр.

Үз-үзләренә ышаныч туып, йокларга яттылар...

Тиқ икесен дә йокы алмый һәм тиз генә алмаячак та иде.

—Йә...—диде Заһидулла.—Сөйләп бетер инде...

Мәкчим тагы нигәдер сискәнеп китте дә, барып, ишекне бикләп килде.

—Ие, кайда калган идем сун әле? Чәпчим...

—Купец...

—Ие... Мәтби Гөргөрич уклау-уклау бармаклы сул кулы белән буып алды да... Ә аның сул кулы хәтәр җегәрле иде, ул сулагай иде бит... Теге акырып җибәрде: «А-а-а!»

—Әле генә синең кебек...—диде Заһидулла аны бүлдереп.

—Ие... Шуннан әйтте: «Бар, фраерларыңны ку! Китсеннәр моннан... Үзең кил, юкса...» Шул сүзләре белән атаманны, чебеш урынына селкеп, карга атты. Тегесе торып кагынды да юлбасарлар янына йөгерде. Иптәшләрен куып җибәрде: «Капканбыз кешесенә,—ди.—Купец Стаканов бит бу! Ананны өшкерер!» Тегеләр күздән югалуга, тагы килеп басты бу купец каршына. «Тыңлыйм, господин»,—ди. Мәтби Гөргөрич кесәсеннән шикәр ваклый торган келәшчә чыгарды да, тегенең башын артка каерып, берәм-берәм тешләрен ала башлады:

—Монысы, Наратлыда караклыгың өчен...

—Монысы, Лубъянда минем әшнәнең тауарын урлаганың өчен...

—Монысы, Сарапул күл буенда Казан байларын талаганың өчен...

—Монысы, әле генә белер-белмәс миңа һәм кучерым Максимга һөҗүм иткәнең өчен...

Мәкчим бер тын сүзсез торды. Тәрәзә пәрдәсенә кунган көзге ялгыз күбәләкнең канатын пырылдатканы да ап-ачык ишетелә иде: «Пы-ы-ыррр... Пы-ы-ырррр»...

Мәкчим тирән сулыш алды:

—Әй, малай! Чәпчим... Ап-ак карга сап-сары, эп-эре, ат теше күк тешләр коелып кына тора... Әйтте Мәтби Гөргөрич: «Тагы урлап-талап хәрәм ризык ашасаң, бөтен тешләреңне суырып бетерәм, ди. Шушы келәшчә белән»,—ди. Чәпчим, шушы келәшчә белән, ди бит... Ә суыннан... Шул юлбасар аның киявенә әйләнде... Чәпчим, киявенә...

—Ничек?—дип сораганын да сизми калды Заһидулла.

—Анысы... икенче история. Чәпчим, икенче история,—диде Мәкчим.

—Төн озын бит, бигрәк тә көзге-кышкы төн... Сөйлә, әйдә!—диде Заһидулла, кызыксынуы бермә-бер арткан иде.

Мәкчим борынын мышкылдатып куйды, янында мыр-мыр килеп яткан мәче баласын сыйпаштырды, тегесе, бу рәхәткә разый булып, киерелеп-киерелеп алды.

—Әй, ул Мәтби Гөргөрич белән күргәннәр!—дип, сулкылдап куйды, Мәкчим.—Сәүдәдә чут эшләрен яхшы белсә дә, бервакытта да диярлек алдатмаса да һәм һиччак үзе дә алдамаса да, дуамал баш иде ул Мәтби Гөргөрич. Бервакытны Биектаудагы знакумында тәгам җыеп утыра бу.

Алдында бөтен каз, түгәрәк ипи, тозлы кыяр һәм чирекле шешә белән самагун. Хәйран калырсын, малай, шул бот юанлыгы шешәне аш кунасы кадәр уч төбе, уклау-уклау бармаклары белән сулагайлап тота да кружкага тутырып сала. Ул чирекле шешә тулы бит, чәпчим тулы, минемише бетәшкәннәр аны ике куллап күтәрә инде. Анда да, ныклап тотмасаң, шуып төшеп китүе бар. Менә шулай салып утыра бу, үзе ныклап кызмый да, урыс-улак! Чәпчим, аек утыра бу. Шунда сезнең Шөн ягыннан Җаклы Җакуб килеп керә. «Бай!—ди бу.—Миңа да салып бир әле,—ди. Салып бирә Мәтби Гөргөрич зимагурга. Бу тагын берне сорый. Рәхмәте дә юк. Ну инде, купецыбыз саран кеше түгел иде, тагы берне салып бирә. Җаклы Җакуб кызып китә, җилпенә башлый, Мәтби Гөргөричкә: «Тагы берне сал!»—ди. Юк, сорамый, үтенми дә... Чәпчим үтенми, ә таләп итә, җикеренә, малай. Купец түземле кеше иде, сабырҗан. Ләкин аны, чыгырыннан чыгарып, женнәрен чакырсаңмы... Чәпчим беттең инде, чәпчимләр беттең. Әнә шунда да әйтте Мәтби Гөргөрич: «Исерден син, житәр!—ди.—Әнә каз боты кимер, кыяр кап»,—ди. Тегеме? Чәпчим кызды, чәпчим юләрләнде. Купец өстенә килә башлады. Шулчак Мәтби Гөргөрич урынынннан чак кына кузгалды да, тегене эт баласы урынына күтәреп, тәрәзә аша урамга атты. Бөтен рамы-ние белән чыгып китте теге, әй! Чәпчим, чәчелеп очты. Малаебызны яшен суктымыни?! Ай—күрде, кояш алды, диләрме әле. Әллә киресенчә: кояш күрде, ай алды, диләрме шунда...

—Ә Тамара?—диде Заһидулла, кычыткан уч төбен кашып куеп. Аны әлеге хатын тормышы кызыксындыра иде.

—Тамара—үзе бер история...

—Сөйлә әле!

—Тамара—чегән кызы ул...

—Йә Алла! Әйткәнием аны...—дип, үз уен кычкырып әйтте Заһидулла, әмма керәшен Мәкчим аның бу оран-инрәвен нигәдер колагына да элмәде. Үзе әйтмешли, чәпчим дә элмәде.

—Күрдек инде, ул Мәтби Гөргөрич белән...—диеп, сүзен дәвам итте:

—Бервакытны без аның белән Казанга барган идек. Шунда чегән табурына эләктек. Араларында хәтәр матур кыз бар иде. Чәпчимнәр дә матур кыз инде менә. Гүзәл инде, чәпчимнәр гүзәл! Бер кашык су белән йот та җибәр... Гашыйк булды бит моңа Мәтби Гөргөрич, тәмаммысы гашыйк булды, чәпчим, гашыйк булды. Андый кызга кем гашыйк булмас сун?! Мәтби Гөргөричнең яшь чагы әле. Утызлар тирәсе генә аңа, чәпчим, яшь.

—Ә синә?

—Миңа егермеләр...

—Кара!—дип шаккатты Заһидулла.—Синә ничә яшь соң?

—Иллеләр тирәсе...

—Менә инде!—дип аптырады Заһидулла тагын.—Мин әле сина кырык та юктыр дип йөри идем. Бик яшь күренәсең ич әле син...

—Чәпчим, җәш әле мин. Бигрәк тә җөрәк җәш...

—Хы!—диде Заһидулла, ә Мәкчим сөйли торган сүзен бер кавымга онытып, үзен мактап китте:

—Нигә җәш булмасын, ди. Мәкчим Чтапан улы. Җегерме җыл Мәтби Гөргөрич кебек байда кучер, аннан ун җыл балыкчы да аучы. Мин бит үз гомеремдә сыңар салам да күтәрмәдем. Ватылган кешемени сун мин?!

—Йә, җарар, аңлашылды!—дип бүлде аны Заһидулла.—Ә Тамара?

—Нәрсә, Тамара?

—Тамара турында сөйлә, дим, Мәкчим агай!

Керәшеннең күзләренә яшь бәрде, борыны мышкылдады, ул Заһидуллага сиздерми генә, төн карангылыгыннан файдаланып, күз төпләрен күлмәк җиңе белән сөртеп алды, аннан йомшаган тамагын бераз кыршылдырып:

—Рәхмәт! Чәпчим, рәхмәт!—диде.

—Нәрсә, рәхмәт?—дип аңламады Заһидулла.

—Агай... дигәнен өчен. Мина Мәкчим дәдә, Мәкчим агай дип керәшен дә, мөселман да әйтмәде монарчы. Үз татарың әйтмәгән, урыс сиңа «дядя Максим!» дип торамы сун инде ул! Аларнын бит бала-чагасына кадәр: «Максим, татарин Максим»,—дип кенә дәшә. Туганлык, олыны олылау сүзләре юк бугай аларда...

Өй эчен куе караңгылык белән тынлык басты. Бары мәче баласы гына: «Мыр-мыр-мыр»... килеп йоклый.

Дөнья тын...

Шушы тынлык икесенен дә җанына ниндидер биниһая зур авырлык өя, дөрес, ул үзе салам эскерте, мен көлтәле кибән кебек зур, дәһшәтле, ләкин гөрәнкәләп карасаң—мыскаллар гына чыга.

Купец Стаканов, аның кызы Тамара һәм гүзәл чегән кызы турындагы тарих икесенең дә аң капкачларын ачкан, шунамы Мәкчимнең авызын ябасы, ә Заһидулланың ау этенеке кебек торгызылган колакларын төшерәсе килми иде.

—Шуннан?—диде ул Мәкчимгә.

—Шуннан, утырган да шуган була инде. Чәпчим, шулай була. Зур акчалар биреп, ярты байлыгын югалтып, үзенеке итте тәки Мәтби Гөргөрич әлеге гүзәлне. Чәпчим, үзенеке итте...

—Акчалар биреп, байлыгын югалтып?

—Ә как же?! Гүзәл генә түгел, чегән бароны кызы иде лә ул!

* * *

Тәрәзә пыялаларына ябышкан төн әкрен генә куба башлады... Иртәнге эңгер-меңгер, йокысы туймаган сабый кебек, күзләрен ачкалап-йомгалап, уйсулык буйларына төште, үр-түбә өстенә менде. Аның хәрәкәтләре авыр, акрын, ипле иде. Ул, тамагы тук җанвардай, беркая да ашыкмый-кабаланмый.

Таң белән ач бүредәй, шыкыраеп кырау төште. Сентябрь ахырындагы шул шым гына төшкән кырау-кырудан чәчәкләр сераеп калдылар.

Сәгать алтылар тирәсендә тыш якка чыккан Заһидулла бер мәлгә тәне белән генә түгел, җаны белән дә бөрешеп, шыксыз вә суык уйга килде...

—Үтте җәй... Үтте, әй! Гомернең тагы бер елы үтеп китте... Үтә гомерләр... Кара инде бу чәчәкләрне?! Беткәннәр, үлгәннәр болар... Ә бит ничек матур утыралар иде...

Ул Заһидә белән, карт тупыл мамыкларына коенып, чишмә янында утыруларын исенә төшерде. Хәтта Аяз хәзрәтнең, авыр таягын болгап, алар өстенә килүе дә кызык бер мәл булып, аның җанына авыр хәл буларак түгел, ә үткәннең мыек астыннан көлеп хәтерли торган матур бер мизгеле рәвешендәрәк хәтер тактасына язылып куелды...

Заһидулла сикергәләп, кулларын җил тегермәне канатларыдай селкеп-болгап, әйләндереп, тәнен язып җибәрде. Аннан, бар үче шунда җыелган кебек, биш-алты таза букәнне, ачулы көч белән тукмаклый-тукмаклый, чырагачка әйләндерде.

—Кар-кар!—дип кычкырды өй тирәсенә ияләшкән ялгыз карга.— Яр, яр... утын яр!—диюеме? Әллә дию пәриеннән кара каргага әйләнгән бу кош сәләмәсе аннан көлмәк буламы? Шунда...

Зәңгәр күктән сагыш-моң инрәде:

—Кыйгак-кыйгак-кыйгак...

Йә, Алла!

Кыр казларының тезелешеп көньякка китеп барышлары икән. Алар өчпочмакланып зәңгәрлекне йөзеп-кисеп баралар иде...

Заһидулланың күзләренә яшь тыгылды, ләкин алар, кара-куе

керфекләрен чылатсалар да, өзелеп китеп, җиргә таммадылар. Ир кешенең сагыш-хәсрәт булып тулган иң авыр яшьләре дә, тышка түгел, ә үз эченә-йөрәгенә тамадыр. Аларның хатын-кыз затыннан чагыштырмача азрак гомер итү сәбәпләренең берсе дә шулдыр. Ни сәбәптәндер, аның җаны моң йомгагына әйләнде, әлеге йомгакның тәгәрәп каядыр китәсе килә, шуңамы—ул үз-үзен кая куярга белми. Нилектән бу? Нилектән?..

Кинәт ул үзен ошбу дөньяда япа-ялгыз бер кеше итеп тойды. Гүя үзе салган шушы йорты бар да, ул өйдә эт-мәче яши дә, рәттән генә урман шаулый да, арырак Нократ елгасы ага да—и вәссәлам! Башка беркем генә түгел, берни дә юк...

Ә кукләр?

Ул аларны күрми...

Ә ерак та булмаган Биектауда әтәчләр кычкыруы, этләр өрүе?

Ул аларны ишетми...

Дөнья манзарасына һәм авазларына күзләре ябылган, колаклары томаланган кешене күргәнегез бармы?..

Ул—аерым тормыш эзләп Шөннән Нократ аръягына чыккан Заһидулла булыр. Идел кичеп килде ул бу урынга, дөресрәге: шушы урманга...

Ләкин...

Аның күңеле тынгылык тапмады, җан тынычлыгы дигән нәрсә килмәде анарга. Хәтта йорт кадәр йорт салып та, ахыр чиктә ул үзенә тере куаныч таба алмады. Бәхет дигәннең кырыен да күрмәде ул. Шатлыклы көннәре шактый гына булса да...

Ә дөньяга күзләре ябылуы, аваз-тавышларга колагы томалануы битарафлыктан түгел иде. Монда сәбәп бик җитди булып, әлеге халәт төнлә йокы вакытында күргән төше белән бәйле иде. Әйе, ул төш күрде. Тәгаены, төштә үзенең үлгәнен күрде... Ә аның...

Аның үләсе килми иде...

Ул бу турыда уйларга да курка иде...

Заһидулла үлем белән бәйле сырышкак чебендәй уйларын һәрдаим куып тора, аларны якын да җибәрми иде. Каяндыр адашып кергән бер уй аның башын томалаган иде: «Башкалар бәлки үләрләр дә, ул—мәңгелек!

Ничек инде? Менә шулай! Ни мәгънә табып шушы тәнне җир астына күмдермәк кирәк ди, ә?! Ничек инде аның череп-таркалып ятуына ризалашырга? Бу аяклар, бу куллар, бу күкрәкләр, бу баш... Йә, Ходаем... Бар икән күрәселәр! Гәүдәнне җиргә күмми, яндырсалар да—бер дә кызык түгел. Бу бит аны шушы ук дөньяда тәмугка кертү, җәһәннәм утларына салу белән бер. Шул гәүдәдән, Тән кадәр Тәннән бер уч көл калсын әле...

Бәлзәмләп төрбә-мавзолейга салу да—Тән өчен мәңгелек төрмә. Әле шушы мәетне карау өчен халык агылса... Нәрсә бу? Эчке әгъзалары алынып, баш мие суыртылган, мамык тутырылган сөяк-тирегә карап хәйран китүме? Әллә вәйран булган Тәннән көлүме, аны мыскыл итүме? Кеше гәүдәсеннән фетиш ясаумы...

—Прес, шайтан!—дип кычкырды Заһидулла яман ачуы килеп.—Син, Иблис, әллә нинди уйлар белән агулыйсың мине. Син явызның эше бу...

—Уйлама баш, боекма күңел... Дөнья ямьсез чагында да начар түгел. Көньякка китүче кыр казларын карап калу да чит-читләре сагыш белән челтәрләнгән кичкенә генә бәхет иҗ! Әгәр син ике аяксыз килеш караватта гына ятсаң, күрер идеңме аларны? Ярый, тәрәзә аша да күчем казларга кул болгап калырга була ди. Ә тома сукыр булсаң... Тагы саңгырау була калсаң—ишетер идеңмени «кыйгак-кыйгак»ларны...

Үз-үзен никадәр җанландырырга тырышса да, Заһидулланың күңеленә тынычлану оялый алмады, киресенчә, төнге төш, үзенең салкын тылсымы, өшеткеч сихере белән аның аңын томалаган иде. Каян керде ул төш? Моңарчы кара чокырда, баткак сазлыкта ятканмы әлеге быткыч уйлар? Аларның җанга ишетелүе дә ниндидер мәгънәсез, тәртипсез,

эзлексез, мантыйксыз булып, авазлар белән генә сөйләшүче сабый бытылдавы түгелме...

Шулчак Заһидулланың эчен нидер кисеп үтте.

—Улым!—дип дәште ул туган авылы ягына карап.—Ничек син анда?..

Аннан Күккә багып күңеленә килгән үз сүрәсен укыды:

—И Аллам! Ник газаплыйсын мине? Нишләп мин үз-үземне тинтерәтәм? Ни сәбәпләр аркасында беркайда да урын таба алмыйм? Мина кешеләр арасында да җайсыз, ялгыз яшәү дә бик читен. Кайда мина дигән тотрыклы урын? Кай төштә мин таяныр, горур басып торыр җир? Бәлки ул Күкләрдәдер... Алай икән, Тән өчен анда күтәрелү мөмкинлеге юк, ал җанымны, Аллам! Җанымны алсаң, Тәнем кала. Ул җәл бит, бигрәкләр дә җәл. Тән бит ул! Җан кадәр Җан сыйган Тылсымлы Савыт ла ул! Аларның кайсы кадерлерәк? Минемчә, икесе дә. Ә кайсысын аеруча ярата адәм баласы? Кайсысының теләк-омтылышларын ихтыяҗларын ныграк кайгырта ул? Нигә Тән вә Җанның үзара тигезлеге, кушылма камиллеге юк?! Җавапсыз Сорау... Амин...

Шулвакыт аның эче авыртып китте. Авыр уйлар азык җыярга да тәэсир итәләрме әллә? «Азыкҗыяр» дип Заһидулла ашказанын әйтә иде. Үзенчәләп, икенчеләп, яңа сүз табып. Гомумән, ни коткы беләндер ул сүзләр ясарга ярата иде. Бу гадәте шәкерт-малай чагыннан килә инде. Мәкчим китек чынаякны урысча «пепельница» ди дә, тәмәке төпчеген ташлый, ә Заһидулла «пепельница»ны тәрҗемә итә, дөресрәге үз сүзе белән әйтә: «Көлкойгыч, көлләвеч»...

... Зур йомыш хәҗәтен үтәргә теләп, ул урман ешлыгына керде дә карт шомырт төбенә утырды. Кинәт...

Аяк астында беләктән дә юан кап-кара елан күреп коты очты, чалбар ерыгын сәдәпләп тә тормыйча, өенә ыргылды.

—Ни бар?—дип шаккатты, пешерергә бәрәңге юып ятучы Мәкчим.

—Ела-ан!—ди алды ул.

—Нинди елан? Чәпчим, аңламыйм...

—Кара елан. Бастырык юанлыгында...

Мәкчимнең җанына да шик корты төште, алай да ул батыраеп:

—Әйдә, барып карыйк әле,—диде.

Бик сагаеп кына карт шомырт янына тәпиләделәр. Мәкчим зур күсәк, ә Заһидулла үзенең мылтыгын алган иде. Барып, ул «утырган» урынны карасалар...

Анда, чыннан да, беләк юанлыгы... кап-кара... шомырт ботагы ята иде.

—Ха-ха-ха!—дип көлде Мәкчим.

—Һы!—дип ыңгырашты Заһидулла.

Аны бит... Аны бүген төнлә төшендә кара елан чагып үтергән иде.

* * *

Адәм баласының күңеле ел фасыллары сыман үзгәрүчән, табигать күренешләре кебек төрле-төрле сурәтләргә, алышыну—әверелешләргә бай.

Өйгә кереп Мәкчим пешергән бәрәңгене ашап утырганда, теге «кара елан» онытылып бетә язган иде. Шунда Заһидулла Мәкчимнең Тамара турындагы өзелгән сүзен ялгатасы итте:

—Кич-чә... Гүзәл кыз... Чегән бароны кызы турындагы хикәятең ярты юлда калды.

—Чәпчим, ярты юлда,—диде Мәкчим.—Самагун парыннан йоклап киткәнмен...

—Төне буе гырлап чыктың,—диде, йокысызлыктан интегеп төн үткәргән йорт хуҗасы.

—Марҗа катын да, каты гырласам, төннәрен тукмаклап уята мине,—

дип ризалашты йомшак күңелле керәшен, үзенең алама эше—каты гырлавы өчен кызарып. Үзе шундук йомры гына бер бәрәңгене әләктереп, эре бөртекле тозга манды да ике кабуда ашказанына, Заһидуллача әйтсәк, азыкжыярга озатты.

—Озын сүзнең кыскасы,—дип дәвам итте ул сүзен мыегына ябышкан ипи валчыгын уң кулы белән ипләп кенә сөртеп алып.—Ие, озын сүзнең кыскасы, чегән баронының гүзәл кызы Мәтби Гөргөрич Стаканга... Стакановка кияүгә чыкты. Хәтәр итеп туй уздырдылар, малай. И, анда коелган акча, түгелгән байлык, ашалган ризык, эчелгән аракы... Исең китәр менә, күрсәң, чәпчим, исең китәр! Шундый олылап туйлар уздыруга да карамастан, алга таба бәхетләре булмады аларның. Купец эчә иде, эчкән саен яңа мәткәләргә тартылды. Берничә ел яшәгәннән соң ул үзенең чегән бароны кызына өйләнгәнен дә онытты булса кирәк. Әле бит аның кайсыдыр авылда да хатыны бар иде сымак. Менә шулай, «бар»—бер заман туйдыра башлый бит ул, чәпчим, туйдыра. Бар туйдыра икән, ул инде күренми башлый, чәпчим дә күренми. Ә юкка күңел тартыла, тәнме-җанмы аны эзли. Чәпчим, эзли...

Мәкчим, тагы онытылып китеп, тәмәке кабызды. Заһидулла, аны сөйләвеннән туктар дип, өйдә тәмәке тартудан тыя алмады. Ни теләсә дә... Үзе эчтән генә уйланды: «Һы! Җиффәрә, өйгә төтен җиффәрә. Тыйсам... Ул кире керәшенме? Шундук сөйләвен туктатачак. Тыштан гына сиздерми, ә эчендә бик тә горур җен утыра аның. Вәт, чукынган татар, тартыпмы тарта. Юк, тыя алмыйм... Тамара турында күбрәк беләсем килә. Өнемне алды ул Тамара, тормышымда әллә нинди кисәки борылыш ясады. Нәкъ менә Нократның борылган төшендә яңа манзара ачыла бит әле. Тамара да миңа—яңа манзара... Өр-яңа, кызыклы хатын-кыз. Килсен иде ул минем яңа өемә бер генә көнгә. Юк, бер генә төнгә... «Дави меня, дави, мой татарский конь!»—дисен иде...»

Мәкчим, сары мыек чалгыйларын тел очы белән чылатып алды да, берни дә булмагандай, төшенке-боек тавыш белән сүзен дәвам итте:

—И, сагышланды да соң инде күчмә тормыш баласы! Иртә таңда тәрәзәләргә капланыр иде дә, ерак офыкларга карый-карый, нидер турында уйланыр иде. Чәпчим, уйланыр иде... Ә кояш үзенең батышына авышканда аның кызгылт нурларына карап гаҗәп тә моңланыр иде. Чәпчим, моңланыр иде...

Керәшен күз төпләрен уып алды:

—Менә шул вакытта...—Кинәт ул үксегәндәй итте:—И-и-иһһ!!!—Аннан соң бер сулышта җөмләсен ярып салды:—Менә шул вакытта җырлап җибәрә иде...—Аннан ул ыңгырашты:—Юк, ул җырламый иде, ул җыр дигән бала тудыра иде. Ул бала шундый да моңлы, шундый да үзәк өзгеч хәсрәтле, сары яфраклардай сагышлы, үзе тирән агышлы... Белмим... Минем андый җыруны дөнҗада башка бервакытта да ишеткәнем булмады...

—Синең «Ачы миләш»ең дә шундый көй-җыр бит,—диде Заһидулла, аны бүлдереп.

—Ачы миләш?

—Әйе!

—Ә, ачы миләш...

—Мин «Ачы миләш» дигән җырыңны әйтәм...

—Дөнҗа—ачы миләш ул,—дип бүлде Заһидулланы Мәкчим.—Карап торсаң дөнҗа агачы нинди матур, чәчәге дә күркәм генә. Ә менә җимеше генә...

—Көзге кыраулардан соң аның да җиләге баллана,—дип, үз уен белдерде Заһидулла.

—Дөрес анысы... менә мин дә, гомер көзенә кергәч, балландым: балык тотам, ауга йөрим, катынга хуҗалыкта булышам. Карт марҗа булса да, әйбәт кеше ул минем катын...

Нәни генә мизгелне биләгән көзге тынлык... Бу тынлык «әйбәт

кеше карт маржа, Мәкчим хатыны»на хөрмәт йөзеннән идеме, Заһидулла анысын күнел капчыгын актара-актара төпченеп белеп-барлап тормады, чөнки аның аңында сүзне баштагы сөрешенә кайтару өчен, әлеге дә баягы дигәндәй, «теге сорау» тора иде:

—Шуннан?

—Нәрсә шуннан? Минем маржа катынмы?

—Юк ла! Чегән бароны кызы...

—Ә-ә-ә...

—Бы!

—Әлиф дин, коръәненә кадалган татар!

—Ба дин, тәресенә чукынган керәшен!

Икесе дә, юләр кешеләр кебек, шаркылдадылар.

—Әй, сатлык татар! Хи-хи-хи...

—Һәй, кире керәшен! Ха-ха-ха...

—Зато, мин—горур,—диде Мәкчим.—Керәшенлегемнән йөз чөермим, татарлыгымны яшермим...

—Мин дә, Аллага шөкер! Үземне урыс димим ич әле,—дип аны кырт кисте Заһидулла.

Кинәт кенә житдиләнделәр. Мәкчим чиләктән су алып эчте. Заһидулла мичнең капкачын ачып ут тергезде...

Су һәм ут...

Яшәешнең иң мөһим, иң кирәкле чыганаклары. Жир, су, ут, һава... Адәм баласы шушы дүртлектә яши, хәрәкәт итә, кирәк санаган гамәлләрен кыла, үз артыннан яңа буын калдырып, тагы жиргә кереп ята:

—Балчыктан ясалган кабат балчык булыр... Инсаниятнең Баш Атасы Адәм үзе дә «Кызыл Балчык» дигән мәгънә йөртә ич... Туфрактан килдек, ни туфаннарны үтсәк тә, беркөн барыбер туфракка әйләнәбез. Күкләр калыр, сулар ага бирер, таулар түбәнәер яисә калка төшәр, утлар янар да сүнәр—без генә булмабыз...

—Асылынып үлде ул, бичара...

—Нә-әр-сә-ә?

Чәйнеккә су тутырып ятучы Заһидулланың кружкасы чүттән генә идәнгә тәгәрәмәде.

—Чегән бароны кызын әйтәм...—диде Мәкчим.

—Ничек а-сы-лы-нып?..

— Сагыштан...

—Сагышын жыры белән сытсын иде...

—Күбрәк ялгызлыктан, шул ялгызлык китергән хәсрәттән, сагышта янып, моңга батып үлде дә инде ул. Онытты аны урыс купецы... Ә ялгызлык—иң авыр чир ул... Аның белән хасталансаңмы? Тереләм димә... Беребез дә Робинзон Крузо түгел...

Авыр тынлык...

Заһидулла башында уйлар өермәсе котыра: «Ни өчен генә яшибез соң без? Әйт әле, Гүзәл Кыз, Чегән Бароны Кызы?! Менә син, байлыгына кызыгып, купецка кияүгә чыккансың... Ә бит иң зур байлыгың—Синең Гүзәллегең иде. Нигә аны акчага саттың? Иң-иң зур байлыгың—исәнлегең-саулыгың иде. Нигә аңа кул салдың?? Син бит инде хәзер беттең: туфрактан килдең—туфракка әйләндең... Жаның кай төшләрдә айкала синең? Рухың һаман рус купецын каргыймы? Гөрләп аккан чишмәләр тавышында синең дә моңың чылтырыйдыр, бәлки. «Кыйгак-кыйгак» дип очкан көзге кыр казлары тавышында синең дә сагышың бардыр, бәлки. Төнге шомлы урманда ябалакның ухылдавында синең дә хәсрәтең чагыладыр, бәлки...»

* * *

Ул төн урталарында уянып китте...

Соңгы вакытларда өч-дүрт сәгать йоклау—аның нормасына әйләнде. Шуннан да артык йоклый алмый ул, тынычлыгы югалган иде.

Ир урын өстендә шактый гына аунады...

Сизгер колаклары төнге тынлыкны тыңлады. Юк, дөнья тып-тын түгел: әнә Биектау ягында этләр өреп куйды. Менә Бояр урманы эченнән ябалакның үтә сагышлы авазы ишетелде:

—Ух-ху! Ух-ху!! Ух-ху!!!

Әлеге аваз, өй янындагы агачларга бәрелеп, аның кайтавазы сары сагышка, хәсрәт-моңга әверелеп тәрәзә пыялаларына сыланды:

—У-у-ух... Уу-у-ух... Ууу-у-ух...

Кинәт!

Челтерәп аккан чишмә тавышы ишетелде.

«Кайда ул чишмә?!»

Заһидулла аңлый алмады, аңы җайсызланган, томанга сарылган иде...

Ә чишмә ага да ага... Челтерәп ага... Әллә баздан бәреп чыкканмы?!

Ул үз-үзен чәчләреннән тартып-өстерәп торгызды. Ишек катындагы юынгычка килеп башына бер чүмеч салкын су койды:

—Бр-ррр!!!

Чишмә авазы юкка чыкты...

Мәкчим киерелә-киерелә рәхәтләнеп йоклый иде әле. Заһидулла тышка чыкты.

—Кыйгак-кыйгак-кыйгак...

Күк йөзенә күз салды:

—Кайдан бу тавыш? Кыр казлары очмый ич?!

—Ух-ху! Ух-ху!! Ух-ху!!!

Ябалак? Ул бит көндез йоклый, ухылдарга вакыты юк аның...

Заһидулла чигәләрен кысты: «Ни борчый мине? Күкләр бирәр нәрсә турында пышылдыйлармы? Ниндидер коточкыч алхәбәрме бу? Ни бар? Ни үзгәрешләр?»...

Аның уйлары тагы кинәт кенә туган йорты белән бәйләнде.

—Әти... Әни... Заһидә... Улым...

Нократ ягыннан кемдер кычкыргандай итте:

—За-һи-дул-ла-а-а-ау!

—Мин мон-даа-ау!

—Мин Әхмәдулла-лаа-ау!!

Урман: «А-а!»лап, «уу-у!»лап улап торды.

Заһидулла, юл-сукмакка күз дә салмыйча, Нократ ярына ыргылды. Ботак-чатакларның туктаусыз тәненә бәрелүләрен, йөзенә чәп-чәп сугуларын тоймады да булса кирәк ул. Ирнең баш мие сыегайган, аңы каткан, акылы томаланган, шуңамы ул ике сүздән торган сөаль аша гына зәгыйфь фикер йөртә иде:

«Ни бар? Ни бар?? Ни бар???»

Ифрат көчле эчке тоем аңа кичә кичтән бирле: «Нидер бар, ниндидер зур үзгәреш, нәрсәдерме, кемдерме бу дөньядан өзелеп төшеп калды,»-дип, катгый рәвештә хәбәр итә, шуңа әзер торырга кушып, кисәтә иде.

Ачыклыкка чыгып, яр өстенә басуга, Әхмәдулла көймәсенә тап булды. Күзләр күзләр белән очраштылар. Соргылт күзләр конгырт-кара күзләр белән.

Әхмәдулла күзләрен көймәсенә, аннан суга төшерде:

—Гый-ба-дул-ла аб-зый... Җизни...—диде ул, сузып кына һәм гаепле кеше сымак.

Заһидулла аңлады...

... Көймәдә бер-берсенә бер сүз дә дәшмәделәр. Сүз кату яисә юату урынсыз иде. Чын мөселман булarak, Әхмәдулла моны гына белә иде. Ә Нократ өстеннән каекта баручы Заһидулла үзе уйлар күленә баткан иде...

Көзге җил, инә белән кадагандай, бит очларын чеметтереп ала. Шадра йөзле елга өсте ниндидер ямьсез, шыксыз, хәтта шөбһәле сымак. Менә-менә су, илаһи көч белән икегә аерылыр да, аларны көймәсе ние

белән йотар кебек. Гүя елга төбендәге ком-ләмдә биниһая зур аждаһа ята. Һәрхәлдә...

Заһидуллага шулай тоелды...

Әхмәдулла ишә дә ишә... Нократ ага да ага...

Гомер агышларымы бу? Нинди туктаусыз агым бу? Вакыт әллә шушы агымнарда яшиме?

Ишкәкче йөзенә тырышып-тырышып ваемсызлык чыгарган.

Шулай булган һәм булачак та!

Тукта! Туктале!!

Бу кискен карар ваемсызлыктан түгел бит. Ул көчсезлектән, ә иниң дөресе, чарасызлыктан килә. Хәйранның вәйранга әйләнүеннән...

Күктән бер төркем каргалар каркылдап узды. Аргы яктагы таллыкта чыпчыклар чыркылдаша. Гүя берни булмаган... Гайса пәйгамбәр ни дигән әле: «Бернигә дә аптырамагыз, чыпчыклар күк чыркылдашып яшәгез,»— дигәнме?..

Ах, шулай яшәп булса иде... Их, шундый гомер үткәрсәң иде...

Әмма...

Нигә кирәк ул кешеләргә? Нәрсә ул «чыркылдашып яшәү»? Моны бит чыпчыклар үзләре генә белә. «Чыркылдашу»—аларның сөйләшүләре инде ул. Ни турыда гапләшәләр алар? Бәндәләргә бу караңгы...

Көймә борынын комга төртте.

Ярга төшкән ике ир авыл ягына атладылар. Ни сәбәп икесенең дә телләрен тегеп куйгандыр, алар авызларын ачмадылар да. Бары авыл очына кергәч кенә, тиздән әтисе үлеп яткан йортка аяк басачагын күз алдына китергән Заһидулла кинәт кенә сорап куйды:

—Кайчан?..

—Кичә кич...

—Авырмый да иде кебек...

—Кинәттән өзелде... Андыйлар авырып ятмый ул... Алар атлап барганда гына авалар...—диде Әхмәдулла.—Иннә лилләһи вә иннә илаһи рәҗигун. Ятачак гүрләре якты, урыны ожмахның түрендә булсын! Җәннәт ана—яхшы кеше иде бит...

—Амин!—диде Заһидулла ике битен сыпырып.

Шуның белән сөйләшер сүз бетте.

Әхмәдулла үз уена, Заһидулла үз фикерләренә күчте...

Әтисенең кинәт кенә үлеп китүе аны тетрәндергән иде: «Һай! Нинди кыска, бигрәк кыска бу гомер... Әле кайчан гына ул, түбәтәйле малай, Чепья, Казан базарларына әтисе белән бара иде. Ат җигеп, тауар төяп... Андагы кызыл билле прәннекләр, әтәч конфетлар! Болар барысы да хәзер төштә генә кебек...»

—Кеше өчен кеше яшәсә дә, бәндә өчен бәндә үлми...

Нәрсә? Ә, Әхмәдулла икән:

—Һәркемнең үз гомере, үз яшәве, үз үлеме...

Нигә фәлсәфә сата әле ул, тыштан караганда күп нәрсәгә битараф булырга тырышкан Әхмәдулла? Әйе... Шалишь, брат! Синең дә җаның сызлана, бәгырең киселә, күңелең кителә. Син аны эчкә генә җыясың, тышка гына чыгарып күрсәтмисең...

Заһидулла тагын ярымсаташулы беренчел уйларына кайтты: Һай! Нинди кыска, бигрәк кыска бу гомер... Иртәнге кояш булып калкасың да, кичкесе булып байыйсың... Шушы кыска гомерең дә бушка узса? Вакытсыз килгән Әҗәл чалгы-кулын сузса?? Тагы да килеп... Соңгы минутларында ялгызың гына калып, янында соңгы бәхилләшү сүзләренне әйтер кадерле кешең булмаса... Инде телсез калып, соңгы сулышыңны алып, тирән караңгылыкка очып барганда, кипшергән иреннәренә каурыйканат белән су тидерер якын ярың тормаса... Үл дә кит инде!

Хәер, син болай да үлеп барасың бит инде... Ә шулай да аң эшли әле, баш мие күзәнәкләре үлеп бетмәгән, алар соңгы балкыш-чайпалыш булып, бар көчләрен җыеп, ахыргы уй-сорауларга әйләнәләр: «Ясин

чыгучы абыстай бар микән?»

Нинди моң бу? Нинди мәкам?

Изге Коръәннең моң-мәкаме ясинда шул эчке аһәңгә, тирән көрсенү газабына, соңгы үкенечләрнең йомшак шавына әйләнә түгелме... Саргаеп беткән көзге яфракларның ифрат сагышлы лепердәве кебек кенә ул. Өзелер алдыннан... Тынычлыкны бозмыйм дигән серле авазның сихер-тылсымга ия пышылдавы гына ул. Югалыр алдыннан... Материясез Җанның үз кабыгын—тынсыз калган гәүдәсен—күргәч, тавышсыз бәргәлә-нүе вә сыктавы гына ул. Очып китәр алдыннан...

Баш мие күзәнәкләре соңгы көчәнештә эшлиләр: «Мин киттем... Кемнәр алып барып җирләр мине? Өчесен, җидесен... кырыгымны, еллыгымны уздырырлармы? Мәңгегә югалгач, искә алырлармы мине?»

Һәм тынлык...

Мәңгелек...

Биниһая...

Олуг...

Тынлык...

## II кисәк

Көзге буразналарда пәрәвез җепселләре...

Кояш үтә якты. Иртәнчәк булганга аз гына салкынча...

Мунча эчендә бикләнеп калган «Котсыз» исемле кара мәче кычкырыпмы-кычкыра, акырыпмы-акыра. Заһидулла ялкау гына елмаеп, әмма усал күзләре белән карап, аны «төрмә»дән коткара. Песи, рәхмәт әйтәсе килепме, аның аяк астына егыла. Тирес өстендә утыручы ана мәче: «Фу, ирлегең-горурлыгың юк синең!»—дигәндәй, аннан йөзен читкә бора. Ә үзе... Үзе ул патшабикәдәй киерелеп, Әби патша булып... тирес өстендә утыра. Тәхет вә ләхет сүзләре бер-берсенә бик якын. Алар арасында нәни генә вакыт аралыгы гына бар...

Шәп көн!

Матур көн!!

Әмма...

Заһидулланың елыйсы килә: «Шушындый да гүзәл көнне улы әтисен күмеп йөрсен әле?! Бу бит бернинди дә мантыйкка сыймый... Ә язмыш мантыйксыз ул. Ләүхел—Мәхфүздә язылган икән—Язмыш инде! Беркая да бара алмыйсын. Монда качып котылу өчен бер ярык та юк. Таракан сыярдай ярык та...»

Тәһарәтләним-рәтләним, госел коеныйм-пакъланыйм дип мунчага килгән Заһидулла янына чиста кием, ак сөлгеләр күтәреп Заһидәсе килеп кергәч, ир заты өнсез калды: «Нинди матур аның хатыны!—Ул нечкә билләре, түгәрәк балтырлары, калку түшләре, зифа сыны! Ул серле елмайган очкын-кара күзләре, аз гына бөдрәләнгән кара-дулкын чәчләре, чиядәй кызгылт-сусыл иреннәре, уймак авызы, нәфис борыны, шаштырырдай колак йомшаклары, гүзәл ияге...»

Түзмәде Заһидулла, эчтән килә торган авыр вә каты, дәрт-дәрман тулган, тынычсызлыгы югалган, ифрат көчле-куәтле авазны тыенкылап, аһылдады да сандугачын кайнар кочагына алды:

—Былбылым! Алтыным-җәүһәрем минем!!

Ни сәбәптәндер, күзләренә хыянәтчел яшь бәрде, аяклары тотрыксызланып китте, күкрәген нидер кыса башлады, башы шаулады.

Менә алар тыелгысыз рәвештә, бер-беренә сарылып, үбешә башла-дылар...

Заһидә чиксездәй тоелган күз яшьләрен җәлләмичә акрын гына, ашыкмый гына, тавышсыз гына елый иде. Әмма...

Күлмәк итәгенең сабыр гына күтәрелеп баруын тоюга, хатын ирнең

кулын тотты һәм кискен генә:

—Кирәкми!—диде.

—Нигә, иркәм?—дип сорады ир, өзгәләнеп.

—Көне ул түгел... Гөнаһ... Зина... Соңыннан...

Ул үз сүзләренә—пәрәвез ятьмәсенә эләккән чебендәй, буталып-буталып беткән!—һәм гөнаһсыз, беркатлы, чиста күңелле, нечкә бәгырьле һәйбәт хатынына карады да аның белән ризалашты:

—Ярамый шул! Гө-наһ...

... Авылның дәрәҗәле кешесе Гыйбадулланы соңгы юлга озатырга кеше күп җыелган иде. Хәтта Заһидулланың кан дошманы саналган кумхуҗ рәисе Габдрахман да, комсомол башлыгы яшь калай әтәч, элеккеге көтүче малае Габдулла да килгән. Кая барсыннар! Кәнсәләрдә: «Мин—житәкче!»—дип, күкрәк каксалар да, үлем алдында—һәркем тигез. Барысына да—шул өч аршын җир...

Җыелганнар, мәетне соңгы юлга әзерләүне көтеп, шыпырт кына, уч төбенә йөткеренгәләп, үзара иплe генә сөйләштеләр:

—Гаҗәп тә матур көн бүген!

—Сөбханалла!!

—Кояшы—җәйге кояш...

—Гыйбадулла абыйның үлеме дә, җирләнүе дә якты көнгә туры килгән, Алланың рәхмәте! Шәп кеше иде...

—Гүре якты, урыны оҗмахта булсын!

—Амин...

... Юылган-кәфенләнгән мәетне, дәфенләү өчен кабыкка салып, зират очына киттеләр. Хатын-кызлар һәм бала-чага туган-тумача, күршекүлән боеккан йөз белән озатып калдылар. Заһидулла күрде: аның әнисе тамчы да еламады. Әйе, керфек тә какмады, бөртек тә яше акмады. Әллә әтисен гомере буе яратып тормаганмы ул? Кырыс иде бит әтисе. Бер генә әйтте. Сүзен кабатлап тормады. Икенче сүз итеп сүс камчы алды. Очы еландай чага торган каешлы сүс камчы. Әйе, аның беренче сүзе—сүз, икенчесе—камчы иде... Ул үз өендә—үз патшалыгында—әнә шулай хан булып яшәде. Татар бит хан булып яшәргә туа, кешеләргә өстәмә сан булып кына түгел...

Шул ук вакытта Заһидулла, капка баганасына сөялеп, өзлегә-өзлегә елаган Заһидәсен дә күрде: «Ах, яраткан икән аның хатыны биатасын! Бик нык яраткан!!»

Хәер, мулла кызы бит ул. Мөселман йола-тәртипләреннән, татар гореф-гадәтләреннән читкә бер адым да атлый торган зат түгел. Үз атасы Аяз мулла, әнисе Асыл абыстайның өй мәктәбен узган, алар кушканча тәрбия алган. Ләкин...

Мәет чыкканда елыйсы түгел дә—елый әнә...

Зират авылның югары очында, Әби патша юлыннан аз гына читтәрәк иде. Аз гына арырак гражданнар сугышы елларында аргы яктагы Биектауда аклар тарафыннан үтерелгән ике кызылармис һәм бер командирның уртак каберләре. Кемнәр алар? Чуртым белсен! Мылтык тотып бу якларга килгәннәр һәм үтерелгәннәр... Кайсы як кешеләре булды икән ул бәндәләр? Туганнары бармы, нигә хет каберләрен эзләми алар?

Җавапсыз сораулар...

Зиратның үр ягына—төньякка борылдылар. Кабер шунда казылган иде...

Калганын Заһидулла тоныкк кына хәтерли бугай. Дөресе, исенә төшермәскә тырыша...

Менә мулла абзый моңлы мәкам белән догалар укый...

—Яхшы кеше идеме, җәмәгать?

—Яхшы кеше иде, бик яхшы!

... Заһидулла, Әхмәдулла һәм тагы бер туганы Гыйбадулла картның үлгәч җинеләеп калган җансыз гәүдәсен ләхеткә индерәләр...

... Ләхет такталары куела...

... Авызын ачкан каберенә дөбер-шатыр балчык коела.
Туфрактан туган туфракка керәчәк...
Һәр дөньяга килгән беркөн үләчәк...
Әйе!

Зиратка кешеләр кабыкта алып килеп, үле тәненне гүргә индереп, кабереңне балчык өеме белән—ишек итеп!—каплагач, сиңа чыгулар юк инде. Бу кабер—гәүдәңә мәңгелек йорт. Гомереңбуе ялгызак син анда...

Заһидулла, әрсез чебеннәрне куган кебек, әлеге шөкәтсез уйларын куарга, баш миеннән җиллә тәп чыгарырга, һичьюгы аларны онытып торырга теләсә дә—максатына ирешә алмады. Әле генә әтисен мәңгегә калдырып киткән кеше буларак, аның башында «үлем», «зират», «кабер» дигән сүзләр туктаусыз гөжләп тора иде...

... Өйгә керүгә ул әнисен кочып алды:

—Их, әнкәй. Әткәй вакытсыз китте бит...

—Гомере шул булган,—диде ана сабыр гына.—Ходай җанын биргән кебек аны кире үз хозурына ала да...

—Син нәрсә, әнкәй? Бер дә җәлләмисеңмени әткәйне?—Заһидулла анасының сабырлыгына шаккаткан иде.

—Кемнең күпме яшисе Ләүхел-Мәхфүздә үк языла,—диде карчык шул ук сабырлыгын җуймыйча...

... Заһидә абзарда маллар карый иде...

Заһидулла олы якта малаен карый иде:

—Их, улым, улым...

Аның күзләренә дым төртте:

—Бабаңны җирләдек бүген, улым. Ә син аны белмисең дә, рәхәтләнеп-изрәп йоклап ятасың...

Кинәт аның баш миен яшен уты өтәләгәндәй булды:

—Хәер... Әйе... Әле син үз гомереңдә күп үлемнәр күрерсең... Якыннарыңны соңгы юлга озатырсың...

Шунда аңа сәер вә сискәндергеч уй килде:

—Балакаем! Беркөн син үзең дә... И, сабый-сабый... Шуның өчен тудыңмыни син?!

Ул сулкылдап елап җибәрде...

* * *

Мәет чыккан өйне юып-пакъландырып, мичләрен агартып-акландырып алу татарда күптән килә, бу—Ислам дине йолаларының бересе. Өйдән соң кием-салым юыла...

Мәет чыккан өй сагышлы вә моңлы, ул телсез, бераз шомлы. Монда кычкырып та сөйләшмиләр, гүя аларны үлем сере шулай тота. Инде көлүгә килсәк, монысы гөнаһ ук санала, чөнки үлекнең Рухы бу шатлыклы гамәлне ишетеп:

—Ах, миннән котылганнарына шулай шатланалармы болар?—дип, ифрат та рәнҗер, имеш. Инде әрвах үзен хурлаганнарын ишетсә, үзенә начар сүз әйтүчене каргап әрләр, ди...

Үзен ифратипле вә сабыр тотса да, Заһидулланың әнисе Гайния—тутырып әйткәндә Гайниҗамал әби—ире үлеп өч көн үтүгә, бик нык тартылды: күзләренә сагыш шәмнәре эленде, аларда моң-хәсрәтле сары уты көйрәп, йөзе дә саргаеп китте. Ни сәбәптер, аның иреннәре сул якка таба бөреште. Бетерешә карчык, бетерешә. Инде әнә килененә дә маллар карарга булышмый, ә бит ире исәндә бөтерелеп кенә йөри иде әле. Хәзер, кайчан карама—кулларында дисбе. Шул иске дисбе,—тылсымы бармы,—аны гел үзенә тартты, шуңа карчык ипле бер җайга килеп, өзелеп-өзелеп, сүзләрен ярым пышылдап тәсбих тартуда булды:

—Бисмиллаһи...

—Сөбханалла...

—Аллаһумәх фәзьна...
—Аллаһумә ихдини...
—Аллаһу әкбәр...

Аңлады Заһидулла: аның әнисе нәкъ үзе кебек үк эчке уйлы, һәр кайгы-хәсрәтен вә шатлык-ләззәтен жан сандыгына жыючы адәми зат икән. Ул үзе дә бит, уйлар йомгагын сүтә башласа, чуалып беткәнче туктый алмый.

Ә менә Заһидәсе күз яшьләрен дә, яшәү рәхәтен дә эчкә агызмый-жыймый, ә гөрләп-гөрләтеп тышка чыгара. Шуна күрә дә аның жаны юшкынсыз, күнеле ашкынулы, рухы утлы, хисе нурлы, уе ачык бугай.

Ялгыз тормышта ир сүгенергә өйрәнә башлады, хәер, бу гадәтләр аңа Урал ягында яшьли шахтада эшләп алганда ук һәм гражданнар сугышы вакытында йоккан иде инде. Күнелендәге тынычсызлык вә чарасызлык урысчалап: «мать твою»ны ешрак әйттерә башлады.

Әле генә, әтисенең өчесенә дип, тәкә суяр өчен пычак кайрап ятканда, Заһидә аңа ничектер сак кына орынып китте һәм, бу хәрәкәт ничектер жайсыз килеп чыкты да, ир кеше Гали пәкеседәй үткен пычак йөзендә бер бармагын канатты:

—Һы!—диде башта.

Аннан сулкылдап типкән йөрәкнең гаярь көче белән бармагына бәреп кан чыккач:

—Мать твою!—дип ычкындырды.

Кычкырып та әйтмәгән иде юкса, хатынның сизгер колагы моны ишетеп, ул иренә үпкә тулы яшьле күзләре белән карады да:

—Кагылма әнигә!—дип кычкырды.

Аннан соң...

Әйе, аннан соң бирчәләнеп-киселеп беткән кулларын Заһидуллага күрсәтте:

—Мин әниләр белән торганда болар юк иде... Минем кул бармакларым аккош канатыдай ап-ак иде,—диде.

Ачу ташу чыгара, ди, түзмәде ир:

—Мулла кызының кулы... Коймак тотып кабара, ди!—шулай ычкынды.

—Нишләвегез бу, балалар?

Борылып карасалар, лапаска комганын тотып Гайнижамал әниләре кергән икән. Соравын каттый итеп, очлы ияген әллә ничек хәрәкәтләндереп, сирәк тешле авызын ачмый гына әйтте кебек ул.

—Оялыгыз әзрәк. «Оялу—ярты иман ул»,—дигән Мөхәммәт пәйгамбәр... Шушындый көнне... Әллә атагызның өчесе икәнен дә оныттыгызмы?

Карчык авыр атлап бакча ягына чыкты. «Монысы—ачу өстенә кычу»,—дип куйды эченнән Заһидулла.

Заһидә кырт борылып өйгә кереп китте. Ирдә аның йомры инбашлары, таза беләкләре, калын вә киң арт чүмечләре ымсындыру илә кызыксыну берлә, ниндидер ятсыну да тудырды.

«Ерагая барам түгелме мин аннан?—дип уйланды ул.—Йә Ходай! Әле бит өйләнешкәнгә дә күпме генә... Тамара, чукынчык, шаштырды... Вәт, Иблис! Шай-тан...»

Өйдә бала елавы ишетелде. Юк, бу акырып-үкереп, өзгәләнеп-сызланып елау түгел иде, ә йокыдан уянган сабыйның үзен сиздереп аваз салуы гына булды. Тик шулай да теге көннән соң Заһидулла өйдә бала елавын күрәлмас кешегә әйләнде. Никадәр сабыр кеше булса да, ул, котырынып китеп, йортка атлады.

—Син кая?—дип сорады әнисе.—Абзарда сарыгың котә...

Ул күзләрен жиргә төшерде, каршында жиз комган гына тора иде. Гүя әлеге сүзләрне дә озын гына борынын сузып шул комган әйткән. Әнә шул борыныннан су да агып китсә... Йә, ни дөнья соң бу? Уйласаң баш китәрлек—әйбәт саваплы эшкә дип йөрү, ә өйдә, әйтик, менә монда—лапас астында—тарткалаш та талаш диярлек хәл-гамәл. Син унар

дип йөрисең, нидер кирегә тарта. Үзең яхшыга омтыласың, ниндидер пычрак-начар нәрсә сине куенына ала...

«Ни дөнья бу, ә?! Кем моңа җавап бирер? Бирер яисә бирә алырмы? Ник юньсез-явызлар ошбу дөньяда барысын да изеп-сытып, кәеф-сафа корып, рәхәт яши, ә әйбәтләргә—михнәт, яхшыларга—шакшылык?»

Ул әтисен күмгән көнне хәтерләде...

Зираттан кайтуга, аны кәнсәләргә чакырдылар. Идарә йортында күмхуж рәисе Габдрахман, авыл советы башлыгы Сабит, партячейка секретаре Ямаш һәм комсомоллар башлыгы Габдулла көтәләр иде.

Елмаеп, үз иткән булып каршы алдылар. Сүзне гражданнар сугышы солдаты, җыелышны оештыручы Габдрахман башлап җибәрде:

—Заһидулла авылдаш, без икебез дә сацалистик эрбәлүтсияне шул эрбәлүтсия атларында яклаган илә дә саклап калган гыражданнар сугышы солдатлары. Хәзер бөтен илдә күмхужлар төзү бара. Менә авылдан берничә кеше илә дә син генә аерым калып ялгызак тормыш алып барырга йөрисең. Әнә Иделнең аръягында үзеңә йорт та салдырып куйгансың. Ну бит...

—Нәрсә «ну»?—диде Заһидулла аңа туры карап.—Син «ну»лама, мин ат түгел «на», «ну» белән чаптырып, тәртә арасында тотарга!

—Кирелегең башыңа киртә булып төшмәсен,—диде Габдрахман, карлыккан тавыш белән хәтәр генә кисәтеп.

—Кая төрттерәсең?—диде Заһидулла салкын гына.

—Кара козгыннар оча башлады...

—Мылтыгым бар...

—Син—бер, алар—мең!

—Тагы ни белән куркытасың?

—Рачкулачивайт итсәләр?!

—Мин бит кулак түгел. Тагы, үзең әйтмешли, «эрбәлүтсия атларында сацалистик эрбәлүтсияне» яклаган, саклаган кеше.

—Андыйларны күбрәк алалар!—диде Габдрахман, кинәт кенә аягына басып.

—Тилгән алырга, мин чебеш түгел—диде Заһидулла ярсып.

—Тилгән түгел—кара козгыннар!

Шул сүздән соң Заһидулла ишекне бәреп ябып чыгып киткән иде. «Тапкансыз көнен!»—дигән иде теш аралаш.

Менә хәзер әтисенең өчесен уздырырга дип кулына пычак алгач, әнисе һәм хатыны белән әргә кергәч, ул тагы шул сөйләшүне исенә төшерде: хәтер кыллары авыр гына зыңлап-чеңләп киттеләр. Гүя аның таш маңгаен тимерчедәге авыр кувалда белән төяләр иде.

Кара тәкәне мөгезеннән тотып, өстерәп алып чыкты да, җиргә салып аякларын бәйләде. Аннан, Гали Пәкесе кебек үткен пычагын бер кавымга гына һавада уйнатып, җан иясенең кара йонлы муенына чалып җибәрде...

... Җиргә гөжләп кан акты...

Кан, кан һәм тагы кан...

Һәр тамчы кан белән кара тәкәнең тормышы бетә, яшәве үтә, җаны савыла иде.

Ни сәбәптәндер, Заһидулланың башы әйләнеп китте...

* * *

Кара тәкә кызыл кан агызып ятканда, ул читкәрәк, мунча янына таба атлады. Аяклары шактый тотрыклы булсалар да, баш әйләнүе бетмәгән, колаклар шаулавы да туктамаган иде.

«Нидән бу?—Ә, каһәре, малны бисмилласыз суйдым ич!—Ул күк йөзенә бакты:—Гафу кыл, ярлыка, Ходаем!»

Мунчага кереп зур бер салкын чүмеч суны башына койды. Тирли

башлаган мангай салкыная төште, чәч төпләрендәге жылы дым да салкынайды.

—Брр-рр!—диде ат кешнәгән кебек. Азрак ангыраеп торуга, аңына кайтты: баш авыртмый, колак шауламый, акыл аек иде.

—Һы,—дип сәерсенде ир.—Бу нинди сер?

Аннан җиңел адымнар белән инде җан биреп күзләре калайланган тәкә янына килде дә, аның аякларын чишеп, махсус әзерләнгән агач җәплеккә элеп куйды. Шуннан гына тәмам тынычлана төшеп, болдырга менде, өйгә тавыш салды:

—Әнәй, Заһидә! Җылы су чыгарыгыз әле...

Дөрес, суны әнисе түгел, хатыны чыгарачак иде, ләкин «баш»ка дәшми, алдан «яшь»кә дәшмиләр—монысы йорттагы атаң рухы өстенә, анаңны хөрмәт итмәү билгесе саналыр иде. Аннан соң күрде бит, Заһидә мич тирәсендә әвәрә килә, ә әнисе «ә-ә-ә»—дип, бер мәкам көйләп, бишектә чыр-чыр көлеп яткан оныгын тирбәтеп ятмыш.

Тиресен тунап төшерергә өлгермәде кара тәкәнең, лапаска кояштай елмаеп хатыны килеп керде. Шунда... Әллә ни булды шунда: ул чүттән генә кара тәкәне ташлап матур йөзле, шалкандай ап-ак тәнле Заһидәсен кочаклап алмады. Ләкин, ни генә дулкынланса да, үзен бу эштән тыеп калды: «Һәрнәрсәнең үз вакыты, һәркемнең үз чираты, ди...»

—Су салып торыйммы?—диде хатыны тагы да матур тавыш белән елмаеп.

—Ашыкма әле. Бар, үпкә-бавырларын салырга табак алып чык,—дип кенә куйды ире, бик тә эшчәнлек вә булганлык күрсәтеп. Мал суюда ниндидер мәҗүси тантана бар ич.

—Хәзер!—Заһидә аңа рәхмәтле, рәхимле, разый вә яратулы иде. Күзләрендә—нур-очкын-ут...

Шушы бер генә бик тә гади сүздән Заһидулла моны үзенең нечкә күңеле белән абайлады һәм тойды. Гомумән, аның Заһидәсе үч саклап, үпкә тотып йөрүче зат түгел иде. Ул үзе дә, кинәт кабынып каты сүз әйтсә, кире кайтучан булды. Бу аңа әтисеннән иңдерелгән холык, характер билгесе булып, ул бервакытта да кешегә үч саклап йөрмәде, үчлекле бәндәләрне сөймәде. Иң мөһиме, тормышта үзенне җинеп, мин-минлегеңне, кирәкмәгән горурлыгыңны сындыру бит. Бу нәрсә дә аңа ерак бабалары җанынннан ук салынган нәрсә...

Хатынының ике табак күтәреп чыгуын ул күреп-тоеп торды.

—Карале, Заһидәм! Шәп бит, симез бит бу тәкә, ә?

Хатын эреп китте:

—Шәп, симез, Заһидулла җаным! Менә яхшылап чистартам, юам да бүген үк эчәгеләреннән тәмле-тәмле бөккәннәр пешерәм. Кара нинди майлы аның эчәгеләре!

—Нигә бүген?—дип каршы төште йомшак кына ире.—Бүген итне болай да күп салабыз.

—Ярый, алайса,—диде хатын да ризалашып һәм өстәп куйды:

—Хәзер төннәрен суык инде, ите дә, үпкә-бавырлары да, эчәгеләре дә бозылмаслар...

—Инде көннәрен дә суытыр чаклар житә,—диде тирән көрсенеп Заһидулла.

Икесе дә беравыкка тынып, эчке борчуга бирелеп алдылар, чөнки ир дә, хатын да үз эчләрендә, баш очларында ниндидер күренмәс, ләкин куркыныч кара болыт торганын сизенәләр иде. Нәрсә дип ажгыра ул аждаһа болыт:

—Аерылачаксыз!—дипме?

—Бетәчәксез!—дипме?

—Үләчәксез!—дипме?

Кем белсен дә, кем аңласын, ди, Кара Язмыш сүзләрен. Ничек төшенергә, ди, аның кая ишарәләгәнен?

—Йа, Алла...

Хатын авыр сулады.

—И, Ходаем...

Ир кысылып тын алды.

Ләкин бу «авыр сулау» яисә «кысылып тын алу» аларның һәркаюсын чолгап алган капчык-тышча эчендә генә башкарылып, бер-берсенең колакларына ишетелмәс эчке пышылдау гына иделәр. Шуна карамастан, барыбер Бер Җан Икенчесен ап-ачык тойды: «Алар уртасында Җир ярылды һәм бу ярык, ачылганнан-ачыла барып, ниндидер кара упкынга әйләнеп ята...»

Заһидулла тагы күз чите белән генә хатынына карап алды: «Йа Алла! Фәрештә икән ич аның Заһидәсе! Менә шулай, Заһидулла мулла! Синең хатының, Аяз мулла кызы Заһидә—алиһә, фәрештә ул! Кулларына тагылган үтә күренмәле канатлары гына күренми дә, беленми дә аның. Һәр төштә, һәр эштә—фәрештә ул!!»

«Кем сөйли моны? Ә уң жилкәдәге Ак Фәрештә икән! Савапчы...»

«Заһидә дип... Урман авызындагы шалашта бергә төн йоклаган Тамара да бер дә ким түгел. Аның ул көлтә-көлтә эре бөдрәле кара чәчләре, чәй чәшкәседәй чем-кара күзләре, мемердәп торган изенке тәне, кырыклап бүрәнә кебек юан ботлары...»

«Ә монысын кем сөйли әле? Ә сул жилкәдә утыручы Кара Фәрештә икән! Гөнаһчы...»

Ул гына телгә килде, колак артына кара ташлар булып утырган шайтан балалары дәррәү барабан кактылар:

—Та-мар-ра!

—Там-мар-рам!!

—Там-тра-та-там!!!

Шулвакыт үз уйларының тирән күленә, хәтта ләменә баткан Заһидулла кинәт кенә үзенең дә икегә аерылуын тойды:

Беренчесе: саваплы фәрештә Заһидулла.

Икенчесе: гөнаһлы шайтан Заһидулла.

Баш миен көйдереп кызган тимердәй эссе сорау туды: «Кем мин? Кем... Нигә бу уйлар? Бүген көне түгел бит... Бу баш кайчан уйларыннан туктар? Булырмы аңа бер тынычлык? Ул бит хәтта төннәрен йокы аралаш та уйларыннан арына алмый... Күп баш аз, ялгыз баш күп уйлар, ди...»

Ир хатынына сүз катты:

—Сал әле жылы суыңны...

Хатыны елмаеп комганнан су агызды:

—Салам, Заһидулла...

Кулга коелган жылы су белән жылы сүз күнелен жебетте, хәтта уйларыннан коткарды.

... Кич Аяз мулла белән мәчет картлары Гыйбадулланың өчесенә жыелып, аның рухына Коръән чыгарып, дога кылып киттеләр.

Өстәл өсте жыештырылып, куе караңгылык төшүгә, йорт йокларга ятты.

Икеле-микеле уйларыннан арынган Заһидулла мулла үзенең Заһидә-алиһәсен ярсулы бер ашкыну белән кочагына алды:

—Фәрештәм минем!

—... ул-ла!..—дип кенә әйтә алды анысы.

... Алар тозлы тиргә чыланып беткән ястыкка юеш чәчләрен салып, яшенле-давыллы яңгырдан соң калган бодай басуы кебек, бер тын белән акрын гына сулап яталар иде, урам уртасында туган жыр тәрәзә пыялаларына килеп бәрелде:

Алга үрмәләп була,
Артка үрмәләп була.
Ялгыз тормыш тормышмыни—
Тормыш бергәләп була.

Бу камсамул Габдулланың кичке уеннан кайту авазы булып, ул

аны Заһидулла колагына төбәгән иде.

«Дур-рак!—дип уйланды ир.—Үрмәләү—тормышмыни ул?!»

* * *

Әтисенең жидесен үткәрүгә, Заһидулланы тагы кәнсәләргә чакырдылар: идарә йортында шул ук кумхуж рәисе, саилче малае Габдрахман, авыл советы башлыгы надан Сабит, партячейка секретаре йолкыш Ямаш һәм Сабир байның элеккеге көтүчесе улы, комсомоллар башлыгы Габдулла. Килеп керүгә аларның һәрберсен нәкъ шулай сыйфатлады Заһидулла:

—саилче малае Габдрахман...

—йолкыш Ямаш...

—надан Сабит...

—көтүче улы Габдулла...

Юк, юк! Кимсетеп тә түгел, ә авылның иң ярлылары, хәерче токымнары, ялкауларның власть башына менүләренә ул менә бүген, менә хәзер, менә шушы минутларда гына төшенде...

«Карале! Мать твою!! Монда бит жыен әтрәк-әләм, затсыз бәндәләр. Йә, Ходай, юкмыни шушылар арасына матур төс өчен Адәм диярлек бер кеше. Юньле инсаннар беткәнмени бу дөньяда? Алай дисәң... Гөлнең кайчан тигәнәкләр арасында утырганы бар, ди?»

—Йә!—диде Габдрахман, канлы үгез күзләрен ана текәп.—Акылыңа килденме инде?—Теге вакытта авыл карты, Заһидулланың әтисе Гыйбадулла аларны сугыштырып җинелгәннән соң, ул яшьтәшенә генә түгел, гүр иясе булган авылдашына, өлкән кешегә дә ифрат ачулы вә үчле иде: «Карт тәре! Ятасың менә хәзер кабердә... Ә теге вакытта малаеңның мине җинәсен белеп күкрәкне төйдерттең...»

—Мин үз акылымда,—диде Заһидулла, сабыр булырга тырышып.—Әмма да ләкин, Иөзмөхәммәт абзый әйтмешли, син менә үз акылыңдамы соң?

—Үз акылымда!—диде кинәт аны бүлеп тегесе.

—Акылыңны күрсәтү өчен хәзер эрбәлүтсия атларында дип жиффәр инде. Алай бигрәк тә хәтәр бит инде ул. Әнә Габдулла маңка кебек ачык авыз һәр сүзеңне селәгәе белән бергә йотарга тора...

—Син! Си-и-ин!!—дип чәрелдәп сикереп торды Габдулла.—Син... контра!!!

—Сүзеңне уйлап сөйләш, энем,—диде Заһидулла аңа мыскыллы караш белән.—Син әниеңнең сөтен имеп ятканда, абзаң гражданнар сугышында кызылармис булып, Совет властен яклап сугышып йөрде. Беләсең килсә, мин Азинның ординарецларыннан берсе идем, штабта тордым...

—Хәзер пәртийнәй аныңны югалтып кулакка әйләндең,—диде Ямаш.

—Минем партиядә булганым да юк ! Ничек югалтыйм ди мин булмаган «пәртийнәй ан»ны?!

—Сәвит хөкүмәтенә каршы барасың бит,—дип бүлде аны Сабит.

—Менә син, Сабит абый, төгәл генә мина шуны әйт әле: нәрсә ул Советлар?

—Соң сәвит сәвит инде,—дип ык-мык килде Сабит.

—һәрхәлдә, миңа шунысы билгеле: Сабит-совет түгел, ә совет—Сабит түгел! Төкердем мин сиңа, Сабит абый. Юньләп имза куя белмисең ич!

—Нә-әр-сә?!—дип акырды тиз кызучан Сабит.—Мин сәвит персидәтеле түгелме?! Иптәшләр, карагыз әле! Бу кулак кисәге миңа яла яга ич. Ул әле миңа гына яла якса ярар да иде, ул бит сәбитләрдән көлә, төкерәм сәбитләрегезгә, ди.

—Мин алай димәдем: советларга төкерергә жыенганым да юк.

Куелган власть, барлыкка килгән система... Ә сине Сабит абый, наданлыгыңа карамастан, халык җыелышта, сәбит хөкүмәте булгач, аның башына әнә Сабитны куярга кирәк дип сайлады ич. Оныттыңмыни?

Сабитны бик үк өнәп бетермәгән Ямаш, борыны белән пошкырып, көлеп куйды. Тегесе аңа карауга, тамагын кырган булып йөткереп алды да:

—Иптәш Ысталинның фәрмилирүфкәсе шундый: авыл тормышын әкәнчәтелни җайга салу, пырадукцияне арттырып алу, тигез-матур тормыш кору өчен авылдагы барлык крәчтияннарны күмәк хуҗалыкларга җыярга...

—Һәм...—дип алып китте Заһидулла.—Шул күмхуҗлар әзерләгән барлык ипине, итне-майны, сөтне... хәтта бетне дә дәүләткә тартып алырга!!

Кинәт шомлы тынлык урнашты...

Стенадагы чебенле сәгать тә туктады кебек. Кәнсәләр түшәме, Сабир байның алтын-сары нарат такталарыннан эшләнгән түшәм, кинәт кенә каралҗым төскә керде.

Бер кавымга күмхуҗ рәисе Габдрахман, партячейка секретаре Ямаш, авыл советы башлыгы Сабит, камсамул Габдулла куе томанга күмелеп, эреп юкка чыктылар...

Бакча артында ялгызак эт өрде... Аның тавышы ифрат моңлы булу өстенә нигәдер үкенечле һәм көчсез иде...

«Ялгыз тормыш тормышмыни...
Тормыш бергәләп була!»

Кем җырлый моны?

Каян килеп керде әле бу җыр Заһидулланың колагына?

... Томан тарала башлады...

Нигәдер иң беренче Габдулланың карсак гәүдәсе чагылды аның күзенә, ә аннан соң көрән томан эченнән бер-бер артлы гыйфритләр кебек Габдрахман, Ямаш, Сабит калыктылар һәм...

Һәм Иосиф Сталин...

Сталинның рәсеме алар артындагы диварда иде. Ул Заһидуллага кара-чәнечке күзләре белән карый. Нинди төстә микән аның күзләре? Сорымы? Яшелме? Нинди генә булмасын, аларда зәһәрлек, усаллык һәм тәмугъ утлары җемелдәшә...

—Йә-йә-йә!—дип, тынлыкны бозды Габдрахман.

—Сәяси хата,—диде Ямаш.

—Хөкүмәткә, сәбитләргә каршы,—диде Сабит.

—Контра!!—дип акырды Габдулла кыска аякларына басып. Ул хәтта утырган урындыгына ук басмакчы иде, Габдрахман кулын селкеп һәм ымлап, аны бу эшеннән туктатты.

—Карале, Заһидулла,—диде Габдрахман, сөйләшүнең шулай кинәт кенә артык тирәнгә керүенә чып-чынлап пошаманга төшеп. Аның бит исәбе бик тә, бик тә гади иде: Заһидулланы бераз куркыткалап килергә һәм шул рәвешле, ялгызак тормышын туктатып, аны да артык тавышланмый гына күмхуҗга алырга. Йөрмәсен үзе генә әллә кем булып! Юкса, барысы да Идел аръягына чыгып үзенә йорт сала башласалар, Шөн авылыннан берни дә калмас! Тагы...

Әйе! Шуның өстенә Габдрахманның өстәл тартмасында бер бәләкәй «урыс малае» күзен мөлдерәтеп ята иде. Кичә кичтән әйбәт кенә төшергәннән соң, бүген авызга тамчы да эләккәне юк. Нишләп катлаулandырды әле бу Заһидулла аңлашу-сөйләшүне. Баш китәр сүзләр ычкындырды бит! Ярый инде икәве генә булсалар... Әле Сабит белән Ямалины да җайларга мөмкин. Әнә теге безкүз Габдулла, ул колагы ишеткәнне җилгә җибәрми дә җибәрми инде...

Заһидулла да үзенең «ычкынганлыгын» аңлады. Югыйсә, күмхуҗлар төзүнең төп максаты—авылдагы һәр нәрсәгә контроль, һәр грамм ипине исәптә тотып, дәүләткә кирәк кадәр сыпырып алу—талап алу!!—икәнен

ул үзе аны белән тойса да, бу турыда теге вакытта чишмәле тупыл төбендә утырганда сөекле Заһидәгә дә әйтмәгән иде ич. Бары күнеле белән сизә иде ул кумхужларның авыл кешесе өчен түгел, ә дәүләткә савым сыер итү өчен төзелгәнен. Бер зур амбарга тутырылганны талап алып китү җайлымы да, йөз кечкенә амбарга тутырылганны тартып алу җинелме? Крестьян үз келәтенә салган ашлыгын сина бирә димени ул?! Әнә продразверстка елларында...

«Чыккан эт оясыннан чыккан, икенчесен чыгарма!—дип үзенә фәрман бирде Заһидулла.—Болар сине тереләй ашаячаклар!»

—Йә-ә-ә!—дип тагы сузды Габдрахман.

—Минем башка сүзем юк!!—Ул ишекне каты бәреп чыгып китте.

Стенадагы Сталин портреты шылтырап идәнгә төште...

Чылтырап пыяла ватылды...

* * *

Чылтырап пыяла коелды...

Ишекне каты итеп япкан Заһидулланың башы гүя шәкерт елларында Казанда гәҗиттә күргән «Пыяла баш» рәсеме иде. Менә шул «Пыяла баш» чылтырап аның аяк астына коелды. Ул ярым аңсызланып ишеккә сөялде. Ишек аны тегеләрдән аралады, ул аларны күрми дә инде, ләкин адәм балаларына Хак Тәгалә биргән ишетү сәләте кинәт кенә тылсымы бер көч белән ике мәртәбәгә артты. Чөнки...

Әйе!

Чөнки теге якта сөйләшәләр иде. Аны сөйләшү дә дип булмас, талашумы, әрепләшүме?—хәтта, йомшаграк итеп әйткәндә, болар фикерләшәләр иде. Ул җаны-тәне белән тойды; хәзер аның язмышын хәл итәчәкләр болар, нигә дисәң, ишекнең аргы ягында, ишекнең аргы ярында—аңа каршы ярда!—Нинди дә давыл кубачак...

—Кон-ты-ра!!!—дип акырды камсамул Габдулла һәм кулларын төйнәп ишеккә чапты.

—Тукта!—дип кычкырды аңа Габдрахман.—Син, малакасус, нәрсә ана йодрык беләнме?! Ул сине түгел...

Габдрахман чүт кенә «мине дә...» дип ычкындырмады, ләкин аек акылы аны нык авызлыклаган иде, шуңа мин-минлегенә ифрат та тия торган «мине дә...» теш-рәшәткәләр артында тоткарланып калды.

Шунда ул һәр сүзенә басым ясап әйтеп куйды:

—Ул сине генә түгел, ләхет такталарын ачып җиде бабаңны җыеп алып кайтсаң да, ярачак сезне. Чеби урынына сытачак! Улмы? Ул бит...

Тагы әздән генә «мине дә» кошы очмый калды...

Ләкин ни гаҗәп, әлеге «мине дә» сүзен ишек артындагы, ишек аръягындагы Заһидулла ап-ачык ишетә иде. «Начар кеше түгел син, Габдрахман. Сине бары система бозган,—дип уйланды.—Власть бозган сине, яңа власть...»

—Нишлибез?—дип сорады кинәт бөтен ярсуы эссе чәйгә салган бер шакмак шикәр кебек эрегән Сабит, тәмам пошаманга төшеп.—Бу бит, бу бит...

—Корткычлык!—дип бүлдерде аны Габдулла.

—Авызыңны тый, дим! Ипи шүрлегеңне җимерәм бит!

Котырып киткән Габдрахман уң кулы белән аның бугазыннан алды:

—Син, әнчек, олылар сөйләгәнне, кинәш-табыш итешкәнне тыныч кына тыңлап утыра аласыңмы, юкмы? Юк-са!

—Габдрахман абый!

—Габ-дырах...

—Габде...

Тимер кул-бармакларга эләккән карсак шундук буыла башлады.

Ишекнең тышкы ягындагы Заһидулла ачы гына көлемсерәде:

—Юк болар арасында чын бердәмлек. Юк...

Нәрсәдер дөбер-шатыр килде...

... Габдулланы урындыгы-ние белән очырган Габдрахман Ямашка текәлде:

—Йә, секлетар... Йә, нишлибез?

Ямаш такыр баш түбәсен кашыды:

—Пүләнкәгә... урганнарга хәбәр итәргә кирәк!

—Син,—диде аңа Габдрахман коры гына. —Син үзеңнең пеләшең белән киңәшмә, минем белән киңәш. Ул органнарның ничек урганын беләсеңме? Алар килсә, син дә юк, мин дә юк. Сәбит Сабит та, менә бу эт баласы да...

Ул егылган урыныннан торып, яңагын тота-тота, ишеккә юнәлгән Габдуллага күрсәтте.

—Әй, син, кая барасың?

—Кайтам... Өй-гә...

—Җыелыш әле бетмәде!

—Җыелыш бетмәде дип, үземне кыйнаттырып тормам ич инде...

—Хәзер үк кире борыл, анаңны эт яламаган нәмәрсә!

—Тагы суксаң...

—Кире борыл, дим!—Габдрахман күзләрен акайтты да шап итеп өстәлгә сукты.

... Тыштагы Заһидулла аларны чын күңелдән җәлләде:

—Юк болар арасында бердәмлек! Ул дуслыкны әйтәсе дә юк. Нинди иптәш, ди, болар бер-берсенә. Боларның барысын тотып торучы уртак дин юк. Коммунист-камсамуллыклары да ташкүлчим...

—Хәзер болай итәбез,—диде Габдрахман.—Бөек юлбашчыбызның рәсемен бергәләп җыеп алабыз, аннан пыяла ватыкларын түгеп, кире рамга куябыз. Юлбашчы өчен пыяла гына табылыр.

Моңарчы әле берсенең дә уена кермәгәнне әйтте күмхуҗ рәисе, чөнки көтүгә хас булган курку, Сталинның портреты стенадан ычкынып идәнгә төшеп челпәрәмә килүе, аларда сарыклар арасына килеп кергән бүредән туган халәтне барлыкка китергән иде. Бу курку Әбүгалисинаның бүре янына бәйләп куелган сарыгы халәте иде. Ул сарык та, берничә көн калтырап торгач, куркуыннан жан тәслим кылган.

Заһидулла Казанда шәкерт елларында бу турыда үзенең мөдәррисләреннән ишеттеме, әллә берәр китаптан укыдымы, инде хәзер аны хәтерләми, ләкин бүре янында торучы сарыклар халәтен, ватык Сталин портреты аркасында мәш килүче Габдрахман, Ямаш, Сабит, Габдуллаларны күргәч, (ә ул аларны ишек аша да күрә иде) тәмамысы да аңлады: әнә бүре—Сталин портреты, әнә сарыклар—Габдрахман, Ямаш, Сабит, Габдулла...

... Чылтыр-чылтыр китереп, пыяла ватыкларын җыеп алдылар. Агач рамны һәм кәгазь сурәтне өстәлгә салдылар.

—Нәрсә, рамы төзекме?—дип сорады үзе дә тәрәзә рамнары ясаучы, пыялачы һәм борыс утыртучы Сабит бик тә пошынып.

—Бер ягы чатнаган...

—Һәй-әй!—дип сөенде авыл советы рәисе.—Төзәтәбез аны, гүпчим төзәтәбез!

«Гүпчим» сүзе бер секундка гына Заһидулла хәтеренә Мәкчим сурәтен тыкты: «Нишләп ята микән анда минем керәшен? Чәпчим Мәкчим...»

—Ә рәсеме?—дип сорады шикле-шөбһәле Ямаш, тагын такыр башын кашып.

—Э-э-эх-хх!—дип ыңгырашты чын күңелдән, кинәт кенә Заһидулла өчен борчылып Габдрахман.—Нишләргә, ә?!

Сталин теткәләнмәсә дә, ертык иде...

—Ә келәйләсәк? Миндә бар ул,—диде Сабит нииндидер өметсез өмет белән.

—Мужныдыр...—дип куйды, икеләнүен яшермичә, Габдрахман.

Ямашның кул-тырмасы тагы такыр басуга керде:

—Лутчы...—диде ул уйлангалап, ләкин аны Габдулланың чәрелдек тавышы бер мизгелдә кисте. Җепне үткен кайчы кискән кебек кенә:

—Ертык Ысталин буламыни?

Барысы да акаеп ана каралдылар:

—Бумы? Бу! Бүре булмаса да—бүре баласы бу. Моның янындамы? Моның янында... Авызынны җиде йозак белән бикләмәсәң, беттен, үләргә әзерлән дә, кабер казытып куй...

—Ертык Ысталин булмый, ертык пәртрит була!—дип, ярсып куйды Сабит.

... Ишектән аркасын ала алмаган Заһидулла үз алдына уйлана бирде: «Шәп кеше син, Сабит абый. Менә сина рам ясап, борыс утыртып, тәрәзә пыяласы куеп кына яшәргә иде, ә син укымаган килеш башынны әллә кая алып барып тыктын...»

—Йә, ярый,—дип тынычландырды барысын Габдрахман.—Кич—кинәшкә шәп, иртә—эшкә!—дигән бабайлар. Бүгенгә җитәр...

Заһидулла аларны, болдырда чүгеп, озатып калды.

* * *

Җиһанда һәр нәрсә изге...

Агач яфрагын өзденме—бәгырендә авырту сизден. Юк, аны тән сизми, ә җан тоя. Менә шулчак Рух уты, җил искәч кыйшаеп киткән учак ялкыны кебек, үз алдына бәргәләнеп ала. Үз-үзен кыйнагандай итеп...

Урам буйлап кайтып барганда, Заһидулланың хәтеренә бөгәрләнеп кара елан кереп ятты. Теге урманда үтергән кара елан...

Нигә хәтереннән бер дә чыкмый ул? Кайвакыт төшләренә кереп газаплый... Үкенечнең уклары бу кадәр дә очлы вә, килеп кадалса, тартып алып булмас газаплы булыр икән!

Әллә ул елан берәр тылсым белән кешедән сөйрәлүчегә әйләнгән нәмәрсә булып, болай да үз язмышын каргап яшәп ятканда, мин бәндәгә очрап, ниндидер яшерен өметләр белән үзенә игелек көткәндә, шулай рәнҗетелеп вә кыйналып үтерелгән бер җанмы соң? Булмас димә! Тукай әнә ни ди бит: «Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул!»

Өенә ул авыр уйларда кайтып керде. Заһидәсе мич тирәсендә кайнаша иде, ана, күк капусы ачылгандай, илаһи бер якты нурларга йөзен тутырып карады да җәннәтнең җиденче катындагы кош булып сайрап китте:

—Заһидулла жаныем, менә син кайтуга эчәге бөккәне пешереп куйдым әле. Әйдә чишен. Кулларынны юып ал, комганда җылы су. Бәләкәчебез йоклый, әни тәсбих тарта... Ә бөккән... Син яраткан!

Ир-зат ана карап хәйран калды: «Юк, юк! Аның Заһидәсе түгел бу. Бу бит... Бумы? Бу бит—хур кызы... бу бит—фәрештә...»

Заһидә гаҗәби бер зәвык белән чибәр итеп киенгән иде. Майлап таралган кара дулкын чәчләре өстенә нәни генә җемелдәп торган калфак элгән. Муенында эре-эре гәрәбәләрдән тезелгән затлыбау, беләкләрендә көмеш беләзекләр, тыйнак зәңгәргә ак түгәрәкләр төшкән күлмәге түшендә зәбәрҗәтле ямьбиргеч. Ак алъяпкыч бавы аның нечкә билен йомшак кына урап тоткан. Билдән соң ымсындырып кинәеп киткән ир заты күзләрен кадаклавыч урыннар—бары да, бары да тантаналы, сихри, серле, хәйрани иде. Тартса да тарта, кадакласа да кадаклый икән Хатын-Кыз Гүзәллеге. Ир исемен күтәреп йөргән чирне...

Әйе, әйе!

Чирне!!

Чөнки хатынының шушы әфсенле балкышын күргән Заһидулла авырып китте. Кинәт кенә аны чир басты.

«Әнә бит ул! Кара: йөзләреннән нур тама... Каян алар? Күзләрендә

жәйге ажаган җемелдәве... Нигә тарта алар? Бала тудырганнан соң тулышып киткән тәне бары иң үткер күз генә тояр дәрт белән үзалдына биеп тора... Кая чакыра ул бию?»

Ниндидер исерткеч ләззәт Заһидулла өстендә аклы-зәңгәрле томан булып йөри иде. Ул кулын да ыхтыматлап юып бетермәде, кыргый көч белән килеп хатынын кочаклады да песи баласы урынына күтәреп алды. Шунда бер генә мизгелгә аның аңгырая башлаган аңында: «Йолдызларга чөяргә иде бу асылҗанны!»—дигән уй кабынды.

Сытылып-изелеп аның күкрәгенә, тәненә керә һәм йотыла башлаган Аяз мулла кызы ир колакларына кайнар итеп саташулы пышылдады:

—Аһ! Заһ!.. си...ни...эш...ли... сең?

—Яратам!!—диде ир, аны сәке өстенә өелгән мендәр-ястыклар дингезенә салып.

—Ял...-гыш-ма! Ән-ни... те-ге... як-та...

—Күрдем: йоклый инде ул...

—Юләрем! Әле бит алда озын төн бар...

—Миңа мең төн рәттән торса да, сине яратып бетерү өчен җитмәс иде,—диде ир, аны үбә-үбә, үзе дә шашыныр дәрәҗәгә җитеп.

—Утны сүндер!—диде хатын, аның колагына утлы пышылдап.

Заһидулла җиделе лампаны сүндереп килүгә, хатыны урынны җәйгән, үзе дә чишенеп йомшак юрган астына чумган иде инде. Ир заты, ак ыштанын салып,—Мәхәббәт Чатыры!—астына керүгә, аның Заһидәсенең җанына каяндыр мәзәк хисе кыенсынып кына төртелде дә ул елмаеп вә көлемсерәп иркә генә пышылдады:

—Ә бөккәннәр?

—Нинди бөккән??—диде тегесе аптырабрак...

—Э-чә-ге...

—Ә! Иң шәп бөккән монда...—диде Заһидулла, хатынының колак йомшагын тешләп.

—Чукынчык!

Ашыгычлык белән Заһидә алкаларын салмаган икән, хатын колакларына үрелде:

—Ничек онытканмын...

—Кирәкми,—диде ир аны туктатып.—Алар безгә комачауламый. Киресенчә, шәбрәк тә әле: алкалы туй!

Шулвакыт ике тәңгәл уй, ике бер буйга искән җил-хис, ике бер якка аккан дәрт-елга, ике иң куәтле теләк бер булып кушылды...

... Идән астында бака сайрап җибәрде. Мич куышлыгында кыш үткәрүче чикерткә «скрипкасын сызды»...

Түшәм ярыгыннан ком-балчык коелды.

... Заһидулланың күкрәгенә башын куеп яткан Заһидә әкрен генә дәште:

—Тагы ник чакырттылар инде кәнсәләргә?

—Күмхуҗга керергә көчлиләр...

—Әллә...

—Юк!

—Әнә әти дә...

—Нәрсә әти?—диде ир хатыны ягыннан «бабай» тиешле Аяз мулланы уйлап һәм аның өчен тәшвишкә төшеп.

—Күмхуҗга үзе кермәсә дә, атларын, таш пулатын, алтыпочмаклы өен бирде. Аның бит дирбиясе тирә-юньдә данлыклы иде. Казан, Малмыж, Алабуга байлары да көнләшеп китә иде аның тәнкәле йөгәннәреннән, бизәкле дугаларыннан. Ә ул тимерхутлары, кошевкалары... Их! Әле дә хыялымда яшь чагыма, дөресрәге, балачагыма кайтам мин, Заһидулла җаныем. Шул атларда җилдерүләр дисеңме... «Гөфтегүләр бар иде»...

—Аңлыйм, матурым... Дәрдмәнд тә юк инде...

Хатын терсәкләренә таянды:

—Болар сытачаклар сине, бәгырькәем!

—Мин бөҗәк түгел, кеше...

—Барыбер!! Аларга кеше ни дә, бөҗәк ни...

—Мин—кеше, аңла шуны!!!—ир азмы-күпме ярсып китте.—Агымга иярергә йомычка түгел һәм бу дөньяга йомышка гына килмәдем, теләгем—үземчә яшәргә. Бу—минем иң зур инсани хокукым... Ә алар... Ә алар мине дулкындагы күбек итмәкчеләр...

—Шул гынамы?—диде хатын сулкылдап.

—Юк...

—Тагы ни бар?

Заһидулла Заһидәгә ачылды:

—Дөрес юл түгел бу. Боларда исабәт юк. Болар бер сүз сөйлиләр, икенче эш эшлиләр...

... Төн уртасында бишектәге сабый кычкырып елап уянды...

* * *

Әиртәнге чәйгә...

Эчәге бөккәне кичәге иде...

Әмма аны Заһидулла да, Заһидә дә атна буе ач торган кешеләрдәй яратып-тәмләп, ашыгып-кабаланып ашадылар. Артларыннан гыйфрит куып киләмени! Бары өстәл янына әниләре килеп утыргач кына, ана да чәй ясаган, әле һаман да наз кочагыннан ычкынмаган килене бөккәнгә башка кул да сузмады, ә карчык, кичә үк бу тәгамне тәмләп-татып караган кеше буларак, аңа борылып та карамады. Йорт хуҗасы бөкте генә бөккәнне. Бер үзенә—бер табак!

Ашап-эчеп туйгач, Заһидә нарасыен имезергә дип, тулышып торган авыр күкрәкләрен ике учы белән каплап чыгып киткән иде (ул күкрәк имчәкләреннән сөт тама башлаган иде инде!) әнисе түрге шкафтан иске Коръән китабын алып килде дә ишек алдына маллар карарга дип юнәлгән улын туктатты:

—Заһидулла улым...

—Әү, әнәй...

—Бер генә кавымга тукта әле...

—Тыңлыйм...

Ул әнисе янына, өстәл кырыена килеп басты.

—Утыр әле яныма...

Ир агач урындыкка (әтисе ясаган!) чүмәште.

—Менә бит...—диде Ана ерактанрак башлап.—Мәрхүм атаң, минем ирем Гыйбадулла түшәккә авырып яткач, Коръән-кәрим эчендәге бу Җиденче бабабыз Җидәннең әйтеп-яздырып калдырган теге хикмәтле язуын Заһидуллага тапшырырсың, чөнки ул аңа нәкъ Җиденче бабай булып тора дигән иде... Менәтерә, хәтер бит... Онытыла язган... Кичә син кәнсәләргә киткәч, Коръән китабын ят күзләрдән читкәрәк... Хәзер бит үзең беләсең... Шул чит күзләрдән ераграк яшерим әле дисәм, шушы кәгазь төште. Җидән бабаңның хикмәтле язуы. Утыр, кара, укып чык, мин кагылмадым, гыйлемем дә юка... Кәг-газь синеке...

Карчык авыр гына кузгалды да, ак яулыгыннан бөртәеп торган аксыл чәчләрен төзәткәләгәннән соң, комганын алып тышка чыгып китте. Теге якта Заһидә, сабые белән уйный-уйный, аңа сөт имезә. Ә нарасый имә-имә, якланган булып, ими очын йә тешли, йә нәни авызыннан чыгарып ук ташлый. Әннәсе кычкыра:

—Абау, балакаем, авырттырасың ич! Тешләренең үткенлеген кара син, ә?!

—Йә, йә... Яклан әле тагы менә...

Ә сабые чырык-чырык килә.

Өйдә тыныч, өйгә мамыклы җылы эленгән. Йорт дигән бу патшалык акрын гына бер җайга яши бирә, Гыйбадулла картны югалту кайгысының

кара корымыннан иплəп кенə арына бара...

Гарəп хəрефлəре белəн язылган, инде саргаеп беткəн əлеге кəгазьне Заһидулла кулына алды һəм укый башлады:

«И, Угланнар!

Угланнарым балалары!!

Ерак Оньк-Оныкаларым!!!

Мин, Җирдə туксан алты ел яшəгəн Җидəн бабагыз, йолдызлы төндə Җидегəннəн, анын да Тимер Казык йолдызыннан җиде пышылдау ишеттем. Əлеге гыйбрəтле, серле, тылсымлы сүзлəрне килəчəк буыннарга калдырам.

*И, Угланнар!*
*Тыңлагыз, колак салыгыз бу сүзлəргə.*
*Алар Тимер Казык Йолдыздан пышылдау булып иңделəр...*

*Шимбə Көн Ишетелгəн Пышылдау.*
*Үз-үзеңне гомер буе үстер-тергез:*
*1) Тəнеңне үстер;*
*2) Хисеңне үстер;*
*3) Акылыңны үстер;*
*4) Аңыңны үстер;*
*5) Җаныңны үстер;*
*6) Рухыңны үстер;*
*7) Нурыңны үстер;*

*Якшəмбе Көн Ишетелгəн Пышылдау.*
*Һəр бəндəдə Җиде Кара Тишек була. Шуларны Ак Ташлар белəн капла.*
*Болар:*
*1) Үзеңне генə ярату;*
*2) Тəкəбберлек;*
*3) Алфикер;*
*4) Үч алу. Каргама! Җиденче каргышың үз башыңа;*
*5) Буйсындыру телəге; Зиналык омтылышы;*
*6) Үкенечлəр һəм тоташ ризасызлык белəн яшəү;*
*7) Үз ишлəреңне яисə башка җан иялəрен үтерү.*

*Дүшəмбе Көн Ишетелгəн Пышылдау.*
*Һəркемдə Җиде Ак Тишек бар. Аларны Кара Ташлар белəн капламa.*
*Болар:*
*1) Вəгъдəле булу;*
*2) Ялган сөйлəмəү;*
*3) Ярдəмгə əзер тору;*
*4) Байлыкка мөкиббəн китмəү;*
*5) Ата-анага хөрмəт;*
*6) Дөньядагы һəр нəрсəгə изге итеп карау;*
*7) Аллаһыга сыгыну. Иман, дин-дан.*

*Сишəмбе Көн Ишетелгəн Пышылдау.*
*Адəм балаларын Җирдə һəм Күктə җиде катлы Җиде көтə:*
*1) Җиделе гомер еллары (7+7+7.....)*
*2) Җиде Шатлык;*
*3) Җиде Кайгы;*
*4) Җиде буынның сихер-чире;*
*5) Җиде буынның тылсым-дəвасы;*
*6) Җиде катлы тəмугъ-җəһəннəм;*
*7) Җиде катлы оҗмах-җəннəт.*

*Чəршəмбе Көн Ишетелгəн Пышылдау.*
*Нилəрең бар һəм булыр, Кеше?*
*Менə болар:*

*1) Барам дисәң, җиде юл сиңа, берсен сайла...*
*2) Кайтам дисәң дә, җиде юл сиңа, берсен сайла...*
*3) Синең җиде дошманың булыр...*
*4) Җиде чын дустың бар...*
*5) Сине җиде тапкыр үлем котәр...*
*6) Җиде тапкыр савыгырсың, котылырсың...*
*7) Ташка да типмә! Җиденчесендә аягыңны сындырырсың...*

*Пәнҗешәмбе Көнне Ишетелгән Пышылдау.*
*Тыңла Инсан:*
*1) Сине җиде начарлык котә...*
*2) Җиде яхшылык эшлә дә суга сал...*
*3) Тәүлеккә җиде буялырсың...*
*4) Көн-төн эчендә җиде чистарын вә пакьлән...*
*5) Максатыңа алты омтылып та ирешмәсәң—өметсезләнмә! Җиденче ыргылу игелек китерер...*
*6) Синең колак артыңда җиде шайтан баласы утыра...*
*7) Синең белән һәрчак җиде фәрештә йөрер!*

*Җомга Көн Ишетелгән Пышылдау.*
*Кешеләрнең Гомер юлы җиде өлештән тора:*
*1) Туу...*
*2) Үсү...*
*3) Савап...*
*4) Гөнаһ...*
*5) Тәүбә...*
*6) Чистарыну...*
*7) Нур (Арыну...)*

Мин, Төркәр угылы Җидән, туксан алты яшемдә Үлем Түшәгенә яткач, әлеге Тылсым Сүзләр Онык-Оныкаларыма, Башка Инсаннарга да Ишетелсен дип, буларны яздырып калдырдым.

Онытмагыз: Сүз—Аллаһ ул...»

... Заһидулла тирләп чыкты...

Ул бер туңды, бер кайнарланды...

Әлеге кәгазь анның кулын пешерә иде, гүя ул утлы күмер...

Ир-затның акылы зәгыйфьләнде һәм...

Әйе, әйе!

Көтмәгәндә генә яктырып китте. Гүя өй эченә туп-тулы, яп-якты, зуп-зур Июль Кояшын Кемдер бер мизгелгә тыгып куйган иде.

... Комганын тотып әнисе өйгә керде. Комган да нурлар бөрки...

Алгы якта сабый: чырык-чырык. Һәр авазында—ни хикмәт!—нурлар!!

Заһидә рәхәтләнеп-инрәп-ләззәтләнеп көлә.

* * *

Шулвакыт...

Дөбер-шатыр китереп ишекне кактылар. Чырык-чырык килеп көлеп яткан сабый тавыш-тынсыз калды. Заһидә шик вә тәшвиш белән ишеккә төбәлде, әниләре дисбе тартудан туктады...

Заһидулла, Җидән бабасы Язуын өстәлдә калдырып, ишек ачарга дип кузгалды. Ләкин...

Ишек үзе ачылып китте һәм анда...

Әйе, әйе...

Анда ике милиционер белән камсамул Карсак Габдулла күренде.

—Әнә ул үзе!—диде Габдул, аңа төртеп күрсәтеп.—Великий вождь Ысталинның портретын ертучы...

Милиционерлар йорт хуҗасынын кулларыннан тотып алдылар.

—Селкенмә! Качарга да уйлама!!

Алгы яктан Зәһидә йөгереп чыкты:

—Зәһидулла жаныем! Дөрес сөйлиме бу Габдулла? Чыннан да ерттынмы Сталин портретын? Бу бит...

—Ерту түгел, уйлаганым да юк,—диде ир тыныч кына. Аннан, карсакка карап, сорап куйды:

—Кайда Габдрахман? Ямаш, Сабит абыйлар?

—Сине кәнсәләрдә көтәләр!—диде камсамул иреннәрен бөрештереп.

Милиционерлар тиз-тиз генә тентү оештырдылар. Сабый куркынып елый башлады, Гайнижамал карчык өнсез калды. Зәһидә кинәт кенә агарып куйды, бит уртасындагы кызыл алмасы да күгәреп китте. «Котсыз» исемле ата мәче, килеп кергән кешеләрдән коты чыгып, ярым ачык калган ишектән тышка сыпыртты.

... Урамга чыктылар...

Йортта сабый елап калды, яшь хатын сыгылып төште, карчык тәмам мингерәүләнде.

Кар төшә иде...

Юеш вә эре-эре ябалак кар...

Ул биткә, борын очларына, иреннәргә, ияккә кунып эри, шуңамы—Зәһидуллага бөтен йөзе тулысы белән елый кебек тоела. Шунын өстенә ул тагы тәнендә генә түгел, жанында да алагаем бер шомлы салкынлык тоеп, күнеле нечкәреп, үзен ниндидер апрель аенда түбә кыегында асылынып калган боз сөнгесе итеп сизеп, менә өзеләм, менә соңгы жеп кенә калды дип хәсрәтләнгән, сагышта йөзгән, кайгыга чумган мәхлук бер бәндәгә охшата башлады...

Югыйсә...

Әле кичә генә үзенең Зәһидәсе куенында ятканда, аннан сихри бер көч жанны күккә күтәрер дәрт-дәрман вә кайнарлык, рухын иң якты шәм итеп кабызыр очкын-нур алганда, үзен Алып Батыр, әкияти Жик Мәргән, Зәркүм, Салсал, Сәет-Батталлардай санап яткан иде. Хыялында гына булса да...

Менә хәзер кинәт кенә шундый тәшвишкә төшеп, әле кичә генә хакимлеккә менгән авылдашларын күпмедер дәрәжәдә мескеннәр дип санап йөргән Зәһидулла бер кавымга үзен дә бер гайрәтсез, тынчу бәндә санады. Нәрсә бу?.. Куркумы?

Әйе, бу курку иде...

Борынгы заманнардан анын жанына инстинкт булып салынган курку иде бу. Кем аны үзендә юк дип саный—ул—чын ялганчы, сүзенә хужа була алмаган бәндәчек яисә ахмак, аңгыра, томана, надан бериш, шулар өстенә мактанчык, шарлатан кеше булачак, чөнки Ходай да үзеннән «Курку»ны тели.

Кичтән чиратып, юеш кардан пычрана башлаган авыл урамы буйлап барганда, анын башына икеле-микеле төрле уйлар да килде, ләкин ул үзенең урманда бүрәнә ярыгына бармаклары кысылган Шүрәле икәнен ачык аңлый иде. Кем кысты мине? Былтыр—кем?

Кәнсәләрдә аны Габдрахман, Ямаш, Сабит каршы алдылар. Йөзләре төксе, күзләре нурсыз-имансыз иде. Шуна да карамастан, алар аңа туры карый алмадылар.

Өстәлдә—Сталиннын ертык рәсеме...

Милиционерлар кесәсендә Жидән исемле жиденче бабасынын Тимер Казык Йолдыздан Пышылдау булып Ишетелгән теге Сәер вә Тылсыми Сүзләр...

—Вот что нашли у него,—диде милиционерлар.—Это че? Против власти что ли?

Бу язуны алар өендә Карсак Габдул укый алмаган иде бит, тегеләр өчесе дә язуга ач этләрдәй ташландылар.

—Ну, ни...—диде аптырашлы Сабит.

—Вот шту...—дип өстәде Ямаш.

—Чепуха эта!—диюе белән Габдрахман барысын да хәл итте—Калдырыгыз бу кәгазьне мина, әбәт ашаганнан соң әбрәкәйгә алырмын мин аны...

Милиционерлар әлеге «комган язу»да бернинди «контра» булмаганын белгәч, ни сәбәптәндер, бу турыда озаклап сорап тормадылар, бары ыржаеп кыска гына көлеп алдылар. Аларның әле тагы кереп чыгасы авыллары бар иде, шуңа ашыктылар.

Ишектән чыкканда, монарчы шактый гына битарафлыкка чумган Заһидулла капылт кына сорап куйды:

—Кайсыгыз сатты мине?

Беркем дә дәшмәде, бары Габдрахман гына Габдуллага таба ымлап күрсәтте.

—Не тявкай, не таратори по-своему!—диде милиционерларның төссез су күзлесе.—Говори по-русски!

«Үз татарың саткач, синен русчаң миңа ни бирер?»—дип кенә уйланды Заһидулла. Ул әле яна гына малайлыктан чыккан Габдуллага карады:

—Жәллим мин сине, егет!—диде.—Йөз ел яшәсәң дә, кеше сатып яшәүдән кеше була алмассың, үләксә козгыны гомерен кичерерсең...

Аны төрткәләп алып чыгып киттеләр.

Кар инде явудан туктаган, тик зәңгәр күкне сәләмә болытлар баскан иде.

Милиционерларның берсе кәнсәләр болдырына бәйләп куелган атны китәр юлга борды. Атның алдында солы саламы, ә артында шул саламнан ясалган нәҗес иде. «Менә бит...—дип уйлады Заһидулла,— боларның үзләрен дә буклап китәләр, мине генә түгел... Йә, Алла!»

Заһидулла болдырда басып торган авылдашларына карамаска тырышты. Дөресен генә әйткәндә, ул алар өчен ояла иде...

Әйе, ояла иде. Шушы стенага жансыз портрет булып кунаклаган «великий вождь» Ысталинның рәсеме ертылуга анын бит бер кәррә дә катнашы булмыйча, ул әле алар өчен бер генә түгел, ничә кәррә оялачак иде: «Их, авылдашлар, авылдашлар... Нишләвегез бу? Иблискә сатылуыгызмы? Гомер ахырларыгыз житеп, тәнегезне чир зәхмәте ашый башлагач, жаныгыз ничә тапкыр үкенәчәк әле бу шапшак, оятсыз, миһербансыз, шайтани гамәлегезгә...»

Ул аларга туры карамаска тырышты. Кем ул Заһидулла бүген? Жинелүче...

Ә ул бит бер дә жинелергә яратмый торган үзсүзле, туры, үзенчә генә яшәргә омтылган Күк Астының инсани заты иде. Дөрес әйтте Заһидәсе:

—Изделәр, сыттылар аны...

Юк, тәнен түгел! Ә—Жанын. Менә иң авыры нәрсә. Әнә иң газаплысы да шул...

Ат кузгалып илле адым узуга, күз яшьләренә коенган Заһидә алар янына йөгереп килде дә иренә төенчек төртте...

* * *

Милиционерларның ат тотканы «старшой» иде булса кирәк, су күзлесенә бәбәген агартып:

—Проверяй, че там?—диде.

—Жратва, наверное...—дип куйды сирәк кенә сакал төрткән сипкеллесе, төенчекне ялкау гына Заһидулла кулыннан тартып алып.

—Во хорошо, с утра ничего не ел...

Алар тагы ялкау гына, кыска гына көлештеләр:

—Охо!—төенчектә теге эчәге бөккәннәре иде. Тагы бөтен ипи, бер гөрәнкә тирәсе сарык ите.

—Богато живет, кулак!—диде ат тотучысы дилбегәсен арба башына

чолгап һәм шыбырдата-шыбырдата борынын сеңгереп. Аннан ул маңкалы кулын чалбар балагына ышкыды да бөккәнгә сузылды.

—Не трогай, мать твою!!—дип акырды кинәт ярсып киткән Заһидулла төенчекне тартып алып.—Проверяли—бомбы нет, вот и успокойтесь.

Су күз дә, сипкелле дә катып калдылар. Ни могҗизадыр—ат та туктады. Ике урыс бер татарга текәлеп каттылар. Күзләрендә ифрат кызыксыну өстенә, нindiдер курку, шөбһәләнү дә бар.

—Хотите довезти меня и доехать спокойно, не прыгайте выше .

Бу сүзләр тегеләргә тагы да катырак тәэсир иттеләр:

—Откуда ты знаешь по-русски? Говоришь почти как русский?—дип сорады Су күз.

—В Казани в учительской школе учился. Да к тому, на гражданской воевал. Был одним из ординарцов комдива Азина. В штабе держали...

Заһидулла күрмәде түгел, күрде, әлеге милиционерларның карашы аңа бөтенләй кирегә, дөресе, әйбәт якка үзгәрде.

—Ә нигә Сталин портретын идәнгә бәрдең?—диде сипкелле, ирен читенә вак кына елмаю җыерчыклары чыгарып.

—Мин Сталин портретын идәнгә бәрмәдем, ә ишекне бик каты бәреп ябып чыгып киттем. Күрәсең, портрет начар эленгәндер, стеналар селкенгәч, ул идәнгә очкан.

—Да-а...—диде ат тотучысы аны җәлләп.—Син, братан, контра түгел икән... Ну, хәзер берни эшләп булмый. Теге малай төнлә үк килеп сине сатты бит...

—Тамагыгыз ачса, әйдә ризыкны бүлгәләп ашыйбыз...—дип куйды күңеле җебеп киткән Заһидулла. Ул русча сүгенүе өчен үкенә иде инде.

Алар, ике милиционер һәм кулга алынган бер адәм заты, сүзсез генә бөккән ашадылар, берәр сынык ипи белән ит кисәген дә капкаладылар. Дөресе: милиционерлар буйга артык озын булмаса да, төптән юан чыккан, үгездәй таза, имәндәй нык бу татарга хөрмәт белән карау өстенә, шөбһәләнү дә тойдылар. Ник дигәндә, әгәр алар аңа бәйләнсәләр, бигрәк тә йодрык белән ташлансалар, ул аларның икесенең дә измәләрен изәчәк иде. Азык-төлек төенчеген тотып барган кул бармаклары гына да урындык аягы юанлыгында иде аның. Ә киң җилкә, йомры инбашлар, үгез муен, таза-нык, юан бот-аяклар...

Заһидулла да алар янында үзен урман аюыдай көчле-гайрәтле итеп тойды.

Күрше авылда бер йолкыш адәмне кул-аякларын бәйләп арбага салгач, дилбегәче милиционер аңа:

—Кеше үтергән бу...—диде.

Ул кеше үтерүчегә ифрат бер җирәнү белән карады. Чыннан да, кеше үтерүче җирәнерлек хәлгә килгән иде: өс-башы пычрак, аннан нindiдер шакшы исләр килә, күз төпләре кыйнаудан чем каралган, иреннәре ярык һәм бүлткән, колак эченә кан укмашкан.

«Йә, Ходаем!—дип уйланды Заһидулла.—Аңлы-акыллы, Җанлы-Рухлы бәндәләреңне яхшыдан—шакшыга, чистадан—пычракка, әйбәттән—начарга, матурдан—ямьсезгә, шәп кешедән—вәхшигә, иманлыдан—имансызга, денледән—денсезгә, инсаннан—хайванга әйләндерер өчен җибәрдеңмени Җир йөзенә?»

Ул шулай бер-берсенә каршы мәгънәле сүзләрне—антонимнарны—тезә-тезә озаклап уйланды: «Менә бу кеше кайчандыр якты дөньяга туган, кемнеңдер бик тә кадерле бер баласы булгандыр. Әнисе аңа күкрәк-ими сөтләрен имезгән, иң тәмлесен авызыннан өзеп биргән. Үсәр, кеше булыр, картаймыш көнемдә мине карар, дигәндер. Ә ул? Кеше кадәр кешене бит... Кеше гомеренә кул сузу—иң зур язык, гөнаһларның да гөнаһысы. Кешенең җанын алу Аллаһы кодрәтендә генә. Нигә Хак Тәгалә гамәленә тыкшынырга ди? Кем яисә Нәрсә аңа мондый хокук биргән? Бармы андый Олуг Хокук? Әллә Тәңренең: «Яхшылык кылсагыз да—үзегезгә, явызлык эшләсәгез дә—үзегезгә»,—

дигән тирән мәгънәле сүзләрендә ятамы ул хокук? Әллә Адәм белән Хаванын уллары Һабил белән Хаинның үтерешеннән соң (Хаин Һабилне көнләшү—хөсетлелектән үтерә) кешелек дөньясы корбаннар аша, һәлак итүләр белән барырга тиешме?..»

Икенче бер минутта ул үтерүчене җәлләп, ана кызганып карый иде инде.

—Синең ашыйсың киләме?—дип сорады ул аңардан.

Теге ризалыгын белдереп күзләрен йомгалады, кипшергән-бүлткән, канлы иреннәр көч-хәл белән бер-ике аваз гына чыгара алды:

—Дд-аа...

Заһидулла дәү кулын төенчегенә тыгып аннан ипи һәм ит кисәге алды. Ипине сындырганда кат-кат бисмилласын әйтте:

—Бисмиллаһи... Ходаем... Ул да синең колың... Аның да жаны бар...

Үтерүче каткан бармаклы пычрак куллары белән ризыкка үрелде һәм, аларны еш-еш авызына китереп, комсызланып ашый башлады. Ипи валчыклары арба төбенә коелды, аларына ул игътибар да итмәде, шуна, аларны җыеп алып, Заһидулла бишмәт кесәсенә салды.

Икенче бер мизгелдә үтерүче ризыгын кабып йоткан иде инде. Ул бер сүз әйтмәде, чөнки...

Үтерүче елый иде...

Яшькелт күзләренә эре-эре яшьләр тутырып елый иде. Ул күз яшьләре тып итәләр дә арба төбенә, солы бөртекләрен чылата-чылата, тамалар...

Милиционерлар эчтән икесе дә сак булсалар да, тыштан гадәти бер битарафлык күрсәтеп, ялкау гына сөйләшеп баралар. Тук-таза, арт сырты бер туры батынкылык белән икегә бүленгән ат тыныч кына атлавын дәвам итә. Бары вакыт-вакыт гаярь генә пошкырып кую гына әле дүрт жан янында бишенче жан иясе дә барлыгын искә төшерә.

Икенче карауга үтерүче йокыга киткән сымак тып-тыныч, бер дә селкенмичә диярлек ята иде.

Пуләнкә тавын төшкәндә ярсу бахбай чүт кенә чыгымлап чабып китмәде, арттан аны арба нык кына этә иде. Ярый әле милиционерлар бер тәгәрмәчкә күсәк кыстырдылар.

* * *

Әаңарчы...

Ике милиционер аларны тиешле урынга алып килеп япкач, күп тә үтмәде, сорау алырга чакырдылар. Иң беренче Заһидулланы...

Тар вә тынчу, яктылык ышкылып-сытылып кына кергән ярым караңгы коридор буйлап бардылар да икенче катка күтәрелделәр. Тикшерүче утырган бүлмә дә бер дә хәйран калырлык түгел иде: тимерчыбык белән бикләнгән сыңар тәрәзә, хан заманыннан калган өстәл белән ике урындык, ә пәрәвезле караңгы почмакка кара шкаф сенгән.

Усал күзле, Сталин мыеклы тикшерүче ничектер көрән йөзле иде. Бәлки моны бүлмәгә яктылык житмәү белән аңлатып булыр да, ләкин әлеге адәм Заһидуллага көрән аю сыман тоелды: йонлач юан куллар, кәкре кыска аяк, мыслап-юешләнеп сулыш ала торган озынча борын.

Ул нигәдер бертуктаусыз йөренде, сорауларны аңа әле уң яктан килеп, әле сул яктан якынаеп, әле арттан торып бирде. Шулай шактый йөренгәч, шкафны ачып, икегә аерылган Сталин портретын аның алдына салды да, беренче тапкыр аның каршындагы, өстәлнең тәрәзә ягындагы урындыкка утырып, сөаль ташлады:

—Ник ерттың моны?!

Әйе, шулай, «великий вождь», фәлән-фәсмәтән диеп тормады, гапгади генә «моны» диде. Гүя сүз тәмәке төрә торган кәгазь турында бара.

Гүяки дөньяда бернинди Сталин да юк, бары бер көрән аюга охшаган усал күзле, үзе дә көрән йөзле кешенең бик ныклап тәмәке тартасы килгән дә, аның тәмәке төрә торган кәгазен нииндидер малай-шалай шаярып ертып ташлаган.

—Мин ертмадым,—диде Заһидулла тыныч кына. Ул бу минутларда Ходайдан үзенә сабырлык сорый иде:

«Йарабби Тәнрем, сабырлыклар бир, мин колыңны бу көрән аю авызына китереп салма...»

—Алайса, кем ертты?

Тикшерүче бу соравын елмаеп ук бирде, әйтерсең лә, берни булмаган, әтисе улын шук эше өчен генә орыша.

—Стенадан Сталин үзе төшеп китте...

Ялгышты Заһидулла, Габдрахманнарны да буямыйм дип, үзен пычратты:

Стенадан Сталин җәяүләп үзе төшеп китәр микән? Ай-һай!..

—Ничек инде?..—дип аптырашта калган булды теге хәйләкәр. Ул хәзер аюдан төлкегә әйләнеп бара иде.

—Шулай менә...

—Ә ничек шулай?

—Мин ишекне каты ябып чыгып киттем дә...

—Шуннан?

—Стенадагы Сталин төшеп китте.

—Хх...—дип уйланган булды тикшерүче.—Ә нигә син ишекне каты ябып чыгып киттең? Сталин кадәр Сталин төшәрлек итеп...

—Алар мине колхозга керергә көчләделәр...

—Ә син?

—Минем керәсем килми!

—Ник?

—Чөнки Вятканың аръягында урманда йорт салып, аерым яшисем килә...

—Монысы ни сәбәптән инде?—тикшерүче мыскыллы гына итеп елмайды.

—Теләгем шундый...

—Урманда йорт салырга агачны сиңа кем бирде?

—Хәзер бит илдәге бар байлык халыкныкы, ә мин—халыкның бер вәкиле...

—Хо, вәкил!—усал күздә очкыннар чатнады.

—Ә нигә?—дип бәхәскә кереп киткәнен үзе дә сизми калды Заһидулла.—Халыкның вәкиле булмыйча, Идел буе балыклары вәкиле түгелдер ич инде мин? Йәисә маймыллар төркеменнән дә бер вәкил түгел!

—Халыкка каршы кеше син!!—дип бүлдерде аны тикшерүче, мыек чалгыйларын теше белән ашап.—Шуның өстенә советка да каршы кеше!

—Мин гражданнар сугышында кызылләрмис...

—Узган эшкә салават! Кичәге белән түгел, бүгенге белән яши акыллы кеше...

Бер минутлык тынлык туды...

Мизгелләр күз иярмәс тизлек белән Мәгърур вә Серле, Олуг вә Кодрәтле Вакытның нәни-җилгер атларында чаптылар да чаптылар...

Шул секундларда Заһидулла кинәт кенә үзенең әлеге адәмнән ерагайганнан ерагая баруын тойды. Юк, тән белән түгел, ә җан белән. Күңеле, калебе, рухы белән... Ишек артындагы дежур милиционерны тикшерүче чакыргач кына айнып китте Заһидулла. Үзен шул тар вә тынчу коридордан «эт оясы»на алып барганда гына төшенде ул:

—Аңа хөкем чыгарылган!

Нинди хөкем? Алга таба нишләтәчәкләр аны? Төрмәдә черетәчәкләрме? Әллә бөтенләй үк атачакалармы?

Шушы уйлар белән сасы камерага кайтып егылганда, үтерүчене

сорау алырга бәргәләп алып чыгып киттеләр:

—Допроска!

Имгәтелгән тәнендә чыгар-чыкмас кына жаны калган әлеге мәхлук ишеккә таба атлар алдыннан ана карап ифрат та бер монсулык, тирән сагыш, кырып та төшереп булмас корымдай кара кайгы белән бераз күлемсерәп караган иде, ирнең йөрәге, алмагачтан өзелгән черек каракөрән алмадай, күкрәгеннән аерылып баз-чокырга очты. Аяк табаннарында үтә бер зәмһәрир суыклык, жан өшеткеч салкынлык сизде Заһидулла.

—И, Илаһым...

Әлеге ачыргаланулы аваз, күкләргә кадәр күтәрелгән ризасызлык-үкенеч ораны аның тәнендәге һәр күзәнәгеннән ашап чыкты, аны йота алмаган сурәттә дә, бәгырьләренә төште, бәдәненә Жидән бабасы язып калдырган Олы кара тишек ясалгандай булды. Ул хәлсезләнеп идәнгә утырды, ләкин урын алган жиренең юешлеген, череклеген сизмәде дә кебек...

Берәр сәгатьтән үтерүчене алып кереп идәнгә аттылар. Ни могжиза, нинди серләр?—ул ыңгырашмады да.

Кич житте...

Караңгы камерага карангылык төшә микән? Тәрәзәсез дөньяга кояш нуры үтми ич...

Әнә Жирнең Зәңгәр Тәрәзәсе—Күге бар. Шул тәрәзә үтәли Кояш аңа яктылыгын сибә, ә ул нурлар—бинийая! Шул Тәрәзә аша Галәмнән аңа Яшәү Көче иңә. Шул тәрәзә аркылы Кодрәтленең Иң Изге Пышылдаулары ишетелә...

... Төн уртасында Үтерүче күзен ачты. Караңгыда күз йомып яисә ачып ятканны кем күрә ала? Беркем дә! Ләкин Заһидулла күрде. Күңел Күзе белән...

—Хәлең ничек?—дип дәште ул аңа.

—Хәлчә... О-зак-ла-мый...

—Сине кыйнадылармы?

—Би-ик... ка-ты...

—Үтергән өченме?

—Юк... Өлкән тикшерүченең абыйсын үтердем мин. Ул бездә коммун-колхуз оештырды. Минем ата-бабамның бар мөлкәтен тартып алды. Шуның өстенә әнием белән уналты яшьлек сеңелемне көчләде... Ү-ү-үч!!!

—Сиңа ничә яшь соң?—дип сорады Заһидулла.

—Егерме... Үч алдым мин... Медведевтан...

Йә, Алла! Ул аңа кырыкны биргән иде бит... «Юк, бу үтерүче түгел, ул—Үч Алучы»,—дип уйлады Заһидулла. Теге «Көрән аю»ның фамилиясе Медведев икән... Үтерүче... юк! «Үч алучы» аның кулында жан бирде. Ул аңа «Ясин» чыкты... Шулчак...

Шулчак Жидән бабасының Күк Пышылдаган сүзләрен ишетте:

—Алфикер—тәндәге кара тишек...

* * *

Икенче көнне «үч алучы»ны—егерме яшьлек гөнаһсыз егетнең гәүдәсен «эт оясы»ннан алып чыгып китүгә, аны тагы сорау алырга чакырдылар.

«Көрән аю» кай ягы беләндер юашланган кебек тоела. Һәрхәлдә, Заһидулланың үткен күзләре, сизгер жаны аның йөзендә, бигрәк тә торыш-кыяфәтләрендә, гәүдә тотышында кичәге гайрәтне, мин-минлекне, бигрәк тә тәкәбберлекне таба алмады. Шингәнме аю? Әллә аңа да Күкләрдән Кисәтү-Пышылдау Ингәнме?.. Болары тоткынга караңгы төн белән бер иде, бу сорауларга жавап эзләү өчен төн кошы ябалак булырга кирәктер...

—Менә нәрсә,—диде аңа тикшерүче.—Сорауга җавапларың буенча, син бернинди дә советка каршы кеше түгел кебек күренәсең... Ерткансың, төшергәнсеңме бөек Сталинның портретын, син аны явыз нияттән эшләмәгәнсең...

Менә шулай...

Әле кичә генә аны, көне буе булмаса да «ярты кояш юлы»—кояшның алты сәгатьләп яктыртуы!—буе сөйләткән Медведев бүген үзе, алай ук озак түгел билгеле—аңаниләрдер турында тоташтан такылдады.

Бары бүлмәсеннән озатканда гына янды Заһидулла.

—Син,—диде тикшерүче Медведев.—Оказывается, син—политический түгел...

—Ә теге егерме яшьлек гөнаһсыз егет...—дип куйды тоткын серхак эзләгән фәйләсуф кыяфәте белән.—Ул политический идеме? Аны шуңа... кыйнап үтердегезме?

Чабатаңны ташлап качасы гына югыйсә. Юк шул! Шайтан телдән тартты...

—Ул—үтерүче...—диде тикшерүче.

—Ул—«үч алучы»...—дип каршы төште тоткын.

—Карале!—дип гаҗәпләнде Медведев.

—Дөрес түгелмени?!

—Менә дөреслекне югарыдарак эзләрсең инде!

Һәм аны...

Әйе, аны Малмыжга озаттылар.

«Сталин рәсемен стенадан алып идәнгә бәргән контра»ны... «Халык һәм совет хөкүмәте дошманы»н...

... Бу юллардан ул әле малай чакта әтисе белән Чепья базарына берничә тапкыр барган иде инде...

Менә мари-чирмеш, ар-удмурт авыллары. Әнә тирә-юньдә билгеле татар авылы Мәчкәрә! Аның данлыклы мәдрәсәләре, алардагы олуг белемле имамнар турында бөек дин белгече, тарихчы вә фәйләсуф Шиһап Мәрҗани дә язып калдырган...

Менә сул якка кереп китсәң—керәшен Чәпчим Мәкчимнең туган авылы Носла. Ә-нә! Зур мәчетле авылга—Смәилгә!—кереп киләбез бугай инде. Ә аннан ары Малмыжга да ерак калмый. Юлы да түбән табарак. Атларга да җиңелрәк. Бер үр алдырасы да...

Әйе шул! Малмыжга кадәрге алтмыш чакрым юлны ул, атка утырып барудан бигрәк, атлап барды. Бу юлы аты да бетәшкән иде, милиционерлары да чучка кебек таза булу өстенә, мәрхәмәтсез бәндәләр булып чыктылар...

... Дөньяны чагыштырулар аша таныйсың. Явызлык янында начарлык чүп кенә, теләктәшлек кырында чын иптәшлек—үзе игелек вә изгелек...

Пычрак юлдан котсыз уйлар атлап барган Заһидулла чучка милиционерларны теге туган авылыннан алып киткән Сукүз һәм Сипкелле белән чагыштырып, соңгыларын фәрештәләргә тиңли башлады. Тик шулай да, бабайлар әйтмешли, булганы булган инде, берни хәл кылыр мөмкинлек юк, бәлкем ерак Җидән бабам язып калдырганча, мин үзем, җиде юл чатында торганда, михнәтләр сукмагын сайлап алганмындыр. Заһидулла әнә шулай да уйланды...

... Малмыжга алар иртүк чыгып киткәннәр иде, анда-монда туктала торгач, төнлә генә килеп җиттеләр. Дөрес, аңа таба борылып, йөз боргач—милиционерлар атларга әз генә дә җегәре калмаган «контра»ны арбага утырттылар. Чөнки ул исерек кеше кебек як-якка ук чайкала башлаган иде.

Малмыж турында инде күптән ишеткәне булса да, соңыннан шаярып: «Париж, Малмыж, Мамадыш—великие города, товарищ»,—дип ычкындыргаласалар да, әлеге кала дигәне гади генә бер сала булып чыкты. Бары алар килеп туктаган урта бер җирдә генә байлардан калган ике-өч катлы таш йортлар кукраеп утыралар иде. Кыланчыкланулары да аңлашыла,

алардан кала тирә-юньдә сәләмә киемле берән-сәрән кешеләр дә кәкрәйгән-бөкрәйгән вә жиргә сеңгән ярым жимерек, ярым черек агач йортлар. Өй дисән—хәтерләре калыр! Заһидулланың Нократ аръягындагы «куыш»ы—болар янында колынчак янындагы яшь айгыр кебек... Шуңа да карамастан, бу шәһәр аңа кай ягы беләндер гажәп тә бер жылылык белән тәэсир итте. Аның нечкә жаны тойды моны. Ләкин, ләкин... Болай гына аңлату да дөреслеккә хилафлык булыр иде, чөнки әлеге жылылыкны ул чып-чынлап, аермачык итеп тәне белән дә сизде-сиземләде. Яктыны якты итеп күргән, баллыны баллы итеп тәмләгән, рәхәт сүзне рәхәтләнеп ишеткән, су жылысына тәне белән ләззәтләнгән кебек...

Малмыж урамнарына керүгә үк, аның үтерелгән өмете Әкияти Көлкош кебек баш калкытты. Яңып көлгә әйләнгән һәм—шул көлдән кабат туган Кош!!

Тәнендәге оешкан каны, шул өмет тууга ук, Мәкчимнең шайтан суы, Тамараның кайнар учак-гәүдәсеннән соң барлыкка килгән ут елгасына әйләнде. Тамара урынына ул монда Гүзәл Заһидәсен дә күз алдына китерергә тырышты, әмма мулла кызы түшәктә артык тыйнак, аңа күп кирәкми, ул булганга риза, артыгы белән разый, аз гына азгынлана башласаң, чамадан тыш ояла, аның колагына ярсып-ярсып: «Мыскыл итмә мине!»—дип пышылдый иде. Инде Тамарага килгәндә, ул бит ниләр генә кыланмады...

Бәндәләрне һәрвакыт тыелган нәрсә кызыктыра, бу бит Оҗмахта Баш Атабыз Адәм белән Баш Анабыз Хавадан башланган, алар да Тыелган Алманы татып караганнар.

Ах! Каһәрле фәрештә, Иблис-Котыртучы...

Ах, Син, Тыелган Алма! Кем үстергән Сине?

Ник котыртасың Кешеләрне? Шулай тиешкәме?

Шуның аркасында күпме алдаулар, хыянәтләр, үч алулар, үтерешләр. Шул сәбәпле күпме ялгышлар, Төзексезлекләр, хөсетлелекләр. Шуңа нисбәтле Кешелек Гөнаһ Сазлыгына кереп баткан. Моннан 2000 ел элек. Дөньяга Гайса пәйгамбәр аваз салганнан бирле. Ул да бит «Тыелган Алма» янынннан тыныч кына узып китә алмаган, үзен тәкәбберлек белән:

—Мин—Алла Улы!—дип атады.

Ну, «Тыелган Алма»! Ниләр генә әйттермисен, ә?!

Йә, әйт инде:

—Алланың Улы буламыни? Аллаһы бар галәмдә «Ялгызак» ул. Аның улы да юк, хатыны да... Аллаһы Бар һәм Бер.

Бу хатаны төзәтү өчен, күрәсең, Тәүбәгә килеп Инсаниятка тагы 2000 ел Чистарыну узарга кирәк. Үлгәндә, Мөхәммәт пәйгамбәр 2000 елдан соң Кешелек 2000 ел Чистарыну узарга тиеш дип, ике бармагын күрсәтеп, шуңа ИШАРӘЛӘГӘН...

Әнә шулай да уйланды зинданда яткан Заһидулла...

* * *

Тән хәрәкәте белән Жан хәрәкәте Инсани затларда күп вакытта туры килми...

Заһидулла күңеле белән Нократ аръягында утыра, ә гәүдә-бәдәнен Малмыж төрмәсенә утырттылар. Юк, әллә кайдан күктән төшкән Явызжаннар түгел, ә аның кебек үк кешеләр яптылар аны кара зинданга. Ә ул аларга нинди начарлык эшләде соң? Юлларына аркылы төштеме?? Адәм балалары йөзен чытып, разый булмас берәр гөнаһлы-әшәке гамәл кылдымы?

—Юк һәм юк!

Бәлки Тамара белән сөешү юньсез эштер? Ләкин ул бит аны көчләмәде, киресенчә урманда очраган хатын заты үзе жаны-тәне белән шуны теләде...

Милиция бүлегенең кара подвалына ташланган Заһидулланың башын гүя идән буйлап чабышып йөргән күселәр кимерде. Менә алар йөгерешә башлыйлар, шул арада әвәрә килеп, бәргәләшеп-тешләшеп тә алалар. Үзләре тагы бер-берсенә рәнҗешеп, чинашырга да өлгерәләр. Нәкъ кешеләр кебек...

Заһидулланың башындагы уйлар өере дә шул күселәр кебек тешләшә һәм чинаша. Ул аларны күреп һәм ишетеп тора:

—Нигә Адәм балалары яшәгәндә бер-берсенә комачаулыйлар, үзара тапалашалар, тарткалашалар, зыян салышалар? (Ишетте).

—Әнә Хаин Һабилне—үз туганын?—үтереп ята... (Күрде). Бары да шуннан башланган...

—Нигә бәндәләр үзләрен башкалардан өстен куярга телиләр, минминлек, тәкәбберлеккә биреләләр? (Ишетте).

—Әнә Понтий Пилат шул тәкәбберлеге өчен Пәйгамбәр кадәр Пәйгамбәрне (!!!) аркылы сугылган баганага кадаклата (Күрде). Тәкәбберлек шул чордандыр...

—Кешелек өстенә җыелган пычрак-гөнаһларны океан сулары да юып бетерә алмас кебек... Инде нишләргә? (Ишетте).

—Иң беренче Тәүбәгә килергә. Мәчетләр салынсын, чиркәүләр төзекләндерелсен, храмнарга халык агылсын... (Күрде).

—Алда безне Нинди Юл көтә? (Ишетте).

—Чистарыну һәм Нур... (Күрде).

... Әнә шулай ярым сулу, ярым саташкан хәлдә уйланып ятты ул нәҗесле һәм сидекле камерада...

Хәер, бирәсе сорауларын биреп бетереп, мыскыл итәсен мыскыл итеп, бер бик кызып китеп, сорау алучы тикшерүчегә ташлангач, карцерга алып кереп, албасты кадәр өч милиционер, кулын-аягын бәйләп, үзләре арганчы дөмбәсләгәч, аны тынычрак, яктырак, иркенрәк зиндан бүлмәсенә яптылар. Килеп керсә...

Килеп кенә кергән иде...

Түбәтәйле, кечкенә генә түгәрәк сакаллы җитмеш яшьләрдәге бер карт елапмы-елап утыра. Заһидулланың үз хәле дә хәл иде, кеше кайгысы түгел, шулай да олы кешенең яшьләренә түзә алмыйча, миһербаны килеп аңа эндәште:

—Бабай, ник елыйсың? Кемнәр тиде? Төрмә җәлладларымы?

Карт аңа йөзен борды һәм нурлы күзләре белән карап шундук сөйләп китте:

—Малмыж мулласы мин... Аллаһы Тәгалә вә Сөбеханәкәнең ни каргышыдыр... Языкларым булгандыр инде... Гөнаһтан тыела алмаганымдыр... Яла ягып, дошманнар, мине күрәлмаучылар үземне, йә, Ходаем, менә ошбу зинданга яптылар, «ләгънәт төшкереләре» дип каргап, башыма язык аласым килми, рәхмәт төшкереләре! Бер сүз әйтмәдем, Ләүхел-мәхфүздә шулай язылгандыр, күрәсем бардыр дип, мунысына да ризалаштым... Хагы—күрәсен күрми, гүргә кереп булмый дип, язмышыма буйсындырдым... Әмма да ликин... Утырган зиндан бүлмәсенә беркөнне Пуләнкә ягыннан өч явыз урысны утырттылар... Зобанилар инде менә, чатнап торган явыз, чын шайтаннар...

Берөзлексез сөйли башлаган картка карап, Заһидулла аны бүлдерде:

—Туктале, бабай! Мин үзем дә Пуләнкә ягыннан бит. Пуләнкәдән булгач, мин дә, бәлкем, явыздыр. Нигә кинәт кенә, әйтәсем килмәсә дә әйтим, миңа ачылып ташладың әле син? Мин татар булгангамы?!

—Иштең ишәк чумарын!—диде Малмыж мулласы көлемсерәп.—Милләтенә килеп, милли яктан аныклый башласаң, аның татары ни дә, урысы ни... Һәркаюсы кешеләр ич алар, Адәм—Хава токымына тоташкан бәндәләр...

—Соң?

—Син—мөселман бит! Ишектән кергәч үк йөзеннән Ислам Нуры чәчелде... Шуна, Күк Капусы ачылгандай, йөрәгемне чиштем мин сиңа, балакай...

—Рәхмәт!—диде соңгы вакытта йомшак сүзгә, тәмле телгә, кырык көнлек юл үтеп суга тилмергән мосафирдай сусаган Заһидулла аның янына чүгеп.

—Утыр әле...—диде карт боермый гына.

Заһидулла аның янына иркенләп үк чүмәште.

Малмыж мулласы, почмактан әллә нинди матур гына сумка-ридикуль сымак нәрсә алып, аннан ак тастымалга төрелгән нәмәрсәне сәке-нарга куйды да тагы сөйләнә башлады:

—Әйдәле, балакай, теге җәлладлар кайтканчы, хәләл ризыгыма хәрәм кулларын тыкканчы, абыстаем, оҗмах кошым җибәргән шушы вак бәлешләрне авыз итеп, Ходай Тәгаләнен биргәненә шөкрана кылып, тамак ялгыйк. —Шулай диде дә Малмыж мулласы муенына ап-ак салфетка элде, ак тастымалга кулын ыхтыматлап сөртте һәм:

—Бисмиллаһир-рахманир-рахим! Ходаем, ризыгыңны юллаган өчен—мең әлхәмде, исемеңне туксан тугыз тапкыр искә төшерү һәм ун дога, биш вакыт намаз,—диеп, бер авыз суын корытып торган бәлешне кулына алды. Икенчесен—Заһидулла... Тамак ялгап алгач, дога кылдылар, икесе дә кычкырып ук булмаса да, пышылдап:

—Аллаһу әкбәр! Биргәнеңә мең шөкер, алгы көннәребездә дә ризыгыңнан калдырма...—диеп, ризалык, олуглау белдерделәр.

Шуннан соң Малмыж мулласы тастымалдагы һәр азык бөртеген җыештырып, кире сумкасына салды һәм Заһидуллага карап:

—Ипинен валчыгын төшерү дә—зур язык. Болары—кошларга...—диде.

—Тавыкларгамы?—дип сорады Заһидулла, төшенмирәк калган иде.

—Хе-хе-хе!—дип матур гына кеткелдәде мулла.—Урман-кыр тавыкларына...

—Чыпчык-песнәкләргә...—аңа ияреп Заһидулла да көлде.

... Төбе тишелгән бинаһая галәмәт бер диңгезгә батучы корабтай, караңгы төшә башлады. Шунда Малмыж мулласы да борчыла-борсалана, читлектәге бүре кебек бәргәләнә башлады.

—Мулла абзый, борчуыгыз нидә?

—Ай, Алла! Ай, Алла! Икенде намазымны да юньләп укый алмадым. Хәзер бит ахшам намазы вакыты җитә. Тагы урынына җиткереп укый алмыйм инде...

Мулла кычкырып елап җибәрде.

Заһидулла сак кына аның җилкәсенә кагылды:

—Сәбәп нидә?

—Әнә бит!—карт караңгы почмакка төртеп күрсәтте.

Сискәнеп китте узаман ир. Хәтта үз күзләренә үзе ышанмады. Үткер аучы күзләрен бер йомып, бер ачып карады. Юк, дөрес икән, дөрес...

Караңгы почмакта бик матур, затлы, чиста түбәтәйне әйләндереп салганнар да эченә сыерныкы кадәр итеп кәк иткәннәр. Әнә шуннан килеп тора икән ул һәрдаим тизәк-нәҗес исе...

Мулла зар елады:

—Минем намаз түбәтәемнән алар шулай көлделәр. Иманымны мыскыл итәргә теләделәр... Башымдагысын мин өй арасында, кешелеккә кия идем. Көнкүреш түбәтәе ул. Тегесе—Иман—диннеке...

Шулвакыт шылтырап ишек ачылды:

—Мелла, дапруска!!

* * *

Өйдә чебен бар икән—димәк, син ялгыз түгел...

Ә монда!—Әх-мә-дул-ла... Ах!..

Бәгырькәем, атын җигеп Малмыжга килеп җиткән бит. Ни сөенеч аның белән очрашуы...

—Ме-нә...—диде ул аңа хас булганча сузып кына.—Аныкы...—һәм

Заһидәсе тутырып җибәргән, ашъяулыкка төреп салган, зур гына төенчекне аңа сузды. Аннан, аларны күрештерүгә алып чыккан милиционерга шүрләмичә генә кырынрак карады да:

—Мо-ны-сы... кһм... безз-здән...—диде һәм тастымалга төрелгән бөтен ипине сузды.

—Ничек анда безнекеләр?—дип сорады Заһидулла, азык төенчекләренә карамый гына.

—Әйбәт!—диде Әхмәдулла...

Аннан уйга баткандай торды да:

—Ярыйсы...—дип өстәде.

«Ярыйсы» Заһидулланың йөрәк ярасына бер уч тоз салды. Ул сизенденидер бар...

—Гайнижамал тәтәне...—диде Әхмәдулла, никтер тәрәзәгә каткан чебеннәргә карап...—Гыйбадулла җизни үз янына алып китте...

Әйе, әйе!

Нәкъ шулай диде:

—Гайнижамал тәтәне Гыйбадулла җизни үз янына алып китте, диде...

Ишетеп торды Заһидулла, эчендәгеме, җанындагымы бер бик нык, бик кадерле, моңарчы аның кайсыдыр авыр-борчулы-газаплы урынын күтәреп-тотып торучы Изге Җан шыртлап вә зынлап өзелде. Шуңамышундук колагы ишетмәс, аңа ияреп, күзе күрмәс булды. Ул хәтта телсез дә калган иде. Аның кинәт күңеле тулып, күзләреннән ташу акты. Бер-бер артлы югалтулар, үзен рәнҗетүләре, нахак гаеп тагып зинданга ябулары, китәр алдыннан гына юк кына сәбәп аркасында Заһидәсе белән сүзгә керүе, өзелеп-өзелеп нәни улы Галимулланы сагынуы бер кара төен булып бәгыренә утырды да үзеннән кара суык тарата башлады.

—Үл-ләм!—диде сыгылып төшеп.

—Үл-ми-сең!—дип кисте аны Әхмәдулла.

—Нә-ә-ә-әр-сә-ә?—ул бу сүзен нәкъ туганнан туганы кебек сузып, аның алдында сабыр гына утырып торучы адәми затка карап әйтте. Әхмәдуллага инде!

—Җебемә!—диде тегесе җикеренә язып.—Кеше өчен кеше яшәргә мужыт, вә әмма, кеше өчен кеше бервакытта үлә алмый. Иртәме-соңмы, алданмы-арттанмы, һәркем үзе өчен үзе генә үлә. Син бит зур укыган кеше, шуңа баш-чүмәләң төшенмиме?

—Нишләргә соң миңа?—диде Заһидулла гаҗизләнеп.

—Яшәргә!

—Ни өчен? Кем өчен?!

—Иң беренче, үзең өчен. Ан-на-ры... гаиләң өчен. Онытма: синең хатының гына түгел, улың да бар. Сабыйны ташлап китсәң, Хак Тәгалә сине ярлыкауга китермәс...

Күрешү вакыты узды...

Кочаклашып саубуллаштылар...

—Әнине...—диде Заһидулла, көч-хәл белән телен әйләндереп.

—Урынына житкереп җирләдек тәтәне... Мәңгелек урыны Гыйбадулла җизни белән рәттән...

—Заһидә... улым... ничек анда?

—Сине көтәләр...

Авыр басып чыгып барганда, Әхмәдулла аңа таба борылды да катгый итеп алдагы сүзләрен кабатлады:

—Өйдә сине көтәләр!

... Аның чигәләрен кысып башы авырта, ни сәбәптәндер, аягының шайтан сөяге тирәсе һәм тез башлары сызлый иде. Урманда агач кисеп, аларны ташыганда авыр китердеме? Әллә Мәкчим белән Сарапул күлендә балык тотканда, җылуга төшеп, чатнама суыкта аякларын катыруы менә хәзер төрмә шартларында үзен сиздерәме? Бәлки болар да түгелдер. Бәгыренә утырган кара төен—кара таш—аның аякларына төшкәндер...

... Шулчак Малмыж мулласын «дапрус»тан алып кайттылар.

—Бәрәкалла!—диде ул Заһидулла алдындагы төенчеккә ымлап.—Өйдәнме? Тиз килеп житкәннәр. Сагыналар, димәк, кайтуыңны өмет итәләр, хәлеңне жинеләйтәләр...

—Әнкәй үлгән...—ирнең башы түбән иелде.

—Үлем, балакай, Ходайдан. Ул жанны биргән кебек ала да... Йәле, анаң рухына Коръән чыгыйк.

... Ни гажәп!

Аның жаны кинәт кенә жиңеләеп китте. Ул Жидән бабасының сүзләрен—Күк Пышылдаган Сүзләрен—искә төшерде:

—Сине Жиде Кайгы көтә...

Менә икесе килде дә инде:

—Әти-әнисенең үлеме...

Йә, Алла! Болардан тыш Биш Зур Кайгысы бар икән ич әле аның...

Шулай булгач, Әхмәдулла туганые әйтмешли:

—Яшәргә!

Ләкин Яшәү—чыдау, түземлелек, сабырлык, үжәтлек, гомумән, хәятнең шатлыклары белән бергә, аның кайгыларын күтәрергә әзер тору да икән ич әле. Ул аны менә хәзер генә, Әхмәдулла алып килгән кайгы хәбәрен аның өстенә кара күлмәк итеп кигезеп киткәч кенә аңлады.

—Әниең кем исемле иде?—дип сорады кызыксынучан мулла.

—Гайнижамал... Гайнулла кызы...

—Бик хуп, бик матур, мөселманча исем! Ә әтиең кем дип атала иде?

—Гыйбадулла Зәкиулла угылы...

—Бәрәкәт,—дип аптырап китте хәзрәт. —Туктале, тукта, Заһидулла! Фәмилжәсе Жиданов түгелме? Шөннән—Гыйбадулла Жиданов...

—Нәкъ үзе...

—И, Аллам! Дөнья нинди тар, барыбыз да бер Күк астында яшибез дә, бер Жир өстендә йөрибез, Ходайның рәхмәте илә... Әтиеңне белә идем ич мин, балакай! Чепья базарына сәүдә эшләре белән барганда, безгә тукталып, чәйләп китә иде, мәрхүм. Йәле, аның рухына да бер дога...

Дога кылгач, хәзрәтнең кызыксынуы тагы да арта төште:

—Ә Шөннең беренче мәхәллә мулласы Фатыйх хәзрәт исәнме әле?

—Сау гына йөри...

—Ә икенче мәхәлләдән Аяз хәзрәт?

—Ул—минем бабай...

—Ничек, кай яктан бабай?—инде Малмыж мулласының кызыксынуы икеләтә-өчләтә артты.

—Аның кызы Заһидә—минем хәләл жефетем...

—И-и-и...—дип суздың хәзрәт.—Кил әле, кочаклыйм, балакай, үзеңне! Фатыйх, Аяз муллалар белән бергә Мәчкәрә мәдрәсәсендә укыган идек ич без. Шәриктәшләр идек без. Икесе дә таза—нык егетләр иде. Фатыйх шаярырга ярата иде, ана—мәзәк булсын! Ә Аяз, ат дигәндә, жанын күлмәге урынына салып бирергә әзер иде. Менә кайткач, өемә дим, абыстаемны, ожмах кошымны, сөендерәм әле исәнлекләрен сөйләп. Ул да аларны белә ич. Аралар сиксән-туксан чакрым булса да, бер-беребезгә кунакка йөрештек ич без. Ә син аларга миннән олуг-олуг сәламнәр күндер!

—Моннан чыгып булса...

—Чыгарсың, иншалла!—диде хәзрәт.

... Шулвакыт шалтырап ишек ачылды һәм зиндан бүлмәсенә күксел йөзле, салкын күзле өчәүне керттеләр. Алар өчесе дә усал карашлы иде.

—Кайттылар жәлладлар...—диде мулла йөзен читкә борып.

—Кемнәр ул?—диде Заһидулла акрын гына.

Тегеләр ыржаеп каршы нар-сәкегә утырдылар. Арадан иң тазасы тупас кына эндәште:

—Ну, молла, сегодня принесли тебе гостинца? А то, смотри, молитву читать не дадим. Во вторую тюбетейку наложим... И—на голову напялим...

—Принесли...—диде озын арыгы, Заһидулла төенчегенә төртеп күрсәтеп һәм нарыннан күтәрелде дә ризыкка кулын сузды.

—Не трогай!—диде Заһидулла, кинәт кенә үзендә куркыныч бер ярсу, тыелгысыз котырыну һәм ташыңны, учына кысса, ком итәр көч-куәт сизеп.

—Это еще кто такой?!—диде теге әзмәвер анын алдына басып.—Че ты раскомандовался, гололобый?!

Ул Заһидулланың ияген келәшчәдәй каты кул-бармаклары белән кысып алды...

Шунда әллә ни булды...

Заһидулла әзмәверне биленнән песи баласы урынына күтәреп алды да таш стенага китереп бәрде. Теге арыш көлтәсе урынына дивардан сыдырылып кына төште. Өстенә ташланган озын арыкның ияк астына баш белән бирде, ә тәбәнәк бик юанының ике бот арасына китереп типте. Ых та итмәделәр, киселеп кенә төштеләр.

—Аллаһу әкбәр!—диде Малмыж мулласы битен сыпырып.

—Караул, татары убивают!—дип акырды тегеләрнең иң беренче аңына килгәне.

Аларны күрше камерага ташыдылар...

* * *

Чәйне чәйнәп булмый!

Бу—һәркемгә дә билгеле...

Ә сүзне чәйнәп була—монысын да беләләр.

Әмма...

Нинди сүз бит!! Сүзнең—Зурысы була. Сүзнең—«кечесе» була. «Кечесе» дию—вагы мәгънәсендә... Тикмәгә генә вак сүз—юк сүз, димәгәннәр.

Ә монда...

Теге өчәвесен камерадан этеп-төртеп, ә иң юанын өстерәп алып чыгып киткәч, алар өстенә кабер тынлыгы ишелде. Ни Заһидулла, ни Малмыж мулласы бер сүз дә әйтә алмыйча интектеләр генә түгел, ә чын газап кичерделәр. Гаҗәеп бер халәт, кеше җанының хәрәкәттән туктаган чагы иде бу. Дөрес, тәндә ул җан бар, беркая да чыгып очмаган, ләкин... Ул каядыр поскан, качкан... Хәтта тән дә хәрәкәтләнүгә каршы булып, алар шактый гына сәке-нарда сүзсез утырдылар. Сүзсез генә түгел, ә оеп, сәҗдәгә китеп...

Ләкин ниндидер бер сүз, сүзбашы табарга кирәк иде ич. Гел мәгънәсез ярым-йорты җөмлә генә булсын, ди, ул да ярый. Мондый вакытта:

—Әтәчегез күкәй саламы?—дию дә ярап тора. Инде шактый караңгы булса да, Заһидулланың күзләре теге караңгы почмакка төште. Озак караңгыда яшәгән кешенең күзләре ябалакныкына әйләнә ич. Күзләр анда эзләгән нәрсәне тапмады, борын тишекләре дә теге зәһәр исне сизмәде:

—Ә түбәтәй,—диде ул үз алдына.

—Нәрсә түбәтәй?—дип куйды мулла сискәнеп.

—Тегеләр нәҗесләгән түбәтәй, намаз түбәтәе, урынында ятмый бит!

—Ә-ә-ә...—диде хәзрәт матур кеткелдәп.—Бүләк иттем мин аны аларга...

—Ничек?

—Аны бит теге күбенгән... Син нечкә җиренә тибеп үтерә яздың бит әле... Шул кыска аяк тизәкләгән иде ич... Менә мин, Йә, Ходаем, үзен ярлыка!.. Түбәтәйне аңа бүләк иттем...

—Аңламыйм,—диде Заһидулла, картның сүзне кая боруын һаман төшенә алмыйча. Шаяра дияр иден, урыны һәм вакыты ул түгел...

—Шулай инде менә, Заһидулла балакай, тоттым да бүләк иттем... Синең аны тибеп егуың гына булды, мин почмакка йөгереп бардым... Нәҗескә кулым пычранудан да куркып тормадым, алдым да түбәтәйне эчендәге бүләге-ние белән тегенең йөзенә каплadым. Шома йөзенә батырып, сылап кигездем. Жандармнар да сизмәделәр, шул бүләге-ние белән өстерәп алып чыгып киттеләр бахырны...

Узды микән бу мизгел?

Алар утырган камераны гына түгел, бөтен зинданны шаркылдап көлү тавышлары күмде. Зәһидулла белән Малмыж мулласы бер-берсен тыя алмыйча, күзләреннән яшь түгә-түгә, үлә-үлә көләләр иде. Әнә бит, ни сабыр, ипле-тәртипле мулла да, үзенен бу гамәленә үзе шаккатып, ак сакалына аккан яшен ак тастымалы белән сөртә-сөртә кеткелди иде. Югыйсә, башта, Зәһидулла сүз катканчы, үз эченнән елмаеп кына утырды, чөнки ул бу эшенә бәя куя алмый борчылып маташты:

—Сөенергәме муңа?

—Сөенерлек бер ни эш юк!

—Көенергәме муңа?

—Көенерлек тә гамәл кылынмады бугай...

Коридордагы каравылчы алар ишегенә китереп типте:

—Че ржете?! Прекратить!!

Ә үзе... Кешни-кешни көлә иде.

—Юри генә кычкыра ул,—диде мулла көлүеннән туктап.—Әйбәт егет, Носла керәшене...

—Нословдан минем дә керәшен дустым бар,—диде Зәһидулла.—Шулай ук шәп абзый. Чәпчим Мәкчим...

—Дөнья тар...—диде хәзрәт, кинәт кенә үз уена чумып. Аннан соң ул, йокысыннан уянган кебек, аңа дәште:

—Ә синдә, Зәһидулла балакай, жегәр, көч-куәт атныкы, үгезнеке икән! Атаңнан күчкән ул... Күргәнем бар иде, әтиең биш потлы капчыкларны ике култыгына кыстырып кына алып керә иде тегермәнгә...

—Көч юк дип зарланмыйм, мулла абзый...

—Сугыша да беләсең...

—Казанда кул сугышына өйрәндем. Гражданнар сугышында файдасы тиде, хәзрәт...

—Белем белән белүнең бервакытта да зыяны юк, Зәһидулла энем!

—Ятыйк мәллә, хәзрәт? Аргансыздыр...

—Бүген минем нигәдер йокы килми...

—Минем дә...

—Алайса, әйдә гәп куертып уздырабыз бу төнне.

—Мин риза, хәзрәт! Ин беренче, сезгә бер соравым бар...

—Ни сөален, әйт...

—Сезгә Җидән бабамның теге Серле Язуы турында сөйләгән идем ич. Нигә анда «җиде» саны дәүләт ханыдай ин югарыга куелган. Гүя башка саннар юк?

—«Җиде»—Изге Сан ул,—диде мулла акрын гына.—Без төркиләрдә дә, башка халыкларда да. Ислам дине өчен дә изге. Җиде кат Күк, Җиде кат Җир асты. Аннан соң ишеткәнем бар: кешеләргә Җиденче Биеклеккә кадәр менү мөмкинлеге куелган. Кече пәйгамбәрләргә—сигез биеклек, Олуг Пәйгамбәрләргә—тугыз биеклек. Фәрештәләр—ун, унбер, уникенче биеклекләрдә...

—Ә Ходай кайсы Биеклектә?

—Аны, Зәһидулла энем, беркем дә белми... Хакның Кодрәте Чиксез...

—Менә, хәзрәт, кешеләрне Җаны-рухы, Акылы-Аңы белән сез ничәнче биеклектә дип санийсыз?

—Иң югарыдагылар алтынчыдадыр, дим... Инсаният һаман да Җиденче Биеклекне яулый алмады әле...

Тынып калдылар. Бер-берсенең җанына күз салдылар. Җаннар тынычсыз иде... Алар билгесезлеккә зур борчылу белән төбәлгән...

—Бөтен бәлаләр дә шуннан түгел микән, хәзрәт?—диде Зәһидулла авыр сулап.

—Шуннандыр, дим...—диде хәзрәт уфтанып.

—Әйтә алмыйсызмы, хәзрәт, Җиденче Биеклек нәрсә ул? Кешеләр өчен, дим...

—Мин аны тәгаен үзем дә белмим. Тою-чамалавым буенча ул Тәүбәгә

килеп Чистарыну һәм—Нурга Ирешү...

Шаккатты Заһидулла. Ул бит Малмыж мулласына Җидән бабасының Серле Язуындагы бу сүзләр турында әйтмәгән иде. Гомумән, ерак бабамның шундый-шундый язуы бар, андагы сүзләрне үзенә Күк Пышылдады дип, язып калдырганын гына сөйләгән иде. Ә хәзрәтнең сүзләрен тыңласаң...

Нинди Тәңгәллек! Каян бу?

Инде гәп куертыр исәпләре бетеп, хәзрәт тыныч кына мышнап йокы дингезенә чумган иде. Ә Заһидулла күзен дә йома алмады...

... Таң ул төнне тиз атты...

Ул әле күзенә йокы элпәсен элгән генә иде, Хәзрәт уянып иртәнге намазга керешкән. Җитмеш яшьлек карт уяу чагында йокы симертү оят эш, шуңа Заһидулла да торып изге гамәлгә кушылды.

Урын-җирләрен рәткә китереп, үзләренчә тәртипкә кергәч, чистарынгач, хәзрәт телгә килде:

—Әйдә чәйләп алыйк...

—Чәе кайда да... кайнар суы кайда?—дип көлеп куйды Заһидулла.

Малмыж мулласының чәе махсус савытта куенында икән, кайнар суны аларга Носла керәшене алып килде. Икесенең дә ризыкларын бергә өемләп, тәмле генә итеп тәгам кылдылар.

—Ашавың таза, ризыкның тәмен белеп, азыкка хөрмәт куеп тукланасың. Менә минем бу сүзләрне искә төшерерсең әле, син бик озак яшәячәксең, Заһидулла энем...

—Рәхмәт! Бирсен Ходай, хәзрәт...

Аллаһыны олылап тагы дога кылдылар.

—Хәзрәт,—диде Заһидулла.—Минем... кичәдән сезгә тагы бер соравым калган иде бит әле...

—Ни сөаль?

—Кешелек ялгыш юлга Гайса пәйгамбәр заманыннан кереп китте микән әллә?

—Ник алай дисең, балакай?

—Соң, тәкъсир, үзен Алла улы дип, ул Тәкәбберлекнең иң яман үрнәген күрсәткән ич!

—Хуп! Соравың кызыклы... Ләкин монда бер нәрсәне онытма: үз иреннән бала таба алмаган Мәрьям-Анага Ходайның бер рәхмәте дә житә. Шул рәхимлелек аркасында әлеге мөэннәс заты бала тудыру өчен орлыклана ала. Аллаһының Кодрәте Чиксез ич аның. Ә син аны Мәрьям-Ана Гайсаны тудыру өчен Хак Тәгаләнең Үзе белән йоклаган һәм якынлыкка кергән дип аңлыйсың...

Заһидулла унжиде яшьлек кызлар кебек кызарды һәм йөзен читкә алды. Ул, ни сәбәптәндер, нәкъ менә шулай турыдан-туры уйлый иде. Шулай да аның бу Остаз булырдай кешегә тагы бер соравы бар иде:

—Гафу, хәзрәт! Тик шулай да... ничек инде Пәйгамбәр кадәр Пәйгамбәр үзен Алла улы диюгә кадәр барып житкән?

—Монысын да аңларга тырыш: ул бит шуның белән кешеләрне үз артыннан ияртергә тырышкан, аларны иманга кертергә омтылган...

—Шулай булгач, Остаз, сез Гайса Пәйгамбәрне һәр яктан дөрес саныйсызмыни?

—Юк, әлбәттә! Нәкъ менә шул сәбәп илә, инсаниятне Хак Юлга Өндәү өчен Аллаһы Тәгалә вә Сөбханәкә үз вәхиләрен Соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәт Галәйһиссаламгә иңдерә дә...

—Мелла, дапруска!—дип акырдылар...

* * *

Аллаһы дип Изге Китаптан уку гына житми, аңа: «Илаһым!»—дигән оран белән кычкырып дәшәргә дә кирәк. Шунда гына ул сине күрер дә, ишетер дә...

Хәер...

«Йә, Алла»,—дип бу дөньяда теләсәң дә, теләмәсәң дә бик күп әйтергә туры килә. Бигрәк тә хәсрәт изгәндә, кайгы ашаганда, чир килгәндә...

Малмыж мулласын «дапрус»ка чакырганда, Заһидулла да:

—Йә, Алла!—дип, камерада утырып калды. Иртәнге ашка бирелгән бер чүмеч төрмә баландасын ул җирәнеп парашага түкте. Нигәдер өзелеп-өзелеп хәзрәтнен кайтуын көтте. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул аңа ифрат та якын бер кешегә әйләнеп, соңгы минутларда Хәзрәт анын Рухи Җитәкчесе, Остазы дәрәҗәсенә күтәрелде. Булса да булыр икән Сүзе Белән (!) шундый нык тәэсир итә торган кеше. Ул бит анын Җанын актарып ташлады. Ә икенче яктан караганда, шул ук Җанына Ипле бер Тынычлык, Эчке Куаныч та салды. Җимерде һәм—шуның белән Төзеде дә. Хаос аша Тәртипкә китерде. Бу Инсани Затта Казанны дошманнардан саклаганда халыкны үз артыннан иярткән сәет Колшәриф Рухы вә Тәэсир Көче бар иде булса кирәк...

Берәр сәгатьтән хәзрәт үзе дә, нурлы йөзен тагы да нурландырып, ай-кояш булып кайтып керде.

—Заһидулла балакай! Котылдым! Дуслар булышканнар, Аллаһы рәхмәтеннән ташламаган,—диде ул чиксез куанып, кулларын уа-уа. —Йәле, утырыйк... Хак Тәгаләгә тагы да сыгыну вә илә мактау булсынга бер дога...

Китәренә калдымы икән ярты сәгать, ул гел Заһидулланы кайгыртты:

—Улым! Шулай дәшкәнгә рәнҗи күрмә тагы...

—Берук, хәзрәт!

—Мин сине бик яраттым!

—Мин дә сезне...

—Менә сиңа теләк-васыятьләрем. Иң беренче, үзеннең Бөек вә Көчле халык Татардан икәнеңне онытма. Вә икенчедән: бел!—синең каныңда татар биләре, тарханнардан килгән Дым-Су ага. Ә тарханнар ханнан кала икенче кешеләр алар дәүләттә, шул ук ханның токымдашлары, бер тамырдашлары. «Тар-хан» ханнан аз гына таррак кеше... Хакимлек буенча... «Татар» сүзе әнә чиннардан. Кытайлылар безне «Та-тар» дип таррак кеше, кимрәк адәм мәгънәсендә әйткәннәр. Үзләреннән ким, янәсе... Ә Урхан-Енисәй төркиләре аларны күп тапкырлар төйгәннәр, акылга утырткалап торганнар. Бары Алтыайныкылар, Байкүлнекеләр бердәм була алмаганнар, үзара гел тәпәләшеп торганнар...

Синең Җидән бабаң да морзалардан булган. Морзалар—затлы нәсел, аксөякләр, зыялылык вә белем ияләре, аларга лаек бул!

Өченчедән, үзең өчен яшәгән сурәттә дә, гомереӊ буе халкың өчен эшлә, ян, көй, анын кирәген кайгырт, хәсрәте өчен хәсрәтлән, шатлыгы өчен шатлан. Ул еласа-ела, көлсә-көл...

Вә килеп, дүртенчедән... Үзенне сакла! Үзеңне үзең сакламасаң, сине—Ходайдан башка—беркем дә сакламас. Хагыбыз да бит: «Сакланганны саклармын»,—дигән. Әйткән идем бит әле сине алда озын гомер көтә дип... Моңа да ышан! Үз гомеренә ышанмаган кеше үз-үзенә хыянәт иткән адәм ул...

Кул бирешеп, кочаклашып, бер-берләренең иннәреннән ярату белән йомшак кына кагышып саубуллаштылар. Һәм шунда гына карт чишелде:

—Минем мондагы бер дапрусчы—үзебезнең кеше. Знакум дияргә була. Чыгышы—Казаннан. Лиф Талстуй галиҗәнәпләренә кардәш адәм. Ифрат та зыялы бер урыс. Синең хакта чыбык очын тарткаларга бардым бит мин бүген. Минем эш хәл итеп язган иде инде. Уңай якка... Менә шул бәндәбез әйтте: «Ул,—диде сине,—пәлитически гаептә. Сталин кадәр Сталинның үзен ерткан бит, ди. Но,—диде—котылуның бер юлы бар. Голодовка игълан итсен, ди. Мин ертмадым, миңа яла яктылар дип барсын, ди. Шунда коткарырга булыр, ди... Син, әйдә, олан, булган ризыгынны ашказаныңа тутыр да бүгеннән үк ачлык игълан ит.

—Ачлык тәмугъка кертер, шайтан белән дә йөртер, дигәннәр... Түзәрменме, хәзрәт?!—моңарчы үз гомерендә бер генә мәртәбә дә ныклап

ачлык күрмәгән Заһидулла шикләнә үк төште. Алар әнә иң ач егерме беренче елда да тамактан тәмам өзелеп яшәмәделәр. Юк дигәндә, бәрәңгесе бар иде.

—Аның бер әмәле бар, улым. Мин бит патша охранкасы тарафыннан заманында зинданга ташланган кеше инде. Шунда бер бәлшәвик «голодовка»ны ничек үткәрергә икәнен өйрәтте.

—Ничек?—дип соравын да сизми калды Заһидулла.

—Баштарак передачалар алып бик шыплатып корсак шәрифләренне тутырасың. Күбрәк итле-майлы ризыклар белән. Аннан «голодовка абъявить» итәсең һәм...

—Һәм?—диде тагы кинәт кенә кызыксынучы зат.

—Һәм өйдәгеләреңә алмашка дип җибәргән күлмәк-ыштаныңны юып, шикәр суында кайнатып алып киләләр дә ашказаның ачка киселгән саен, имчәк бала кебек шуларны суырып ятасың. Тамак туймый билгеле, әмма да ләкин йөрәккә хәл кереп китә. Ә ачлыктан курыкма, аның дүрт көне генә авыр. Аннан...

—Һы!—иялəнгән ымлык үзеннән үзе атылып чыкты.

—Килештекме?—диде хәзрәт.

—Ә шикәрле күлмәк-ыштанны миңа йөз чакрымнан кем ташып торыр икән?

—Анысына борчылма,—диде хәзрәт һаман да тынычлыгын җуймыйча.—Анысы—абыстаң эше...

Һәм...

Заһидулла ачлык игълан итте. Әлбәттә, Заһидәсе җибәргән ризыкларны тәгам кылгач. Шулар өстенә туганые алып килгән бер бөтен ипине бөкләгәч. Шуның кадәр ризык тар гына ашказанына ничек сыйгандыр, ул үзе дә аптырашка калды. Йә, Алла! Адәм баласының аерым бер гамәлендә билгеле чикләре юк бугай. Булса...

Һы!

Бер ат йөге ризык-тәгамне ул эчке мәгарәсенә шыплап тутыра алмас иде...

Атна үтәр-үтмәстә, теге шикәрле күлмәк-ыштан да килеп җитте. Коридорда сакчы-каравылчы булып Носла керәшене торган көнне.

И суырды инде Заһидулла шикәрле киемнәрне! Башта—күлмәкне... Аннан соң ыштанны... Ими яратучан улы Галимулла да әнкәсе күкрәген болай суырмагандыр. Менә яталар алар бу дөньяның ике «сабые» «ими имеп». Берсе—атасы йортында, икенчесе—үзе дә кеше тәне өчен Мәңгелек Төрмә булган Җир шарының инсаннар төзегән төрмәсе эчендә.

Атнага ияреп атна узды...

Тагы бер атна узуга, аны «дапрус»ка чакырдылар. Күренгәнчә, барысы да алдан көйләнгән булып чыкты...

... Төрмәдән аны алырга дип, Малмыж мулласы үзе килгән иде. Хәзрәтнең күзләрендә яшь. Ләкин болар инде шатлык яшьләре иде.

Капканы чыгуга, аларны тимерхутка сылу озын гәүдәле күк айгыр җигелгән, утыргычта өлкәнрәк яшьтәге кучер утырган «экипаж» көтә иде.

—Менә шуның өчен дә утырттылар инде мине төрмәгә,—диде мулла.

—Ат өченме?

—Икесе өчен дә...

—Ничек икесе өчен дә?..

—Ат тотуың гына җитмәгән, үзең ялчы да асрыйсың, диделәр. Ә кучерым Мулламөхәммәтне куып та карадым, аякларыма тезләнеп ялвара: «Синең белән гомерем узды, мин, алтмыш яшькә җиткәч, кемгә кирәк?—дип елый.—Аллаһы хакы өчен кума мине, минем хатыным да, балаларым да юк, кемгә барып сыеныйм?»—ди.

—Өйләнмәгән идемени?

—Өйләндердем, ике тапкыр өйләндердем. Беренче хатыны яшьләй үлеп китте, икенчесе инкыйлаб булуга, аны ташлап качты... Шуннан соң өйләнмәде...

—Әссәламегаләйкүм!—диде кучер, алар якынлашуга, Заһидуллага йөзен борып.

—Вәгаләйкемәссәлам!

Заһидулла күрде: хәзрәттән ун яшькә кечерәк булса да, кучер инде бетерешкән, сары йөзле, моңлы күзле бер карт иде. Соныннан авыру икәнен дә белде: бавыры белән интегә икән.

... Абыстай кечкенә генә гәүдәле, гажәп тере, бик тә хәрәкәтчән, әле матурлыгын һич тә җуярга теләмәгән алтмыш-җитмеш яшьләрдәге хатын иде. Заһидулла аны эченнән «курчак карчык» дип атады.

Малмыж мулласында бер көн кунак булып, мунча кереп, юган өс-баш киеп, иртәгә алар кучер Мулламөхәммәт белән кайтыр юлга кузгалдылар. Озатканда хәзрәтнең күзләренә тагы чәчрәп яшь чыкты:

—Заһидулла улым, күңелем сизә: бу соңгы очрашуыбыз. Дөресе, беренче һәм соңгы очрашуыбыз. Минем баш очында үлем козгыны торганын сизәм. Сина васыятем шул: эчке уй-теләкләреңне эчкә яшер. Яман заман килә, мин аны күптән тоям инде. Үзеңне сакла, гомереңне мәгънәсезгә әрәм итмә. Халык өчен эшлә! Кайткач, мәктәпкә укытырга кер. Син бит учительская школа, Казан мәдрәсәсен бетергән кеше. Урысчаң урысныкы кебек. Халкыбызның урысчасы начар, өйрәт балаларны шул телгә... Алга таба бик кирәк булачак ул.

—Иң зур сабак—сезнең төрмә дәресләре, хәзрәт!

Алар, ата белән бала кебек, бер-берләреннән һич кенә дә борылып китә алмыйча аерылыштылар...

* * *

Җир шары чәчәкле гөлбакчадан хаҗәтханәгә әверелә бара.. Әйе, планета бәдрәфкә әйләнә бара. Аның күгендә—кара тишекләр, өстендә—кара ташлар...

Ә бит ул тулысы белән гыйбадәтханә булырга тиеш. Илләре дә—гайбәтханә. Бер-береңне күрә алмау пәрәвезе, ялган-алдау сөреме, үзара чәйнәшү-рәнҗетешү корымы Җир йөзенең кершән ягуы түгелме хәзер?!

Көнбатыштан, Кояш байый торган яктан, ниндидер караңгылык килә. Ул караңгылык авыр сулый, мыш-мыш көлә, ләкин утлы сулыш бу. Үлем сулышы... Явыз көлү бу...

Әнә шундый тоем-кичереш салды Заһидулланың нечкә вә сизгер җанына Малмыж мулласы.

Инде аерылып китеп, тимерхут арбага меним генә дигән иде, кире борылды ул.

—Хәзрәт, тагы бер авыр соравым калган иң...

—Әйт, мөгаллим Заһидулла!

—Минем бер зур гөнаһым бар: хатыным була торып, чит хатын белән зинага кердем...

—Син аны көчләмәдеңме?—диде мулла, бераз уйланып торгач.

—Юк, юк! Ул үзе моны теләде, үзе мине шуңа тартты...

—Шайтан коткысы!—диде хәзрәт үз алдына.

—Нәрсә дисез?

Малмыж мулласы дәшмәде...

—Остазым... Хәзрәт! Сез мине бу авыр йөктән коткара аласызмы?

Мулла кызыбрак китте:

—Син нәрсә, Заһидулла энем?! Мин поп түгел бит, мулла. «Отпущение грехов» кирәк икән, Малмыж побы янына бар. Аларда, кеше үтерсәң дә, гөнаһыңны ярлыкыйлар. Шунда ук... Поп дигән кешеләр үзләре үк. Менә аларның тагы бер ялгышлары нидә! Ислам динендә гөнаһларыңнан Аллаһы Тәгалә үзе генә азат итә ала. Ярлыкау Хокукы бары анда гына... һәм бу шулай да... Хак бу...

Яшь ир кызарынып башын иде һәм уйланды: «Китәсе иде. Нигә

борылдым? Ник чишелдем?»

—Ә кылган гөнаһыңны мина әйтүең дөрес,—диде хәзрәт.—Менә күрерсең, гөнаһ авырлыгың бермә-бер җиңеләячәк...

Аннан соң ул аңа сынап карап торды да сүз катты:

—Ул мәэннәс затын... син... яратыпмы? Әллә болай гынамы?

—Бик тә яратып, хәзрәт! Хәзер дә төшләремә керә ул...

—Хет, яшерен генә булса да, никах укытырга иде... Шәригатьтә берничә хатын рөхсәт ителә ич...

—Булмый, хәзрәт! Чегән хатынының кызы ич ул, безнең дин кешесе түгел...

—Йә, ярый онытыйк муны. Соң нишләрсең, ир-хатын бер-берсен сөяр өчен яратылган...

Аннан ул тирән көрсенде:

—Мундый әллә нигә бер ялгышулар булыр инде ул. Менә гасыр ахырында ничегрәкләр булыр микән бу хәлләр? Шикләнәм мин, шикләнәм...

Китәргә ашыккан Заһидулла аны бүләргә җөрьәт итте:

—Соңгы соравым, хәзрәт...

—Тыңлыйм, мөгаллим Заһидулла...

—Авылыма кайткач, олуг-олуг сәламнәрегезне Фатыйх, Аяз муллаларга күндергәндә, сәлам иясен кем дип атыйк?—берничә көн эчендә ул да хәзер Малмыж мулласыныкы кебегрәк җөмләләр белән сөйләшә башлады.

—«Мәһди» дип атарсың...

Алар тагы бер кат җылы гына саубуллаштылар...

... Күк айгыр, канат куеп күктән генә очкан кебек, бик җиңел юырта. Җир өсте кабат җебемәскә диеп шакыраеп каткан. Ахыргы киресе белән каткан, чөнки бер катырып, бер җебетеп тору аны да туйдырган булса кирәк. Күктә, чакрымнан чакрымга дигәндәй, чын кышның беренче билгеләре булган, җиргә төшсә, эреми торган эре күбәләк карлар оча. Алар атның дугасына куналар да җил белән очып китәләр, җир өстендә дә тыныч кына ята алмыйлар, аз гына һава дулкыны—менә очам, менә очам дип, дертсенеп-ымсынып яталар.

Кучер сүзсез абзый булып чыкты. Әмма аны Тукайча:

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

дип, һич кенә дә әйтә алмассың!

Малмыжны чыгып, туры юлга аяк кына басканнар иде, абзый, күк айгырны үз җаена куеп, борын эченнән генә шыңшый башлады. Анасы үлеп, сөткә тилмергән, кышкы суыклар килеп, җылыга интеккән көчек баласымыни. Каян сыя икән шушы җыйнак кына гәүдәле, сары йөзле, моңлы күзле кешенең бетерешкән тәненә бу хәсрәт-сагышлар? Әллә аның бәдәне кечкенә, ә Җаны бик-бик зурмы? Әллә ул Күкләрдән иңгән Илаһи Моңны тавышсыз гына күңеленә җыя да ифрат кызганыч аһәң, йөрәгенә кан савар оран белән Җир өстенә сибәме? Бәлки киресенчәдер, кешеләр җанына җыелган сары сагышны бер үзенә сеңдереп, шул Моң-Зар Көен Күккә юнәлтәме ул? Күренеп тора ич: Йөрәге елый аның... Бик тә, бик тә бәхетсез кеше ул...

—Йә, Аллам! Тилмерер, газап кичерер, михнәт чигәр өчен генә киләбезмени без—Шушы Илаһи Чатыр!—Зәңгәр Күк астына?..

Заһидулланың күзләренә яшь бәрде. Ул хәзрәт биргән иске толыпка төренебрәк, тимерхут арбаның кара чыбыклардан үрелгән терәлгеченә җайлабрак ятты. Җылыда ятса да, тез башларына вакыт-вакыт сызлауның йөзләрчә энәләре кадала. Малмыж төрмәсенең юеш, таш идәнле камералары Сарапул күлендә җылуга төшеп боз булып каткан аякларга чирне тагы да өстәделәр булса кирәк.

Смәил авылына кергәч, мәчетне узып, бер йортка тукталдылар. Элегрәк әтисенең тукталу урыны иде бу. Таза тормышлы кешеләр. Гыйбадулла карт шул якларга барсаң, шул-шул кешеләргә керерсең дигән иде. Санга да

сукмаган иде анын бу сүзләрен исәрбаш Заһидулла. Менә бит ул дөнья ничек!

Исән булсан—дусларың исәпсез булсын!

Атка коры печән салып, чәйгә керәбез дип, аякларын гына язып торалар иде, өй эченнән хужа кеше белән...

Әйе! Хужа кеше белән... шул үзе—Әх-мә-дул-ла килеп чыкты.

—Бәрәч!—диде ул шаккатып.

—Тәрәч!—дип шаяртты кичәге тоткын.

Ике туган, башкача аңлаша алмагач, шап-шап китереп, бер-берсенең аркаларын төя башладылар. Куанычтан...

Эх!

Кучер, зур рәхмәтләр һәм тунны алып, кире борылды, бары эреп тә эремәс, юып та юылмас хәсрәт-сагышы, илаһи моны гына Заһидулланың колагында мәңгегә эленеп калды.

—Мин сине үзем дә алырга дип килгән идем инде!—диде Әхмәдулла, күренеп торган ике төенчекне арбадагы печәнгә яшереп.—Заһидә киленгә дә шулай диеп чыгып киткән идем...

Эх! Эх!!

Суган гына булсын туган, барыбер ул туган!

Юл буе сөйләшеп туя алмадылар. Заһидулла бик тә җентекләп авыл хәлләрен сораштырды, ә Әхмәдулланың, төрмәдән битәр, Малмыж мулласы хакында беләсе килде. Ә соңыннан:

—Булса булыр икән кеше!—дип, аның белән бик нык соклануын белдерде.

Шөңгә алар төн куелыгында кайтып керделәр. Ярты авыл утларын сүндереп йокларга яткан иде инде. Урамда кешеләр дә йөрми диярлек. Анда-монда берән-сәрән этләр генә өрә...

Эх! Эх!! Эх!!!

Туган авылның этләренә кадәр сагындырылган. Йортлары да кул биреп сәламлиләр кебек. Төнге тәрәзәләрдән төшкән сирәк-мирәк утлар таңгы кояш нурларына тиң...

Сагындырылган...

... Йорт ишеген ачуга, анын борынына туган өе исе бәрелде. Иләнгән, тәмле, рәхәт, хәтта башны әйләндерерлек, һуштан яздырырлык хуш ис.

Түшәмдә, өйне балкытып, җиделе лампа яна. Иң беренче Заһидулланың карашы нәкъ менә шул матчага асылган яктырткычка төште.

—Заһидулла җаныем!—дип аһылдады, аркасын сандыктагы ястыкмендәрләргә терәп утырып торучы Заһидә, елый-елый.—Кайтыр, дидем. Кайттың менә!

Ул елап шешенеп беткән. Хәтта бераз ямьсезләнгән дә. Күз төпләрендә кара күләгәләр...

—Әнине...—диде ул әрнеп һәм гаебе булган кебек.

—Беләм...—диде ир.—Малай ничек?

—Саклый алмадым. Сине алып китүләрен кичерә дә, күтәрә дә алмады... Ә улың сау-сәламәт! Йоклый ул...

Урын-җир җәелмәсә дә, Заһидә аны караватка тартты:

—Кил, ят... Кочакларында үләргә риза! Ләкин миңа бүген кагылмыйсың. Барысы—иртәгә, мунчадан соң...

Ә иртәгә...

Заһидулла иң беренче эш итеп әнисе каберен зыярәт итте.

*Ахыры киләсе санда*

*Җиңүнең 55 еллыгына*



# Марс Шабаев

## ЯРТЫ ТӨН БӘЙРӘМЕ

ПОЭМА

*Сугыш елларында ир бәхете татый*
*алмый картайган барлык*
*әби-апаларга багышлыйм бу әсәремне.*

Автор.

1

**Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.**

**Минем юләрлектән көлмә, яме:**
**Бу бәйрәмне үзем уйлап таптым,**
**Үзем куштым сәер исем-атын.**

**Хатын-кызның шулай инде аның:**
**Сагыш-хәсрәт талкыганда җанын,**
**Чыгара ул нәрсә булса уйлап.**
**Юк, булмый ул һич уеннан—уймак.**
**Бер юаныч була, бер таяныч,**
**Юанычсыз дөнья, һай, аяныч!**

**Мин дә менә сәер бәйрәм ясыйм—**
**Икебезнең бәйрәм булып калсын.**

**Бу бәйрәмгә ел да сине көтәм.**
**Кайтасың да, имеш, ияреп китәм…**
**Акыл аңлый синең кайтмасыңны:**
**«Әйдә!»—диеп мәңге әйтмәсеңне.**
**Кайтасың юк синең… Син—җанымда,**
**Бәгыремдә минем, менә монда…**
**Искә алам, яд итәмен бүген**
**Ярты төнен ерак яшьлегемнең,**

---

Журнал варианты

Икебезгә уртак Ярты Төнен
Өлешемә тигән көмешемнең—
Язмышымның...

Кинәт тәрәз шакып, сәгать бердә
Килеп кергән идең син ул төндә:
«Ут кабызма... Ай яктысы җитәр...»—
Пышылдады бугай төнге җилләр...
Гөлтләтеп ут нигә кабызмадың?
Тыныч иде минем ялгыз җаным.
Әллә кайда, күңел төпкелендә
Яши иде синең исемең дә—
Мәктәптән үк җанга сеңгән исем...
Юк, юк әле,—кая!—сөю хисен
Татымаган иде минем йөрәк.
Ә син пышылдадың: «Кил тизрәк...»
Караңгыда калдык икәү шулай,
Балкып торды бары күктәге Ай...

Ут алмадым бүген дә мин менә,
Охшатасым килде ерак төнгә.
Калыкты Ай, аның нурларында
Сызылып ага үткән елларым да...
Урындыкка бүлмә түрендәге,
Ап-ак эскәтергә өстәлдәге,
Урындыкка (аңа син утырган...),
Эскәтергә (аны син сыпырган...)
Нәрсә яза бүген Ай нурлары?
Яза алар бер сүз-исем бары,
Укымый да беләм: синең исем,
Еллар уйган исем, йөрәк кисеп...

Белмим, ничек сине таныганмын?—
Армиягә киткән таңында мин
Озатмаган идем... Хәтерләмим
Ничек киткәнеңне хәзер дә мин.

Моңсу бәйрәм... Моңсу көмеш бу төс
Көмеш әкият кенә; көмеш бер төш
Ник булмаган икән, ник булмаган?
Көлсу-моңсу төннән, бу дөньядан
Китек күңелемә мин ни алам?..
Ник оялам?..
Көлсу чәчләремдә—көлсу нурлар...
Түгел, имеш, еллар... Бары нурлар...

2

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Ал син мине үзең белән, яме—
Бәлки, соңгы булыр бүгенге төн,
Бер янәшә атлыйк әле бүген.
Ерак бармам. Тик бер генә гомер.
Ул гомер бит безнең икебезгә бер.
Барыйм басу капкасына кадәр,
Барыйм үргә, юл чатына кадәр...

Без ул юлдан бер дә үтмәдек бит,
Йөрешмәдек, үбешмәдек тә бит—
Өлгермәдек...
Безнең үрдән дөнья күренә, дип,
Күренмәсме яшьлек гомер дә, дип,
Без торырбыз икәү тып-тын гына,
Тирә-якта булыр тик моң гына...

Син һаман яшь, син һаман да шулай.
Мин генә карт... Шаһит әнә шул Ай:
Миңа инде йөздән артык бардыр!
Бәлки, әле аннан артыграктыр...
Бәлки, ялгышамдыр...
(Кем өчендер аздыр җиде дистә.
Һай, күп икән!—төннәр ялгыз үтсә...)
Сине көтеп бүген Ай тулышкан.
Аста йоклый болын. Ул сагыштан
Шулай бәсәргәнме, әллә чыктан?
Болын күлен аксыл томан йоткан...

«Җиләк күп, дип, Усай болынында»,—
Без кыз-кыркын килә идек монда.
Хәтерлимен әле күтәргәнем,
Ояла-ояла, күлмәк итәкләрен,
Елга суын кичеп чыккан чакта.
Үтмәдең син җилеп елгыр атта
Ул елларда бер дә яннарымнан.
Кача-поса безне карап торган
Үсмер малайларның арасында
Күренмәдең, ничә карасам да...

Томан-тынлык ага шомландырып...
Безне ялмап алмак буладыр ул—
Китик моннан! Минем җаным туңа...
Җаным туңа...
Җылы җитми миңа
Безнең изге Ярты Төннән бирле...

3

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Иyртермен сине үзем, яме.
Без барырбыз Тупач тауларына—
Кара Таш янына.
Син ул ташны белә идең микән,
Түбәсенә менә идең микән?
Менгәнсеңдер... Егет-җилән анда
Уя торган иде берәр тамга.
Үзенә күрә шундый бер ырым бу,
Бер башламы кебек бер җырның бу—
Һәр буынга насыйп изге җырның,
Тормыш дигән озын-озак юлның.

Мин һәр язда килəм Кара Ташка.
Хыялымда, куеп башны-башка,
Синең белән бергә утырам мин.

Аннан үрмәләргә тотынам мин
Ташның төбәсенә... Өмет өзмим—
Бер табылыр, диеп, һаман элим
Синнән калган ырым-тамганы мин.
Эзлим... Сизмим яшьләр тамганын мин
Кара Ташка... Миннән башка тагын
Ничә еллар, күпме яшь тамганын
Белсә белер Кара Таш тик үзе...
Тик таш дәшми, ташлар була түзем.

Нинди булды икән синең тамгаң?
Минем күңелдә ул—кан кызыл таң...

4

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Ярты төнне бөтен итәрбез дә
Китәрбез ич?! Без китәрбез бергә.

Хакыйкатьне беләм мин, әлбәттә:
Һәркемнең үз юлы мәхәббәттә.
Аерым эзләп, икәү таба аны—
Кабына шулай гашыйкларның таңы.
Һәркемнең үз юлы үлемгә дә,
Гомер ае сүнеп, күмелгәндә...

Бәгыремне телеп, сызыла бүген
Егерме бер мең... фәләненче төн...
Ярты түгел алар, тулы төннәр...
Озын төннәр... Салкын, шомлы төннәр...

Рәсемеңә карыйм. Рәсемеңне,
Әнкәй исән чакта, беләсеңме,
Кыймадым мин бер дә күрсәтергә.
Безнең Ярты Төндә без бит бергә
Шул гомердән бирле икәү генә.

Әткәемнең инде сиңа кадәр үк,
Күптән инде хаты-хәбәре юк.
Соңгы хаты Мәскәү тирәсеннән
Салкын кышта иде безгә килгән:
«Илем өчен утка керәм,—дигән,—
Изге ни бар тагын туган илдән?»
Сине белми һәлак булды әткәй,
Сине белми вафат булды әнкәй.

Әнкәм минем безнең Ярты Төндә
Ник булмады икән, дисәң, өйдә?—
Киткән иде алар Минзәләгә,
Чәчү орлыгына, симәнәгә...
Әнкәм өчен мин бит сөелмәгән,
Саф кыз килеш калдым... Ир белмәгән...

Авылда да белми сине беркем:
Хәтереңдәдер, ут алмадык ул төн.
Тик Ай гына шаһит иде безгә,

Ай укыды никах икебезгә...
Шаян күрше авыл малае, син
Куштың миңа шул төн яңа исем:
«Төн Гөлем син, дидең, Төнем Гөле...»
Шуңа күрә, ахры, шуннан бирле
Мин җанымны ачам төнлә генә,
Көндез йомарланам бер төенгә,
Кертмим күңелемә беркемне дә.
Эрегән идем кайнар сулышыңнан,
Ашыктырды сине кан кызыл таң...
Җитдиләндең кинәт, кырысландың,
Юатырга мине тырышмадың:
«Сөйләр сүзләр, дидең, булыр хатта...»
Килмәде шул бер хатың да хәтта...
Язгансыңдыр, таба алмагандыр,
Кан кызыл таң аны ялмагандыр...

5

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Синең бүләк—куян мамык шәлне
Иңнәремә салам, танымассың...
Иңгә салдың киткән таңыңда син
Шушы шәлне... Хәзер мине шәлсез
Танымассың—еллар үтте хәтсез...
Дүрт сәгатьтә күпме генә күрдең!
Мине шушы мамык шәлгә төрдең...

Мамык шәлем шуа иңнәремнән,
Шуа-шуа ага төннәремнән,
Шуа-шуа ага тәннәремнән...
Ак мамык шәл тынлык булып ага,
Җылы тынлык эзләп төренәм аңа...
Юк, кара шәл ябынмадым бер дә
Ул хисапсыз салкын төннәремдә.
Күңелемә кара кертмәдем мин,
Синең исемеңне йөртмәдем мин
Кара хәсрәт итеп, Янар Йолдыз!
Калсам калдым ялгыз, ялгыз—тол кыз...

Ак юлымны каралтырга теләп,
Үзләренә каратырга теләп,
Күпләр таптандылар—тапмадылар,
Тапмадылар ләкин йөрәккә юл...
Ялгыз язмыш үзе өйрәтә ул—
Ачылмады синең Төнге Гөлең,
Белүче юк иде аның телен.
Синнән башка аны белсен кемнәр!
Шаһит иде тик Ай, көлсү төннәр...

Мин салкын ай идем, буй җитмәслек,
Синнән башка беркем эретмәслек
Тулышкан ай... Минем нурларымда
Буташтырды күпләр юлларын да.
Үзләренең татлы уйларында

Мине баштанаяк чишендереп,
Кочагыма кереп, эреп бетеп,
Тик бер төнгә төтен булу бәхетен
Күпләр эзләделәр ничәмә төн!
Аксак-туксаклар да, чулаклар да...
Шулай булмый тагын, ул чакларда,
Ул елларда сиңа кемнәр булсын!
Юк, кимсетеп әйтмим, телем корсын!—
Бик күп кызлар бәхет санадылар,
Өлешенә чыкса яралылар—
Дүрткә берәү кайтты алары да.

Тыштан таш мин. Эчтән... үзем беләм...
Яшәгәнмен нинди түзем белән?
Нинди юл бар? Бары Ай нурлары—
Сафлык юлы, пакълек юлы бары.

6

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Сөйлә берәр нәрсә, сөйлә әле!
Юри генә сөйлә, кызык итеп,
Йә ачулан мине, кызып китеп,
Сорау гына бирмә, бирмә сорау!
Күпме йөрсәм дә мин урау-урау,
Сиңа уңай җавап таба алмам:
Ни әйтсәм дә, булыр төсле ялган.

Ашыгырга кирәк түгеллеген,
Вәсвәсәле үсмер кыз күңелен
Икебез дә аңламаган икән,
Сөюдә без булган надан икән.
Сөешергә вакыт кирәк икән,
Сөю фәнен гомер өйрән икән.
«Алып кит!»—дип мин ялвардым кемгә?
Алу кирәк иде тулы төнгә.
Ник ышандың ярты төнгә генә?
Җитмәде бит ул төн Төн Гөлеңә!
Төн Гөлеңне өзә белми өзден...
Тулыр-тулмас иде унсигезем—
Тулысынча ачыла алмый калдым,
Кыраулары сукты алсу таңның...
Мин бит шуннан бирле ачылмаган,
Куырылган гына салкыннардан,
Синең ачылмаган Төнге Гөлең.
Иярт мине! Өзелергә телим...
Юк, үзгәртеп булмас язмышымны—
Өз син бары минем сагышымны!

Мин бу йортны тотып торам ялгыз,
Тотып торам ялгыз, Янар Йолдыз,
Кутәрәмгә калган иңнәремдә...
Мин бер өрәк айлы төннәремдә—
Әйтерсең, мин һаман үсмер бер кыз,
Ай нурында йөрим тавыш-тынсыз,
Кайнар тәнне төреп ак җаймәгә,

Йөрим шулай яз-көз, кыш-җәйләрдә...
Мин кычкырмак булам: «Юк, үкенмим!
Бик бәхетле идем ярты төн мин!
Тик җитмәде генә ачылырга—
Язган миңа гомер ачынырга...»
Әйе, мин бик көткән идем аны—
Икебезгә уртак нәни җанны...
Көткән идем синең тере канны...
Уйлый идем: «Улым булса әгәр,
Килмәсә дә синнән бер хат-хәбәр,
Бер кайтырсың барыбер, бер кайтырсың.
«Кайттым, улым!—диеп бер әйтерсең.—
Йотмак булган иде кан кызыл таң,
Көчле булып чыкты тик сезнең кан,
Илгә-өйгә тик сезнең кан тартты,
Үлемнәрне җиңеп, әткәң кайтты».

Уйлыйм әле менә тагын шуны:
Улым булса, мин дә гонаһымны
Яшереп йөрмәс идем ил күзеннән.
Ялвармас та идем: «Бир түземнәр!
Сабырлык бир, диеп, и Ходаем!»
Булмады шул улым-балакаем...

7

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Булгач булсын әле, йә, әйдәле!
Бер җырлашыйк: җырда—дөнья яме,
Җырда—күңелләрнең моңы-гаме.
Түгәрәккә басып җыр җырларга
Чакырмадың кичке уеннарга.
Чакырмадың бер дә биергә дә.
Оялган булыр идем килергә дә—
Мин бит әле үсмер генә идем,
Күзгә күренмәс бер Төнге Гөлең.
Күңелдәген, йөрәк түрендәген
Кайчан сизгәнеңне белгермәдең.
Мин мәктәптә берме-икеме тик
Сизеп калдым, синең ничек итеп
Миңа карап-карап алганыңны.
Сизгәнемне минем аңладыңмы?

Сине армиягә алган елны
Миңа әле тик уналты тулды.
«Сахалинга китте—җир читенә...»—
Диеп сөйләделәр. Әй читен дә
Булган иде миңа! Белми калдым
Сезнең елгыларның алынганын.
Ул бит әле тыныч еллар иде,
Күңелдә тик якты уйлар иде.

Җырладыңмы икән киткәндә син,
Безнең авыл аша үткәндә син?
Белмим, белмим... Синең киткән көнең
Хәтеремдә сакланмаган минем.

Әллә бераз үпкәләдем микән:
«Сиздермичә киткән... Әйтми киткән...»
Хәтерләмим. Хәтеремдә бары
Кырык икенең кандай кызыл таңы.
Мең тугыз йөз кырык икенче ел.
Дүртенче май таңы—безнең Төн ул...

«Икәү китик!»—дидем. Ияртмадең.
Сыпырып алдың минем күз яшьләрем...
Әниемнән курку түгел иде,
Куркулардан үткән төнем иде.
Без китәргә тиеш идек бергә,
Кирәк икән—утларга керергә.
Таш яуса да барыр юлыбызга,
Бәхет яулап туар улыбызга,
Җиңү яулап туган илебезгә,
Кайткан булыр идек икебез дә!

Без ул таңда белмәгәнбез генә:
Өч ел калган Җиңү Көненә дә!
Шул өч елга сыйган синең гомер,
Минем гомер... Сыйган аңа меңнәр...
Ничәмә тол... Күпме ятим-җилпе...
Дөнья айкап йөрде афәт җиле...

Без Ярты Төн кичтек икәү бергә.
Бер күрешү—үзе бер гомердә
Бу зур бәхет иде. Сиңа рәхмәт!
Күрешә алмаганнар юньләп-рәтләп,
Ярты төн дә бергә булмаганнар,
Язмышларын куша алмаганнар
Өелешеп калды, илләр тулып...

Син балкыдың Янар Йолдыз булып...

8

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.

Карыймын да синең рәсемдәге
Күзләреңә тутырып, озак итеп,
Онытылып аннан, исем китеп,
Утырамын шулай: «Өнме соң бу?
Илле биш ел буе миңме соң бу?
Үз-үземә сәер бәйрәм ясап,
Ятам әле, димен, һаман яшәп?»

Күп тапкырлар булдым авылыгызда,
Күп үттем мин капка яныгыздан.
Килен булып мин төшмәгән авыл,
Ят та кебек миңа, якын да ул...
Килен булып мин төшмәгән йортың...
Төннәреңдә кабызып өмет утын,
Күпме көтте икән карт әниең?..
Язмыш уртак: синең юк этиең.
Ул да һәлак... Исеме янәшәңдә—
Бергә яшисез сез таш һәйкәлдә.

Исемлектә үзең син—җиденче.
Син беренче әмма минем өчен!
Беренчесе... Соңгысы да бул син.
Җирдә ул һәйкәлләр соңгы булсын.
Авыл саен һәйкәл—өши җаннар!—
Дөнья буйлап күпме куелганнар...
Йөрәкләргә мәңге уелганнар
Сезне ялмап алган кызыл таңнар...

Бүген безнең Ярты Төн Бәйрәме.
Бүген мине бик оялтма, яме...
Бик текәлеп карыйларны шулай,
Күрше авылдан килгән шаян малай!
Оялтасың... Минем баш әйләнә...
Соңгы булыр, ахры, бу бәйрәм дә.
Егылырмын төнге төпсезлеккә,
Сине йоткан салкын чиксезлеккә...

Ярты төн тиз үтә. Хуш хәзергә!
Әнә инде кояш күтәрелә...
Озакламам, озакламам мин дә,
Дөнья эшен җыеп бетерим дә,
Дөнья эшен, дөнья сагышларын—
Сәфәремне сиңа багышлармын...
Илле биш ел буе көткән идем,
Артык түзәрлегем бетте минем,
Көтә алмам илле алтынчысын—
Чакыра-дәшә мине синең исем,
Бердәнберем, ирем! Газизҗаным!
«Газизҗаным...»—диеп, гаҗизләнеп,
Сиңа алгысына Төнге Гөлең...

Ярты Төн Бәйрәме иде бүген.

Ә биш көннән—
Бөек Җиңү көне.

*1985—2000.*

# Чәчмә әсәрләр



## Рахмай Хисмәтулла

## «ОНЫКЛАРЫМ, СЕЗ БӘХЕТЛЕМЕ?»

ЛИРИК ПОВЕСТЬ

### Мин аңа ышанган идем...

Яшьлек дәртем белән фанатикларча бирелеп, йорттан йортка кереп, төпченеп, Әнәк тарихын җыеп йөргән хыялый чакларым иде. Ләкин авыр тормыш йөген тарта-тарта хәтерләр киселгән, буыннар өзелгән иде. Үзеннән-үзе тирән тарихлар кемдә дә булса, кайда да булса язма истәлекләрдә генә сакланып калган булырга мөмкин икән дигән карарга килендә. Ә язмалар зыялы кешеләрдә генә булырга мөмкин иде. Андыйларның иң затлысы, әлбәттә, шагыйребез Нур Баян иде. Ләкин аның эзенә төшү дә җиңел булмады. Авылыбызда аны белүчеләр бик сирәк калган иде инде. Белгәннәре дә тирән керә алмый иде.

Нәкъ шул вакытларда авылыбызга бер Агай кайтты.

Һәм ул сөйләде...

Әле хәзер дә ул Агайның сөйләгәннәре исемә төштеме, йөрәгем гел җу итеп китә. Авылыбыздан үсеп чыккан олы шагыйребез, чын булса, шундый кызганыч язмышка дучар булган ки, мин озак еллар буена ул тарихны онытырга тырышып яшәдем һәм бик озак аңа булган карашымны уңай якка үзгәртә алмый интектем.

Бернишләр хәлең юк: ул Агай безнең авылыбызда шагыйребезнең Казан тормышын белгән бердәнбер шаһит дип уйлый идем мин. Агайга ышанмаслык та түгел иде шул. Бабасы аның әтисен мулла итәргә укыткан булган. Тик заманалар совет ягына авышкач, солдаттан кайту белән волком секретаре булып китә. Менә шул волком секретареның улы иде ул Агай. Ватан сугышын кичеп кайтып, вузлар бетереп, кайсыдыр бер авылда укытучы булып эшли иде инде. Аның үз-үзен тотышыннан зыялылык бөркелеп тора иде. Тик... тормышында дөньяда булмаган дөреслекне эзләп бик каты тукмалып, бик бәхетсез булып ята иде булса кирәк ул үзе. Аның ул вакыттагы авыр кайгы-хәсрәте, моң тулы кара күзләре менә кырык елдан соң да минем күз алдымда тора.

---

Рахмай ХИСМӘТУЛЛА (1934)—*шагыйрь, прозаик, публицист. «Салават күпере», «Үземне таптым», «Яшенле тау» һ.б. китаплар авторы. Ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучыларның Гаяз Исхакый премиясе лауреаты.*

Исемдә... без анын белән алар тыкрыгыннан инеш буена төшеп, карт өянкеләр төбенә утырдык.

—Кара инде, бабайлардан безгә менә шушы черек орылар гына мирас шул,—дип сүз башлады ул, колач җитмәс карт өянкеләрдән утырып калган агач төпләренә күрсәтеп.—Ә бит бу өянкеләрнең һәрберсен яңа туган балаларга багышлап утырткан булганнар. Ә кая хәзер алар?..—Миңа черек төпләр бары тик моннан гына тора иде сыман. Ул моң эрегән кургаш сыман минем җаныма тама иде.—Кара инде минем йортыма,—дип дәвам итте Агай, озак еллар кешесез торып каралып беткән, тәрәзәләренә такта сугылган туган йортына ымлап.—Югыйсә бит монда балалар чыр-чуы гөрләп торырга тиеш иде. Әмма хәсрәт мине җиргә сытты да менә шушы хәлгә китерде,—ул тирән итеп уфылдап куйды.—Сине Нур Баян гына кызыксындыра инде, белә-әм...

—Юк, алай гына түгел...

—Әнә шул өянке төбе кебек кенә инде без хәзер. Кырдылар бит безне, бетерделәр.—Аның кара күз төпләренә юшкын булып утырган кара кайгысы, бабалар серен яшергән, гипноз көченә ия сыман кара нурлары минем бәгырьне дә кисә иделәр.—Сугыштан кайтканда мин шушы Әнәгемдә бәхетле гаилә корып, чөкердәшеп балалар үстерермен дип хыялланган идем. Барып чыкмады. Әллә Әнәк мине кабул итмәде, әллә мин Әнәкне. Дөресрәге, кайгы куды мине моннан, туганнарымны югалту кайгысы...—Агай авыр көрсенгәннән соң, дәвам итте:

—Куркыныч, авыр еллар кичердек бит без. Беркемгә дә дөресен сөйләргә ярамады. Бер гаепсез кешеләрне алып китеп юкка чыгаралар иде. Безнең Әнәккә дә яла яктылар. Кара инде син ул Галим абзый белән Таҗи абзыйларны. 1934 елны районнан вәкил килә. Җыелышта Ленин белән Сталинны сайлау турында сүз бара. «Кем соң ул Ленин белән Сталин? Скрипкачымы, гармунчымы, тәрепкәчеме?»—дип сорау бирә тынгысыз Таҗи абзый. «Әйе, дөресен сөйлә син, кемнәр алар? Шарманкачылармы?»—дип көлә-көлә күтәреп ала аны Таҗи абзыйга чыбык очы булган Галим абзый. Бу тетрәткеч сораудан вәкил шыр җибәрә. Һәм шундук җыелышны ябып, кайтып китә. Чөнки мондый сорау өчен анын үзенең дә башын кисәргә мөмкиннәр. Безнең агайларны шул ук төнне икесен дә авылдан урлап ук алып чыгып китәләр. Һәм алар суга баткан кебек юк булалар. Сугышта кан койдык, җан суын түктек без. Тылда калганнар да Кирам, Әгъләм, Сәлим абзыйлар фронтка җылы киемнәр, тире-яры, оекбашлар, кипкән бәрәңгеләр җыеп озатып кына торганнар... Ләкин түккән көчнең игелеген генә күрмәдек.

Ул чагында, энекәш, без барыбыз да башны саклап калырга гына тырыша идек. Мин исән кайттым да соң, ләкин саулыкка туеп булмый. Бик каты контужен булып, күп яралар алып кайттым. Әйе, син Нур Баян белән кызыксынасың инде. Аңлыйм. Ул да балакай башын ничек сакларга белми йөргәндер инде. Күнелсезрәк анын тарихы. Шул башын сакларга тырышып, марҗага өйләнгәндер инде...

Мондый сүзләрне ул чагында мин башкалардан да ишеткәли идем. Тик аны бу Агай сыман зыялы кеше авызыннан тыңлыйсым килә иде.

—Казанда Лозовской урамының өченче номерлы сары агач йортында тордылар алар. Хатыны Мария летчик булса да, язучы хатыны булгангамы, сугышка бармый калды. Берәр ничек җайлагандыр инде, бик шома иде, шельма. Бертуган апам дус кызы, әшнәсе фурмасында Мария янына баргалап та йөргәли иде. Анын бөтен хәлен белеп тора иде. Кызганыч, Нур Баян, мескен, фашистларга каршы сугышта каты кан коя, хатынына сагынып хатлар яза, ә Мария тылда бер майор кисәге белән кутить итә иде. Аракыга акча бик күп кирәк: җиткерә алмагандыр, күрәсең. Ахыр чиктә Мария тота да Нур Баянның егерме ел буена җыйган искиткеч бай китапханәсен базарга алып чыгып җилгә очыра: бөтенләй очсыз бәягә сатып җибәрә. Кульязмалар да, хатлары да, дөньяга чыкмаган шигырьләре дә—барысы да шунда пыран-заран килеп, тузып юкка чыга.

Сызылып-сызылып йөрәгем сызланды. Язмыш дәрьяларының упкыннары тирән, утлары рәхимсез икән шул. И-их, чиксез газаплар аша шагыйрь булып та, хәтереннe шулай жилгә очырсыннар инде...

Агайга мин ышандым, ышанмый да булмый иде шул. Ул тагын да борычлап дәвам итте:

—Аракы эчкәч, алар, майор белән маржа, башларына рюмка куеп, шул рюмкага пистолеттан атып уйный торган булалар. Хәтәр уен инде, үлем белән уйнау. Әз генә каушадың, башына тиден, бетте бит инде. Чыннан да берсендә Мариягә чират житкәч, ул майорны капут ясый, башына тиеп майор жан тәслим кыла. Тикшерү башлана, яклар кешесе—ире Нур Баян еракта, сугышта каңгырап йөри. Мария йорт-жирен, бар әйберен промотать итеп бетергәч, каядыр, әллә Киров, әллә Мәскәү якларына качып китеп, төрмәдән котылып кала.

—А-алла инде... Чын микән соң бу? Бигрәк жәл бит,—дидем мин, үтә каты аптыравымнан.—Ә Нур Баяннан бер бала да калмыймы?

—Нишләп калмасын, кала. Робендер атлы сәер исемле бер улы кала. Ләкин белмим: аның баласы булды микән, юк микән, бик каты сала дип сөйләделәр аны, верәт ли, берәрсе калса, тавыш бирер иде бит, гәзитләргә булса да язып чыгарларые. И-и,—ул өянке төбеннән кара туфрак алып учында кысты.—Туган илләрдән, туган туфрактан бер аерылсаң, тамырлар өзелә икән ул, брат. Хәзер аны, Нур Баянны күтәрүче юк инде. Ә заманында нинди нык шаулаган шагыйрь иде! Мәктәпләрдә шигырьләрен класс белән ятлап, аягүрә хор белән сөйли идек.

Агай сүзен тәмамлады бугай. Минем аңа башка сораулар бирерлек хәлем юк иде. Миңа бик монсу булып китте. Агай исә минем белән саубуллашып, яр башындагы, ишек-тәрәзәсе кадакланган йортына юнәлде.

Ышандым мин бу агайга. Артыгы белән ышандым. Чөнки монарчы авыл карчыкларыннан сорашканда да бер дә төпле сүз әйтүчене таба алмый идем. Алар, шагыйрьне бераз чит-ят иткәндәй, «кызыл иренле бер маржа ияртеп кайта торганые инде шунда» дип кенә әйткәлиләр иде.

Менә шулар тәэсирендә мин «Татарстан» журналының 1995 елгы 5-6 саннарында «Туган яклар сагынып зар елый...» дигән эссемда болай язганмын.

«Туган ягыма кайткач, яланга чыгып утырырга яратам.

Жәйге көн. Күк чалт аяз. Тирә-як гөлчәчәкләргә күмелгән. Сабый чакларым тәгәрәп үткән иске үрләр өстендә тирән уйларга чумам. Хәзер яшел чирәм каплаган бу үрләр—безгә кадәр яшәп үткәннәрнең йортнигез эзләре. Бик монсу булып китә. Жәйге жил әнә үләннәрне, чәчәкләрне тибрәндереп, ул ерак нәселдәшләремнең моң-зарларын, шушы туган нигезләрен сагынуларын сөйли сыман. Чөнки аларның күбесе бу нигезләрдәге гомерләрен яшәп бетерә алмыйча, империя өчен мәжбүри сугышларга китеп һәлак булганнар. Һәм аларның нәсел агачлары корыган...»

Әйе, бүген 25 йорттан торып калган кечкенә генә Әнәк авылыннан йөзләгән авылдашым япон, герман һәм тагын әллә нинди сугышларга китеп, әйләнеп кайтмаганнар.

Алар арасында авылдашым, шагыйрь Нур Баян да бар.

Әйдәгез, аның сугыштан килгән авазына колак салыйк.

*«Ржев шәһәрен күз алдыгызга китерегез. Һәр адым саен немецлар тарафыннан асылынган үле гәүдә. Урамнар буенча кеше түгел, ә күләгә генә булып калган кешеләр ава-түнә йөриләр. Ржевта тиф авыруы таралган. Бөтен жирдә үлекләр, үлекләр. Немецлар шәһәрдә генә түгел, сугыш кырларында да хатын-кызларны мәсхәрәлиләр.*

*Фашист этләре безнең туганнарыбызны әнә шулай асалар, кисәләр, мәсхәрә итәләр.»*

Шагыйрьнең сугышта подполковник дәрәжәсенә күтәрелеп, батырлыгы өчен орден-медальләр алуы белән мактанасым килми. Әле танылып килгән талантлы шагыйрьгә нибары кырык яшь кенә бит.

Исән булса, ул әле ниләр генә иҗат итмәс иде...

Рәхмәт авылдашларыма: алар колхозыбызга аның исемен биреп, идарә бинасы каршысында аңа һәйкәл куйдылар...

Ләкин исемен биреп тә, һәйкәлен куеп та аны туган авылына бөтенләй кайтарып булмый шул. Һич югында аның туган авылында үз нәсел дәвамы булсын иде...

Әмма Нур Баянның бу авылда үз нәсел дәвамы юк. Шулай инде без... Кайсы гына язучы, шагыйрьнең калган соң үз авылында нәсел дәвамы?! Моныкы бигрәкләр дә кызганыч вә аяныч. Маржага өйләнү башкаларның милли тамырын ничек корытса, моныкын да аямаган, җәлләмәгән. Маржага өйләнгәндә һай бәхетле булам дип уйлагандыр инде, мескен. Кайдадыр Казан якларында югалып яшәп яткан урыслашкан балалар Әнәкнең чишмә суларын татымадылар, шагыйрь әтиләренең туган авылына аяк та басмадылар, әйләнеп тә карамадылар. Ах, ни кызганыч, вә никадәр фаҗига...»

Бу хатирәләрдән соң бик күп сулар акты. Нур Баян дөньясын, иҗатын, тормыш юлын күтәрүче күренмәде. Гәзит-журналларда аның моңсу рәсемен күргән саен күзлеге астыннан синең вөҗданыңа туп-туры карап торган бу егетнең дөньяга тавыш бирерлек бер-бер җан иясе—дәвамы калмады микәнни соң, дип, аны бик кызгана идем. Заманаларның артык кырыслыгы да аның эзләрен сөртә, җуя бара иде. Язучыларның гаилә тормышы укучы өчен иң кызыклысы булса да, кызганыч, совет чорында ул турыда чынын бөртекләп язарга ярамый иде шул. Язсалар да, ул да каткан-поткан сәясәттән генә тора иде.

Миңа килгәндә мин дә әнә шул журналда язылганнан артык ерак китә алмый идем.

Хәзер уйлыйм да, үзебезнең, адәм балаларының бер-беребезгә булган битарафлыгына гаҗәпкә калам. Әйтик, әле кем-кайсыбыз шагыйрьнең әнисе Мәүлихәттәй исән чагында аның хәлен белеште? Кем аңа ярдәм кулы сузды? Мәктәптә укыган чагымда: «Ашарына да юк бугай мескеннең, бигрәк читен хәлдә калды инде», дип сөйләнеп йөргәннәрен ишетә идем. Әле Әлмәттәге кызларында, әле Әнәктә кагылып-сугылып йөрде дә, дөньяның бер рәхәтен-хөрмәтен дә күрмичә төп йортына күчте мәрхүмә.

Ил өчен кан койган шагыйрь турында партия-совет органнары да ныклап кайгырткан булса, бәлки әле Нур Баянның өе дә сакланып калган булыр иде. Өй артында үскән шомырт-миләшләре дә, чия, алмагачлары да бәлки исән булыр иде. Ара-тирә аның истәлегенә багышланган кичәләр, әдәби укулар үткәреп, музеен да оештырган булсалар, авыл халкы да, хәтта мин дә аңа башкачарак караган булыр идем. Булмады бит, берни дә булмады. Барыбызны да үз тормышыбызның чиктән ашкан мәшәкатьләре суырып йоткан иде.

## Ачы сабак

Хәзер мин сиңа, укучым, олы шагыйрьгә үземнең битарафлыгым аркасында алган ачы сабагымны сөйләп бирәм.

Үтә дә үзәк өзгеч гыйбрәт булды ул.

Инде кырык ел үтеп киткән. Миндә теге беркатлы милләтче егет тә юк инде. Минем теләгемнән башка да ак сакалым үз урынын даулый. Инде без, язучылар, барыбыз да шаша-шаша мактап җырлаган социализмны да җимереп, капитализм төзеп маташалар. Кешеләр дә үтә кырысланды, элеккеге кебек бер-беренә ярдәм итүләр онытылды, әкият булып калды.

Көннәрдән беркөнне Әнәктә безне—язучыларны, аларның шушы вазифаны үтәргә тиешле оешмаларын оялткандай итеп, Нур Баянның бер чыбык очы булган Айрат Габсәләмов болай дип мине үтә дә шаккаттырды:

—Рахмай абый, әйдәгез әле Нур Баянның китабын чыгарыйк. Менә монда урам почмагында аның скверын да ясап, бәлки яна һәйкәлен дә эшләтербез!

Бәракалла-а! Шагыйрь турында уйлаучы бар икән бит! Кем диген әле син? Дөньяда язучылар барлыгын белмидер бу дип, аңа язучылар сукыр бер тиен дә тормыйдыр дип, мин кул селтәгән егет үзе!

Бу урында мин барысын да ачыктан-ачык язмасам, гөнаһлы булырмын. Эш болай булды. Соңгы биш-алты ел эчендә миңа бу егет белән шактый аралашырга туры килде. Колхозның бөтен төзелеш эшләренә башлык иде ул. Пилорамага да ул хуҗа иде. Пилораманы аерып әйтүем шуңа—чөнки ул минем үзәгемә үтте.

Мин авылда кечкенә генә булса да бер агач йорт салып керү турында хыяллана идем. Бик ераклардан—Алабуга якларыннан, ике йөз чакрымнан, бура һәм такта өчен бүрәнәләр кайтарттым.

Менә шул агачларны пилорамада ярдырып аласы иде. Акча түләп инде, кәнишне, колхоз җитәкчесеннән «Ярып бирегез!» дигән запискам да бар инде, кәнишне. Тагын ни кирәк, китер дә ярып ал...

Ләкин алай түгел икән шул... Бер киләм, ике киләм, йә чират тими, йә пилорама «ватылган» була, йә кызу эш чоры дип якын җибәрмиләр. Олы хөрмәт белән турыдан-туры Айратның үзенә дә мөрәҗәгать итеп карыйм. Ләкин юк кына бит. Һәм өмет тә күренми. Мин генә аңлап бетерә торган кеше булмады ул, ахры. Арада әллә нинди аңлаешсыз томанлы пәрдә эленеп тора. Әллә соң бу шушы болганчык елларның хәйләкәр бер вәкилеме? Әллә соң мин олы яшьтәге кеше аңлап бетерә алмый торган башка хәлләр бармы? Хәтерлим, яшь чагымда авылга кайтып бабайлар белән сөйләшеп утырганда алар белән минем арада еллар, чорлар пәрдәсен тоя идем. Күпме тырышсам да, мин аларны ахырына хәтле аңлап бетерә алмый идем сыман. Ахры, менә үземә дә чират җитте бугай: инде мине аңламыйлар... Бүрәнәләр инде ике-өч ел яңгыр астында җирдә, суда, карда ята-ята муртаеп та беттеләр. Бер булмаса, булмый икән ул. Әллә берәр олы бүләк алып барыйм микән дип тә уйлап куям. Ләкин алтмыш яшьлек язучының да горурлыгы бар бит инде. Кыенсынам.

Бер кайтам, өч кайтам, ун кайтам авылга Чаллыдан, бүрәнәләр урыныннан да кузгалмаган. Ачу килә. Ә үзем һаман могҗиза көткән булам. Менә килерләр дә: «Рахмай абзый, син авылның бердәнбер язучысы бит инде, ярдәм итик әле сиңа, ярып бирик,» дип, ярдәм итәрләр сыман тоела. Ләкин юк...

Башка авылда булса, язучыга ярдәм итәрләр иде сыман да тоела. Башка җирдә, валлаһи, мин үземә ихтирам да тоя идем сыман. Ә монда, туган авылымда, тәмам бәгырьләрем көйде. «Чит илләрдә озак йөрсәң, туганнар да ят була», дип, сагышлы көйләрне кычкырып җырлыйсым килә, аннары утырып елыйсым килә. Бик авыр бит инде бу. Авылга кайтасым килми башлады. Ничек болай була ала икән соң бу? Бу кешеләр алдында нинди гөнаһларым бар икән соң минем? Туганнарым өчен үч алалармы әллә? Күршедәшләр бер-берләрен күрә алмаганнанмы әллә? Алай дисәң, андый дошманлык та бер үтә, бер сүрелә ләбаса.

Туган җирендә үзеңә ихтирам, «әфтәритет» булмауны болай сөйләү түгел, сиздерергә дә ярамыйдыр, югыйсә. Укучым, гафу ит, мин түзә алмадым, ычкындырдым инде. Аннары, минем «мин мин микән, мин кем микән» дип тәкәбберләнеп йөрүне җенем сөйми. Ә юкса бит, монда минем кешеләргә зыян салып та йөргәнем булмады. Киресенчә, «Ватаным Татарстан» газитендә Президент авылын яңартырга чакырып, беренче булып мин язып чыктым. Шуннан соң Әнәккә асфальт килде. Ул безнең тыкрыкка кермәсә дә, Айратның ишек төбенә кадәре үк килеп туктады. Шулай булгач, шуның өчен генә булса да, Айрат, пилорама хуҗасы буларак, валлаһи дим, бүрәнәләремне ярдырып бирсә, бер дә хәрәм булмас иде кебек...

Ә шулай да Фазулла абыем, ике-өч ел буена ялынып йөри торгач, ниндидер бер могҗиза белән ярдыртты аларны. Ләкин суда яткан бүрәнә такталарының сыйфаты китеп, сагызы юылып беткән иде инде.

Күңелдә рәнҗү юшкыны утырып калды. Әнә шунлыктан Айрат минем күңелемә язучылар дөньясына битараф, алар белән бөтенләй кызыксынмый торган чит-ят бер кеше булып кереп калган иде.

Һәм менә һич тә көтмәгәндә шул егет миңа, Нур Баянның китабын чыгарыйк әле, дигән тәкъдим ясады. Мин авылдашларымның әдәбият белән кызыксынуына шатланып бетә алмадым.

Һәм шунда ачыш ясавыма үзем дә аптырап киттем. Бәй, бу тәкъдимне Айрат түгел, ә инде күптән мин үзем ясап, китапны чыгаруда ярдәм кулын сузарга тиеш булганмын түгелме соң? И-и, күпме яшәп тә дөнья рәтен белмәгән беркатлы юләр мин. Соң, Нур Баян белән кызыксынуымны беренче башлап мин үзем сиздерсәм, бүрәнәләрем таза килеш ярылып, ихатама очып кайтып куначаклар иде түгелме соң?

Ләкин андый сүзләрне беренче булып әйтергә әлеге дә баягы авыру милли хисләрем каршы төшкән булгандыр шул мин сабый картлачка.

... Нур Баянның рухы рәнҗемәсен. Ул башка шагыйрьләр кебек үк социализмны ярсу яклап язган шагыйрь буларак, шактый шигырьләре бу капиталистик чорга бик үк ятышып бетмиләр иде инде.

Шунлыктан аның ачы, фаҗигале язмышын ачып бирә торган бер лирик повесть кирәк булачак иде.

## Шагыйрь әтисенең бертуганы

Уфа архивларында эзләнеп, миңа билгеле булганы шул—шагыйрьнең әтисе Габделбаян булып, аның әтисе Галим, аның әтисе Габделгани, аның әтисе Корбангали, аның әтисе Габделвахит, аның әтисе Әпсәләм, аның әтисе—ерак баба Юлай була.

Мин үзем белгән, үзем күргән кешеләр турында гына язарга яратканлыктан, Габделбаянның бертуганы Габсәләмне тасвир итеп, Нур Баян образын да күпмедер ача алырмындыр сыман.

Габсәләм бабайны без Әпсәләм бабай гына дия торган идек. Аның соры киез эшләпә кигән, ябык йөзле чандыр гәүдәсе кыштыр-кыштыр килеп безнең ындыр артындагы бакчада әле һаман да йөридер сыман. Кыярларын, алмаларын шулай кадерләп үстереп йөри иде ул. Аның мәрхәмәтле истәлеге һаман да күз алдында булмый хәле юк. Ул Әнәктә яшелчә, алма үстерүче бердәнбер кеше иде, ахры. Кичерсен бабакай, без малайлар төннәрен аның кыяр бакчасына бурлыкка төшә идек. Их, аның кыярларының тәмлелеге! Хуш исе! Искиткеч була иде алар. Чөнки безгә ул чагында нәкъ менә кыяр витамины житми иде. Бераз ялгышам: ул вакытта татар баласына бик күп төрле витаминнар, бик күп нәрсәләр житешми, житми, житми иде.

Каян килгән аңа бу алдынгы шөгыль, каян белгән ул безнең үлепләр кыяр яратканны? Мин моның серен картның вафатыннан соң, аның карчыгы Гыйльменур әбидән ишетеп белә алдым.

Ә Гыйльменур әби Әнәктән олы дөньяларга чыгып китеп, озаклап читтә йөреп кайткан бердәнбер хатын-кыз иде бугай. Ул бик тә ушлы, урысчаны да яхшук сукалый, бик акыллы, гыйлем карчык иде.

Моннан утыз еллар элек үк ул миңа ярты Әнәкнең шәҗәрәләрен яттан әйтеп яздырган иде. Күпләр хәтта якын бабаларының исемнәрен дә көч-хәл белән генә хәтерли торган бик тә хәтерсез бу заманда ул үз улы Салихжанның һәм Нур Баянның җиде буын бабаларын чатнатып әйтеп биргән иде. Архив аның дөреслеген раслады. Ул болай сөйләгән иде:

«Әнәк тарихын мин бабайлардан бераз гына ишетеп калдым инде, улым. Олы елганың теге ягында марилар яшәгән, диләр иде. Олы елга

дигәне безне Пучы авылыннан аерып торган инеш кенә инде. Ә зиратлары Әнәк ягында булган. Ни хикмәттер, безнең авылда да, башка җирләрдәге кебек, мал чирләсә, мари зиратына алып барып, әйләндереп йөртсәң, мал терелә, имеш, диләр иде. Моның бер-бер хикмәте бардыр инде, булмаса, сөйләмәсләр иде. Аны бер ачарлар әле. Ниндидер бер бик хәтәр яудан соң монда татарлар килеп баскан. Типтәрләр булганнар алар. Аларга җир бирелмәгән диярлек. Шунлыктан әнәкләрдән бик күпләр боярга йөреп хезмәт иткәннәр. Безнең яшь гомерләр дә боярга бил бөгеп үтте. Боярлар урыслар иде инде, Матвеевкада—элекке Кәҗә авылында Никольский бояры барые. Минем әтием Габидулла анда бакчачы, рамчы, балта остасы иде. Боярның балаларын француз кызлары гына укыта иделәр... Аннары Исаеф боярда да тордык. Хуторда. Әти анда унҗиде ел хезмәт итте. Минем булачак картым Гәпсәләм гирман сугышының кызган чагында плингә төшә. Дүрт ел буена шунда интегә. Нимес телен тәмам өйрәнеп бетеп, миңа да «их лиебе дих», дип кенә җибәрә иде. Анда әнәкләрдән яшәп калганнар да булган. Минем икенче абыем Хәбибулла шунда калды.

Гәпсәләм ниместән бик күпне белә торган булдыклы кеше булып кайтканые. Дөнья рәтен танып. Ул Әнәк тормышына гына риза түгелие. Чөнки җирләр дә кысан, тар, җорт салырга урман да югые. Без тоттык та казакъ якларына—Семәйгә чыгып киттек. Анда җиде ел буе яшәдек. Иртеш буенда. Икешәр дисәтинә җирдә иген игеп яшәдек. Шунда егерме дүртенче елның гыйнварында Салихҗаныбыз туды. Усть-Каменогорскига, Үскәминкә генә дия идек, якын идек инде. Анда ирегие. Кыса торган калхуз-мазар да югые. Тик, нишлисең бит, туган якта авыр булса да, бик сагындырды, кайттык.

Минем үз якларым да көчле затларые. Кайсы кая таралып, юкка чыктылар. Рәхмәтулла дигән нәселдәшне урыслар тукмап үтерде. Элек бит суд та, мурт та югые. Кыек муен Шәрифулланың малайлары партизан булып үлеп беттеләр. Миңнехан дигәне кайтканые, Такталачыкта йортка кереп калды. Бәхтегәрәй ачлыкта үлде. Салихморзаның бар иде бер улы. Ул да, үземнең Идиятулла дигән абыем да герман сугышында беттеләр. Дүрт баласы калганые—ачлыкта үлделәр. Безнекеләр гел сугышта кырылдылар. Гел сугышта, әстәгъфирулла, и алла-ам. Авыр туфраклары җиңел булсын».

Рәхмәт Гыйльменур карчыкка, бик асыл зат иде.

Шулай итеп, Германнан алып Уралларга кадәр дөнья гизү Әпсәләм бабайның күзен ачкан. Хәзер Әнәктә ул беренче булып башлаган шөгыль чәчкә ата инде: һәркемнең бакчасында яшелчә-җимеш үсә.

Бүген бу якты дөньяда дөнья бәһасе торырлык затлар Гыйльменур карчык та, Әпсәләм бабай да юк инде. Безнең бу сагынып искә алулар аларның рухын шат әйләсен. Урыннары җәннәттә булсын. Әнием мәрхүмә 97 яшендә дә әрвахлар рухына багышлап җанны иркәли торган догалар кыла-кыла: «Исемнәрен искә алсаң да—алар бик сөенерләр, ә сиңа бик зур савап булыр», ди торган иде. Амин шулай булсын.

Җәйләрен аларның каберләре өстендә, мең төрле кыр чәчәкләре белән бизәлеп, хуш исле печәннәр үсә. И ул үлән-чәчәккәйләрнең әрвахларның җылы өннәрен өреп җилләрдә тибрәнүкәйләре!

## Нәселнең янәшә дәвамы

Хәзер бу зиратны—рухлар, гөлләр илен Әпсәләм бабайның асыл дәвамы, бердәнбер улы Салихҗан ага карап тота. Габделбаянның дәвамы Нур Баян булса, Әпсәләмнеке—Салихҗан. Алар ике бертуган берүк Галим бабай, Юлай бабай дәвамнары. Шулай итеп Салихҗан ага—бер нәселнең янәшә дәвамы.

Мин аның турындагы поэмага тиң язмамны бик озак еллар күңелемдә йөрттем. Ниһаять, менә көн килде. Мин аны тимер һәм гөл жырын бергә кушып кына язарга утырдым. Әйе, әйе, һаваларны сафландыра, нервыларны тынычландыра торган яран гөле утыртыр өчен гөл савыты ясарга кирәк иде. Калдык-постыкларны чыгарып атарга жәлләвем сәбәпле (табигатьнең сулышы кысылмасын дим!) гөл савытының такталарын кагарга да башта бик озаклап, бик тәмләп кәкре кадаклар төзәттем. Һәм чүкеч, һәм сандал, һәм кадаклар музыкасын—тимер рухын уятып тыңлаганнан соң гына, тимер иярләре белән догалар алышкач кына, бөек тимерче, печәнче, зиратчы Салихжан ага турында сүз әйтергә батырчылык иттем.

Иң яраткан шөгыльләремнең берсе булган кадак турайту минем рухымны сихерләп жибәрде. Тимер кисәкләрен юкка гына баш очына куеп йокларга киңәш итмиләр икән. Серле көчләр бар тимердә.

Салихжан ага турындагы бик күптән күнелдә йөрткән, күптәннән әйтелергә тиешле нәсеремне әнә шул тимер сере язарга илһам бирде.

Бу ага Әпсәләм токымының бик көчле нәсел орлыгы булды. Ул бердәнбер буларак юкка чыгарга да мөмкин иде. Әмма ул язмыш-тәкъдирләрнең хәвефле, газаплы юлын гизеп, мәхшәр-сугышлардан да исән-имин кайтып, колхозда тимерче булып эшли башлады. Шагыйрь йөрәкле тимерче иде ул, гажәеп тимер патшасы иде. Әнәк, күрше Пучы, Айман су-яр буйларыннан, юл читләреннән тутыгып, рәнжеп яткан тимерләрне, ниндие туры килсә дә, матур жыр, алтын тапкандай яратып, шатланып жыеп йөрер иде. Ул шулай экологик табиб сыман табигатьне чистарта, киңәйтә иде. Теләсә нинди кәкре-бөкре тимер дә аның оста, кайнар кулы аша узып, бик кирәкле бер әйбергә әверелә дә, сандалыннан елмаеп сикереп төшә иде. Йә, бу шагыйрьлек түгелмени?!

Хәзер инде ул пенсиядә. Әмма мондый чакма йөрәкле, чәер канлы, чыгыр бәдәнле кешене өйдә тик яткыра алу мөмкин түгел икән. Елның һәр фасылында ул үзенә матур шөгыль табар. Ямьле жәйләр житсә, ул—кырлар, печәннәр патшасы. Ул табигатьнең иң шифалы бүләк ризыгы булган печәнгә исраф-әрәм булып ятуга һич тә ирек куймас. Бу аның өчен гөнаһ саналыр иде. Һәр чокыр, һәр ташландык кишәрлек—аныкы! Ул, үләннәрне рәнжүләрдән аралап, үзенең бәләкәй тимер арбасына төйи-төйи, гүя табигатьнең шәфкатен-савабын жыя, жирне дәвалый. Без моны әлегә әйтә генә белмибез. Бу да үләннәрнең моң-хәсрәтен аңлаудыр, бу да шагыйрьлектер...

Салихжан ага тагын бер жирдә патшалык итә—ул зират карауч, аның сакчысы, хужасы. Ул аны туктаусыз барлап, чистартып, тәртип кертеп тора. Коймаларын ныгыта. Корыган-ауган агачларны жыеп, карт тупыл төбендә зур итеп әрвах учаклары яга да, жаны-тәне белән бирелеп, үткән гомерләр, яшәү, жан һәм тән турында моңсу фәлсәфи уйларда йөзә. Аның тимерчелектә эшләп мәңгегә кызгылтланып калган бите-йөзе моңга чума. Күңеленнән әрвахларның бишекләрен тибрәтә, ә иреннәрениләрдер пышылдый. Мин аның ул кыяфәтеннән менә мондый шигырь укыйм:

Аһ, ташлыйсы килми жанның тәнне...
Тәнсез аны кемнәр кадерләр?
Жир йөзендә ятим жанны сагынып,
Елап ята күпме каберләр.
Елап ята тәннәр туфрак булып,
Исраф булып, мәңге мон тулып.
Онытмабыз мәңге дисәләр дә—
Онытылып, бәгърем, онытылып.
Тән белән жан, Сак белән Сок сыман,
Өзелә үзәк мәңге каушусыз.
Исәннәрне генә жәлләгәнгә—
Түзә алар, йөри шау-шусыз.

Яшәсеннәр, диеп, жирдәгеләр
Язмышларга Ходай язганны;
Куптармыйлар тетрәү-давылларны,
Чакырмыйлар Ахырзаманны.
Ә юкса бит, Ахырзаман житсә,
Тәннәргә жан кабат инәчәк.
Аh, чын булса, бөтен галәмнәрне
Мәңгелек нур белән күмәчәк.
Әмма, ни аяныч,
Яңа чәчәк аткан
Сабыйларның гомерен өзәчәк.
Аh, өзәчәк...
... Жаннар түзә, гизә галәмнәрдә,
Кагылып-сугылып көтеп төннәрен...
Тәңре генә белә үзәкләре
Ничек итеп өзелгәннәрен...

Салихжан ага болай үзе бик бәхетле гомер кичерде. Соңгы көннәрен ул бер дә үкенеп каршыламастыр. Жан юанычы, жан тынычлыгы табар өчен аның бөек бер дәлиле бар. Ул яшьлегендә үк төнката урамнарны яңгыратып, бөтен Әнәкләрне ду китереп, үзенең «Жаныйлаең» юкка гына жырлап йөрмәгән икән. Аның ул жыры әле һаман да минем колагымда яңгырый сыман:

Уфалардан кайткан, диләр, әй-әй-әй,
Сиксән сигез матур бичә, әй-әй-әй.
Шул чибәрләр кайтып житкәч, әй-әй-әй,
Сезгә дә көн бетәр әле, әйттер бикәкәй.

Күрәсең, бу жыр башта аның күңелен аңлап бетермәгән берәүгә багышланган булгандыр. Тапты ул үзенә тиң гажәеп кәләшне, тапты.

Кемнәрдер анда милләт өчен иң беренче кирәк булган эшкә—аны ишәйтүгә, үрчетүгә юньле өлеш кертмичә, авыз суларын корытып, «милләт, милләт» дип балавыз сыккан булып, юк-бар вәгазьләр чәчеп йөриләр. Ә үзләре иң күп булса, бер йә ике бала булдыралар да, шуның белән чикләнеп, корып калалар.

Ә Салихжан ага нәселен, милләтен дәвам итүдә Флүн агадан кала авылның икенче чемпионы булды. Ул—бер кыз һәм жиде егет атасы! Жиде егет! Менә кем ул иң булдыклы чын милләтче!

Гүя ул сугыш кырларында бер дәвамсыз ятып калган фронтташ дус-ишләре өчен дә, сыекланып яткан Әнәк токымының умыртка сөяген ныгыту өчен дә, татарда нәселе югалып барган янәшә тугаңы Нур Баяны өчен дә асыл егетләр булдырган. Алар аша гүя Нур Баянның татарлык рухы да, нәсел заты да, милли хыялы да ашкынып якты дөньяга бәреп чыккан.

Юкса, Нур Баян да көчле татар нәселе, ныклы варислар калдыру турында хыялланган бит. Әле алда булыр әле, дип, үзен юаткандыр. Ихтимал, сугыштан соң татар кызына өйләнермен дә, дөньямны янабаштан терелтермен дип өзгәләнгәндер...

Бу нәүбәттән алда сине, укучым, гажәеп сюрпризлар көтә әле... Мин бит әле бик күп нәрсәләрне белмичә йөргәнмен...

Мин еш кына, борынгы нигезләргә утырып, безнең әби-бабайлар ничек, нинди холыклы булдылар икән дип уйларга бирелә́м. Алар, минемчә, нәкъ менә дөньяны тимер арбага утыртып, жиргә ята-ята тартучы Салихжан ага сыман, юмартланып сигез бала алып кайткан, көчле рухлы, тыйнак холыклы хәләл жефете Саимә апа кебек, һәр тутык кадагын жыеп барган бөртекчел, хужалыкчыл, туганнары өчен үлеп торган, юмарт, игелекле, мәрхәмәтле Маһижамал апам кебек булганнардыр.

Болар бер буын, бик тә кешелекле буын кешеләре.

## Шагыйрьнең адвокаты

Дөньяда адвокаты, яклаучысы булмау аркасында күпме язучыларның архивлары юкка чыгып ята. Үзләре вафатыннан соң дан-шөһрәтләре сүнә-сүрелә. Хәтта туган ягында да аны искә алучыларны табып булмый.

Ә ник якын туганнары, балалары, яисә исән булса, хатыны кайгыртмый, диярсез. Әйе, әйе, мин сездән нәкъ менә шундый урынлы сорау көткән идем дә. Ләкин юк шул, бик күп язучыларның туганнары (хатыны турында инде әйтеп тә торасы юк), хәтта балалары да әтиләренең язганнарына бөтенләй салкын, битараф булалар. Аларның интеллектуаль үсешләре моны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгән буламы, әллә язучыдан берничә баскыч түбәндә калалармы, белмим, әмма күп очракта алар язучы мирасыннан бөтенләй читләшәләр. Киләчәктә язучы кульязмасының бик тә кыйммәтле, алтын бәһасенә торырлык бер реликвиягә әверелү мөмкинлеге турында алар уйлап та бирмиләр. Моңа башлары җитмәсен дә ди. Язучы хатирәсен күтәрү аларның үз абруен күтәрү икәнне, бу абруй аларга яшәргә әзме-күпме ямь, җиңеллек китерү ихтималын да, язучы исеменең нәсел горурлыгы булып торуын да, күрәсең, аңлый алмыйлар. Аларда моны аңларга тырышу теләге-омтылышы да сүнгән була.

Нәрсәдән бу? Каян бу битарафлык? Язучыга артык күп уйланып яшәгәне өчен Ходай тарафыннан җибәрелгән бер-бер каргышмы?! Белмим...

Әмма язучының кульязмалары таралып-сибелеп бетә, рәнҗептилмереп яд итү, игътибар көтеп яткан хатирәсе өстенә мүкләр үсә, мүкне сыйпап җилләр исә һәм аннары барысы да онытыла...

Бу яктан алганда Нур Баянның бәхет кояшы, дөресрәге истәлек кояшы батмаган булып чыкты. Ике бертуганы, янәшә нәселдәше легендар Салихҗан аганың бер улы Айрат Габсәләмов, колхоз рәисе булып алгач, алда әйткәнемчә, нәкъ менә шагыйрь турында сүз кузгатты. Айрат моңа тотыныр өчен нәкъ менә үзенең көнен-сәгатен көткән булгандыр...

Тирәнгәрәк керсәк, болай булды.

Айрат, Казанның Төзүчеләр институтын кызыл дипломга, ягъни «отлично»га тәмамлап кайтып, туган колхозында тимерче әтисе кебек берегеп эшкә кереште. Күрделәр: егет сабыр, эш өчен җанын бирә, оештыра белә. Колхозның бөтен төзелеше аның кулында. Алда әйткәнемчә, аның әмереннән башка бер бүрәнә дә тәгәрәмәде, бер такта да шомармады, бер таш та урыныннан кузгалмады.

Әмма тулаем алганда колхоз артык мантый алмады. Чөнки торгынлык заманындагы легендар Замановтан, үзгәреш чорындагы ашкын холыклы, төзү-тимер җене кагылган Әхмәевләрдән соң бик озак еллар буена Әнәк белән Пучыны берләштергән хуҗалыкка юньле җитәкче таба алмый интектеләр. Хуҗалык гел аксап-туксап, сырхаулап ятты. Күрәсең, аның заманасы да шундый сырхау, таркау, башсыз иде бугай.

Шулай да Президент апасының малае Илшат Фәрдиев, бу колхозның рәисе булып алгач, хәлләр яхшыга таба үзгәрә башлады. Усы әбиләре ягыннан сәүдәгәрлек каны уйнадымы, чорны аңлап алып, сату-алу эшләрендә зур осталыкка иреште, күмәк хуҗалыкны Чаллы эшмәкәрләре, сәүдә дөньясы белән бәйләде. Моңарчы хезмәт хакы ни икәнен дә оныткан колхозчы ай саен акча дигән могҗизаны кулына тотып карый алды. Бер ел эчендә хуҗалык аякка баса башлады.

Күтәрелеп китәр көне җиткәч тә, Фәрдиев туган колхозны җил иркенә калдырмады. Ул үзенең урынбасары булып эшләп йөргән Айратка моңарчы да сынап-сынап карый килә иде. Егет ачуыңны китерер дәрәҗәдә тешләк булса да, сабыр бит. Булсын! Җитәкче кеше өчен сабырлык — алтын хәзинә ул. Син аңардан артык сүзне кычкыч белән дә тартып ала

алмыйсың. Булсын! Тавыш, шау-шу, гауга, бәхәс, тарткалаш тулы колхоз тормышында кешегә агулы начар сүзне әйтми калдыру иң-иң кирәкле сыйфат ич ул! Моның өстенә иң мөһиме—төптән-тирәннән үк уйлап эш йөртә. Кешеләр күнелен аңлап, аларга ярдәм итә белә.

Әйдә, кайберәүләр, булмас аннан, эше барып чыкмас, дисеннәр. Аның белән кулга-кул тотынып эшләгән Фәрдиев беләме, әллә юньләп эшләмичә кара гайбәт сатып йөрүчеләр беләме?! Мәңге шулай инде ул: явызлык кылычы үткен, гайбәт әнәсе тирән үтеп керә, ләкин Фәрдиев гайбәтләрне урап кына узды.

Айрат Салихжан улы колхоз рәисе булып күтәрелде. Сөен, шагыйрь Нур Баян, синең чыбык очың, синең исемеңне йөрткән колхозның абруйлы җитәкчесе булды! Хәзер инде аның әмереннән башка яфрак та селкенмәс!

Айрат Габсәләмов үзенең остазы Илшат Фәрдиев сызган юлны дәвам итеп, Президентлар үстереп чыгарган Әнәк тәвәккәллеге, Әнәк дипломатиясе белән бер ел эчендә хуҗалыкны районкүләм яктылыкта тотты. Аның турында хәтта өлкә матбугаты хуплап язды.

Егеткә абруй килде.

Әмма, тел төбемне аңлыйсыңдыр, укучым, Айратның асыл егетлеге төзелешләр күтәрүдә дә, колхозны алга чыгаруда да түгелдер. Андый уңганнар шактый күп алар.

Аның асыл егетлеге авыл һәм районкүләм кешелекле җитәкче булып танылуда гына да түгелдер. Мондый булганнар да, шөкер, очрап тора.

Аның иң асыл егетлеге язучылар, зыялы-укымышлылар өчен, татар халкы һәм киләчәк тарихларыбыз өчен башка бик күп җитәкчеләрдә җитешмәгән сыйфаты ачылуда, Нур баянның исталеген күтәрүне кузгатуда булды! Моның өчен теге вакытны мин аның бүрәнәмне ярдырып бирмәвен дә гафу иттем. Үпкәм-ачуларым сүрелде.

Нур Баян туган нигездә авылны ямьсезләп, мескен итеп, сагышка батырып, моңайтып, гасырлардан калган хәсрәт сыман, мунча кебек каралып беткән кечкенә өйләр тора иде. Ул рәис булганчы ук шул урынга, борынгы бабаларның рухларын сөендереп, таштан бик мәһабәт биек йорт житештергән иде. Бу Әнәктәге беренче таш йорт иде. Бу сиңа теге Матвеевкадагы әбисе хезмәтче булып эшләгән Никольский, Исаев боярларының хуторлары гына түгел инде. Авыл яңарып кына калмады, яшәреп, нурланып китте. Озакламый бу йорт янында, урам почмагында Нур Баян скверы ясалып, аңа исталек ташы да куелачак!

Тик авыл гына моны зурлап билгеләп үтмәде әле. Дөнья бит, бераз көнләшеп куючылар да булмый калмагандыр...

Салихжан-Герой кебек булдыклы, үрчемле янәшә туганы һәм Айрат кебек кайгыртучан эшлеклесе булган Нур Баянның тормышы, юк, мин белгән кадәре генә булырга тиеш түгелдер. Ничек мондый токым андый язмышка гына риза булып түзеп ятсын, ничек мондый югалу белән килешә алсын?! Нәсел энергиясе тигез бүленеп бирелә бит ул—Нур Баянның токымы өзелергә тиеш түгел. Түгел!

Казанга, Казанга—кичекмәгән булсам, барысын да ачыкларга иде!

## Йолдызлар, юлың уңар, диләр

Юлга чыгар алдыннан атналык йолдызнамә миңа сәфәрең уңар, дигән иде. Бирсен Ходай, үзем дә нииндидер бер гаҗәеп күтәренкелек сизеп йөрим...

Мин Казанга килеп төшү белән бик каты кар явып, көчле буран башланды. Радио-телевидение «Юллар ябылды, беркая да юлга кузгалмаска киңәш итәбез», дип һәлакәтләрдән кисәтеп, хәбәрләр тарата иде. Мине әллә фәрештә канатлары саклады инде, килеп җитеп калдым бит.

Иң элек «Мәдәни җомга» гәзитәсе мөхәррире Зиннур Мансуровка

сугылдым. Анда бер ханым тырышып-тырышып Диас Вәлиевнең соңгы сандагы «Җиңелү» дигән мәкаләсен пыран-заран китерә иде. Вәлиев анда үзенең матди хәленең үтә аяныч булуына зарланган иде.

—Соң, ходаем, ул кадәрле инде хәерче хәленә төшәрлек булгач, язма, язучы булма, сине язучы булырга ул кадәр беркем дә мәҗбүр итми бит,—дип чәбәкләде Вәлиевне әлеге ханым.

Рөхсәт-фәлән сорамыйча, гафу үтенмичә, юл ярсуы белән мин дә әңгәмәгә килеп кушылдым:

—Юк, ханым, дөресен яза ул. Бик авыр хәлдәге язучылар бар бит. Аларны шушы хәлдә калдырган җәмгыять җинаять эшли. Олигархлар халык байлыгын, илне урладылар бит. Дөнья болай бара алмый.

—Ярый, мин сине тоткарламыйм, сөйләшегез,—дип, ханым чыгып китте.

Шунда гына мин үземнең әңгәмәгә урынсыз, тупасрак килеп кушылуымны чамаладым. Әмма Казанга бу килүемдә минем бөтен барлыгым һөҗүм дәрте белән тулган иде...

Казан вакытының минутын да әрәм итмәскә тырышып, нәшриятка чаптым. Анда китапханәдән Нур Баянның 1948 елда чыккан китабын эзләп табып, Нәшрият директоры Харис Әшрәфҗановка кердем.

—Менә шушы китапны әйбәт итеп чыгарасы иде бит.

Ул китапны алып актаргалап, укыштырып утырды да:

—Боларны чыгарып көлкегә калмыйк инде. Монда бит Сталин да Сталин. Аның соңрак чыккан китабы бар бит. Шуннан карарбыз инде, сайлап алырбыз,—диде.

Мин Нур Баянның ул шигырьләре өчен бик борчылып куйдым. И-их, лирика гына язып ятасы калган да соң, менә бит хәзер Сталин турындагы шигыре бик читен янгырый шул инде.

Ул финансистларга китапның күпме торачагы турында белешмә әзерләргә кушты.

Ул өлгергәнче һаман да шул Татарстан житәкчелеге турында сүз куерды.

—Монда Шәймиев урынына кунар өчен очынып-очынып йөри башладылар инде. Шулай итеп ул китәр микәнни?—Аның исәбе тел төбемне белеп карауда кебек.—Болай, үзара әйткәндә, тыныч кына алып бара иде бит әле ул дөньяны. Башка булса, ни буласын кем белгән...

—Әлегә бу ситуациядә башка кеше килсә, дөньяның асты-өскә киләчәк, ужас булачак. Әмма, минемчә, аның тирә-юне аңа китәргә ирек куймаячак. Башка йолдыз бик үк күренми бит әле,—дидем мин.

Ул арада, басылачак Нур Баян китабының калькуляциясе әзер иде...

Икенче көнне мин инде конкрет Нур Баян эзеннән киттем. Ләкин кызганыч, Язучылар берлегендә аның турында мәгълүмат таба алмадым. Беркем дә аның элекке яшәгән адресын белми иде. Әдәби фондта да варисларының адресы юк иде. Шулай сине кайгыртып, артыннан йөрерлек варисларың, туганнарың булмаса, беттем, юкка чыктым, диген инде син.

Бердәнбер өмет ике-өч тапкыр аның турында мәкаләләр язып чыккан Айдар Сабирда иде. Аның янына китәр алдыннан «Шәһри Казан» редакциясенә керимме-юкмы, дип, икеләнеп басып тордым. Нигәдер аягым тартты, кердем. Ахырдан гына белдем—бу гаҗәп аяк тарту, йолдызнамәләр белән генә аңлата алырлык аяк тарту булган икән. Югыйсә, Айдар Сабирдан мин бернинди дә адрес таба алмыйча, Нур Баянга юлым өзелеп, Казан уртасында басып каласы булганмын...

«Шәһри Казан»да язучы Равил Вәли белән сөйләшеп торганда нәшриятта эшләгән энциклопедист редактор, язучы Таһир Нурмөхәммәт килеп керде. Болай гына, сүз арасында гына Нур Баян артыннан йөрүемне ычкындырдым.

—Ай-һай, Айдар Сабирдан бер-бер әйбер ала алырсың микән. Дөрес, ул Нур Баян турында язды. Ләкин бик беткән бит инде ул. Бик читен бит аның хәле.

—Ә син, Тарих бабай буларак, Нур Баян хатыны турында бер-бер хәбәр әйтә алмыйсынмы соң?

—Сон, мин аларның торган җирләрен дә беләм белүен. Тик менә фатир номерларын гына хәтерләмим.—Ул шунда ук урам, йорт, фатирларына хәтле планын да сызып бирде.—Анда аның кемедер яши бугай.

—Һо-о! Була болай булгач!—Башларым күккә тиде.

Кара әле нинди гаҗәеп очраклылык! Нинди гаҗәеп сихри туры килү диген син! «Шәһри Казан»га кермәгән булсам, мин моны белә алмый идем бит инде. Ни соң бу?! Нинди фәрештәләр миңа канатҗилпәзәкләр ачып, юллар күрсәтеп торалар икән соң? Әллә йолдызнамә кулымнан җитәкләп йөртәме!

Канатланып урамга чыгуыма каршыма тыйнак елмаеп, шагыйрь Шамил Маннап килә иде. Аның белән олылап күрештем.

—Юбилееңа сүз әйтә алмый калдым. Әйтермен мин сиңа, әйтермен. Йөрәктә син. Чөнки газаплы вөҗданга кидерелә торган таҗлы түбәтәй син,—дидем. Ул елмайды.

—Равил Вәли аша синең монда икәнне белгәч килүем,- диде ул. Юбилеема «Өндәге төшләр» дигән китабым дөнья күрде бит! Хөрмәтләп сиңа бирәм. Бәлки, укыгач, фикереңне дә әйтерсең әле үземә. Юкса, бездә бер-беребезгә битарафлык көчле бит...—Бу аның мине тануы гына түгел, сүземнең көченә ышануы да иде. Нишләп бүген болай мине бөтенесе зурлый соң әле? Хатирә-ядкарьләр күтәреп, изге юлда йөргәнгәме әллә?

## Һәркемнең кызганыч киләчәге

...Чыннан да Айдар Сабир бик тә бетерешкән иде. Өй һавасы мине, нурлы канатлыны мәхшәргә тартып төшерде. Коточкыч иде бу. Инде дүрт ел буена урамга да чыга алмыйча урында беркеп ята каләм заты. Йә, Аллам, бир сабырлык адәм баласына: аның үзенә һәм җәмәгатенә...

Язучының йөзләгән папкалары, китаплары, гәзит-журналлары да авыр ис чыгарып, кирәксез-кадерсезгә калып, төрле җирдә чәчелепсибелеп аунап яталар иде.

Килүемне алдан хәбәр иткәнгәдер инде, мескеннең үзенә бизәкле матур түбәтәй кигезеп куйганнар иде.

—Нур Баян гаиләсе турында ниләр беләсең? Аның хатыны турында сөйли алмыйсыңмы?—дигәч, ул:

—Ул сугышта үлде инде, сугышта үлде,—дип бер-ике сүз әйтте дә еларга керешге.

—Елама, Айдар, елама,—дип юатты аны хатыны,—менә, мине оныттылар, дип ята иде, онытып ук бетермәгәннәр ләбаса.

—Нур Баянның кемнәре барлыгын, адресларын белмисеңме?—дигән соравыма ул:

—Юк, юк, мин аның адресын да белмим, аның бер кешесе дә калмады,—диде. Башка сорауларыма-да ул шул халәт белән җавап биргәч, мин инде бирегә бик сонарып килүемне аңладым.

Хатыны бик каты рәнҗеп зарланды миңа.

—Менә дүрт ел шушылай интегәм инде. Ул хәзер беркемгә дә кирәк түгел. Беркем килми, беркем хәлне белми. Ул бит гомере буена эзләнде, кайларда гына булмады. Сугышта һәлак булган нинди генә кешеләрне, язучыларны күтәрмәде ул. Менә бит аның китаплары...—Ханым бер-бер артлы төрле телләрдә чыккан китапларын алдыма өя барды. Сөйли торды:

—Элек безгә бит кемнәр генә килми иде... Менә бу йөзләгән папкаларны кем рәткә салыр инде хәзер. Болар бит карачысыз макулатура булып югалачак!

«Чыннан да берәр яшь язучы монда килеп эшләсә, боларны икеөч айда рәткә салыр иде. Монда бит инде бик затлы энжеләр дә югалып ятадыр...»—дип сызланып уйладым мин.

—Ә хәзер почет та юк, яклау да юк, ярдәм дә юк. Ни әйтсәң дә сугыш ветераны да бит әле ул. Әнә гәзитләрдә аның китапларын файдаланып язалар, шунда аның исемен телгә алып узсалар да, ичмасам күңел булыр иде. Юк бит. Бармактан суырып язган күпме язучыларның юбилейларын зурлап, олылап үткәрәләр. Ә моның житмеш еллыгын искә алган кеше дә булмады. Житәкчегезгә дә әйтеп карадым, ярдәм итмәде. Телгә дә алмадылар. Үпкәсе шешкән аның, бронхит, адинома, йөрәк, бөтен жире авыру аның. Ходаем ни язган инде. Мин аның белән кырык бер ел яшәгәч, карыйм инде, нишлисең...

Аһ, мин монда мондый зарлар ишетермен дип килмәгән идем шул. Аларны жайлап, көч-хәл белән чыгып киттем. Хатыны Кадрия апа, әлбәттә, ирен карап, бөек батырлык эшли иде. Бөтен вөжүдем белән рәхмәт укып чыктым мин аңа. Мондый хәлгә калсаң, һәм ул озакка да сузылса, синнән хәләл жефетең генә түгел, туганнарың, балаларыңның да баш тартуы мөмкин ич. И Ходаем, жинел үлем вә иман бир кешеләргә...

Урамга атылып чыккач, бик озак жилләрдә, һаваларда йөргәннән соң да, борынымда һаман да шул фатир исе иде. Анда күргәннәрем мине һаман эзәрлекли, бәгъремне телгәли иде. Һәр кешенең шушы хәлгә каласы бар ич әле. Бу бит безнең кызганыч киләчәк. Ләкин ул киләчәкне бу кадәр коточкыч хәлгә калдырмаска иде. Алдан ук бер-бер чарасын күрәсе иде. Бу картлыкка, шушы көнгә хәзердән үк әзерләнәсе иде.

Шәһәр таш капчыгында түгел, ә кайдадыр авылда, шаулап аккан елга буенда, урман-болында, яшенләп-күкрәп яуган яңгыр астында, йә коточкыч буранда калып, йә тау башында кояшка карап жан бирәсе иде. Жаның кояш нурлары белән тоташып, кояшка күчеп калсын иде... Ярабби Ходаем...

## Упкын читеннән бару

Мин Нур Баян эзләреннән йөрим бит әле. Аның турында очерк язгач, Айдар ага аның адресын да, исән булса, балаларын да белергә тиеш иде бит инде. Бу мине бик каты борчуга салды. Барыбыз да бер-беребезгә карата бик битараф шул без. Менә мин үзем дә, Нур Баянның авылдашы була торып, хәтерләр өзелгәч кенә, кырык елдан соң гына аның эзеннән юлга кузгалдым шул. Гамьсезләр без. Юкса бит, мин шушы Казанда укый-эшли сигез ел яшьлек һәм студент елларымны үткәрдем. Һава суларга чыккан чакларда булса да аларга барып килү, хәлләрне белү берни дә тормый иде ич инде. Хәзерге кебек, Чаллыдан йөзәрләгән сум акчаларыңны сарыф итеп, килеп йөрисе булмаган бит. Әле ул чагында Робендер да исән булгандыр...

Мин базардан күчтәнәчләр алып, Таһир биргән схема буенча аларны эзләп киттем. Менә «Рубин» кибете, менә кибет артында эре панельле йорт. Менә икенче подъезд. Менә бер ханым шуннан чыгып килә. Ялгыш кулга эләккән кош сыман йөрәгем леп-леп тибә. Дулкынланам. Булырмы?

—Сез очраклы булса да, дүртенче катта, мену белән сул кулда шагыйрь Нур Баянның берәр чыбык очы торганын белмисезме?—Теге, юк, белмим, белмим, дип, ашыгып китеп барганда, безгә таба килгән икенче бер ханым сүзгә кушылды:

—Ә-ә, андамы, анда кемдер бар. Сез шуларны эзлисездер сыман. Язучының улы күптән вафат инде. Кемнәредер Әмәт тавында аларның. Ә монда, мөгаен, оныклары яшидер.

Әмма монда подъезддагы тимер ишекләр дә бикле була икән. Бер минутка гына соңга калган булсам да, бу ханымнан аймыл булып, мин монда керә алмыйча китеп барасы икәнмен. Рәхмәт яугыры, бу ханым

тимер ишекне ачып, мине үзе белән алып керде. Серләр ачыла башлаячак фатирны күрсәтте: 53 нче фатир иде ул.

—Адель, Адель,—дип дәшеп карады ханым. Әмма 53 тән беркем дә җавап бирмәде. Нишләмәк кирәк, мин: «Кичен килермен»,—дип, язу калдырып, китеп бардым.

Сәгатем житсен дип, беразга гына «Мәгърифәт» редакциясенә, күптән күрешмәгән шагыйрь Әхмәт Гадел дустым янына сугылдым. Ул:

—О-hо-hо! Тере классик килгән,—дип, уенын-чынын кушып мине үсендереп, дәррәү урыныннан күтәрелеп, тирә-юньне шаулатып каршы алды.

—Юк, юк, мин түгел, менә Рәшит классик,—дидем мин, күрше өстәл янында утырган Ягъфәргә күрсәтеп.—Ул Салсал батыр сыман милли мәгърифәт өчен көрәшә ич.

Соңгы вакытта мин Әхмәт Гадел турында бер мәкалә язган идем. Чыннан да ул урыс телендә, урыс тарихында яшеренеп-күмелеп яткан татарлыкларны тузаннардан шундый да оста кагып ялтыратып тартып чыгара, башта тиз генә ышанмыйсың, алар ялган сыман тоела, аннары уйланып-уйланып хәйран калып торасың. Кара әле, дөрес әйтә бит бу шайтан, дисең. Шуның өчен дә һәм сүзе белән сине тетрәнүләрдән арындырып, күңелеңне күтәреп җибәрә белүе өчен дә хөрмәт итә идем. Шуларга минем турыдагы «классик» дигән ялганы да килеп кушылгач, күңелдә шушы шигырь туды:

Яратам мин, Әхмәт дустым, сине,
Язганнарың өчен яратам.
Валлаһи, дим, чын күңелдән сине
Ялганнарың өчен яратам.
Шулар белән рәхәт әкият синең—
Балаларча матур, сөйкемле.
Әллә нинди серле тойгыларны
Уята-уята назлый күңелне.
Шундый керсез, матур ялган алар,
Өзелгәннәр кабат ялганалар.
Бар хәтерләр томаланып беткән,
Синдә генә исән калган алар.
Ялганнарда күккә ашырасың,
Айкап-чайкап тәңре катларын.
Ул катлардан юынып һәм яңарып,
Батыр булып күренә татарым.

Мин Нур Баян эзеннән йөреп, очерк язып аның китабын чыгарырга йөрүемне әйткәч, аның йөзендәге елмаюлар сүрелде, ул бик житдиләнеп калды һәм, коедан таш тартып чыгаргандай авырыксынып, әйтеп куйды:

—Беләсеңме, ул шәхескә карата миндә антипатия көчле бит.

—Ну-ка, ну-ка,—Аның телен ачар өчен мин сүз сөрешен бераз сабынлап та куйгандай иттем.—Миндә дә менә аңа карата электән үк нидер бар иде бугай шул. Ләкин менә шуны ачыклап бетерә алмыйча гомерем үтте. Ә бәлки без ялгышабыздыр?

—Бәлки, бәлки... Бервакыт Сибгат ага Хәким белән опера театры яныннан үтеп барабыз. «Менә, Әхмәт,—диде Сибгат ага, сугышка китәр алдыннан менә шушында Нур Баян белән очрашкан идем мин. Кинәт кенә каршыма килеп басты да бу минем: «Бәй, син исәнмени әле? Сине атмадылармыни әле?»—диде. Мин куркып калдым. Фронтка китәргә дигән повесткам кесәдә иде, барыбер беткән баш беткән инде, ичмасам әйтеп калыйм дип, мин дә турысын бәреп әйттем:

«Мин үлмим әле, мин синнән соң да яшәячәкмен әле»,—дидем дә кызу-кызу атлап, китеп бардым. Бер-бер чара күрә күрмәсен бу дидем дә, өйгә кайтып тормыйча, вокзалга чаптым. Аннан хатынга шалтыраттым: хәзер үк вокзалга мине озатырга килеп жит, дидем. Шуннан туп-туры

фронтка китеп бардым. Шул очрак минем күңелемдә бик озак яра булып йөрде. Аннары гафу иттем инде. Ул да шул чор корбаны иде бит. Сталин вассаллары кешеләрнең кире сыйфатларын бик оста файдаланып эш итәләр иде. Язучыларның да көнләшү, күралмау, башкалардан алга чыгарга тырышу аркасында бер-берләренә төрлечә яла ягулары гадәти бер хәл иде...» Менә, дустым, Сибгат аганың шул сүзләреннән соң, мин Нур Баян турында ни уйларга тиеш соң?..

Якташ шагыйрь эзләреннән йөрүләрем мәгънәсезләнеп калгандай булды. Күңелем төште. Әмма эчемдә бүреләр уласа да, мин аны Әхмәткә сиздермәскә тырыштым.

—Соң, дустым, язучылар арасында элек нинди генә хәлләр булмаган соң инде. Шәйхи Маннур, Хәсән Туфан, Мин Шабайлар, Фатих Кәримнәр төрмәләрдә юкка утырып чыкканнармы? Әле бүгенге көндә дә андый ызгыш-талашларның тукталганы юк бит. Язмышлар безнең кәкрәеп-бөкрәеп беткән инде...

Анысы-анысы, Әхмәт боларны аңлый. Ничек итеп моны авылдашларыма, шул ук Нур Баян өчен ут йотып йөргән Габсәләмовка аңлатыйм? Андый хәлләрне бу хәбәрдарлык заманында инде читләтеп үтәргә дә ярамый. Борычлап, кылычлап тәнкыйть итәргә торучылар гаскәр, гаскәр. Аннары, моны язмасаң, гыйбрәтсез, ялган китапның кемгә кирәге бар?

Тышта караңгы төшкән иде инде. Мин башта 53 фатирга, Адель дигән егет янына җәяү генә юл тоттым. Әхмәт сүзләреннән соң шомлануым көчәйдеме, курка башладым. Кайдадыр мине сугып егарлар да, кулымдагы күчтәнәчле сумканы талап алырлар сыман тоелды. Юкса, бер генә тукталыш барасы калган иде инде, куркуым мине янәшә барган троллейбуска куалап кертте.

Кызганыч, ул фатир тәрәзәсендә утлар юк иде. Кышкы салкында бер сәгать буена әле кибетләргә кереп, әле тегендә, әле монда сугылып, әйләнеп-тулганып йөрдем. Ут кабынмады. Подъезд төбенә барып бастым. Аның ишеге тагын бикле иде.

Әһә, менә, ниһаять, бер хатын шушы подъездга таба кайтып килә. Кышкы караңгылык, кеше юк, ә бандитлардан куркалар. Аның минем белән сөйләшеп тә тормавы мөмкин иде. Бар барлыгым белән үземнең бандитлар төркеменнән түгеллегемне ничек тә расларга тырышып, йомшаак кына итеп, ялынып-ялваргандай шул фатирны сораштым. Рәхмәт яугыры, аңлады мине.

—Адель монда бик сирәк була шул,—диде.—Аның менә шушы ук йортта әнә теге почмакта, дүртенче катта туганы бар. Шулардан кереп сорап карагыз, алар белергә тиеш аны. Ләкин әнә аларның да утлары юк икән шул әле. Көтегез, бәлки, кайтырлар.

Менә бит, подъезд төпләрен саклап булса да, хәбәрләр җыештырам. Ярый хәлемне аңлап, фәрештәләр миңа аларны белгән кешеләрне җибәреп тора. Юк, йолдызнамә юкка гына миңа уңышлы юл вәгъдә итмәгәндер.

Кышкы суык мине инде шактый биетә иде. Тагын әйләнеп-тулганып йөреп килдем, ике фатирда да һаман утлар алынмаган иде. Калганмы соң аның үзеннән соң берәр җан иясе, әллә бөтенләй өзелгәнме? Белеп булмый, булмый бит белеп.

Студент елларымда шушында килеп танышып йөрмәвемә бик үкендем. Ни әйтсәң дә, ул бит әле мин яраткан Әнәк тамыры да, минем кавем-кабилә тамыры да.

Әмма ул тамыр өзелгәндер шул. Өзелмәгән булса, шагыйрьнең 80-90 еллыкларында кем дә булса берсе гәзитләрдә истәлекләр язып чыгар иде. Ни дә булса булыр иде. Ә болай ул билгесез, бер хәбәрсез югалган шул инде. Беркеме дә калмагандыр аның. Калган булса да, урыслашып беткәннәрдер. Хәзер инде алар, гадәттәгечә, татар ягына, татар бабалары ягына борылып карарга да җирәнәләрдер. Аһ!

Ул Робендерлар, аның дәвамнары каядыр еракта, барып җитә

алмаслык томан эчендә иде инде хәзер.

Үзем дә, бөтен татар да бик кызганыч тоелып, бик монсу, ямансу булып китте.

Уйлар белән буылып,
Калды моннарым сулып.
Үтерә бу монсулык,
Җан елый сулык-сулык.

## Әһә, тәрәзәдә ут кабынды!

Кат-кат киенгән булсам да, инде ныклап тундыра башлады. Тагын якын-тирә кибетләрне әйләнеп йөреп бетердем. Оныгыма фломастер, үземә стерженьнар сатып алдым. Йортның башка фатирларында бер-бер артлы утлар кабына торды. Әнәктән килгән мин мосафир өчен ут кабынмый да кабынмый иде.

Тыштагы февраль салкынлыгы, караңгылык, бикле подъездлар төбендә ялгыз калуым, Әхмәтнең әле генә сөйләгән авыр хәбәре минем хәлемне тагын да авырайта, ятим итә иде.

Урамнарны дүртенче кат урап килүемә кардәшләре дигән тәрәзәдә, ниһаять, ут кабынды. Минем өчен өметләр, хәбәрләр кабынды!

Подъезд төбенә йөгереп үк бардым, ләкин ул бикле иде. Дүртенче каттагы утка, подъезд эчендәге утларга бик озак тилмереп-тилмереп карап тордым. Берәү дә керми дә, чыкмый да... Инде салкын аяктан йөрәкләргә хәтле үтте бугай. Их, бу тимер ишекләр, аһ, бу бикле тимер ишекләр! Хәзер аны фатирларга гына түгел, подъездларга да куеп бетерделәр.

Аларны төнлә генә түгел, көндезләрен дә бикләп тота башладылар. Социализм заманында юк иде бит алар. Бу кадәр бандитлары да юк иде. Әйт дустың кем һәм мин синең кем икәнлегенне әйтеп бирәм дигән сыман—илендә бандитлар үрчиме, үрчесә, шуларга карап, хөкүмәтең турында фикер йөрт инде. Җен ачуларым чыкты...

Ни булса шул булыр дип, бер агач ботагы сындырып алдым да беренче катның утлы тәрәзәсенә таба якынайдым. Ләкин мин тәрәзәгә әз генә төртүгә үк бүлмәдә ут сүнде һәм подъезд эчендә дөбер-шатыр ишек ачылган, урысча сүгенгән хатын-кыз тавышы ишетелде:

—Вот придурки, вот придурок, кем сезгә минем тәрәзәмне кагарга рөхсәт бирде?

Күрәсең, алар, минем подъезд төбендә озаклап йөрүемнән шикләнеп, күзәтеп торганнардыр. Мин төшенке тавыш белән акландым:

—Подъездга үтәргә, дүртенче каттагы фатирга керергә кирәк иде. Бик салкын бит, гафу итегез инде!

—Какое мое дело! Кемгә килден, шуның тәрәзен как, придурок! Ә үзе җитмәсә сакаллы.

—Мин еракта́н килгән мосафир.

—Төкерәм мин синең мосафирлыгына!

Борын-борыннан ерактан килгән юлчыларны хөрмәт итү дигән нәрсә бар бит инде. Әмма бу маржа минем авыр хәлгә калган юлчы булуым турында уйлап та карамый. Дөрес эшлидер, мин аның өчен фатир басу ихтималы булган бер бандит кынадыр. Шунлыктан маржаның бу кадәр мыскыл итеп сүгенүе (матларын төшереп калдырдым) мине артык рәнҗетмәде. Иң мөһиме—миңа тимер ишек ачылды. Мин хәзер дүрт дистә ел буена белә алмаган хәлләрне беләчәкмен!

Дүртенче катка ничек очып менгәнемне дә сизми калдым. Ахры, гомеремдә беренче мәртәбә шулай очып менгәнмендер. Кыңгырау төймәсенә бастым.

—Кто?—диде бала тавышлы берәү.

Берданбер ышанычлы сүз «Адель» генә булырга мөмкин иде.

—Я от Аделя,—дидем мин. Инде төн якынлаша, ачмаулары да бик мөмкин иде.

Ачкыч-йозак шалт-шолт килде. Ишек ачылды! Минем алда ябык кына, аксыл, матур мөлаем йөзле бер кыз бала басып тора иде. Беренчеләрдә укыйдыр.

Әңгәмә урысча барса да, татарчага күчереп бирәм.

—Әти-әниең өйдәме соң?

—Юк.

—Ә өйдә кемнәр бар соң?

—Мин берүзем.

—Ә кем белән торасың соң?

—Мин әбием белән яшим.

—Ә ул кая?

—Эштә ул, эштә... Ул төнге уникедә генә кайтачак әле.

Башка ишекләрдән бу сөйләшүне тыңлап торсалар, бу бик куркыныч иде. Мине фатирбасар дип гаепләүләре мөмкин иде. Шунлыктан мин тавышымны кысып, куркып кына сөйләшә башладым.

—Ә нигә алайса ишегеңне ачтың? Болай ярамый бит.

—Сез бит Адельдән килдем, дидегез.

—Алайса, син аны беләсеңмени?

—Ул минем абыем бит. Ул әнием белән яши. Моннан аларга өч-дүрт кенә тукталыш.

—Ә син татарча беләсеңме?

—Э, нет!

—Ә әбиеңнең исеме ничек?

—Нурия.

Эчемә жылы йөгерде. Димәк, монда Нур Баяннан соң Мария яклары түгел, ә Нур Баян яклары өстен алган икән дип уйладым мин. Менә-менә күңелгә килгән алга килә ул, безнең сөйләшүне ишетеп, бишенче каттан бер татар карчыгы төшеп килә иде инде.

—Сез боларны белмисезме,—дидем мин, аңа турыдан-туры татарча.— Мин бик ерактан килгән идем, әбисенең кайтканын көтеп тора алмыйм. Ят шәһәрдә кире кайтуы куркыныч бит.

—Аларны мин белмим шул,—диде татар карчыгы.—Аларның Клара дигән кешеләре бар иде инде. Аның балалары күп иде бугай. Ул Украинага кайтып китте, маржа иде. Боларның Казанда туганнары бар, ләкин төгәл генә әйтә алмыйм.

Нурия әбинең ике көн эшләп, ике көн ял итүе ачыкланды. Мин бер көннән иртә белән килергә сөйләштем. Һәм күңелгә нур сирпеп торган бик сөйкемле бу бала һәм мөлаем татар карчыгы белән саубуллашып, күңелемә әллә нинди рәхәт нурлар бәйләме алып кайтып киттем.

Гүя Ходай, шагыйрьне белгән кешеләр белән очраштырмыйча, серләрнең ачылуын юри шулай озакка суза иде.

Аннан мин шәһриказанлылар таралышканчы кайтып элгәштем. Алар минем тирәмдә шау-гөр килделәр.

—О, Рахмай абый, синең дин турындагы язмаңны бик ошаттылар, унбиш бит килеш тәкъдим иттеләр. Корылтайга шәп була,—дип шауладылар. Равил Вәли үзе дә: «Фотоң белән бер бит итеп бирәбез», дигәч, мин шактый ук күкләрдә йөздем. Бәхәсләр уятмый калмас. Ни әйтсәң дә, мүкләнеп каткан урынга кагылам бит, динне татарчага күчерүне күтәрәм. Алга китеп әйтим, бу мәкалә чыннан да бик оригиналь булгандыр. Ярты ел буена аның тирәсендә бәхәсләр дулкыны тирбәлде. Кемдер хуплап, кемнәрдер сүгеп яздылар. Сүгүчесе күбрәк иде, ахры. Әмма затлы журналист Римзил Вәлиев аны телевидениедән елның иң яхшы мәкаләләреннән берсе дип билгеләп үтте.

## Бер ишектән бер ишеккә нур эзләп...

Нишләптер, беркем дә миннән «син кайда кунып яшисен сон Казанда?» дип сорамый иде. Ә бит ул бүгенге көндә ин авыр проблемаларнын берсе. Мин кунакханәгә кереп урнашып, тәүлегенә 60-70 сум түләп яши алмыйм бит инде. Алай итсәм, ике-өч көндә ыштансыз калыр идем.

Шул ук вакытта Казан мина бик кадерле иде.

Чаллыда зыялылар белән аралашу җитмәүдән зарыгып, саргаеп яшәүче мин фәкыйрегезгә Казан вакытынын һәр минуты алтынга тин. Ни әйтсән дә, башкала татарнын бөтен акыллы зыялысын магнит сыман шушында тартып җыйган. Алар белән бер очрашып биш-ун минут сөйләшеп алу да үзе бер академия. Монда кемнәр белән генә күрешмисен дә, нинди генә хәбәрләр, әкәмәт сүзләр ишетмисен. Заманында мине Казаннан биредә борынгы тамырларым һәм фатирым булмау куаласа, икенчедән, анын эчкечеләр дөньясында харап булуымнан куркып, Түбән Кама кебек яшь шәһәргә китеп барган идем. Инде хәзер Казанга кире кайта алмыйча гомерем үтеп бара. Әмма барыбер мин әле бирегә кайтырмын сыман.

Килгән саен мондагыларнын бу шәһәрнен авыр шартларына түзеп, һаман да иҗат, милләт, дип язу-көрәшләренә хәйран калам. Мондагы һәрбер иҗат шәхесе үзе бер газап лабораториясе ич. Казанга килгәндә-киткәндә мина, дөресен әйткәндә, Ходайнын рәхмәте төште. Мин абыемнын кызы Гөлүсәләрнен фатирында бушлай яшәп китәм. Редакцияләр белән янәшә урнашкан йорттагы дүрт бүлмәле якты, рәхәт, яна фатир ул. Гөлүсә үзе киявебез Госман белән Сухарекада болын кадәр иркен ике катлы йорт, юк, йорт кына түгел, коттедж салып чыктылар. Мин яулап ала алмаган Казанны, ичмасам, алар, абыемнын балалары, яулап алдылар.

Гөлүсәләр эшләп алган бу затлы фатирны абыемнын өйләнмәгән, әмма гаҗәеп тәртипле, эшчән, унган улы Феликс, Гөлүсәнен балалары өйләнгәнне көтеп, саклап, карап бер үзе яшәп ята. Минем өчен хөррият инде монда. Хет шунда вакытлыча берәр әдәби салон, яисә берәр фирка офисы ачып җибәр. Мин монда мескенлектән өстен, мин монда үз иркемдә, үз хыял-иҗатымда йөзәм, җиде каналдан җиде төрле программа карап, Казан гәзитләрен укып кинәнәм, тантана итәм.

Танырга кирәк, дуслар, Казаннын урыс гәзитләренен теле, стиле, кыюлыгы, югары юморы, энергиясе, заманчалыгы белән татар гәзитләреннән күпкә өстен. Татар гәзите һаман да тел, милләт тирәсендә казына, ләкин аны үзәкләргә үткәзерлек көчле итеп, давыл куптарырлык итеп күтәрә белми!..

Бу фатирда мина ураза тотарга да бөтен шартлар бар. Ураза көннән-көн минем зиһенемне ныграк ача килә. Кар-буран булса да, җандатәндә гаҗәеп сафлык, җинеллек, хушлык тора. Тән, ашаган ризыкка бик сизгер реакция биреп, артык баллы капсан да, кычыта башлый иде...

Абыемнын балалары бик унган, булдыклы булып чыктылар. Болай каты мактануымнын сере турыдан-туры Нур Баянга да барып тоташа. Юкса, бәлки болай тәфсилләп тә язмас идем. Ул болай: абыемнын хатыны Рәйсәнен әтисе Нургали бабай Нур Баяннын туганнан-туганы. Әйе, әйе, алдамыйм, валлаһи. Нургалинен әнисе Хәдичә әбекәй Нур Баяннын әтисенен сенелесе. Менә бит ул, дөньялар кайлардан кайларга килеп тоташа.

Димәк, Нур Баян истәлегенен тузаннарын кагып төшерү, анын чын образын калку итеп дөньяга чыгару ул әле минем туганлык-кодалык бурычым да икән бит.

* * *

Алтынчы февраль коры суык, аяз, бик рәхәт көн иде. Мин иртә белән үк татар халкының иң асыл әдәби мәгълүматлары саклана торган җиргә, университет китапханәсенең сирәк кулъязмалар бүлегенә ашыктым.

Барышлый янабаштан төзелмәк булып яткан тимер юл вокзалы корылмаларын, хатын-кызларыбызның базар тирәләрендә салкында сату иткән булып басып торуларын, авыр йөкләр күтәреп изалануларын күреп, кәефем кырыла. Адым саен диярлек хәер сорашучылар. Кызганыч. Ни булды безгә?! Ил җимереклеге Гражданнар сугышы чорларын хәтерләтә. Ә юкса, алай булырга тиеш түгел иде бит, түгел иде.

Сирәк кулъязмалар бүлеге хуҗасы, күптәнге танышым, татарның асыл зыялысы Җәүдәт Миңнуллин мине хөрмәт белән каршы алды. Ул каты эшлидер инде, бераз ябыга төшкән, саргайганрак та димме, нечкә кысалы күзлекләре дә тартылып, ябыгып киткән шикелле.

Соң, шулай булыр инде. Иске кулъязмалар сиңа шомырт чәчәкләре түгел. Аларда күпме борынгы кер һәм авыр ис... Элек биредә минем якташым мәшһүр Альберт Фәтхи эшләгән иде. Әллә инде шул иске кулъязмалардагы мең төрле микробларны сулый-сулый зәгыйфьләнде, ялгызы яшәп, китап шыплап тулган фатирында һич тә көтмәгәндә вафат булган иде. Аның турындагы бик тә кадерле истәлекләрем үзенең чиратын көтеп ята...

—Кызганычка каршы, бездә Нур Баян турында мәгълүматлар сакланмаган,—диде Җәүдәт.—Сиңа тарих институтына Марсель Әхмәтҗанов янына барырга кирәктер. Менә анда язучыларның архивларын җыя башладылар. Мөгаен, аларда Нур Баянныкы да бардыр.

Бик зур өметләр белән мин тарих институтына юнәлдем. Ниһаять, максатыма якынаям бугай. Тарих институты бирегә инде берничә ел элек үк күчкән булса да, бинасы һаман ремонтланмаган иде. Әллә ничек бөтен җире караңгы, җимерек-җомырык, стеналарда купкан, ярылган урыннар... И-и, илне уңнан да, сулдан да талаучылар ялт итеп торган коттеджлар, тәкәббер офислар, наркотиклы төнге клублар салалар, ә татар тарих институты ягына борылып караучы да юк икән. Хөкүмәтне әйтеп тә тормыйм. Кая икән соң ул безнең «яңа байларыбыз», кая икән хәлле бай патриотлар? Үз тарихларының ятим булуы киләчәктә аларның үз балаларын ятим итәчәген эш узгач кына аңларлар шул бу байлар...

Галим урынында юк иде. Казандагы вакытымның минуты да алтынлыгын истә тотканым хәлдә, авыл тарихлары бүлеге мөдире Равил Әмирханга сугылдым. Татар тарихын яктыртып утыручы үзе бер йолдыз кебек шәхес тә сүзен зарланудан башлады:

—Менә Әмирханнар фонды ачып җибәргән идек тә, артык эш майтарып булмый шул, акча күчерүче юк.

Әнә шулай кая барма, кая кермә, дөнья зар белән тулган иде. Ул миңа Әнәк авылы тарихын Таһир Кәримовтан белешер өчен телефоннарын бирде. Кәримов миңа таныш егет иде инде. Үз эшенә фанатикларча бирелгән бик сәер кеше иде ул. Әнәккә килеп тарихларны өйрәнеп йөргәндә мин аңа шактый булышлык күрсәткән идем. Ләкин ул гына менә тәртәгә типте бугай. Чират житсә, язарбыз.

Мин кабат әйләнеп килгәндә мине шыксыз бер бүлмәдә чал чәчле Марсель Әхмәтҗанов көтеп утыра иде. Искереп беткән, нурсыз, соры бер журнал битләрен актаргалап алды да:

—Болай унлап язучының архивы бар бездә. Ләкин Нур Баянның берние дә юк шул. Барлык язучыларның да кулъязмаларын җыяр идек тә, акчабыз юк. Әле менә Риза Ишморатныкын, Ибраһим Салаховныкын алган идек, аларга түләргә дә акчабыз юк. Татар язучыларының архивлары төрле җирдә таралып беткәннәр инде алар. Менә Әпсәләмов белән Мирсәй Әмирләрнең архивлары һаман хатыннарында саклана. Бәяләре

күтәрелсен дип, бирмичә үзләрендә саклап маташканнар иде дә, менә, замана кирегә борылгач, аларның бәяләре төшкәннән-төшә бара. Ә Нур Баянның аның архивы Дәүләт музеенда түгел микән, Җәлилләр белән берләттән. Анда берничә язучының архивы бар, сина шунда барырга кирәк.

—Да-а, шәптән түгел икән, Марсель туган, безнең хәлләр. Зыялы халыкларда язучы архивлары бер урынга Дәүләт архивына тупланганнар бит. Кем күтәрергә тиеш соң моны?

—Кем белә инде аны, әйтә-әйтә без дә ардык инде. Милләтнең, гомумән, үзәге юк бит безнең, юк... Ә Нур Баянга килгәндә, ул болай төшеп калганнардан булмаган, ахры. Үзен бер дә обидага бирмәгән ул, кыю, тәвәккәл, үзенекен итә торган кеше булган. Сугышта подполковник дәрәҗәсенә ирешә бит ул. Мондый хәрби дәрәҗә татар язучыларыннан бик сирәкләргә генә тәтегән. Көчле ихтыярлы кеше булган.—Чал чәчле әдип-галим, күзләрен челт-челт йомгалап, бераз көлеп тә алгалап, бераз чеметтереп алгандай итеп тә сөйли иде.—Аны менә безнең заманның крутой-хәтәр егетләре кебегрәк тә булган, диләр бит. Пистолет белән генә йөргән бит ул. Моны миңа укытучы әтием сөйләгән иде. Моны башка беркемнән дә ишетә алмассың син. Әтием Казанга килеп язучылар белән аралашып йөри торган булган. Ул вакыттагы язучыларның бер-берсенә мөнәсәбәтен гаепләп булмый инде. Хәзер генә тәүфикълы песи сыман йөргәч тә, күпләр бер-берсе өстеннән донослар язганнар. Империя шымчылары язучылар арасын болгатып, кара шәүләләр уйнатып торган.—Шул заманнарның стрессларын саклап торкан сыман ярым караңгы бүлмә, иске шкафлар, буялмаган стена-идәннәр безнең бу сөйләшүне тагын да караңгылата, тагын да шомлы итә иде.—Әле ярый, хет ичмасам менә хәзер авызны ачып сөйләшә алабыз. Шунысына рәхмәт әйтерсең.

Бу ифрат кызыклы әңгәмәчедән аерылуы бик кыен булса да, миңа Нур Баян артыннан чабасы иде.

Дәүләт музееннан мин берни дә таба алмадым. Шулай итеп, җил иркендә калдым. Соңгы өмет—иртәгә: ул очрашу миңа йә ни дә булса ачачак, йә мин бернисез кайтып китәчәкмен...

Ә татар язучыларының архивлары язмышы турындагы уйларым, муеныма авыр таш асылган сыман, өйгә дә ияреп кайтты.

Төн. Казан үзәгендәге тугыз катлы йортның иң өске катында әйбәт якты фатирда мин. Моннан бөтен Казан уч төбендәге кебек күренеп тора. Казан һәм татар язмышы да уч төбендә кебек. Ризыгым бар, ятагым чиста, бүлмәм җылы, ләкин күңелдә болыт, әллә нинди татар ятимлеге. Барысы да бик тиз уалырга, җимерелергә тора сыман. Бик мескен бит әле бу милләт дөньясы. Ирек килеп тә, без әле аңардан рәтләп җимешләр өзеп каба алмадык. Бүген әнә күпме җирдә зарлар ишеттем. Йоклый алмый ятам. Салкын карасу зәңгәр күктән миңа чекрәнләп Ай карый. Дөнья шулай шул ул, абзыкаем, ди кебек ул. Әйе, син язучы булып, синең әллә нинди кульязмаларың да булырга мөмкин. Ләкин син аны саклый белмәсәң, мәңгелеккә алып китә торган ышанычлы кулларда калдырмасаң, язмаларың вакыт упкынына төшеп югалачак!

Каян табарга соң миңа хәзер Нур Баянның архивын? Гадәттә, язучы үз язганының өчтән берен генә дөньяга бастырып чыгарып кала. Аның күп өлеше архивына салына бара. Кая Нур Баянның сөйгәннәренә, дусларына, туганнарына язган җырлары, шигырьләре? Кая табыннарга багышланган хикмәтләре? Кая аның күңеленең шикләре, сагышлары? Кая җаны рәнҗегән чагында аһларга күмелеп түгелгән сызланулары? Мария дигән маржасы таратып бетерде дисәләр дә, ышанмыйм мин моңа! Булырга тиеш иде бит алар, булырга тиеш!

Менә бүгенге көндә кара инде син. Ничек инде шулай була ала? Язучыларның архивлары төрле аерым кулларда, кайсы тарих институтында, кайсы Дәүләт архивында йә музеенда, кайсы Горький музеенда, әнә Сибгат Хәкимнеке мәдәният үзәгендә—шулай итеп, кайсы кайда чәчелеп-

сибелеп яталар. Кайчан да булса татар аларны бер җиргә җыеп бер рәткә сала алырмы? Шул архивларны һәм халыктан җыйган меңләгән сирәк кульязмаларны бергә туплап, әрмәннеке кебек үзенең Матенадаранын булдыра алырмы? Белмим...

Моны, ахры, бары тик Президент Указы гына хәл итә аладыр.

## Яшь аралаш шатлык һәм сагыш...

Ниһаять, серләр сандыгы ачылачак. Мин Нурияләр ишек төбендә озак-озак итеп кыңгырау шалтыратам. Ишекне таза гына, чем кара чәчле, әле чибәрлеге югалмаган чын татар йөзле ханым ачты. Алтмышлар тирәсендә булыр.

—Бу мин кичә килгән кеше идем.

—Рәхим итегез, рәхим итегез, мондый кадерле кунакларның инде күптән күренгәне юк иде,—дия-дия, ул бик ягымлы, бик үз итеп мине өйгә уздырды.

Мин үгезне мөгезеннән алып, Нур Баян, аның нәсел-нәсәбе турында сораштыра башладым.

—Белмим шул, мин алар ягыннан түгел бит,—диде ханым. Соңгы өмет, өзеләм-өзеләм, дип зынлап ыңгырашты. Кит аннан. Шушы кадәр йөреп тә инде. Ә ханым дәвам итте:—Мин яңа бистәдә туганмын. Әтиләр безнең Пенза ягыннан Неверкинский районы Мазарка авылыннан булганнар. Ренат Акчурин да, теге Ельцинның йөрәгенә операция ясаган хирург, безнең авылдан бит.—Ханымга минем борчылуларымның бары ни, югы ни. Ул тәмләп сөйләнә-сөйләнә бөтенләй үз якларына кайтып китмәкче иде.

—Ә Робендерның Нур Баянның улы икәнен беләсезме соң?

—Әйе, беләм. Асылынып үлде ул... Аннан Илдар, Йолдыз, Ләлә, Лиля, Венера исемле биш бала кала.

Ал-ла-а... Йә илаһым... Болар бит алтын-зөбәрҗәтләрдән торган бисмиллалы дисбе кебек исемнәр... Йә илаһым, ниһаять, мин дә иркен сулап куярмын икән. Беркеме дә калмаган дип йөргәндә синең алга шундый йолдызлар тезеп куйсыннар әле. Көчле булган ла Нур Баянда әнәклек, бәҗәнәклек! Куәтле булган безнең канның кайнавы!

—Белмим, нигә шулкадәр күп бала кирәк булгандыр инде.—Болай булгач, әлбәттә, Нурия ханым минем шатлыгымны һич кенә дә аңлый алмый иде.—Рабиндарга артык хәсрәт кенә булганнардыр бит инде алар. Ә ул мескен, дөнья белән үзе теләп хушлашкан.

Кара әле, Робендерның исемен Рабиндар дип бик матур татарчалаштырып әйтә бит әле бу! Күңелемдә минем яшеннәр яшьни, күкләр күкри иде. Аптыраштагы уйлар-сораулар сугышты. Марҗадан туган Рабиндар балаларына ничек итеп болай татар исемнәре куштыра алды икән соң? Әллә хатыны татар булды микән? Нишләп без анардан шундый ишле нәсел калуын моңарчы белмәгәнбез? Ни өчен бу турыда беркайда да язмаганнар? Әмма, ашыкма шатланырга...

—Татарча беләләрме соң алар?

—Кызганыч, берсе дә татарча белми. Алар барысы да, нишләптер, урыс ягына чыгып беткәннәр.—Нурия ханым бу сүзләре белән бик каты итеп бәгъремнең сызлавыгына басты. «Мескен шул әле татар!» дип кычкырып җибәрәсем килде. Татар башкаласында татар шагыйренең оныклары...

—Ни өчен алай булгандыр ул, никак не пойму,—дип, бер дә исе китмичә дәвам итте Нурия ханым.—Югыйсә, әниләре Клара бик оста, бик матур итеп татарча сөйләшә инде. Керәшен түгел микән әле ул. Менә киләсе майда аңа җитмеш яшь тула бугай инде. Ну вот, шулай китә инде ул хәзер, аларның балалары да, шагыйрьнең правнуклары булалар инде, татарча белмиләр инде.—Нурия ханым тагын да эчкәрәк

үтте, гүя сызлавыгыма пычак белән чәнечте. «Аһ, үз иленә хужа түгел шул әле беркатлы татар!» дип оран саласым килде. Ә ханым дөньяның татарны эретеп башка формага кертеп коюына әз генә исе киткәндәй дәвам итте.

—Юкса бит менә без дә Казанда үстек. Яна бистәдә үстем мин. Тоткынлык еллары, диләр иде ул чакны.—Торгынлык диясе урынга аның «тоткынлык» диюе ул елларга тагын да бер көтелмәгән мәгънә өсти иде. Ханым дәвам итте:—Шуңа карамастан без менә 35 нче татар мәктәбендә укыдык. Татар балаларын урыс мәктәбенә алмыйлар да иде. Мин шунда унбер класс бетердем. Аллага шөкер, үкенмим, гомерем буена туган телемнән аерылмадым. Ул бит вузга кертәм, дип, урыска тыга ата-ана баласын. Теләге булган кеше башы булса, татарча укып та вузга керә бит инде. Укытабыз, әллә кем итәбез, дип, туган теленнән аерып бетерделәр инде татарны. Кызганыч, кәнишне.

—Хәзер Рабиндарның балалары кайларда инде?

—Илдар маржага өйләнде. Бер баласы бар бугай. Университет бетерде ул. Аның эше яхшы бара бугай. Йолдыз урыска кияүгә чыкты. Өч баласы бар. Ләләсе хохулга военныйга чыкты да Украинага күченеп киттеләр.—Дөмбәсләдә генә мине Нурия ханым бу хәбәрләре белән.—Клара кышларын шунда үткәрә, бала карыймы шунда. Лиля Находкада, ире моряк, урыс инде анысы да, ике баласы бар...—Мин хисләремне тышка чыгармадым, баса бардым.

—Венерасы, минем килен була инде анысы, бердәнбер ул гына татарга кияүгә чыкты. Ләкин минем улым Эдуард аның белән озак яши алмады, вафат булды. Алардан менә минем оныгым, Нур Баянның правнугы Диана гына калды.

—Ул да татарча белми бит.

—Белми шул.

Диана күптәннән инде нидер әйтергә теләгәндәй, күзләрен елтыратып, бер миңа, бер әбисенә карап тора иде. Һәм ул безне аңлый булып чыкты. Шунда киләчәккә китә торган бу гөл балкып чәчәк атты. Ул урысчалап:

—Ә мин белергә телим. Тик менә әбием генә минем белән гел урысча сөйләшә шул. Мин кемнән өйрәним инде?—дип куйды.

Мин инде беренче килүемдә үк бу баланы бик яраткан онычым Айгөлгә охшаткан идем. Инде менә мондый кыю, мәгънәле сүз дә әйткәч, минем аны кочып-кочып үбәселәрем килде. И балакай, и газизкәй, и шагыйребезнең асыл дәвамы! Әнә бит синдә нинди изге орлыклар шытарга тора: өр генә нур, нур гына бир!

—Монарчы әнисе белән генә яшәде ул. Хәзер менә өйрәтәм инде мин аны. Тик мәктәбендә татарчаны бик начар укыталар шул. Прусты формально гына. Шунда йөри, берни белми. Мин монда мәктәп өчен өйрәтеп ятам. Ул нинди татар була инде. Шул ипи-тозлык инде. Ул тугач, мулла бабай чакыртып, мин исем куштырдым аңа.

Их, Нур Баян үзе исән булса. Яна тормыш төзибез дип аһ итеп көрәшеп йөргән шагыйрь хәзер менә чит кавемне үрчетү өчен генә тырышканын күрсә, нишләр иде икән соң? Кызу канлы кеше буларак, наганын үзенә төбәр иде микән? Юктыр, пожалуй. Без артык киң күңелле халык бит. Белмим тагын, белмим.

—Мин алайса, барысын да сөйлим инде,—дип дәвам итте Нурия ханым. Нур Баянның тагын бер хатыны була бит. Аңардан да бер кызы кала аның. Менә анысының кайда икәнлеген белмим инде. Нур Баянның безнең заманда даны бик зур иде бит. Без аның шигырьләрен ярыша-ярыша ятлый идек. Хәтта әле Тукай урамын үткәч, Нариман турысында Нур Баян урамы да бар иде элек. Яңа йортлар салгач, нишләптер, аның урамы, аның исеме югалып калды. Мин барыбер аптырыйм инде: элек бит ул бик шаулый иде, хәзер аның турында рәтләп язмыйлар. Бер тавышы да ишетелми.—Нурия ханым дөньяларның, заманнарның

үзгәрүенә, Сталинны, партияне күбрәк мактап ташлаган шагыйрьләрнең даны-кадере китә баруына әнә шулай борчыла иде.

Ул Дdespite Дианаilaн курше

Ул Дианаsaны күршеләренә кертеп, Йолдыз-Юлияләргә кеше киләчәген әйтеп шалтыраттырды. Мин Дианага күчтәнәчләр калдырып, саубуллаштым.

Тышта әле һаман өттереп ала торган суык иде. Трамвайга утырып, дүрт тукталышны бик бөртекләп санап барып, илаһи киң Ибраһимов проспектына килеп төштем.

Һи-и, дөньяда Ибраһимов проспектлары да бар бит әле. Сталин аның муенына үлем богауларын кидергәч тә үзе генә түгел, үз нәсел-нәсәпләрен татар итеп калдыра алган чын татар классикларыбыз да бар бит әле!

Йолдызлар әле яңа гына йокыдан уянып яталар иде, ахры. Мин ишектән килеп кергәч, бер бүлмәле тар гына фатирдагылар, ду килделәр, диван-караватлар шап-шоп, ыгыр-чыгыр килде. Алар шушы тыгында идәннәрдә дә йоклыйлар иде булса кирәк. Ике олы кеше—Йолдыз һәм Венераны, өч баланы кая сыйдырып бетерәсең. Нурияләр йортындагы фатирларының буш торуы гына аңлашылып бетми иде.

Йолдыз ханым мине бик читенсенеп кенә кухняга үткәрде. Залда барган ыбыр-чыбыр астында сөйләшү озак бармаска охшаган иде. Нишләптер, Венерасы каядыр китеп өлгергән иде.

—Йолдыз ханым, мин сезне бик озак, бик ераклардан урап-әйләнеп эзләп таптым. Хәзер көне буена сөйләсәгез дә, тынлаячакмын... Сорауларым диңгез минем...

—Рәхим итегез, рәхим итегез,—диде ул, бик тә ягымлы итеп. Беренче сүздән үк ул бик мөлаем, җанга ятышлы кеше иде. Нечкә билле, нәфис гәүдәле чын татарча каракучкыл йөзле Йолдыз ханым чибәрләр конкурсында катнашырлык матур иде. Менә бит, нинди гүзәлләребез бер дә булмаган төсле югалып яталар икән бит. Юк, чит кавемнәр югалтмый, алар безнең затлы гүзәлләребезне чүпләп кенә тора.

Мин аңа башта татарча дәшеп-дәшеп тә, гел урысча гына җавап алгач, урысчага күчәргә мәҗбүр булдым.

Әмма ул сорауларымның артык һөҗүмчән булуыннан шүрләдеме, мине шунда ук бераз «артка чигендереп» тә куйды.

—Мин әллә ни сөйли алмам инде. Әтиебез Рабиндар, әнисе башка кешегә кияүгә чыккач, бала чагында күпчелек Навил абыйларда торган бит. Сез менә шул Навил абыйларга шалтыратып алыгыз әле, ул белә инде барысын да.

Димәк, ата-анадан аерылып, ятим үскән икән бит бичара Рабиндар. Без җинел генә уйлап, хөкем итмәкче булабыз да, барысы да бик катлаулы, үзәк өзгеч булган, ахры, монда... Аягыңны сындырырлык, башыңны ярырлык драмаларга кереп китәбез түгелме соң?

Йолдыз киңәш биргәч, нишлим, алардан ук Навилга шалтыраттым... Ул өлкән кеше иде, озаклап, тәмләп сөйләшергә җыенмакчы иде. Барасы булгач, мин бик кыска тотарга тырыштым. Бу йорт гаиләсе дә кыска тотуымны көтеп өстемдә тора иде сыман.

—Сез аларны каян беләсез соң, Навил туган?

—Бәй белмәскә, минем әни Оркыя, Нур•Баянның хатыны Суфия апа белән бертуганнар иде. Рабиндар минем двоюродный брат бит инде.

Мин чак кына артыма утырмадым.

—Как? Ничек алай? Нур Баянның хатыны татар идемени? Тукта әле, аның хатынын миңа марҗа дип сөйләгәннәр иде бит. Мин шулай дип язып лар да чыктым. Нишләп беркем дә кире какмады?

—Юк, юк, дөрес түгел, татар, татар. Ул соңыннан гына бераз марҗа белән буталды.

Бусы минем өчен көтелмәгән шатлык иде. Моннан да көчлерәк тантананың булуы мөмкин түгел иде. Әнәк жегете, бәҗәнәклегенә тугры калып, башта барыбер татарны сайлаган. Үз татарыннан көчле токым калдырган... Нишләп элегрәк миңа бу турыда беркем дә берни дә

сөйләмәде икән соң? Нишләп бу турыда әдәбиятчылар берни дә язмадылар икән? Моны бит берничек тә гафу итеп булмый.

—Мин сезгә бераздан барып чыгам, көтегез!—Уфылдап трубканы куйдым.—Шулай итеп, Йолдыз ханым, сезнең әбиегез Суфия татар була икән бит. Бабагыз татар шагыйре. Ә сезне нинди җен саташтырды соң? Нишләп сез татарча белмисез?

—Әйе, бер уйласаң, әнием Клара Исмәгыйловна Фәхриева да татарчаны бик әйбәт белә. Бик әйбәт, ягымлы кеше. Ләкин без белмибез шул. Бик оят инде, бик оят инде, әлбәттә. Ләкин хәзер берни дә эшләп булмый. Казанда шулай киткән бит инде ул.—Ул бу сүзләрне шундый газап белән, шундый читенсенеп әйтте ки, аны җәлләп күзләремнән яшьләр атылып чыкты. Нишләптер ул, әнием татар кешесе, димәде. Бу Клара исеме астында бер-бер сер яшеренеп ятмый микән соң?

—Бу өйдәге егетләр сезнең балаларыгыз буламы инде?

—Әйе: Адель, Олег, Сергей.—Укучым, татар шагыйре торыннарының мондый исемнәрен ишеткәч, син минем хәлемне аңлыйсың инде. Әле башта татар рухы бирешмәскә тырышкан. Беренче исемне татарча куштыру бәхетенә ирешә алган. Һәм аннан соң хакимлек кулдан киткән. Бер нишләр хәлең юк...

—Гафу итегез, Рабиндарны бик эчкән, ахырдан асылынып үлгән, диләр. Шул дөресме соң?

—Ну что вы!—диде Йолдыз ханым, аның тонында ризасызлык, рәнҗү-үпкә тулы иде. Тиз-тиз генә шүрлектән бер папка алып алдыма салды.—Әтием Рабиндар 1975 елда 44 яшендә вафат булды. Ул бик яхшы әти, чын әти иде. Ул безгә бөтен яклап ярдәм итә иде. Ул татарча бик әйбәт сөйләшә иде. Ул бик матур күңелле әти иде, без аны бик ярата идек. Менә аның күпме мактау кәгазьләре калды.—Йолдыз ханым алдыма искереп, ертылып беткән бик күп мактау кәгазьләре өйде.—Менә җиде классны гел отличнога гына бетергән. Менә яхшы тәртип өчен мактау кәгазе. 15 июнь 47 ел. Менә Севастопольдән армиядәге командирларыннан әнисенә рәхмәт хатлары. 28 декабрь 53 ел. Менә тугыз сәгать буена салкын диңгез суында торып баткан судноны коткаруда катнашканы өчен бирелгән исемле сәгать. Ул үзе гариза язып гади гаскәрдән диңгез флотына күчә.

Мин дә яшьлегемдә диңгез хыялы белән «авырып» хәрби диңгез училищесына китеп барган идем бит. Димәк, аның канында да диңгезгә омтылыш уйнаган. Әнәкләрнең бәҗәнәкләр чагында ук Кара диңгез буйларында, ә аннан да алдарак Атлантика океаны ярларында яшәвеннән киләдер, дип уйлыйм мин бездәге бу диңгезгә тартылуны.

—Менә Идел буе комсомол райкомында яхшы эшләгәне өчен мактау кәгазе. 21 октябрь 58 ел. Ә менә болары—аның фотолары.

Рәсемнәрдән миңа елмаеп, бик чибәр егет карап тора иде. Әмма һәр фотосында күз кырыйларында әллә нинди бер әйтелмәгән үпкә, ниндидер моң-зар, хәсрәт шәйләнә иде сыман. Ата-анадан аеры үсүдән калмады микән алар...

—Бусы Нур Баян бабайның кайбер кәгазьләре, фотолары...

—Башка юкмы?

—Юк шул.

Әлбәттә, иң кадерлесе аның хатлары иде. Тик ул берләнбер иде. Аны нинди телдә язылса, шул телдә китерми мөмкин түгел. Чөнки ул шагыйрьнең урыс телен гаҗәеп төгәл белүе турында асыл бер дәлил булып тора ала. Хатынының апасына яза ул аны һәм анда улына карата никадәр мәхәббәт, никадәр өзелеп сагыну! Алла үзе түземлек бирсен шагыйрьгә! Юк, Суфиялар белән ул араны һич тә өзәргә теләми!

*«Ркия дорогая!*

*Получил Ваше письмо, за которое большое спасибо. Нахожусь на украинских степях. Воюем.*

*Настроение хорошее. Жив и здоров. Приехать, пожалуй, придется не скоро. Нужно уничтожить гитлеровских мерзавцев, а потом домой и опять вместе... И тогда можно будет продолжать творческую работу. А пока не пишу ничего.*

*Передай привет родным и друзьям, особенно моему сыну. Пусть учится на «отлично». Я буду бить немецких негодяев за здоровье сына.*

*С фронтовым приветом Нур. 1.07.43.*
*Пишите.»*

Өзелеп калган бу сөю-мәхәббәтләрне, улы янына ашкынуларны бездән башка кемнәр яд итәр соң?!

Шулай да безгә кадәр дә изге җаннар табылган икән. Әнвәр Бакировның «Барысы да күңелдә» дигән ноталы җырлар китабында Нур Баянның бер җыры басылган. Ул китапка композитор: *«Тышлыгы искерсә дә, Нур Баян сүзләре мәңге искермәсләр. 25 май, 1979 ел»* дип, автограф калдырган. Монда да сагыну, туган илгә ашкыну...

Хат язсам да бармас төсле,
Ахры, ерак киттем илемнән.
Бала чакларымда уйнап йөргән,
Чия чәчәк аткан җиремнән.
Ерак киттем. Бөдрә таллар
Көтәләрдер таныш җырчысын;
Көтәләрдер кырлар, биек таулар
Шат күңелле еллар юлчысын.
Борчылмагыз, минем дуслар,
Шат җырчыгыз сезне онытмас,
Бер кайтыр ул якты кояш сыман,
Дошманнардан җирне корыткач!

Артыннан йөрүчесе булса, бу җырлар җырланмас идемени? Исеме дә яңгырый торыр иде. Аһ, ләкин ят телле гаиләдә хәзер моны укый алучы да юк шул, бу ашкын сагыну җыры да таш астында ята сыман. Башта мин язучы, Нур Баянның авылдашы дигән сүзләр Йолдыз ханымга артык тәэсир итмәгән иде кебек. Ә инде:

—Бабай ягы белән араларны өзеп, сез бик күпне югалткансыз. Бүгенге Президентыбыз Шәймиев тә аның авылдашы бит,—дигәч, ул:

—Как? Кит аннан! Моны мин һич тә көтмәгән идем. Гафу итегез. Хата бездә, нишлик соң...—дип куйды.

—Юк, бу гафу итәрлек хәл түгел. Сез әз генә булса да бабай ягын да белешеп торырга тиеш идегез. Болай ярамый. Һич тә ярамый.

—Ярамый, әлбәттә, ярамый. Ләкин менә икенче агымга эләктек шул, ул безне суыра да суыра...

—Ул гына да түгел. Президент белән аларның нигезе күршеләр иде. Шәймиев аны бик хөрмәт итә. Авылда колхозыбыз аның исемен йөртә. Ул гына да түгел, Чаллыда «Нур Баян» сәүдә йорты бар! Ул гына да түгел, менә «Нур Баян» фонды ачылды. Аның туган йорты янында Нур Баян скверы булачак.

—Ай-яй-яй, нишлик соң, нишлик соң. Әлбәттә, болай ярамый безгә. Сез әйткән хәбәрләр безнең өчен могҗиза болар. Болай без үзебез дә төшеп калганнардан түгел-түгелен, аллага шөкер. Үзем—институтта лаборатория мөдире, ирем—төзүче. Әле коттедж төзеп ята. Ләкин сез әйткән хәбәрләрне белми идек шул, белми идек. Ай-яй...

Нечкә күңелле Йолдыз ханым өзгәләнеп януымны сизде, ахры.

—И-и, изге күңелле кешеләр бетмәгән икән әле,—диде ул. Бу юлы чибәр ханымның тавышы үкенечләрне эретеп, күңелләрне юып алырлык бик тә ягымлы, рәхәт иде. Күптән инде мондый ягымлы дәшүләрне ишетмәгән мин дәрвишнең күңеле җебеде.—Инде без бабайны беркемгә дә кирәкмидер дип йөри идек. Бик зур рәхмәт сезгә аның исемен

күтәреп йөрүегез өчен. Мин сезгә, нигәдер, бик ышанам. Менә бәлки китабыгызда файдалана алырсыз, бу безнең гаилә реликвиясе—соңгы истәлек булса да, бирәм инде бу фотоларны. Менә монда аның турында чыккан материаллар да бар...—Ул аларны өр-яңа папкага салып бирде.

Мин соңыннан «Социалистик Татарстан»да Ш. Хамматов һәм К. Тәхауларның «Утлы көннәр сулышы». (24.04.82 ел), Мәхмүт Хөсәеннен «Аяз таңнар жырчысы» (16.05.85 ел) дигән ул материалларны карап чыктым. Әмма хәтта аларның да Нур Баянның асылына, гаилә тормышына кереп тасвирларга көч-хәлләре житмәгән иде...

* * *

Бик арган идем инде. Бүген үк Чаллыга кайтып китәргә жыенган кеше өчен тагын өченче жиргә бару бик кыен булса да, мин инде Навилне дә тыңламыйча һич тә китә алмый идем. Чөнки минем соңгы түземлек чыбыкларым янып ята иде.

Мине Йолдызның уртанчы улы Олег озата чыкты. Ул ачык күңелле үсмер иде бугай, минем белән сөйләшеп китәргә тырышты. Сүз, әлбәттә, урысча бара иде.

—Значит, в Челны? Мой крестный отец тоже в Челны ездит.

—Нинди крестный отец, кем була соң инде ул?—дип, сорау бирми түзә алмадым.

—Сез белмисезмени? Ул мине чукындырган чагында катнашкан кеше була. Ә бу очракта минем әтинең абыйсы ул. Ә әти минем Әмәт тавында тора. Анда ул ике катлы коттедж салып ята.

—Аерым торамыни ул?

—Әйе, ул шунда тора.

Олег кай ягы беләндер әнәкләргә охшаган бик тә мөлаем бала иде. Аның күңеле, үз-үзен тотышы шулкадәр саф, чиста, эчкерсез, итагатьле иде ки, тагын да бераз сөйләшеп бара алмавыбызга бик үкендем. Минем автобус килә иде инде. Автобуска өлгерер өчен йөгерәсе булгач, ул хәтта минем авыр портфелемне үзе сорап алып күтәреп йөгерешге. Бу сирәк була торган мәнлелек иде. Утыртып жибәрде, кулларын болгап, матур итеп озатып калды. Безнең арада әллә нинди бик югары бер элемтә бар иде сыман.

... Ләкин ул Әнәктән бик-бик нык аерылган иде шул инде. Ул инде, ни дисәң дә, чукындырылган татар баласы иде... Их, түгелә бит Әнәк энергиясе ятлар дингезенә...

Сизәм, жанны нидер тырный, жанда нидер ярсый иде, эчемнән ниндидер бер вулкан атылып чыгарга тора, әмма эшнең ашыгыч булуы гына миңа уйларга бирелергә, ярсырга, кызарга ирек бирми иде...

## Көтелмәгән фанатик

Ишекне тәбәнәк буйлы, бераз бөкрәя төшкән, чәчләренә чал кергән алтмыш биш яшьләр тирәсендәге ир ачты. Фатирга керү белән аның чисталыгына хәйран калдым. Өй эче шәп итеп акшарланган, яңа гына ремонтланган иде. Фатирның кире кара энергия жыя торган почмаклары да казан төбе формасында агышлы итеп сылап эшләнгән иде. Хәтта әйберләр саклана торган караңгы почмагы да якты, һәр иске әйбере юылган сыман чиста булып күренеп тора. Моңарчы гел каралып беткән иске биналар, иске фатирлардан соң бу үзе бер ап-ак, саф һавалы дөнья иде. Гүя мин карурманда кара күләгәле ябалдашлар астында адашып йөргәннән соң, кояшлы урман аланына килеп чыктым. Сулышлар иркенәеп, күңелләрем күтәрелеп китте.

Ләкин бу фатир әллә ничек артык чиста да, артык саф та шикелле булып, аңардан ниндидер бер сәерлек тә бөркелә иде.

Бүлмә уртасындагы өстәл өстенә кульязмалар, китаплар, яңа языла башлаган кәгазьләр бик пөхтә итеп җәеп куелган.

Гүя фәрештәләр юри мине шулай капма-каршылык—контрастлар илендә адаштырып йөртәләр иде.

Хуҗа мине хөрмәтләп кәнәфигә утыртты да, сулыш алырга да ара калдырмыйча, алдымда җил-җил хәрәкәтләнеп, сөйли дә башлады:

—Мин төрле фәннәр буенча урыс-татар сүзлекләре төзим. Менә бусы икътисад һәм юридик терминнар сүзлеге. Менә хәзер бизнесменнар, бухгалтерлар, финансистлар өчен аңлатмалы сүзлек әзер булачак...

Татар кырылып югалып яткан җирләрдән соң инде мин татарның берниндидә уңай энергиясенә очрармын дип өмет тә итми идем. Мин Казан тоташтан, тоталь рәвештә урыслашып яткан шәһәр икән дип, күңелгә нык беркеткән идем. Бу юлы кинәт нәкъ киресенә тап булдым түгелме соң?! Рәхмәт фәрештәләргә! Карачы син бу егеткә! Бу бит Казанның гади бер кешесе түгел, бу бит Нур Баянның хатыны ягы карендәше.

—Бу сүзлекләрне төзеп без татар телен дә, урыс телен дә баетабыз. Бу сүзлектәге сүзләрне бик күпләр белмиләр, хәтта галимнәр дә. Ә мин эзләп табам. Юкса мин үзем бер класс та татар мәктәбендә укымадым. Урыс балалар бакчасында тәрбияләндем. Мин экономист та, финансист та, филолог та түгел. Бары тик университетта марксизм-ленинизм бүлеген бетереп, социолог-политолог булып киткән кеше генә. Менә теләгең булса, була икән ул. Миндә татарның тирән рухлары кузгалды. Ул бүлмә буйлап Наполеон рәвешле бөек кыяфәттә атлый башлады.

—Бик хуплыйм, бик тә күңелемә рәхәтлек китерә торган сүзләр сөйлисез, Навил туган. Менә шул рухлар белән бергә Нур Баян бәгъребезнең дә рухы уянып килсен иде безнең янга. Мин бит аның асылын ачыкларга йөрим.

—Ачыкларбыз без аны! Мин эшләгән институтта татар телендә укытуны да мин беренче булып күтәрдем. Ректор башта игътибар итмәде. Бераздан чакырып алды да, оештыра башла, диде. Тора-бара мин аңа шушы сүзлекләр турында сүз каттым. Игътибар итмәде. Ә бераздан чакырып алды да, давай, группа туплап эшли башла, диде. Күрәсең, кайдадыр аның койрыгын боргычлаганнардыр. Оештырдым егетләрне, менә эшләр бара. Чыккан сүзлекләремне бик күпләр сорап йөри хәзер.

Аны, һич тә туктатып булырлык түгел иде. Ә бит минем бүген үк Чаллыга китәсем бар. Тик мин татар теленнән китеп барган кешеләрдән соң хәзер, киресенчә, татар теленең хакимлеге өчен көрәшүче өр-яңа бер фанатикка юлыктым лабаса. Минем моңарчы мондый кешене очратканым юк иде.

—О-о, болай булгач, бүген үк Чаллыга кайтып китәргә ашыксам да, Навил туган, сезне төбегез-тамырыгыз белән өйрәнеп китәм инде.

—Аһ, шайтан алгыры, бер мавыксам, каты мавыгам мин. Сез бит мосафир! Мин сезгә иң беренче кайнар чәй эчерергә тиеш. Өстәлем әзер, хәзер чәйне кайнарлатам. Хуш исле үләннәр белән. Идел буеннан. Сихерләп-сохырлап ясыйм хәзер.

—Әй рәхмәт, мин ураза шул.

—Кит әле, язучылар арасында андый кешеләр бармыни соң? Странно, странно. Рәхмәт, рәхмәт. Нур Баян авылында әле ничава кешеләр яши икән алайса.—Ул очына-очына архивларын алып килеп, каршымдагы диванга тезеп салды. Фотолар, гарәп шрифтындагы гәзитләр, китаплар, әллә ниләр, әллә ниләр. Мин бер тартма өстендәге гәзит кисәген карамакчы булып алган идем, ул: «Юк, юк, берәмтекләп, тәртип белән мин үзем күрсәтәм»,—дип, шунда ук аны кулымнан алып, кире тартма өстенә куйды да, тартмасын алтын тулы савыт шикелле алдына кочаклап утырды. Аннары гаҗәеп бер кыенлык белән интегеп, тартма төбеннән сак кына, берәмтекләп фотолар ала башлады. Юкса бит, өстәге әйберләрен

читкә алып кына куясы иде. Юк, ул алтынымны күрә күрмәсеннәр дигән сыман, өстәгеләр белән каплап-каплап кына астан казынып ала иде. Алдымда бабалары, әбиләре фотолары тезелеп китте. Байларча киемнәр, эре кыяфәт...

—Бабам—Әлкинең Салман авылыннан Нигъмәтҗанов Гарифулла. Гарифуллин фамилиям шуннан. Әтием Кәримулла. Әтинең әнисе—Дөбъяз ягы Битаман янындагы Көектән, мари чиге. Әтием башта бер байда кибетче булган, мәдрәсәдә дә йөргән. «Кызыл армия» гәзите тирәсендә чуалган. Урта Азиядә булган. Вахитовны, Ленинны күргән.

—Мина Оркыя, Суфия яклары гына кирәк иде.

—Юк, тыңла син, тыңла. Тамырларга кара син, тамырларга! Алар бер-берсенә бик нык бәйләнгән. Күр син, ерак бабам Исмәгыйль граждан-нар сугышы чорында генерал Чанышев белән дуслаша. Алар икесе бергә Татарның хәрби революцион комитетына сайланалар. Әле бер ара бабам аның председателе булып күтәрелә. Чанышев ул заманда аның замы гына була. Менә кара, монда бабам портфелен ничек кочаклап утырган! Ул бу сайлануга зур өметләр баглый.

—Һи-и, кара син, ә! Шулай укмы?—Мин сокланган саен Навил һаман очына гына иде.

—Менә кара, менә ул хәрби комитет! Кара син бу фотога, болар бит татарлар барысы да. Боларның һәрберсен премьер-министр итеп сайлап куярлык. Һәрберсен! Без хәзер генә мескенлеккә биреләк. Кара, һәрберсе горур, бәйсез, нинди мәһабәт кыяфәт! Ул килеш-килбәт! Бу бит үз кадеренне-кемлегенне, дәүләтле халык икәнлегенне белү, болардан көч-куәт, яшәү дәрте бөркелеп тора! Шәп бит! Булган бит татарның кыю чаклары. Халык башын күтәргән. Мона карап үзе бер китап язарга була. Менә бусы—Фәрит Сәйфелмөлековның әтисе. Менә бусы—Касыйм Шамильский. Болар безнең үз патшабыз, ханыбыз бар иде һәм ул булачак, дип утыралар түгелме соң? Боларга карап татарда әле барысы да исән ич әле дип ышанасын. Менә шушы кыяфәте белән татарның югары катлавы революция сафына баса! Һәм алдана... Аһ, алдана... Нур Баяннарның алдануы да шушыннан башлана.—Навил сәүдәгәр әби-бабаларының затлы киемнәрдән төшкән открытка-фотоларын алды. Алар хәзерге открыткалар-дан да затлырак иде.—Әнием Оркыя булып, аның сеңелесе Суфия Нур Баянның хатыны бит инде, аларның әнисе Чистай ягыннан Гаяз Исхакый-лар тирәсеннән иде. Ә дәү әни, ягъни әбием Шәмсекамәр—төртеп куй, бәлки кирәк булыр, аның да әнисе Маһруй була—Казанга килгәч, сәүдәгәр Исмәгыйль Абдрашитовка кияүгә чыга. Менә кара, алар гаиләсенең фотосын. 1904 елда ук бит инде бик затлы, бик бай булып, түбәтәйләр, калфаклар киеп, затлы милли күлмәкләрдән төшкәннәр. Менә бусы—Мәрьям Айтуганова гаҗәеп модалы киемдә, бөек актриса диярсең, әбием Шәмсекамәр Уразгильдиевага бүләк иткән. Менә Мөхәммәтша Бигиев фотосы, алпавыт бит инде, алпавыт. Һо, ул Исмәгыйль! Аның әтисе Әхмәдулла, аның әтисе Габдрәшит Арча ягы Бәрәскәнеке була. Пассажда антиквар әйберләр кибете тоткан ул. Театрларга йөргән, язучылар белән аралашкан. Хәтта «Католог русских монет» дигән китап та чыгарган ул. Бу китапны хәзер монеталар җыю белән шөгыльләнүче Мөхәммәдиевләр дә белми. Менә шушы ике яктан килгән ике көчле токым Шәмсекамәр белән Исмәгыйльнең эшләре худка китәргә тиеш була да соң, бер-бер артлы Оркыя, Суфия кебек матур кызлары да туа, ләкин революция аларны кирегә әйләндереп сала...

Менә шушындый Исмәгыйль бабам шикелле милләтне милләт итәрдәй кешеләр Учредительное собраниега да сайланалар. Ләкин Ленин матрос Железняклар мылтыгын шушыларга төбәп бит инде ул собраниене тарката. Китә юк итү, китә үзара бер-берсен ашау. Шушы геноцидтан соң Ленин үзе дә истерикага бирелеп, өч көн буена тыела алмыйча хохотать итеп йөргән дип сөйлиләр бит. Чөнки кешеләрнең өнәрә, җаннары кытыклаган аны, тынгылык бирмәгән. Исмәгыйль бабам да

шушы «тегермәнгә» эләгә, кибетен тартып алалар, үзен Казакъстанга сөрәләр. Ул мескен шунда ялгызлыкта 41-елны вафат була. Бу фаҗигалар үсмер кызлар Оркыя белән Суфия күз алдында бара бит инде. Элекке затлы, бай гаилә өстенә тирә-яктан чит итү, түбәнсетү ишелеп төшә. Алар хәерчелектә кала. Син ашыкма, боларны аңламыйча, Суфияны аңлап булмый, Суфияны аңламыйча, Нур Баянны аңлап булмый. Тә-әк, ярар. Алар тешләре, тырнаклары белән ябышып булса да, бу замана арбасыннан төшеп калмаска тырышалар. Әнием Оркыя, элекке сәүдәгәр кызы, Язучылар союзына эшкә урнашу җаен таба. Суфия шунда апасы янына баргалап йөргән чакларында Нур Баян белән танышып китә. Шагыйрьләрне акылдан яздырырлык чибәр була Суфия...

Мин аның фотосын кулыма алдым. Миңа өттереп ала торган кара күзле матуркай карап тора иде. Бу әнәкләргә нинди каза төшкәндер инде, гомумән, аларның күбесе шушындый кара-конгырт күзле чибәрләр утында көйделәр. Нур Баян белән алар 1930 елда өйләнешәләр. 1931 елда Рабиндар туа. Матур гына яшәп киткән җирләреннән өсләрендә яшеннәр яшьни башлый. Илдә һәр нәрсәгә сыйнфый караш, сыйнфый көрәш көчәя. Үткәннәрне тагын актарып чыгара башлыйлар. Иҗади уңышлар, дан яңгырында коенып йөргән Нур Баян башта моңа бирешмәскә тырыша. Чөнки ул өзелеп ярата Суфиясын. Әмма уннан да, сулдан да «ул капитализм калдыгы—сәүдәгәр кызы белән тормыш корган, советка каршы элементларга сатылган, ул байлар ялчысы» дигән гайбәтләр аның бөтен тормышын агулый. Суфияның хатын-кыз сизгерлеге боларның барысын да тоя, күңеле авыр шомнар белән тула. Өстәвенә аңа күзләре төшкән егетләр дә очрашкан саен: «Сезне юкка чыгаруны мактап җырлаучы белән ничек итеп яши аласың син, Суфия?»—дип, аның канына тоз салып торалар. Драманың төбе шушында була. Әтисе казакъ далаларында сөргендә газап чиксен, аларны шунда кууны яклап ирең шигырь язсын. Ничек моңа түзмәк кирәк? Нур Суфияның аңа салкынайганын сизенә. Партшколада укыган чагы. Андыйларга наган белән йөрү рөхсәт ителгән иде бит инде. Ул Суфияны бик каты көнли башлый. Беркөнне кайта да, Отелло сыман хисләренә чыдый алмыйча, «Мин сине атып үтерәм болай булгач» дип, куркытырга теләп, стенага атып җибәрә. Менә шуннан соң Суфия Нур Баян өйдә юкта Рабиндарны безгә китереп куя да, үзе бер егет белән вакытлыча китеп югала... Һи-и, Нурның күргәннәре. Ул безгә килеп, бәрелеп-сугылып, «Суфия кая? Суфия кая? Аны кая яшердегез?» дип, еларга җитешеп, эзләп йөри.

—Ә Суфия безгә яшерен генә килеп йөри иде,—дип, авыр сулады Навил.—Әнием Нур Баянны гел мактап сөйләсә дә, тегенең аны күрәсе дә килми иде. Ниндидер осадок калган иде аңарда. Ой, улын ярата иде инде Нур, ярата иде. Менә аның бер хаты да сакланган бит әле.

Хат бик матур почерк белән язылган иде.

*«Робендарчигем!*

*Бүген синнән башка кундым. Күңелсез булды. Бәбкәм, акыллым, мин бүген Мәскәүгә чыгып китәм. Син мине озата алмадың инде. Хуш, минем кара күзем! Күзеңнән үбеп, Әткәң: Нур.*

**P.S.** *Хуш, бәбкәм, хуш,*
*Мин китәмен,*
*Мин китәм, син каласың.*
*Онытма мине, кошчыгым,*
*Ике күзем карасы!*

*Бәбкәм, сиңа Мәскәүдән берәр нәрсә алып кайтырмын. Көтеп тор, яме. 9.03.37 ел. N.B.*
*Суфия!*
*Син балага әллә нәрсәләр өйрәтмә. Ана бул. Мин киттем.*
*На обороте. Дорогому сыну Робендеру».*

Нинди өзелеп бала ярату сусыны! Бу сусынны ул инде гомер ахырына чаклы берничек тә баса алмаячак.

—Мондый өзгәләнү каршында, Навил дус, соравы да читен. Шулай да, нишләп ул баласына бер дә тузга язмаган исем куштырды икән?

—Шагыйрь кеше бит инде, аны да анларга була. Ул чагында Союзга Һинд шагыйре Рабиндранат Тагор бик еш килә торган була. Аны зурлап каршылыйлар иде. Шул хөрмәткә Рабиндар дип кушкандыр дип уйлыйм инде мин.

Чаллыга кайткач, Нур Баянның иҗатын тагын бер кат күздән кичергән идем. Ул чагында шагыйрьгә үзенең эчке хисләрен, гаилә тормышы низагларын язарга бик үк ярамаса да, Нур Баян түзми, тетрәнгеч хәлдә калуын бөтен җәмәгатьчелек каршында ачып сала. Алданудан, хыянәттән тетрәнә шагыйрь йөрәге. Ул бәхетсез, ул ташланып хур ителгән. Ләкин ул үзенең бу халәтен сиздермәскә, үзен юатырга тырыша. Менә аның соңгы салкын сүзе: «Туң йөрәк», 1936 ел.

Җиенып чыгып китте,
Авыр түгел,
Була шундый гамьсез аналар,
Кырда йөргән вәхши хайван кебек
Чит мәхәббәт белән яналар.
Китсәни сон...
Китсен әйдә,
Ни югалттым андый анадан,
Саф күңелле тормыш аналары
Кул селтәми булыр баладан.
Чыгып китте.
Китсәни сон,
Туфрак күмсен киткән юлларын,
Башка берни түгел—
Нәфрәт кенә
Тудырып китте миндә ул бары.
Йөрәкне дә алып китә алмады,
Туң йөрәге китте үзендә,
Бала калды өйдә,
Китүчегә,
Нәфрәт туды ике күңелдә.
Башка ни юк.

Исе китмәгән сыман «Башка ни юк», дип тыныч сыман гына язса да, эчендә бик тә авыр утлар дөрләгәне күңелгә бәреп тора. Бу шигырьдән соң аны барыбер кызганасын, аның бик тә тирән кайгыларын бүлешәсе килә.

Кызганыч ки, Навилдә дә Нур Баянның дөньяга чыкмаган кульязма мирасы сакланмаган иде. Шулай да эзләнүче тарихчылар өчен кирәк булырга мөмкин ике әйбер: «Йолдыз» газитенең 1870 нче саны (21.02.1918 ел) һәм Мәрҗанинең горур, бөек кыяфәтле фотосы Навил архивын бик бәһале итә иде. Монда шулай ук киләчәктә Нур Баян музеена күчәргә лаек әйберләр: бүләк итеп бирелгән—эшләпәдән төшкән зур, матур фотосы, «Онытылмас яшьлек» (1934 ел), «Янгырлы төн» (поэма-хикәя, 1933 ел) китаплары саклана.

Рабиндар турында мин ишеткән ямьсез хәбәрләрне әйткәч, Навил дә ярсып-кабынып каршы күтәрелде:

—Ышто-о сез, искиткеч кеше иде ул. Ул бит хыялый-романтик иде. Үзе теләп флотка китүен генә ал син аның. Ә баткан корабны чыгарышу?! Әлбәттә, кайткач, аңа сразу эш юк иде. Ләкин данлыклы шагыйрь улы буларак, эш таптылар. Башта ул комсомол райкомында икенче секретарь, аннары Татпотребсоюзда инструктор, аннары Министрлар Советында инструктор, аннары хәтта обкомның пропаганда бүлегендә инструкторлык дәрәҗәсенә күтәрелде ул. Но чын белеме юк иде, вузлар бетермәгән иде. Сәләт белән генә йөрде. Аны Чистайга райисполком председателе итеп тә җибәрмәкчеләр иде, авыл хуҗалыгын белмәгәч, тыелып калды.

Ой, бик добрый кеше иде ул. Минем әни дә, дәү әни дә бик яраталар иде аны. Кара менә аның син бу фотосына: әнисе Суфия кебек чибәр иде ул. Урамнан үткәндә хатын-кызлар анардан күзләрен ала алмыйлар, борылып, каерылып карап калалар иде.

Ул бик веселый, шат, көләч, остроумный, талантлы кеше иде. Аның теленнән уен-көлке сибелеп кенә торыр иде. Ул елларда Казанда бер маньяк йөрде. «Из горгаза» дип ишек ачтырып. Ачсалар, кешене

балта белән тураклый торган булган. Рабиндар ишек шакыгач, кем ул, дисәң, юри, авыз ерып: «Из горгаза» дияр иде. Аннары, хатыны аңардан өч-дүрт яшькә өлкәнрәк иде. Кешеләр белән очрашканда гел: «Таныш булыгыз, бу минем әнием» дип көлеп җибәрер иде. Дөрес, ул да фәрештә түгел иде. Хатын-кызлар белән чуалган өчен аны обкомнан чыгардылар.

—Хафаланма, Навил дус, миңа андый егетлекне хупларга гына туры килә. Бу бит Әнәк кабиләсенең сыйфаты, узган гасырда безнең бабалар барысы да ике-өч хатын белән яшәгәннәр. Бу система гына кысты безне. Менә шуңа ризасызлык белдергәндер ул.

—Әмма аны бөтенләй салып таптамадылар, яшелчә-җимеш кибетенә директор итеп куйдылар. Хәтерлим. Аның янына баргач, сатучылар акча-выручканы кертә иделәр. Ул аны шунда санамый гына өстәл тартмасына салып куяр иде. Бикләмичә, мине озата чыгар иде. Кешеләргә ышана иде ул. Ә бит дөньяда төрле бәндә бар. Нәтиҗәдә недостача булып, аны эшеннән алдылар. Ә анда директор булып эшләгәндә мул яшәде: балалары апельсиннарны туп итеп кенә уйныйлар дип сөйлиләр иде. Салгалап та йөрде инде, анысы булды. Аннары аны Казан-Чаллы юлы төзелешенә профком председателе итеп куйдылар. Аннары гражданнар оборонасында эшләде. Әтисе кебек кызу канлы кеше иде. Салмыш хәлдә кайтканда трамвайда бәйләнәләр аңа, и башына таяк белән сугалар. Нейрохирурглар операция ясадылар аңа. Шуннан соң ике ел чамасы интегеп авырып яшәде дә вафат булды. Чәчәк кебек ир чагында, кырык дүрт яшендә дөньядан китте.

—Кызганыч, үкенеч, авыр туфрагы җиңел булсын. Шулай да нишләп шундый кешенең дә балалары татарча өйрәнеп кала алмадылар икән соң?

—Тирә-як мохиттан инде бу. Балалар бит урамга чыксалар, татарча сөйләшсәләр, аларны урыслар гел «каля-баля», дип мыскыл итәләр, үчеклиләр, котырталар иде. Туйдыргандыр инде бу балаларны да, аналарны да. Шуннан китә инде: шеште-пеште, менде-төште. И вот, пажалысты, татардан урыс әзер. Аннары, үзе иртә китте бит. Үзе булган булса, ихтимал, алар татар булырларые. Үзе юкның күзе юк бит инде.

—Ә бу Клара ни караган?

—Катлаулы ситуация бу. Аның әнисе татар булмаган бит, белорус булган. Хәтта ул авылда яшәп татарлашып беткән кеше сыман булса да барыбер үзенекен иткән, Кларага христиан динен дә, урыслыкны да нык сендереп калдырган. Ул бит безнең хатын-кызлар гына беркатлы. Урыска чыктымы—вәссәлам татарың. Бездә бит татар телен саклау буенча катылык юк, җинен сызганып ныклап тотынган патриот юк.

Соңгы сүзе белән ул барыбызга да бик каты китереп орды.

Бу сүз мине айнытып җибәрде. Кайтасым да бар бит әле.

—Ә, тукта, онытканмын бит. Шагыйрьнең ахыргы язмышы?

—Соң, Суфия ташлагач, татар хатын-кызыннан күңеле кайткандыр инде. Ул эше буенча Мәскәүгә барып йөри торган булды. Шунда бер машинистка марҗа белән таныша да, шуңа өйләнә инде. Бу 1939 елда була, ахры.

—Аh, дустым, мин ашыгам. Кышкы юл бит, киттем. Синең фатирың искиткеч җиhазландырылган. Чиста яшисең син.

—Соң, мебельләрне үзем ясыйм бит. Әле син минем дачаны барып күрсәң иде. Шәп урында, Идел буенда, анда ионизированный воздух. Рәхәт анда. Яз-җәй килсәң, үзеңне алып барам әле шунда. Син кергәлә безгә, әйдә, якыннар булыйк. Кая, күчтәнәчләр биреп җибәрим әле үзенә юлга.—Ул кухняга атлады.

—Юк, юк, рәхмәт,—дип, туктаттым мин аны.—Кара әле, дустым, шушы кадәр әйбәт фатирда бер үзең генә яшисеңме? Ә хатын?

—Юк, әле-е...—диде ул бик читенсенеп.

Шомартып, итагать белән сөйләшеп торырга вакытым тар иде инде. Сүзләр гел маңгайга бәрелде:

—Нишләп?

—Да-а, юк инде-е...

Мин килеп кергәч үк күзгә-күңелгә бәрелгән сәерлек анын артык чиста фатирда бер үзе яшәп ятуыннан—ялгызлыгыннан килгән икән.

Аһ, тегендә татар ярсып-ярсып чит кавем үрчетсә, мондагы татар, зыялы, затлы милләт патриоты була торып та, милләтне үрчетми, балаларсыз, киләчәксез тамырлары өзелеп ята. Ни аяныч! Нигә сез, фәрештәләр, мине мондый каршылыклы хисләргә батырасыз?..

Ватыгыз коллык богауларын!

Чыннан да, нindидер югары көчләр мине канатлары белән сыйпап, саклап йөртәләр иде булса кирәк. Югыйсә, бер көн эчендә шушы кадәр гел унай килеп торуы мөмкин түгел иде. Мин бит, сонга калдым, Нур Баян турында инде берни дә таба алмам, дип кенә юлга кузгалган идем. Ә анын хатирәсе генә түгел, бер кабилә дәвамнары да исән икән бит, исән икән! Инде бүген кайтып китеп булмас, ахры, дип икеләнеп кенә, бик ашыгып атлап, Себер трактының Чаллыга китә торган чатына чыгып бастым. Кабынып кызу-кызу атлаганда саф һава канны әйбәт куды, ахры, инде менә тынычланып, тирән итеп тә сулыш ала башладым. Бу кичергән-күргәннәрем каршылыклы булса да, мине тәмам канәгатьлек хисе биләде. Әллә нигә Казан шау-шуын, бөтен тирә-якны рәхәтләнеп, йотылып, сөенеп күзәттем. Бар вөҗүдем йөргән эшләремнең унай булачагына, татарның бөек киләчәгенә гаҗәеп ышаныч белән тулды...

Шулчак минa иманлы йөзле бер татар егете килеп дәште:

—Сез Чаллыга түгелме, абый?

—Әйе, машинанны күптән йөртәсенме?

—Дүрт ел инде Казан юлын таптыйм.

—Юкса, менә бу сумкада искиткеч тарихлар, кадерле ядкарьләр, энем. Аларны алып кайтып китап итеп чыгарырга кирәк. Алар харап булырга тиеш түгел.

—Сон, исән-сау алып кайтам, абый.

—Күпме аласын?

—Әйдәгез, утырыгыз, абый, борчылмагыз, бирә алган кадәр бирерсез, очып кына кайтырбыз.

Егетнен көр тавышы, эшлекле кыяфәте, тәмле итеп хөрмәт белән татарча сөйләшүе, магнитоласыннан янгырап торган милли музыкасы күнелемне тагын да күтәреп җибәрде. Менә бит, менә, автобус көтеп тә чиләнәсе булмады. Асфальтнын кардан арчылган чагы: машина җил кебек оча да башлады.

—Сез бик әйбәт татарча сөйләшәсез, абый. Случайно сез язучы түгелме? Кайдадыр күргән дә бар сыман үзегезне.

—Әйе, язучы. Шунын белән кайгырып, хәсрәттә янып гомер үтте инде, рәтләп яшәлми дә калынды бугай...

—Ни турыда язасыз сон?

—Үзем турында. Гомерем буена бары тик бер сынны, үз сынымны сүз белән ясыйм. Сагыш ышкысы белән ышкый-ышкый, кайгы кәйләсе белән китә-китә, хәсрәт пычкысы белән кисә-кисә ясыйм.

—Сез алайса шәп сынчыдыр.

—Юктыр ла, бик сирәк шатлык сабыны белән юынам, оныткaнда бер хуплау суы белән коенам, ара-тирә генә дан себеркесе белән чабынгалыйм.

—Кызы-ык...

Радиодан классик музыка янгырый. Таныш аһәннәр. Бәй, бу Бетховеннын бишенче симфониясе ич... Инде берни сөйләшмичә, тынып кына, оеп кына кайтасы иде. Әмма бөек көрәш симфониясе Казаннарда кабарган уй дингезләрен чайпалдыра, тойгы туфаннарын тузгыта башлады. Әллә машина, әллә мин үзем, әмма нәрсәдер гүя, бер үрләргә очып менә, бер упкыннар өстендә тирбәлдерә иде. Үлеп арганмын икән бит. Очабыз... Ә кая очабыз сон?

Кинәт айкалды-чайкалды, җир тетрәп, бар дөньясы асты-өскә килде.

... Офыкларда, күкләрдә җил-давыл иде. Елларга, гомерләргә дөрләп биек-биек ут баганалары кабынды. Бар дөньяны яшен утлары чорнап алды. Гүя, кыямәт көне житеп, каберләр кубарылды...

Кемдер җилкәмә кулын куйды сыман. Карыйм, беркем дә юк. Бик каты куркып, коелып төштем.

—Тыныч бул, энекәш, бу—мин. Беләсеңме, сугышта һәлак булганнан бирле тәкъдиремнең рәхимсезлегеннән минем рухым таш булып катып калган иде. Әниемнең күз яшьләре белән кылган догалары да бу ташны эретә алмаган иде. Бер кадер-хөрмәт, бернинди иркә-наз күрмичә, нибары өметләргә генә алданып киттем бит мин бу дөньядан. Ятим киттем. Әнием үлгәннән соң да ул ташны эретер өчен мине чын күңелдән искә алып беркем дә бер тамчы яшь тә тамызмады. Рәнҗү-каргыш ташы булып каттым да каттым. Синең минем эздән йөрү дулкыны миңа килеп бәрелгәч, башта мин тагын «Черек күл»гә чакыралар икән дип, таштан җан тиремне чыгарып курыккан идем. Ә син изге юлда йөрисең икән. Йолдыз оныгымның туган телсез калуын җәлләп, күзләреңнән тамган кайнар яшьләрең минем рухыма җан өрде, валлаһи. Айрат энекәшемнең минем истәлегемне күтәреп йөрүе дә канат куйды, ахры, миңа.

Ул һәр сүзен әйткән саен давыллы күктә ялт-йолт яктылыклар уйнаклады. Мин сулышсыз, өнсез катып калдым.

—Кайткач әйт син аңа. Айрат бит ул гайрәт дигәннән. Көч-куәт, батырлык, кыюлык, каһарманлык дигәнне дә анлата. Йолдызларга баксаң, аларга гадилек һәм эшчәнлек, тырышлык һәм булдыклылык, юмартлык һәм башкаларга игътибарлы булу хас, диләр. Ә кайбер борынгы кабиләләрдә ул ыруг башы, кенәз дигәнне дә белдергән. Әйт син аңа, энекәш, исеме җисеменә туры килә икән бит аның. Минем олы рәхмәтемне тапшыр. Ә син үзең ник дәшмисең соң әле, энекәш? Бу—мин бит, мин бу! Эзләп йөргән якташ Шагыйрең булам. Гомерем буена мин күңелемне беркемгә дә бушата алмадым. Батырлыгыңны җыеп тыңла инде. Китапларымда да миңа эчемдә янган җәһәннәм утларын әйтергә ярамады. Безнең тормыш юлыбызны да тешкә тиярлек төче итеп яздыралар иде. Хәтта авылыма кайткач та, ачылып сөйләшергә ярамый иде. Арттан донос язарлар сыман тоела иде. Бушанулар алда булыр дип өметләнә идем. Әмма мин фани дөньядан бушаналмый киттем. Ә юкса, ә юкса...

Мин ярлы крестьян баласы булып саналсам да, юк, ялкаулыктан түгел иде ул ярлылык. Кеше хакына керергә теләмәүдән, артык намустан иде. Юлай бабайдан ук килә, диләр иде безнең ул сыйфатны. Үсмер чагым көтүче булып, кеше тупсаларында йоклап узса да, минем кулым эш ярата иде. Әтиемә ияреп, кулыма балта тотып, бик күп авылларда йортлар салып йөрдем мин. Шөкер, таза идем, гармунчы да, җырчы да идем. Уен-көлке ярата идем. Бу яктан Рабиндар улым да миңа охшаган иде... Йортлар салып йөргәндә халыкның күпме моң-зарларын, кайгылы җырларын тыңладым мин. Күңелемә шул җырлар шыплап тулганга, ахры, мин шигырьләр яза башлаганмындыр. Халык җырларын мин бөтенләй әйтә алмый китеп бардым.

Күктәге ялт-йолтларның коточкыч күкрәүләре килеп житте. Кара болытлар ачылып китеп, нык яктырып алган бер арада мин дә телгә килдем. Мине күптән борчыган сорауларымны биреп калыйм дидем.

—Ә ничек син, Шагыйрем, үзәктән ерак, карангы бер авылдан чыгып, Казан зыялылары арасына күтәрелә алдың?—Тагын дөбердәп күк күкрәде. Кара болыт кара ташлар булып ватылып-чәрдәкләнеп аска, әллә нинди мәхшәр киләчәк заман упкыннарына коелды.

—Бүген анда революцияне хурласыннар, таптасыннар, әллә нишләтсеннәр, әмма безнең кебекләрне бары тик революция генә яктыга тартып чыгарды. Гади халыкның тигез, гадел тормышка өмете шулкадәр көчле иде ки, шул халык өмете мине житәкләп Казанга алып килде. Без ул вакытта барысына да изге итеп ышана идек. Шулай булырга тиеш дип уйлый идек. Әмма Корыч бабай тәхетне үз кулына алгач, дөнья болганды,

асты-өскә килде. Революция идеалларын таптап, ул гади халыкны кырды. Без берни дә дәшә алмый идек. Чөнки безнең өчен бу ожмах та, тәмуг та иде. Менә шушы мәхшәрле дөнья мине—шат күңелле егетне үз-үзенә бикләнгән тешләк кешегә әверелдерде. Бер уйласаң, безнең гомерләр тоташ гыйбрәт-сабак, тоташ фаҗига...

Күктә, биектә дөрләп янган рамнар эчендә Шагыйрьнең гигант рәсеме пәйда булды. Аның уң ягына—М. Җәлил, сул ягына С. Хәким рәсемнәре өстәлде. Аның мәртәбәле горур кыяфәт белән мактаулы уртада торуы чыннан да тормышта булган чын фотосын хәтеремә төшерде.

—Ә ничек син, Шагыйрем, шулай батыр булып алар уртасына баса алдың? Башкалар нахакка кулга алынып, инде харап булып ятканда син ничек ОГПУ богауларыннан котыла алдың?—Күктәге утта дөрләгән портретлар тирәсендә куркыныч кара күләгәләр уйнаклады. Кайдадыр козгыннар шомлы итеп кычкырды, бүреләр улады.

—Әйе, минем тирә-ягым да шымчылар белән мыжгып тора иде. Хәтта без шагыйрьләр дә бер-беребездән шикләнә, курка идек. Кайчан кулга алып, таш капчыкка илтеп тыгарлар икән инде, дип, афәт көтеп яши идек.

—Шундый халәттә була торып та, 1934 елда, сыйнфый көрәш каты куерып килгән бер чорда кулга алудан курыкмыйча, ничек син, бунтарь шагыйрь Такташны яклап менә мондый юлларны яза алдың?

Күккә карыйм:
Күктә бер йолдыз да
Болытларга мәңге күмелми;
Җиргә карыйм:
Җирдә зәңгәр күзле
Сөйгән шагыйрь
Такташ күренми.

Бу үзе бер батырлык түгелме соң? Ә бит син иҗатында бары бер шагыйрьгә, бары тик аңа гына шигырь багышлагансың. Ничек шулай булды бу?

—Беренчедән, Такташ минем остазым иде. Мин анардан өйрәнә идем. Мин аның фатирына да барып йөри идем. Ул мине бик җылы кабул итә иде. Мин аның белән уртак тел таба идем. Ул миңа, йөрәк парәм, сиңа кыен булыр, син артык кайнар, холкың да кырысрак, сак бул, синең киләчәгең алда әле, дия иде. Мин аны чын күңелемнән ярата идем.

Икенчедән, мин аның бөеклеген алдан күрә идем. Алар белән мөнәсәбәттә дә, таш капчыклардан котылып калганда да мине Әнәгемнән алган сыйфатлар: Әнәк кыюлыгы, сабырлыгы, сизгерлеге җитәкләп йөретте. Безнең әнәкләрдә, күз буып, кеше алдында кинәт юкка чыгып, кабат барлыкка килә ала торган легендар борынгы Серле Бабай булган. Кайберәүләрдә шуннан исән калып килгән гипнозчы, экстрасенс талантлары бар иде. Кара син, кендек әбисе Хәтирә әбине—ул бит авылның дипломлы докторы сыман иде. Ә академик Гыйльменур әби?! Ә теге, теле белән тисә дә чуаннарны юк итә торган Галим бабай карчыгы?! Һи-и...

—Йомшак урыныма кагылдың, Нур Агам, миңа бит әнә шул гүзәл Әнәк әбиләренең дәвалау осталыклары «Мәңгелекнең сере кайсы тамырда?» дигән тыйбби әсәр язарга илһам бирде. Әнәк кешесе беркайчан да бер-берсенә мактау сүзләре әйтергә яратмады. Әмма форсаты чыккач әйтеп калыйк. Безнең очтан Гайнуллалар, Хәнифәләр, Рәмзия, Резидәләр, сезнең очтан Мәдәнияләр, Дәмин бабай балалары, Әхнәф Заһировлар Әбугалисина оныклары диярлек иде бит. Яшь буыннан Ринат, Феликс, Илшат Фәрдиевләр, Алмаз, Айвар Шәриповлар хәзер дөнья402 тоткалары! Ә Авзал малае Сәлах турында син белмисеңдер әле. Тынгысыз, сәер кеше булган ул. Типографиядә басылган сыман итеп дөнья һәм ил карталары ясый торган булган. Димәк, анарда борынгы сәйяр җан, ерак

сәяхәтләрдә йөргән бабаларның кан хәтере уянган. Ә аның энесе бүген Чаллыда яшәп ятучы Инсаф Авзалов һәвәскәр галим. Ул татар теленең жиде законын ачкан. Ул Колумб корабында татар кешесе тәржемәче булган дип фаразлап язылган пьеса авторы да.

Ә Напалеоннарга тиң фәлсәфә корырга яратучы башлы егет, Президентлар киңәшчесе булырлык инженер-философ Вәсим Фәррахов үзе генә дә ни тора! Күршең Минтимер турында әйтмибез дә. Ул бүген бөек Кешеләр рәтендә. Әнәк уртасында авылның күренекле кешеләренең һәйкәлләреннән бер аллея ясарга булыр иде.

Аһ, аяныч, аракы диңгезенә йөзеп кереп киткәннәрдән бик күпләр кире бу як ярга чыгып житә алмадылар.

Күк уфылдап куйды. Суда баткан ташлар авазлары ишетелде.

—Менә ни аяныч, без дә шул суга баткан ташлар халәтендә идек. Революцияне ялкынланып каршы алсак та, соңыннан йөрәк теләгәнне яза алмыйча, сәясәт кушканны, чор боерганны, шуңа яраганны гына язарга мәжбүр идек. Шигыреңдә Корыч Бабайга дан булмаса, цензура төшереп калдыра иде. Жанны, рухны жәзалап кына яза идек.

—Сугышка кадәр син, Нур Агам, Жәлилләр уртасында булып та, сугыштан соң чыккан китапларда Жәлил, Кәрим, Кутуйлардан соң дүртенче булып кына урнашкансың. Нидән бу?

—Аһ, авыр моны тану. Мине мәхәббәт сагышы басты. Улымны үз янымда үстерә алмавым бәгырьләремне яндырды, үкендерде. Сигез яшендә миннән калды бит ул. Мин бу турыда тетрәндергеч драма язармын дип йөргән идем. Ара чыкмады. Сугыш кисте бөтен планнарымны. Ә сугышта язганнарымны жибәрә тордым, югала торды. Хатынымның апасы Оркыядан башка ышанычлы кешем калмаган иде.

Гүя таулар тауларга бәрелеште. Күкрәү, чыңрау, шыгырдау, дөбердәү, уфылдау авазлары барысы бергә кушылып мәхшәр хасил итте. Гигант утлар жиргә капланды, жир туп сыман күккә ыргылып, кара болып упкыннарына батты. Дөньяны дөм караңгылык каплады.

—Ә улың? Ә дусларың? Соңыннан оныкларың? Ә маржаң?

—Елатма мине, күз яшем юк. Авырттырма жанны, рухны, туганым. Рух авыртуы ул тән авыртуыннан миллион мәртәбә коточкыч, тәмуг дигәне дә шушыдыр аның. Улым балалар борчуына кереп батып дөнья кугандыр. Ә оныкларым... Аһ, оныкларым, алар минем утлы күмерле куанычларым гына шул. Алар мине үз туган телләрендә укый белмәделәр. Аларга мин кирәкмәдем. Кирәк булсам, еллар узгач та, Казанда яши торып, минем ижатым белән кызыксынырлар иде. Алар бит минем турыдан-туры варисларым. Бу бит аларның вөждан бурычы иде. Әмма аларның берсе дә төрле жирдә таралып яткан кульязмаларым исән чагында жыеп туплый алмады. Берни дә язып чыкмады. Такташтан башка, ахры, минем дусларым юк иде! Ә маржа? Аңа өйләнү ялгыш өстенә ялгыш кына булды, ахры. Ул да мине утка салды. Кыскасы, минем ижатымны саклар кешем юк иде.

Мен тарафтан чатырдап яшен утлары атылды. Гүя бөтен пәйгамбәрләр уянып, жир катына төшә иде. Каралып-яшелләнеп-зәңгәрләнеп йөргән болытлар да чыдый алмадылар, кызардылар, бик каты оялдылар бугай.

—Ярый әле Айрат белән сез булдыгыз, тагын, тагын рәхмәт сезгә. Менә ни бит ул туган телеңдә калу. Ул—хәтер, хатирә, ул изгелек. Аһ, жәл, Коръән һәм истәлек ашларын да оныкларым ясый алмаслар инде. Көтсәм, бары тик сездән генә көтәм. Казаннарга өметем өзелде.

—Казан дигәннән, күкләрдә бер-бер хәбәр юкмы соң? Казанны кайчан, кем татарга кире яулап алып бирә алыр икән соң? Көн туды исә милләтчеләр Казанны уятып булмый, дип шаулый, ярсый, бәргәләнә. Ярый әле анда Чаллы бар дип, заманында син редактор булып эшләгән Чаллыга килеп егылалар да бөтен зар-моңнарын шунда түгеп китәләр. Аңлыйм мин аларны. Казанда анда татар балалары чиркәүләрдә чукынып йөрсеннәр дә, нишләп алар милләт ягына сүз-сәламнәр юлласыннар?!

Ничек итеп Казан йоклама...—Кинәт минем өстемә шыбырдап су коела башлады. Суы әче, тозлы иде. Юк, бу су түгел, ә озак еллар буена җыелып буылып яткан күз яшьләре иде, ахры. Бу ни бу, дип, югарыга карасам, Нур агамның рухы рәсеме күз яшенә күмелеп елый иде.

—Аһ, чиркәү дип ник әйттен, ник уяттың таш булып каткан рухымны?! Бу мин яна-яна елыйм күкләрдә. Мин бит балаларым үз юлымны, телемне дәвам итәчәкләренә шикләнми дә идем. Дөрес, без урысча белергә омтыла идек. Ләкин урыс теле безнең оныклар авызыннан газиз туган телен тартып алыр, аларны бөек рухи нәфислектән мәхрүм итәр дип башыбызга да китерми идек.

Аһ, елыйм мин, рәнҗим. Өзелде бәгърем. Шулай да ташым эреп ашларына таммасын иде. Нишлим, кем булсалар да, мин аларга изгелек кенә телим. Оныτсалар да, бөтенләй искә алмасалар да, бәгырь итләрем ич алар минем. Тик алар минем бу дингездәй күз яшьләремне күрсеннәр иде. Юк ла, күрмәсеннәр... Ә шулай да бәхетләме соң алар?

—Кичер, зинһар, Нур Агам, мин сине болай ук рәнҗетергә теләми идем. Әле ярый син Рабиндарыңны татарчага өйрәтеп калдыра алгансың. Ә бит башкалар бөтенләй дә әллә кая торып чапканнар... Ә яшь минем өстемә коела да коела иде. Гүя Әнәкнең урман чишмәсе сулары иде ул. Җанны тетрәтә иде.

—Ничек болай соң инде бу? Татар илендә татар башкаласында татарның асыл дәвамнарын үз кавеменнән читләшергә ирек куябыз? Җитмәгәнмени инде аларга без биргән меңләгән Державиннар, йөзләгән Карамзиннар? Кая безнең чын горурлык, чын милләтчелек? Бу хәл башында уе булган һәр татарны тетрәндерергә тиеш. Монарчы бер каршы сүз әйтмәгәнгә шулай бит ул. Кемнәрдер анда милләтчеләрне экстремизмда гаепләмәкче булалар, мондый чакта экстремист түгел, әллә кем булырсың.

Каядыр күкләрдә чын татарча көчле ыңгырашып, чын татарча куәтле елаган тавышлар ишетелде. Гаҗәеп татлы авазлар иде бу. Богаулар шартлап өзелгән тавышлар күкрәүләрдән дә көчле иде. Безнең җаннарның иң югары әрнүле, рәнҗүле газабы күкләрнең җиде катыннан да югары торган бөек рухны чакыра иде, ахры.

Кинәт Көнчыгышта куәтле яктылык пәйда була башлады. Ул ниндидер нечкә бер торбадан суырылып-сызылып агыла, зур газап белән тартыла-тартыла чыгып килә иде. Бу яктылык чәчелде дә җыелды, чәчелде дә җыелды. Аннары бер формага керде. Каршымда элекке сәер борынгы танышым Ак Әүлия басып тора иде.

—Әйе, әйе, мин дә сезне хуплый-хуплый сөйли алам. Әйе, ул хәсрәтләрне ачыктан-ачык әйтергә мөмкин хәзер. Әйе, бер уйласаң, алданмасын иде, зар еламасын иде инде татар, саташкан юллардан китмәсен иде. Әйе, бу килүдә син очрашкан депутатларга да уйланыр урын бар. Әйе, ник алар сессия трибунасыннан язучыларның нәкъ үзләренә кагылган нечкә хәлләр—үз балаларының туган телен белмәү гарьлекләре турында җаннар сызланырлык итеп, ачыргаланып кычкырмыйлар? Чаң какмыйлар? Ник алар чын күңелдән телгә, халыкка табынмый торган ясалма язучыны үзләренең «мөфтиләре» итеп күтәреп, милли доганы ялганга төреп укырга ирек куялар? Шуннан да башлана торгандыр ул оныкларның ялгышу сукмагы. Безнең оныклар, язучыларның да ялгышлары—ул тирә-як җимеше. Сина бүләк итеп биреп калдырган китабында Шамил Маннапов язмыш кушуы белән саладан калага киткән авыл кешеләренең уртак язмышы турында әнә ничек яза:

Тик белмәдем, авылымнан китеп,
Үз тамырым үзем кискәнем,
Чит җирләрдә янә тамырланып,
Җимеш бирү кыен икәнен,
Нигезеннән китү—
Диненнән дә,
Теленнән дә китү икәнен,
Мирасыннан китү—
Үзеңне дә
Дәвамыңнан мәхрүм иткәнен
Белмәдем шул...

Бер дә әнә татар авылында тора салып урыс үрчеми. Бернинди указлар да, бернинди ярсу каһәрләр дә кирәкми. Казанда 70 процент татар булса, өр-яңадан татарлашу башланачак. Күрче дә шуны, белче дә моны, үрче, татар, котылып каласын килсә, кайтар читләрдәге татарыңны, татар. Бераз дорфарак булса да әйтим, үз телен оныткан татарга якты йөз күрсәтмә, татар. Һәм бу кайгыларыгыз әкренләп эреп юкка чыгар.

Күктә әллә нинди илаһи искиткеч гүзәл мәчет манаралары пәйда булды. Алланың иң бөек катына якынайта торган азан авазлары яңгырады.

—Рәхмәт, Ак Әүлиям,—дидем мин, аның белән килешеп.—Нур Агама да йөрәк борчулы сүзем бар. Минем тел дип, дин дип чыгымчылап йөри торган чакларым узган инде. Хәзер мина тыныч кына үз динемне тотып, тын гына табынып, ахыргы көннәремне уйлар вакыт житкән. Диннәрнең төрлелегенә дә исем китми минем. Беләм, Дөнья бер, Алла бер, Яшәү бер. Минем динем генә яхшы, дип, ахмак кына тәкәбберләнер. Әмма менә шул бер генә яшәешендә үз кавемең белән үз телеңдә чөкердәшеп яшәүләргә ни житә дип саный идем мин. Ләкин, тагын кабатламый булдыра алмыйм, синең дәвамнарны күргәч, әллә ничек мин бабай кешенең дә сүнеп-сүрелеп торган милли хисләре, яшьлегендә ярсу арслан кебек ажгырып торган милли холкы, үч-ачу катламнарын актарып, дулкын-дулкын давыл булып куптарылды. Һәм, Нур Агам, оныкларыңны туган телләрен онытканнары өчен оялткандай иттем. Соңыннан үзем дә бик читенсендем, Нур Агам, син мине гафу ит. Дөнья бозык бит. Аларның миңа: «Нигә син безнең дин ирегенә, безнең хокукларга бәйләнеп йөрисең?»—дип әйтүләре дә мөмкин ич. Юкса мин катырак та әйтә, бураннар да туздыра алыр идем.

—Әй, энекәш, энекәш, аларның иреге өчен без һәлак булдык. Син дә оялтмасаң аларны, кем оялтыр соң? Без мәрхүмнәр аларга берни дә әйтә алмыйбыз. Моны сез, исәннәр генә эшләсәгез инде. Син чигенмә, син дөрес юлда, Ходай сиңа сабырлык кына бирсен.

—Аннары тагын бер бик читен, әйтергә кыен гаебем бар синең алда.

—Ярар, улым, анысын мин әйтим,—дип яктырып телгә килде Ак Әүлия.—Бүгенге Татарстанның хужасы—Президенты син яшьтән бергә уйнап үскән күршең Шаһишәрип углыМинтимер ич. Һич көтмәгәндә, уйламаганда бу энекәшеңнең 60 яше тулганда Президентыбыз аны Казанда бөтен мәшһүр зыялылар алдында бик матур итеп котлады. Мактау кәгазе дә тапшырды. Ул аны синең дәвамчың дип атады. Ләкин кайчак артыграк һавалы була синең бу энекәшең. Ул бу чагыштыруны кабул итә алмыйча бераз үпкәләп, шактый кәефсезләнеп тә йөрде. Беренчедән, ул сине маржага өйләнеп, татарда нәсел-нәсәпсез калган кеше дип ялгышып чит итсә, икенчедән, синең сәясәткә киткән ижатыңа, әрәм янган гомереңә тинләшәсе килми иде. Шагыйрьлекнең асылы системаны, сәясәтне яклауда, мактауда түгел, ә чын шагыйрь мәңгелекне, тормышны, үлемне, мәхәббәтне, табигатьне жырларга тиеш, дип саный ул. Һәм бераз гына аңарда хаклык та юк түгел. Менә хәзер генә, синең ачылмаган йолдыз икәнлегеңне ачыклагач кына, ул Президентның зирәклегенә кайта-кайта сокланды. Аллаһым үзе аның соклануын кабул итсен. Президент синең эздән йөрмәсә дә, синең, Нур, газап утында янган чын ижатчы булуыңны йөрәге белән сизенгән, акылы белән аңлаган икән.

—Беләм, беләм, гомерем буена миннән гел шулай шикләнеп йөрделәр. Дусларым да, сөйгәннәрем дә, хәтта авылдашларым да. Нишлим соң, замана мине тешләк булырга, йомыкый булырга, авызымдагы канны төкермәскә мәжбүр итте,—диде Нурның Рухы.

—Әйт, Ак Әүлия, нидә соң безнең хаталарыбызның очы-башы? Европаны тетрәндереп торган Аттилалар кавеме ник болай үз Рухы белән Сак белән Сок хәлендә сөйләшергә мәжбүр булып калды?—дидем мин, аклыкка төбәлеп.

—Европада күптән инде татар сөякләре өстендә чын ирек байраклары

жилферди. Һәр халык үз тормышын үзе теләгәнчә төзи. Анда тәкәббер империядән калган шешләрне күптән инде көйдереп аттылар. Монлагы милләтләр генә иске кысаларда тилмереп яталар. Күтәрел дә, татар, бер киерелеп, ташла искергән кануннарны җимереп. Синең үз рухлы булып яшәргә тулы хакың бар. Чөнки Аттиладан алып Муса Җәлилләргә, Нур Баяннарга хәтле бөек татар юлы сузылган, бөек татар Дәүләте җәйрәп ята.

Мөстәкыйльлеккә таба барган бу Дәүләтнең узган юлында күпме хата-ялгышулар... Әллә соң без әлегәчә ярата белмәгәнбезме, Ак Әүлиям?

Монда инде Нур Агам түзмәде, телгә килде.

—Аһ, әйе, кызганыч, татар артык йөрәк белән ярата, ахры, намус белән ярата. Бу кин дала мирасыдыр, мөгаен. Ә башкаларда исәп-хисап өстен. Менә минем Рабиндарым да йөрәк хисенә бирелеп ялгышкандыр, күрәсең. Беркемгә сиздермичә, Ходайга инәлеп, күз яшьләрем белән ана бәхет ялварсам да, аһ... үкенечләре калган тезелеп...

Ак Әүлия:—Кызганыч та, аяныч та. Ул нибары татар авылында туган гади бер кызга өйләнә. Инде монда чишелеш татар файдасына булырга тиеш иде сыман. Әмма ул кызның нибары әнисе генә белорус була. Күрәсең, аңарда миллилек татардан өстен булгандыр. Менә шул белорус Ана аңа: «Кызым, зинһар, үз динеңне ташлама!»—дип, шундый тирән иман сеңдергән ки, бу бала чатнатып татарча сөйләшсә дә, үсеп җиткәнче татарлар арасында яшәсә дә, эчендә яшерен генә анасы динен тоткан.

Үз диненә сусап, татар башкаласына килгән ярым белорус баласы шагыйрь баласының гаиләсен ботарлап ата, аны чит кавемнәр коллыгына аударып ташлый. Бер уйласаң, аны да гаепләп булмый кебек...

Аһ, үрнәк алсын иде анардан хәзерге көндә үз карыныннан төшкән баладан чит кавем кешесе ясап ятучы татар хатыннары!

Рухтагы Агам да, мин дә катып калдык. Моннан да югары сүзне әйтеп булмый иде кебек инде.

Күк тә тынычланып калгандай булды. Анда шомырт чәчәк аткан хуш исле бакчалар пәйда булды. Башларны әйләндерә иде бу хуш исләр. Шушы хуш исләрдән тынычлык, илһам алып булса кирәк, Ак Әүлия безне юатырга кереште...

Ак Әүлия:—Икегез дә артык шикләнәсез. Корыч Бабай заманы чиреннән арына алмыйсыз. Сез бик артык борчылмагыз әле. Бер сынык шигырь, бер кәкре хикәя язсаң да, син язучы исемен алсаң, нәселең, авылың, халкың өчен зур казаныш ич. Бер шагыйрь аша меңләгән, йөз меңләгән кешеләрнең рухы, халыкның рухы мәңгелеккә җитеп аваз бирә ала.

—Шулай да, Ак Әүлиям, син бераз ирекле фикер йөртергә ирек бирче. Әнә Нур Агам:

> Мин ант итәм сиңа, акылым көчен
> Туры юлың өчен бирергә.
> Коммунизм җирдә җинсен өчен
> Мин әзермен утка керергә!—

дип тә язган бит. Хәзер бу сүзләр, мин татарымнан китеп, башка кавемнәрне ныгыту өчен гомеремне бирергә дә әзермен дигән ант булып яңгырый түгелме?

Ак Әүлия:—Юк, ялгышасыз, бу—аның гаделлек анты!

Мин:—Коммунизм дигән сүзләрне таптап киттеләр бит инде, Ак Әүлиям, бүгенгеләр безне дөрес аңламаслар. Элекке мираслар, иҗат гомерләре көлгә очты, җәмгыять кире юлдан китте. Бөтен нәрсә ватыла, җимерелә, күп нәрсә кирегә ага. Колхозлар таркала, кулак, сәүдәгәр, капиталистлар ыржаеп кире кайта.

Ак Әүлия:—Юк, коммунизм сүзе ашарга сорамый ич ул. Элек кыерсытылганнар бәхәсне бик каты куерта. Алар реванш алмакчы.

Коммунистик идеология гүзәл идеология. Әмма аны тормышка ашыру гына пычрак юл белән алып барылды. Менә бусы башка! Ул сүз беркемгә дә зыян салмый. Анда сатлыкҗаннар, комсызлар гел ул сүзне сатып, таптап йөрсеннәр, ул кешелекнең соңгы көнендә дә иң газиз сүз булып калачак. Әле бүгенгә байлыкка омтылу яры булып кешенең күзен гүзәллектән, хакыйкатьтән томалый. Килер бер көн, әгәр болай шыр байлык туплау дәвам итсә, кешелек бушлыкка, экологик, эгоистик һәлакәткә генә килеп чыгачак. Киләчәк кешелекне ул афәттән ни дә булса коткарып кала алса, бары тик шул идея генә коткарып калачак. Кешеләр соңгы чиктә шул идеяне эзләп чүлләр, үлемнәр аша аның бинасына барып чыккач, кипкән иреннәре белән ташларын үбә-үбә: «Без ялгыштык»,— дип тәүбә итмәсләрме?..

Мин Ак Әүлияне сокланып тыңладым. Авыллардан-авылларга тарихлар эзләп сәяхәт итеп йөргәндә аның белән бик сәер генә бер очрашкан идем инде. Арыш басуында.

Ул, мин Әнәкнең борынгы карты булам, дигәч, эзләгәнемә юлыктым бит, Ходаем, дип, сөенеп, үзем белән авылыма ияртеп алып кайткан идем... Аның белән милли дөньялар, Әнәк тарихлары турында сөйләшербез дигән идем. Ләкин Әнәк җиренә аяк басу белән аңа әллә нәрсә булды, ул чын мәгънәсендә телсез калды.

Ул көнне мин мунчадан соң тынычланырмын инде дип уйлаган идем. Әмма бөтен тәнне-җанны нидер кыса, баса иде. Минем каядыр китеп, күңелемне бушатасым, яланнарда озаклап сөйләшеп йөрисем килде. Ләкин Ак Әүлиянең һаман теле әйләнми иде.

Гомумән, мин олыгая барган саен болай да үземә сердәш, гәптәш, дус күңел таба алмый интегә идем, моңа шомлана идем. Бу минем бик тә авыр хәләтем иде.

Элек йоклый торган урынымны—веранда идәнен, үзе сорагач, Ак Әүлиягә бирергә туры килде. Ә үзем борынгы пружиналы тимер караватка урнашып карадым. Әмма уңга әйләндем, сулга әйләндем, сыртыма ятып та, капланып ятып та карадым. Җәйге саф һавада булуыма карамастан, һич кенә дә йоклап китә алмадым. Башым, мең төрле вак чүкечләр белән суккан сыман, зыңлап шаулый да шаулый иде.

Бераздан караваттан төшеп, кунакның аяк очына да ятып карадым. Ләкин бу да ярдәм итмәде, башымда шаулау көчәйде генә. Ахры, Ак Әүлиядән миңа ниндидер энергия күченә, мин аның аурасына эләктем булса кирәк.

Йокы көтү газабында шулай таңга хәтле ятылды. Инде таң атып, яктырып та килә иде.

Берзаман мине ниндидер сәер, сихерле көч саф һавага чакырды. Мин ишекләрне шап-шоп ачып тышка ташландым. Баскычтан таң ягына баксам, хәйран тамашадан шаккатып, өнсез калдым.

Анда офыктан күкләргә ашкынып, төрле төсләргә күмелеп, шашынып болытлар кайный иде. Мондый ярсулы кайнаган җәйге болыт ташкынын минем беркайчан да күргәнем юк иде. Тирә-ягымда агачлар җан фәрманга бөгелә-сыгыла шаулый. Болытларда әллә нинди ялкынлы гигант катламнар барлыкка килә, урта бер җирдән каракучкыл болыт полосасы яна-яна, җилләр, яшеннәр белән тартышып, телгәләнеп, әллә нинди коточкыч упкын хасыйл итә. Ул упкынга зур-зур мал көтүләре бөтерелеп кереп китеп юк була, җир сөргән тракторлар, танклар пәйда була да юкка чыга, сугыш мәхшәрләре, пушкалар, бомбалар, туплар шартлавы астында очсыз-кырыйсыз гаскәрләр—бәндә балалары шунда төшеп югала, гүя бөтен кешелек язмышы шунда дөрләп яна иде.

Карарга куркыныч, тетрәнүле бу фантастик таң күренеше гүя дөньяда барган коточкыч фаҗигаи хәлләрнең бер чагылышы иде. Гүя Ш. Камаллар, Горькийлар, Шекспирлар, Еникиләр язган бөтен-бөтен фаҗигалар шушы бер упкында бергә кайный иде. Бу ниндидер хәвефләрдән кисәтү иде, ахры. Җилкәмдә авыр бер көч тоеп, артка борылдым. Ак Әүлия утлы

кара күзләре белән мина төбәлеп басып тора иде. Ул яланаяк чирәмгә баскан. Мин дә бәпкә үләнендә яланаяк идем. Ул телгә килде:

—Бу Европа белән Азия шулай бәрелешә!..—диде.

Шушы төндә татар илен шактый җимереп, агачларны аударып, йорт түбәләрен очыртып, афәтле өермәләр узган иде.

Инде менә Ак Әүлиянең безнең Нур Агам белән очрашуларны да догалы итәсе килә иде, ахры.

—Әйдәгез, мин сезне хәзер Европада татарлардан борынгы истәлек булып калган Алып тауларына алып китәм. Хәтерлисезме, Нур, минем шулай дәшүемә аптырамагыз, мин монда барыгыздан да өлкәнрәк, мин ике мең ел буена әнәкләрне җитәкләп йөрткән Кабилә Рухы.

23 апрель көне иде ул. Җиргә шаулап язлар килгән мәл. Без шул мизгелдә үк Австриянең Алып тауларында идек инде. Бөтен тирә-якта бомбалар шартлый, йөзгә кайнар сугыш ялкыны бәрә. Чәчәк исләре дары-төтен исләре белән буталса да, җирдә-кырда яшәү дәрте, сөю иләслеге өстенлек итә иде.

—Хәтерлисеңме, Нур, нинди нурлы иде ул көнне синең күңелең?

Нур Агам, үзенең нибары Рух кына икәнен онытып, үзәк өзгеч хисләргә бирелде...

—Сугыш башлану белән урыс-яһүд язучылары мәрхәмәтле тыныч урын эзләп Татарстанга, Чистайга күченеп калдылар, ә без татар язучылары пачкалап-пачкалап сугыш кырларына, ут эченә юнәлдек. Үзебез теләп. Шулай... авыр вакытларда татар үзе теләп ярдәм итә бит ул иленә... Армия гәзите редакторы булып гел алгы сызыкта идем. Эшемне күргәннәрдер, подполковник дәрәҗәсенә үк күтәрелдем. Инде менә атна-ун көннән сугыш та тәмам булачак. Бүген ничәсе әле, егерме өченче апрельме? Хуш, Ак Әүлия, син туган якка кайтып хәбәр итә торсаң да була.—Нур Агам аяк астыннан тау чәчәге—эдельвейс өзеп алды, аны борынына якын китерде.—Аһ, нинди хуш исле, нинди рәхәт яз килә, туганнарым, җиңү язы... Туган илләрнең сагынычлы шифалы җилләре борыннарны кытыклый, дусларым. Туган авылым Әнәгемне, газиз әниемне, чәчәкле болыннарыбызны, Бажана, Ык буйларын, төшләремә кереп, хисләремне кузгаткан урман чишмәләрен сагындым, туганнарым. 1939 елны мин сугыш алдыннан:

> Киткәнемә инде бик күп еллар,
> Сагынгандыр мине карурман;
> Мин югымда инде бик күп уллар
> Үскәннәрдер, хәзер мин аларны
> Кыйнап китсәләр дә танымам!—

дип язган идем бит мин Әнәгем турында. Аһ, нинди күңелле булыр җиңеп туган илгә кайтулары, нинди рәхәт булыр туганнарым, якыннарым белән очрашулар...

Шулчак Ак Әүлиянең йөзе карала башлады. Болгана-болгана карала иде аның йөзе. Ул нәрсәдер әйтергә, кисәтергә тели иде, ләкин ул бу юлы тагын хәрәкәтсез вә телсез катып калган иде. Мин нindидер хәвеф сизеп, тетрәнеп, телсез калдым.

Ә Нур Агамның сөйләве аның саен көләч, шатлыклы, бәхетле була бара иде.

—Моңарчы минем иҗатым әле зур иҗатка кереш кенә иде. Мин сүзнең бөеклеген әле аңлап кына килә идем. Мин кайткач, өр-яңадан тугарылып-җигелеп, илһамланып иҗат итәчәкмен. Әнәгемнең тарихын өйрәнеп, аның турында китаплар чыгарачакмын. Юкса бит әле минем шагыйрь булгач, авылым кешеләре белән рәтләп очраша алганым да булмады. Шулай озак очрашмый йөргәнем өчен алардан әле минем гафу үтенәсем бар...

Күктә әллә кояш тотыла иде инде. Тирә-яктагы үлән-чәчәкләргә дә кара күләгәләр төште. Туп тавышлары тау битләреннән килгән кайтаваз

белән көчәеп, бөтен дөньясын мәхшәр тавышларга күмеп китте. Таулардан зур-зур мәрмәр ташлар тәгәрәде. Шагыйрьнең туган ягын, халкын сагынган Бөек Рухы сугыш тупларыннан көчле иде, күрәсең... Тавышы күкрәүләрдән өстен яңгырады:

—Минем әле өзелеп яраткан Рабиндарымны кочаклап үбәсем бар, аның әнисен гафу итәсем бар. Алтын дисбе кебек оныкларымны иң олы мәхәббәт белән яратып сөя-сөя, Иделләрдә йөзәсем бар. Татар дөньясының чәчәк атуын күрәсем бар. Бар! Бар!!

Их, яшисе килә җир күкрәтеп,
Ал чәчәкле якты илемдә!
Без күрәшләр кичтек җир тетрәтеп,
Бирешмәбез тиген үлемгә!

... Аһ, шул вакыт тау ягыннан очып килгән туп нәкъ аның янына төшеп шартлады. Башка аның тавышы ишетелмәде. Гәүдәсе дә, бөек хыяллары да калын җир катламы белән күмелеп калган иде...

* * *

Ак Әүлия мине әле һуннар, әле монгол-татарлар, әле миллионлаган татар солдатлары гасырлар буена бер көнбатышка, аннары тагын көнчыгышка туктаусыз дулкын сыман тирбәлеп, дала чабып, шомартып, таушалдырып бетергән төрки юллар буйлап Алып тауларыннан Казан якларына кайтарып төшерде...

* * *

... Ике яктан да көчле итеп бәргән яктылыктан мин, машинада баручы абзагыз, уянып киттем. Кара, минем Казаннан кайтып килешем икән бит әле. Күземне ныклабрак ачсам, без Кама аша салынган озын күпердән, Кама диңгезе аша, гасырлар аша үткән Сират күпереннән чыгып бара идек. Ике якта да Каманың кышкы ак кинлекләре җәйрәп ята. Кояш нурлары ул кырлардан прожектор утлары сыман кайтарыла иде.

... Ак киңлекләр аша ак күпер...

—Менә кайтып та җиттек, абый,—диде шофер егет.—Әй сез бик тирән йокладыгыз.

—Рәхмәт, энем. Шушы ике сәгать эчендә синең машинаң бөтен дөньяны гизеп чыкты. Изге юлда йөрде. Эшләрең уңар синең, энем.

## Соңгы сүз

Шулай итеп, аерылу минутлары да җитә, укучым. Моны язганда миңа фәрештәләр гел канатларын җәеп, гел уңай җай китереп тордылар...

Кара инде, әсәрем тәгәлләнеп килә, ә радиодан, ни могҗиза, әсәр өчен бик тә кирәкле хәбәр яңгырый. Ташкентта яшәүче композитор Садыйков турында тапшыру бара. Диктор болай ди:

—Ул беренче көйләренең берсен Нур Баянның «Уйланганда» дигән шигыренә яза. Композитор хәзер үзенең иҗатын сөекле Татарстанына алып кайтып җиткерү хыялы белән яши.

Нур Баян сүзләре әнә нинди еракларда музыка канатында кайтачак икән әле... Аны Әнәк бәйрәмендә яңгырату нинди күңелле булачак!

Әнә, миңа телефон шалтырый.

—Бу—мин әле, Навил абзаң булам. Менә Чаллыга килеп чыккан идем дә, хәлеңне белеп китим дидем.

Миңа нәкъ ул җитми иде. Нур Баян әнә соңгы сулышында Суфиядан

гафу үтенәсем бар, диде ич. Ә мин ул ханымның язмышын сораша алмаган идем. Бәхетле була алды микән ул шагыйрьнең беренче газиз хатыны?

—Хәзер синең янга очтым, дустым...

Аның хәлләре искечә иде. Чаллыда үзенең сүзлекләрен тарату эше белән мәшгуль икән.

—Теге вакытны өлгерә алмый калдым бит. Суфиянның теге кеше белән булган романы ничек тәмамланды соң? Меңләгән укучылар көтә хәзер синнән бу җавапны.

—Мөхәммәт Нигъмәтуллин исемле яшь инженер-химик иде ул. Университет тәмамлаган иде. Җилле егет иде болай. Әллә саулыкка туеп җитмәде инде, сугышка алмадылар аны. Сәүдә системасында эшләде: Кольцода гастрономда директор булып торды. Өч балалары булды. Чыңгыз дигән уллары океаннарны өйрәнү институтын тәмамлады. Зур галим булып, Калининградта төпләнеп калды, ахры. Икенче уллары Рөстәм авыл хуҗалыгы институтын бетереп, кандидатлык яклады.

Карасана, Суфиянның икенче тармагы да югарыга таба очкан икән бит, дип, тын да алмыйча тыңладым мин. Элекке сәүдәгәр токымы бирешмәгән, әнә фән дөньясына үрмәләгән бит. Өченчесе нишләде икән?

—Соңгы балалары Сания исемле иде. Ул бик чибәр, әнисеннән дә чибәр бер ханым булып, бик бәхетле гомер кичереп ята булса кирәк. Ул филология фәннәре кандидаты булды. Немец-француз телләрен су кебек эчә. Олы-олы түрәләр чит илләргә чыкканда аны үзләре белән тәрҗемәче итеп алалар. Ирнең дә ул шактый биектәгесен, уңганын сайлады. Ире энергетика институтының ректоры. Алар бергәләп Карловы Варыларда гына ял итәләр. Бик модница инде—киемнәрен Париж салоннарында гына заказать итә, диләр.

Шулай итеп, Суфия ханымның хыялы, образы аңарда дәвам итә икән. Берни дә юктан бар булмый, дигән бит бер философ.

* * *

Навил шалтыраткан бу көн тагын 23 апрель көне иде. Мин үзем дә, Навил дә Нур Баян һәлак булган бу көнгә игътибар итмәдек. Инде караңгыланып килә. Бераз гына яңгыр сибәләп ала. Без Чаллы урамнары буйлап йөрибез. Навил Әнәк бәйрәме, Нур Баян бәйрәме турында тәкъдимнәре белән уртаклаша.

—Менә кара әле анда авылга керә торган берәр күпер юкмы?

—Бар бит.

—Ну вот, шул күперне матур итеп аркалар ясап, Нур Баян күпере итеп бизәргә иде. Исемен язып, Чишмәләр булса, чишмәләрне дә матур итеп бизәргә кирәк иде, әнә теге, нефть якларындагы сыман. Шуңа карап башка җирләрдә дә язучыларның исемен хөрмәтләрлек булсын.

... Каманың ак киңлекләр аша салынган ак күпере...

Һәм менә тагын Әнәк күпере...

Юлай бабайның бер-берләренең бар икәнлекләрен дә белмичә яшәп ятучы токымнарының, Әнәктәге татар телле, Казандагы урыс телле дәвамнарының шушы күперләр аша бергәләп чыгасылары бар бит әле. Әнәк Сабан туена бергәләп барасылары бар. Ике як та ничек, нинди телдә сөйләшергә белмичә бик аптырап читенсенер инде. Моңарчы күрешмәгәннәренә уңайсызланып, кулларын кая куярга белмичә, оялып-оялып читкә карар инде. Кардәшлек тамырларының тибрәнүе күзләрдә энҗе яшьләр булып та елтырар, мөгаен...

* * *

Көндәлекләремне, язмаларымны карап чыккач, 23 апрельгә тагын тукталмыйча булдыра алмадым. Минем өчен егерме өченче апрель, Нур Баян һәлак булган көн, күңелемне йә шатлык, йә кайгы белән

тетрәндерә торган көн булып киткән икән. Туры килүме бу, әллә бер-бер рухлар уенымы, белмим.

1997 елның 23 апреле мине аеруча каты тетрәтте. Мин телем белән җир себереп, йөз суымны түгә-түгә, алар өчен бик күп яхшылыклар эшләгән кешеләр нәкъ менә шушы көнне мине бик авыр хәлдә калдырып, хыянәт иттеләр, нахак бәла яккан кешеләр ягына аудылар...

Башымны ташка бәреп еларлык авыр иде миңа. Рәнҗү-хәсрәтемнең биодулкыны шулкадәр дә тетрәндергеч булгандыр, күрәсең, шул көнне миннән 90 чакрым ераклыкта Әнәктә яшәп ятучы әнием әҗәл авыруы белән авырып киткән иде...

Ә 1988 елның 23 апреле, киресенчә, миңа дәртләнеп күкләргә ашкынып очарлык куаныч китерде. Мин Илшат Фәрдиевнең олуг ярдәме белән «Нур Баян» фондын оештырдым. Бу көн минем узган елгы кайгы-хәсрәт юшкыннарын юып ташлап, яңа иҗади биеклекләргә күтәрде!

Нур Баянның һәлак булган көнендә нидер бардыр, ахры, нидер бардыр...

* * *

Ләкин соңгы сүзне язганда күңелемне әйтеп бетергесез әллә нинди моң-сагыш биләп алды. Ничек була инде бу? Шулай итеп аерылышабыз да мыни инде, укучым? Миңа Казан-Чаллы юлында иңгән ярым хыял төшем белән аерылуы да бик авыр лабаса.

Ни булса шул, солдат Нур Баян язмышы—изге кеше язмышыдыр ул, васыятьләрен дә әйтеп китә алмаган безнең әтиләр, бабайлар һәм меңләгән билгесезләр язмышыдыр...

*Чаллы шәһәре, 1999 ел.*

---

## Киләсе санда укыгыз:

«Гарәп телен белмәү сәбәпле, хәзерге вакытта татарлар Коръәнне рус телендә укый, ата-бабаларның иманына рус телендә төшенергә тырыша. Әмма алар бу Изге Китапның эчтәлегенә төшенәләрме соң? Балачакта әби-бабаларыннан ишетеп калган сүз-фикерләр һәм рус телендә әйтелгән мәгънәләр үзара тәңгәлме? Бу хәл кешеләрдә шик тудырмыймы? Минем фикеремчә, Коръән сүрәләренең мәгънәсен бөтен тирәнлеге белән татар үз телендә генә аңлый ала»,—дип яза академик **Мирза Мәхмүтов «Коръәннең татарчага тәрҗемәсе турында»** дигән киң колачлы һәм этрафлы мәкаләсендә. Ул журналыбызның 5 нче санында басылып чыгачак. Ә инде 6 нчы саннан башлап, журнал битләрендә Коръән Кәримнең татарчага өр-яңа тәрҗемәсен бастыра башлау күздә тотыла. Аны Коръәннең моңа кадәр татарча, башка төрки телләрдә һәм рус телендә чыккан вариантларын тирәннән өйрәнеп күренекле язучы **Рабит Батулла** башкарган.

**Исегезгә төшерәбез: журналга Татарстандагы һәм Россия Федерациясендәге элемтә бүлекләрендә теләсә кайсы айдан башлап язылырга мөмкин. Ярты елга язылу бәясе—39 сум. Журналның индексы —73210.**

# ШИГЪРИЯТ



## Шамил Маннап

### МОҢСУ ПАРЧАЛАР

⚬

Табигатьнең шау чәчәктә чагы,
Әй, син, Вакыт, узма, туктап тор!
Гомернең дә чәчәк аткан мәле—
Узмас кебек тоелса да мәңге,—
Була икән... була бер тапкыр...

⚬

Адәм баласына ни биргәнен
Ходай кире алмый калырмы?—
Яшьлегеңне ала, саулыгыңны,
Гомер җыйган байлыгың да кала,
Акылыңны ала, җаныңны...

Бер нәрсә дә бушка бирелми шул,
Туры килә икән түләргә:
Бу дөньяны күрсәткәне өчен
Күзең ябып кертә гүрләргә.

⚬

Өлкәнәйгән саен чүгә адәм,
Искергән өй кебек басыла.
Торган саен тәнне тарсына җан,
Мәңгелеккә, ахры, талпына.

Килмәс кебек ләкин Әҗәл, күрсә
Илһамланып иҗат иткәнең:
Алып китәр өчен—котәдер ул
Эшләреңнең кулдан төшкәнен.

*

Мин табындым сиңа,
Тик үзеңнән
Бик аз булды шәфкать-мәрхәмәт:
Синең белән кыен,
Синсез, бәлки,
Тагы да кыенрак, Мәхәббәт?!

*

Яши-яши искәрәсең
Каршылыклы тормышта,—
Искәрәсең, сискәнәсең:
Көн озын, гомер кыска...

*

*Әзәл абый Яһүдинның җәсәден җирләгәндә килгән уй*

... Татар зиратында урын бик тар,
Ләхет алып булмый—ишелә.
Ике аршин җирне көчкә таптык
«Дөнья киң!»—дип, өләшеп күпме шатлык,
Сәхнәләрне тоткан Кешегә...

*

Әй, сез—яшьләр, без—картларга
Хөрмәт белән дәшегез:
Бүгенгегез булса яшьлек,
Картлык—киләчәгегез...

*

Еллар уза, хис-тойгыда сүреләбез,
Дөнья мәшәкатьләренә күмеләбез,
Яхшыга да, начарга да күнегәбез,
Картайсак та матурлыкка үреләбез,—
Шулай булмый, фәрештәләр түгел лә без!

*

Корып егылганчы үсә агач,
Үсә өскә, үсә тамырга.
Әй, замандаш, тырыш гамәлеңдә
Табигатьтән үрнәк алырга.

*

Өлкәнәйгән саен ялгызлыкка
Күнегә кеше, кими дуслар да.
Әллә инде шулай әзерләнә
Мәңгелеккә—ялгыз йокларга?!.

*

Яшь вакытында җил-давылда
Бөгелә-сыгыла агач:
Бөгелә-сыгыла исән кала...
Шартлап сына карт алмагач...

*

Кәүсәләре калынайган саен
Бәгырьләре тора шыңгырап:
Бәгырьләре нечкә карт агачның,—
Яфраклары шавы моңлырак...

*

... Васыять язмасам да, сезгә калыр
Җан җырларым—күңел байлыгым.
Язылмаганнарын калдыралмам,
Үзем белән бергә алырмын.

*

Бәхетле чагым кайчанмы?—
Яратып, янган чагым,
Ул да мине ярата, дип,
Кат-кат алданган чагым.

Бәхетле чагым кайчанмы?—
Яшьлегем тойган чагым,
Хыянәт һәм үлем барын
Онытып торган чагым,—
Шулдыр бәхетле чагым...

*

Кемнәрдәндер безгә калган
Гүзәл ханым—бу Дөнья,
Бездән дә калыр бервакыт,
Соңрак килгән буынга.
Аларны да, яратам, дип,
Алдар әле бу Дөнья!

*

«Әлегәчә гафу кылдым
Сине, яраткан өчен.
Хыянәтең кичерә алмам,
Җаным канаткан өчен!»—
Дигән идем дә бит... Менә
Вәхи килде гарештән,
Назлы итеп колагыма
Пышылдады фәрештәм:

«Үзе яраткан адәмне
Кичерә ласа Ходай.
Үзебез ятраткannарны
Без дә кичерик шулай...»

Кайчак ачу кайнаса да,
Чыгармыйм, тыелып калам.
Сабырлык атлы фәрештәм
Куйнына сыенып калам.

Өйдә булсын, эштә булсын,
Тыңла—буйсын, тыңла—буйсын.
Җаныңны богауда тоткач,
Аннан коллык ничек чыксын?..

Уйлаганың юкмы: ник тезәләр
Тимер юлга агач шпаллар?—
Тимер булып хәтта тимерләр дә
Йомшаклыкка, ахры, мохтаҗлар...

Яшь вакытта гомер чиксез кебек,
Көч-дәрт ташып тора диңгез кебек.
Вакытыңны туздырасың уңга-сулга,
Кинәт искәрәсең: яшьлек узган!

Килә—вакыт кадерен белер вакыт,
Эштән соң да туры өйгә кайтып,
Төнлә кочып салкын ястыгыңны,
Син саклыйсың инде картлыгыңны...

Әни кабере өстендә дә—каен,
Әти кабере өстендә дә—каен.
Газизләрем үзләре юк... Инде хәзер
Шул каеннар белән сөйләшергә калдым.

Син әлегә мине аңламыйсың,
Гаҗәпләнмим моңа, үпкәләмим,—
Яшел яфрак аңлый аламыни
Өзелергә торган яфрак хәлен?!

●

Кемнәрнедер күмә Дөнья
Алтын-көмеш, мал-әйбергә,
Данга күмә.
Ләкин соңра
Күмә туфрак белән... кабергә.

●

Сыерчыклар куна талларга,
Яз узганчы сайрарга, сайрарга.
Син дә үз җырыңны җырлап кал,—
Җыерчыклар кунар маңгайга, маңгайга...

●

Ник бу Әҗәл шагыйрьләрнең
Сафларын сирәклидер?—
Бәлки бу дөньяга нечкә
Күңелләр кирәкмидер?..

●

Горур бул—тәкәббер булма,
Усал бул—явыз булма.
Тырыш бул, тик әрсез булма,
Бөртекчән бул—саран булма,
Гашыйк бул—сагыз булма!..

●

Матурга кызыга, табына һәр кеше,
Ә матурга табыла үз ише.
Читтән генә сөеп, сагынып яшәү—
Бик күпләрнең шулдыр язмышы...

●

Вәгъдәләргә яшьлекнең юмартлыгы!—
Вәгъдә бирми генә килә картлыгың...
Их, тагын бер кичерәсе иде, дим,
Яшьлектәге буш вәгъдәләр шатлыгын.

Шуңа аңлыйм сайлау мәрәкәсендә
Түрәләрнең вәгъдәгә юмартлыгын:
Халык белән кичерәләр ич алар
Үзләренең буш вәгъдәләр шатлыгын.

●

Балачакта, яшь вакытта
Саф алмаз кебек идек.
Алмаз кебек тутыкмас вә
Картаймас кебек идек.

Узды да китте гомерләр,
Ә Дөнья тора көлеп,
«Сине генә сөям!..»—дигән,
Аннан, башканы яраткан—
Җан өзгән кызлар кебек.

*

Нишлисең, адәм баласы
Хатадан хали булмас:
Әрвахлар догадан туймас,
Әрсезләр даннан туймас.

*

«Заман ахырында, диләр,
Теләсәң файда итәргә,
Яхшылыкны аңламаслар»,—
Белмәссең кайда итәргә!

*

Аз булмады матурларга
Сокланып караганым.
Коры куаныч булса да,
Юаныч булды гомергә—
Шулардан алданганым.

*

Әйткәннәр лә:
«Властьны алып була,
Ләкин саклап калу икеле...»
Алтын сүзләр—
Сәясәттән бигрәк,
Мәхәббәткә карый шикелле.

*

Локман Хәким әйткән сүзләр, иптәш:
«Җир кадерен белмәгәнгә—Ходай җир бирмәс,
Ил кадерен белмәгәнгә—Ил бирмәс,
Ир кадерен белмәгәнгә—ир бирмәс...»

*

*Заманыбыз Хуҗа Насретдинына*

Уйлыйсыңдыр: «Мине яраталар
Шаянлыгым, шаяртуым өчен».
Алай түгел,
Яраталар сине
Кешене ихлас яратуың өчен.

*Җиңүнең 55 еллыгына*



## Рәис Сафаров

# ӘҖӘЛ БЕЛӘН ЯНӘШӘ...

### Чирканчык алу

Сугышның дәһшәтле өермәсенә керү минем өчен трагикомик төстәрәк булды— көләргәме, еларгамы, дигәндәйрәк...

Мин Мәскәү хәрби училищесының (элек «Кремль курсантлары мәктәбе» дип йөртелде) соңгы курсында укый идем. Сугыш башланып, ул җитди төс ала башлау сәбәпле, чыгарылыш берничә ай элегрәк булды. Кичәге курсантларга «лейтенант» дәрәҗәсе биреп, өр-яңа «комсоставский» киемнәребезнең якаларына икешәр «кызыл кубик» тагып, Кызыл Армиянең фронттагы частьләренә дошманны тизрәк дөмектерүне теләп озаттылар. Ә мине һәм тагын берничәбезне училищеда калдырдылар. Нигә икән? Белмибез. «Сезгә аерым приказ булыр», диләр. Бер ун-унбиш көннән килде бу приказ: «Фәлән Фәләновларны Кызыл Армия Баш штабы каршындагы Разведка Идарәсе карамагына җибәрергә».

... Әллә ничә «пропуск бюро»ларын үтеп, Разведка идарәсенең тиешле кабинетына килеп җиттек. Берәмләп кенә чакыралар. Чыкканнарны каядыр икенче бүлмәгә озатып торалар. Башыма төрле уйлар килә: бу бит андый-мондый гына урын түгел... разведка! Бик каты, энәсеннән-җебенә хәтле тикшерәләр булса кирәк. Эчемнән генә «тәрҗемәи хәлем»не кабатлыйм: алай бәйләнерлек «кара таплар» юк шикелле, шулай да кем белә?! Әнкәемнең сеңлесе Гөлчирәттәйнең ире Салих җизнине «нэпман» дип биш елга сөргенгә җибәргәннәр иде, ә мин бу фактны яшереп килдем, бәлкем шуның эзенә төшкәннәрдер, дип уйлап, ана да үземчә җавап әзерләп торам.

Кабинетта ике майор утыра. Мин керү белән берсе немецчалап: Erlaube stehen bleiben! (Басып торсагыз да була!)—диде.

Мин шундук аңлап алдым: бирегә азмы-күпме немецча белгән хәрбиләрне чакыртканнар икән, югыйсә бу майор минем немецча сукалаганны каян белер иде?! Икенче майор да немецча сорау бирә башлады;

—Was fur eine zivilbildung haben Sie? (Гомуми белемегез нинди?)

Димәк, болар мине немец теленнән сынамакчы. Белмәмешкә салынып булмый, дөресен әйтергә кирәк!

—Jch habe eine landliche mittelschule absolviert! (Авыл урта мәктәбен тәмамладым!)

—Wie sohon wissen yie deutsch? (Немецчаны ничегрәк, яхшы беләсезме?)

—Nicht besondeps, aber doch, umgansprache. (Бик үк түгел, шулай да сөйләшү телендә ярыйсы...)

Тагын берничә сорау бирделәр дә, икенче бер бүлмәгә озаттылар. Анда мине көтеп торалар икән инде. Бер полковник кулыма кәгазь тоттырды.

—Сез Беренче хәрби һава десанты корпусына җибәреләсез. Адресы кәгазьдә язылмаган, хәтерегездә тотыгыз: корпус—Люберцы шәһәрендә! Хәерле юл, уңышлар телим!

Корпус штабында мине 214 нче десант бригадасына разведка начальнигының ярдәмчесе итеп билгеләделәр. Бу бригада шәһәр читендәге йортларда урнашкан, ә штабы һәм бер ротасы урта мәктәп бинасында икән... Разведка начальнигы майор Стерховка аның карамагына хезмәткә килүем турында рапорт бирдем.

—Ярый, яхшы, күптән кирәк иде миңа ярдәмче,—диде майор.—Беләсең, бездә светомаскировка, кич булганчы урнашып ал, ә эш, вазифаларың турында иртәгә иртән сөйләшербез. Кирәк-яракларны склад ябылганчы бүген үк алып кал! —Майор ординарецын чакыртты:

—Лейтенантны урнаштыр!

Ординарец миңа бер буш класс бүлмәсеннән урын күрсәтте. Анда коры тимер караваттан башка бер нәрсә дә юк иде. Ординарец белән бергә складка барып десантчыга тиешле әйберләрне алып килдек.

—Туклануыгыз беренче каттагы 7нче «Г» классында булыр, комсостав ашханәсендә!.. —Ординарец киткәч, бирелгән кирәк-яракларымны бер почмакка өеп куйдым: парашют капчыгы, нәрсәләрдер тутырылган вещмешок, ППШ автоматы. Чишенмичә-нитмичә генә как караватка яттым.

Күпме вакыт үткәндер, сиренаның ачы тавышы колакны ярды:

—БОЕВАЯ ТРЕВОГА!!!

Нишләргә? Кая барырга! Мин сикереп торып коридорга атылдым. Күрәм, десантчылар парашютларын кочаклап коридордан тышка йөгерәләр. Тиз генә бүлмәмә кереп вещевой мешокны аркага, автоматны иңгә асып, парашютлы чехолны кочаклап алар артыннан иярдем. Тышта йөк машиналары безне көтә иде инде.

Хәрби аэродром караңгылыкка чумган, озын рәт булып тезелгән самолетларның шәүләләре генә күренә. Машинадагы десантчылардан калышмый мин дә бер самолет янына килеп бастым. Бер кече лейтенант команда бирде: парашютларны кияргә! Ничек кияргә, ничек асарга? Мин моны белми идем, чөнки парашют дигәннәрен гомеремдә беренче мәртәбә кулымда тотуым. Аны күкрәгемә кыскан килеш самолетка мендем. Самолетка утыруым да гомеремдә беренче мәртәбә! Тиздән самолет дерелдәп, чайкалып алды, күккә күтәреләбез шикелле. Нишләргә, кая җайлашырга белми торганда яныма әлеге кече лейтенант килде:

—Сез нигә парашютыгызны кими торасыз, иптәш лейтенант? Ярты сәгатьтән сикерәбез бит. Сез кайсы подразделениедән, күргәнем юк шикелле сезне. —Мин аңа бу частька моннан берничә сәгать кенә элек килгәнемне, кем икәнлегемне, парашют белән эш итә белмәвемне әйттем. Кече лейтенант миңа гаҗәпләнебрәк карады да, озын итеп сызгырып куйды.

—Сезгә бу десантта катнашырга кирәк булмаган. Пожалуй, Сезгә шушы самолетта базага кире кайтырга туры килер!—диде. Ләкин бераз уйлаганнан соң:

—Юк, болай да ярамас, чөнки бригаданың бөтен командованиесе бүгенге десантта оча, ә Люберцыда калган особистлар Сезгә дезертирлык чәпәүләре мөмкин. Сикерергә туры килер!—диде.

Кече лейтенант шунда миңа ничек сикерү турында кыскача «инструктаж» бирмәкче булып, парашютны тышлыгыннан чыгарган иде, тагын серле генә итеп башын чайкый-чайкый сызгырып куйды.

—Ну, бәхет килеп кенә тора икән үзегезгә, иптәш лейтенант! Сезгә үзе ачыла торган ПАР (парашют автоматического раскрытия) урынына үзегез ача торган ППР (парашют принудительного раскрытия) биргәннәр! Д-а-а! Эш катлаулана бара... Башка чара юк, шуның белән сикерергә туры килер. Дикъкать белән тыңла...

Кече лейтенант башта миңа бу ППРны асты, төрле урыннан каешларын тартып бәйләп беркетте, шуннан соң сикерү тәртибенә күчте:

—Значит, менә болай. Менә күкрәгеңнең сул ягында боҗра, мин «пошел» дигән команданы биргәч тә, бер мизгел дә уйланып тормастан, тышка, һавага ыргылаасың! Шундук, очып төшеп барганда, эчеңнән генә «бер, ике» дип, бишкә кадәр санайсың, «алты» дигәндә менә шушы боҗраны нык итеп үзеңә тартасың... Тагын санай башлыйсың. «Биш» дигәнеңдә бот төбеңә каты суккандай булыр, бер мизгелгә очудан шып туктап калырсың, димәк, парашютың ачылды, салмак кына аска төшә башларсың...

—Әгәр ачылмаса?

—Шундук, югалып калмастан, запас парашют божрасын тартасың, анысы менә монда, астарак, кендек турысында, тагын бишкә кадәр сана...

—Ә «биш»тән соң да ачылмаса?

—Димәк, капут, бәхетең шул, син гаепле түгел, парашютың бозык булган! Андый очраклар да булгалый! Шулай да, өметсезләнмәгез, җирдә кар ярыйсы гына тирән, бәлкем йомшак кына барып төшәрсез дә... Андый хәлләр дә була, әнә 217 нче бригададан бер десантчы 800 метрдан ачылмаган парашют белән төшеп исән калган, кабыргалары гына сынган... Хәер, ул текә яр читенә туры килеп, кар астыннан берничә метр шуып барган... Ә без түбәнрәктән, алты йөз метрдан гына...

Шулай тынычландырды мине әлеге кече лейтенант.

Штурман «хәзерләнергә» дигән команда бирде. Десантчылар дәррәү урыннарыннан сикереп торып, электән өйрәтелгән тәртип буенча ян-яктагы ишекләр һәм идәндәге люк алдына килеп бастылар. Алар ачылу белән җил бәреп керде. Мин, дөресен әйтим, каушап калдым, үземне кая куярга белмичә бөтергеләнә идем, моны күреп кече лейтенант терсәгемнән тотты да, люк алдындагы чиратның артына куйды, үзе салонның уртасына басты. Штурман ана ниндидер ым бирде шикелле, ул барыбызга да ишетерлек итеп аваз салды: «ВНИМАНИЕ!» Шундук ун кулын күтәреп «ПОШЕЛ!» дип команда бирү белән ишектән дә, люктан да ике десанчы һавага ыргылды. Бу «пошел!» берничә секунд саен кабатлана торгач, чират мина да килеп житте. Чират дип, салонда әлеге кече лейтенант белән икәү генә калган идек (мин аны десант ташлауга житәкче икәнен аңлаган идем инде). Мин люк читенә килеп, аякларымны тышка салындырып сикерергәме юкмы дигәндәй, әкренләп арт ягым белән шуыша башлаган идем, белмим, самолет кире борыла башлагангамы, әллә минем шүрләгәнемне сизеп-күрепме, бу кече лейтенант арттан килеп, «пошел...» дип кычкырып, итеге белән аркамнан көчле генә итеп тибеп тә жибәрде... Мин караңгы бушлыкка очтым. Куркуым-каушавымнан, кече лейтенантның мондый тупаслыгына ачуланудан да (жилкәмә типмәсә дә үзем сикерер идем ич) ул өйрәткән «инструкция» хәтердән чыккан, ә исемә төшү белән, бишкә кадәр санап-нитеп тормыйча, дәррәү түштәге божраны тартып жибәрдем, шул арада бот төпләренә, култык асларына нидер каты итеп суккандай булды. Нәкъ «инструкция»дәгедәй, очу кинәт бер мизгелгә туктап калды, шул ук мизгелдә парашютым әкрен генә кузгалып, жиргә таба юл алды...

Жирне күрмәсән дә, аңа якынлашу сизелә икән (парашютның төшү тизлеге арта бара), кулларым белән парашютның бауларына ныграк ябыштым, тезләремне бөктем, күзләремне йомдым, «ни булса да булыр!»

Берни дә булмады, дия алмыйм—кар өстенә килеп кунсам да кабыргаларым шактый сыдырылды. Әжәлем житмәгән, күрәсен!

Парашютымның каешларын, тасмаларын чишеп, аны астыма салып утырдым. Таң сызылып килә, тирә-як тып-тын, һичкем күренми. Биштәремне чиштем: нәрсәләр бар икән анда? ППШга бер запас магазин, ике граната (РГД), бер банка коры спирт, ике кисәк шоколад, сухари, тоз, шырпы. Яктырып килә. Киң басу, аның читендә авыл, кайбер өйләрнең моржаларыннан төтен күтәрелә, ерак түгел, урман. Ялгызым. Кая барырга? Юк, ялгыз түгелмен икән! Миннән ике йөз метрлар чамасы, кар өстендә кинәт берничә кеше пәйда булды. Алар урманга карап баралар. Мин дә шуларга таба кузгалдым, бераздан урман ягына баручылар күбәя башлады... Безнең десантчылар! Урман авызында очраштык. Бу урман безнең бригаданың базасы икән. Ни өчен, нинди бурыч белән ташлаганнар икән безне немецлар тылына?

1941 елның ахырында, безнең гаскәрләр фашистларны Мәскәү бусагасында туктатып, үзләре каршы һөҗүмгә күчәләр, һәм 200-300 чакрым куып китәләр... Әмма артык мавыгып, кайбер частьләр, шулар җөмләсеннән генерал Беловның атлы корпусы, чолганышта кала. Безнең бригада немецларның тылына төшеп һөҗүм итәргә, фронтны ерып коридор ясарга һәм атлы корпусны чолганыштан алып чыгарга тиеш булган. Без бу бурычны үтәдек, 300 чана олауга төялгән яралыларны да алып чыктык. Бу операциядә катнашуым сугышның ачы хакыйкатен беренче мәртәбә татуым иде.

Алда тагын ниләр көтәдер?..

## Партизаннарда

Бу заданиене уңышлы үтәүдә безгә Смоленск өлкәсенең Семлев, Знаменка районнарында хәрәкәт итүче партизаннар зур булышлык күрсәтте. Безнең бригада үз бурычын үтәгәч, базага, Люберцыга кайтып китте, ә десантчыларның кайберләрен—шартлатучыларны, диверсантларны, хәрби техникларны , шулар җөмләсеннән мине дә тәрҗемәче итеп партизаннарга ярдәмгә дип калдырдылар.

Смоленщинаның партизаннар төбәгенә әверелгән, җирле халыклардан, чолганышта калган һәм әсирлектән качкан хәрбиләрдән оешкан күп санлы һәм зур булмаган партизан отрядлары хәрәкәт итә башлаган ел иде бу: «Чайка», «Ураган», «Щорс», «Лазо» һ. б. Мине «ФД» исемле отрядта калдырдылар. Тегеләренең исемнәре ачык, таныш, ә менә «ФД» нәрсәне белдерә икән? Мин бу исемне башта ул елларда тимер юлларда йөри башлаган иң көчле паровозлардан берсе («ИС»—Иосиф Сталиннан кала) «ФД»—Феликс Дзержинский—дип уйлаган идем, юк, алай түгел икән! Үзе шикелле чолганыштан чыккан хәрбиләрне җыеп, партизан отряды оештырган майор Федор Данилович Гнездиловның инициаллары булып чыкты бу «ФД». Ә отрядның комиссары «товарищ Гена» иде. Чын исеме Геннадий Семенович Шевцов икән диеп йөресәм, бераздан, танышып киткәч, шунысын да үзеннән белеп алдым: бу «урыс»—Башкортстанның Мишкә районыннан алынган чеп-чи татар, өлкән политрук Гаян Суфьянович Әмиров булыр чыкты. Егерме елдан соң без тагын очраштык, бу юлы инде Казанда. Ул чак, 1962 елда, Гаян филология фәннәре кандидаты, Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге, Тел, әдәбият һәм тарих институтының лексикография секторы мөдире иде.

«ФД» отрядында мин өч ай чамасы булдым. Бу арада ул зурайды, кечкенә отрядтан «РККАның 24 еллыгы» исемендәге аерым партизаннар полкы булды, партизаннар хәрәкәтендә үзенең сугышчанлыгы, батырлыгы белән дан тотып, Бөек Ватан сугышы тарихында мактаулы урын алды.

Полк милли яктан бик чуар иде. Миңа анда үзебезнең якташлар белән дә еш очрашырга туры килде. Алар күп иде, ләкин полкта дан тоткан кайберләре хәтеремнән әле дә чыкмый, шуларның берничәсен телгә алмый кала алмыйм.

**Әхмәт Хәсәнов.** Отрядның кыю разведчигы һәм подпольщикларның элемтәчесе иде. Аны «Ахметка отчаянный» дип йөрттеләр. Аларның часте сугыш башында ук Минск янындагы бәрелешләрдә чолганышта кала, группалап түгел, һәркем үзе фронт сызыгын үтәргә булалар. Бер авылда Әхмәт немецлар кулына эләгә, төнлә кача, артыннан аталар, яралана, таң алдыннан Михалевка дигән авылга килеп керә, аны Николай Иванович дигән колхозчы үз мунчасына яшерә, дәвалый. Бераздан Панков дигән кешене староста итеп билгеләп бу авылдан немецлар китеп баралар. Берничә көннән соң өй хуҗасы Әхмәткә:

—Панков күрше авыллардан безнекеләр чигенгәндә ташлап калдырылган коралларны җыеп, үз өенә алып кайткан, иртәгә Ельняга, немецларга илтеп тапшырмакчы икән,—ди. «Моңа юл куймаска кирәк», ди Хәсәнов. План коралар. Николай үзенең атын киң үрәчәле йөк чанасына җигә, Әхмәт җиңенә полицайлар бәйли торган чүпрәкне урый да, староста өенә киләләр. Николай:

—Менә, берәү Ельнядан, комендатурадан килгән, сине эзли,—ди Панковка. Ишек ачылгач, Әхмәт старостага ташлана:

—Син, твою мать, нигә җыелган коралларны яшереп ятасың! Партизаннар килеп алганын көтәсеңме! Әллә аларга илтеп үк тапшырмакчысыңмы! Комендантның приказын белмисеңме әллә! Давай, төя коралларны чанага, безнең белән үзең дә барырсың комендант янына!

Чанага пулеметлар, мылтыклар, автоматлар, гранаталар төялә.

—Давай, утыр үзең дә!—ди Әхмәт. Панков шүрли:

—Баруымның ни хаҗәте бар, миңа, коралларны тапшырды, дип расписка бирсәгез, шул җитә.

Старостаның хатыны да җиңенә ябышкан, җибәрми. Ну, ладно,—ди Әхмәт, старостаның өенә кереп «расписка» язып калдыра. Анда латинча (яңалифчә) хәрефләр белән татарча «Тот фәлән җиремне, предатель» дип язылган була. Әхмәт олауы белән олы юлга чыга һәм партизаннар ягына юл тота, аларны табып үзенең «күчтәнәчен» тапшыра.

Ә менә **Фоат Кәлимуллинның** батырлыгын Михаил Девятаевныкына тиңләштерергә була. Ул да чолганышта калып, әсирлеккә төшә (аның танкысының ягулыгы бетә һәм туктап кала, немецлар чолгап алалар). Аннары концлагерьга эләгә, анда аны, танк механигы буларак, немецларның танк полигонына җибәрәләр һәм ремонт эшенә куялар. Ул берничә танкны яхшы гына ремонтлап бирә. Ә чираттагысын ремонтлагач, «сынап карау» өчен аны Фоатның үзенә тапшыралар һәм ул полигонны ике мәртәбә әйләнгәч, өченчесендә полный газ биреп, полигон диварын бәреп үтә һәм фронт ягына ычкына. Артыннан снарядлар ява, әмма ул исән-сау гына партизаннар краена килеп житә, биредә дә фашист тәресе ясалган танкны гранаталар белән каршы алалар, туктаталар, ә танкистны кулга алалар. Соңыннан ул «үзенең» партизаннар сафтан чыгарган танкын да, безнекеләр ташлап калдырган ике «Т-34» танкын да ремонтлап, отрядны «механизацияләгән батальон»га әйләндерүдә зур өлеш кертә. Ул Башкортстаннан, Дүртөйле районыннан иде шикелле. Мин полктан киткәндә ул исән иде әле, соңыннан язмышы ничек булгандыр—белмим.

**Нәфыйк Ибраһимов**—Урал бөркете (ул үзен шулай атый иде), Пермь өлкәсеннән. Ул да концлагерьдан кача, ике мәртәбә тотыла, өченчесе уңышлы була, күпме юллар, газаплар кичеп, бәлаләргә тарып, ниһаять, бер авылда чегәннәр өерен очрата, чегәннәр аны кабул итәләр һәм ул алар белән фронт сызыгына таба байтак юл үтә (ул чыннан да чегәннәргә тартым, кара кашлы, кара кучкыл битле, зур гәүдәле иде). Фронт сызыгына якынлашкач немецлар чегәннәрне кире боралар, ә Нәфыйк яшеренеп, Ярцево авылында кала, ул ничек тә партизаннарны табарга уйлый. Бераздан аларның Замощьеда булганнарын белеп ала. Әмма, үзеннең кем икәнлегенне ничек расларга? Партизаннар тикшерәчәкләр, ә кулда бернинди документ юк! Ул кичкырын, хәер сорашучы чегән булып, староста өенең бәләкәй капкасын шакый, ул ачылу белән ишегалдына үтә һәм хуҗаны егып сала да, авызын томалый, кулларын бәйли һәм безнең отрядка алып килә. Тирә як халкына, үз авылына күп яманлыклар китергән бу сатлык җан, элекке авыл советы секретаре Колесниковны безнең партизаннар һич кулга төшерә алмаган булалар.

Безнең якташлар турында күп сөйләргә була, алар байтак иде. Мәсәлән, Велик шәһәрен азат иткәндә үтә зур кыюлык, батырлык күрсәткәннәре өчен Кашаф Төхфәтуллин, Әхәт Саматов, Гани Бариев шәһәрнең мактаулы гражданы исемен алдылар.

## Әҗәл белән очрашулар

ӘҖӘЛ нәрсә ул? Үлем килгән, җан биргән вакыт. Дин әйтүенә караганда, бу фани дөньяда яшәү өчен Ходай Тәгалә сина дип биргән мөддәтең тулу белән ук, ягъни әҗәлең җиткәч, синең яныңа Ходай үзенең фәрештәсе Газраилне җибәрә дә, ул килеп җаныңны теге дөньяга алып китә икән. Ул төрлечә килә—берәүләргә әкренләп, бик көттереп, хаста түшәгендә газапланып ятканда, ә икенчеләргә һич уйламаганда, көтмәгәндә килеп җитә дә, бер мизгел эчендә җаныңны алып китә! Шуңа күрә, әҗәлгә дару да юк, аннан котылып та булмый, диләр. Юк, котылып була икән аннан, әгәр коткаручылар янында булса! Газраил кайчакта үзе дә ялгышып-алашып килә икән дә, җаныңны алмый кача икән!

Без, фронтовикларга, аның белән ничә мәртәбәләр очрашырга, җаныңны менә алам дигәндә генә, качып киткәнен күрергә туры килгәләде. Минем үземә дә. Ничәмә еллар үтте, инде картайдык та, ә сугышның әнә шундый, әҗәл белән очрашу мизгелләре һич тә истән чыкмый, алар әле дә төшләргә кереп, саташтырып уята, уйлата, яшьлектәге дәһшәтле көннәргә кайтара...

* * *

СТАЛИНГРАДТА туктаусыз сугышлар бара. Мина безнең бер рота биләгән бинадан батальонның командалык пунктына кайтырга кирәк иде. Янымда Сейдәли (безнең телдә Сәеттали) исемле үтә дә сизгер, җитез, минннән бер адым да калмый торган посыльныем—кырым татары егете бара. Ачык урынны—трактор заводының стадион кырын—атлый-йөгерә үтеп барганда, кинәт һавада өч «Юнкерс» пәйда булып, бомба яудыра башладылар. Без шундук якындагы тирән генә бер бомба

чокырына сикердек. Фронтовиклар арасында: «Бер үк ноктага, бер үк чокырга икенче кат бомба да, снаряд та, мина да төшми, бомбежка вакытында шул иске чокырга посып ятсаң, исән каласың», дигән ырым таралган. Мин моңа үзем дә ышана идем, чөнки сынап караганым бар иде. Әлеге чокырга сикереп төшеп тыныбызны алганда, якында гына зур бомба төшеп гөрселдәде, һавага фонтан булып атылган таш-туфрак жиргә кире кайтып төшеп тә өлгермәгәндер, Сейдәли жиңемнән тарткалый:

—Иптәш командир, әйдә тизрәк әнә ул яна воронкага!

—Без болай да воронкада ятабыз ич!

—Карышмагыз, әйдә минем арттан!

Яңа воронкага сикереп төшүебез булды, шул мизгелдә, әле генә без яткан элекке чокырга бомба төшеп шартлады. Өстебезгә коелып төшкән балчыкны каккалый-каккалый Сейдәлигә текәлдем:

—Ничек сиздең моны?—дим аптырап.

—Мин әжәлнең килгәнен күреп калдым, Алла саклады безне,—дип елмайды. Бер мизгел...

* * *

МИНЕ АШЫГЫЧ рәвештә үзебезнең 109 полк штабына чакыралар. Ул безнең КП дан ерак түгел, бер квартал түбән, Дзержинский урамындагы жимерек йортның подвалында урнашкан иде. Ара ерак булмагач Сейдәлине ияртмәдем, ППШ ымны муеныма астым да, аны күкрәгемә кысып, штабка карап йөгердем. Урам чатына житеп сулга борылуым булды, нәкъ аның почмагында минем шикелле, йөгереп барган кемдер берәү белән маңгайга-маңгай бәрелештек. Карасам... немец! Аның да күкрәгендә тимер автомат! Икебез дә бер-ике адым чигендек, икебез дә бу көтмәгән очрашудан каушап калдык. Немецның күзләре шардай, йөзе көлдәй булды. Хәер, минеке дә шулай булгандыр. Нишләргә белмичә икебез дә катып калдык. Дөресен әйтим, башта немец аңына килде: калтыраган куллары белән автоматына тотынды, аның түтәсен эзли, капшана башлады. Шунда инде мин дә «уянып» киттем, ярый әле, миңа автомат түтәсен эзләргә туры килмәде, йөгергәндә селкенеп, күкрәккә суккаламасын дип, мин аны тотып бара идем. Шуңа күрә мин немецтан житезрәк булып чыктым: һушыма килү белән ППШ ның чакмасына бастым, автоматым ук сиптерде. Немец автоматын ычкындырып, куллары белән чебен кугандай селтәнә-селтәнә ава башлады, мин аның жиргә егылганын көтмәстән, алга йөгердем. Бу очрашу шул хәтле көтмәгәндә булды һәм каушатты ки, мин штабка килеп кергәч тә калтырануымнан рәтләп рапорт та бирә алмадым. Әжәлем, миңа килеп житим дигәндә бер метр калгач, туктап калды, чигенде бит...

* * *

ПОЛКНЫҢ подразделение командирларын, политрукларын Фронт Хәрби советының приказы белән таныштыру өчен бер урынга кыска гына вакытка чакырганнар иде. Өске катлары жимерелгән, үткән төндә генә фашистлардан бушатылган шәһәр поликлиникасының ярымподвалында полк штабыннан киләсе кешене көтеп утырабыз. Күптән болай бергә жыелганыбыз юк иде. Немецлар ягыннан сирәк-мирәк минометлардан аткалап торалар, ләкин мондый «пүчтәк»кә берәү дә игътибар итми, подвалның стеналары калын, тәрәзәләре яртылаш кына урам якка карый, ә ишегалды ягында алар бөтенләй юк. Кайберәүләр тартмаларга, кирпеч өемнәренә, ватык караватларга утырган, кайсылары как идәнгә сузылып, кырын яткан. Кызыклы эпизодлар сәер хәлләр, анекдотлар сөйлиләр, шаркылдап көлешәләр. Махра төтененнән балта асарлык. Мин үзем тартмагач, бераз һава суларга кирәк дип, тышка чыкмакчы булдым. Урынымнан торып, баскычтан күтәрелеп, ишек уемының бусагасындагы соңгы тактасыннан ишегалдына атлавым булды, артымда, ярымподвалда, каты гөрселдәү ишетелде. Кире йөгереп төшсәм, берни күренми, тоташ тузан, ыңгырашу тавышлары ишетелә. Бераз тузан басылгач, күрәм: әле генә, берничә секунд элек кенә, шаярып, көлешеп утырган кешеләр идәндә ята, бер-икесенең авызында тәмәке төпчеге әле дә төти, кайберәүләре үрмәләп баскычка таба шуыша... Санап карасам, алты үлек, бик күп яралылар...

Аңладым: бер «адашкан» мина тәрәзә уемына туры килеп, подвал эченә төшеп шартлаган. Ә берничә секунд кына элек мин торып китмәсәм, яисә бер генә баскычны сонлабрак атласам... Бер адым гына... Бер адым гына куып җитә алмаган явыз әҗәл!

* * *

ИДЕЛНЕҢ сул ягындагы Ленинск шәһәрчегендә өч атна чамасы кыр госпиталендә ятканнан соң, безне—Сталинградта авыр яраланганнарны—тишелеп беткән, ишексез товар вагоннарына төяп, каядыр алып киттеләр. Вагонның бернәрсә дә түшәлмәгән как идәнендә утыздан артык ялары ята. Поезд бераз гына бара да, тәгәрмәчләрен шыгырдатып, тагын туктый, Сталинградка баручы хәрби эшелоннарга юл биреп, сәгатьләр буенча пошкырып тора да, тагын шалтыр-шолтыр кузгалып китә. Әнә шулай этләнеп баруыбызга инде менә ике тәүлек була.

Ә бу юлы эшелонбыз озакка туктады, менә ул икенче тәүлек инде, ап-ак кар баскан дала уртасында тып-тын тора, алда, кайдадыр тимер юлны бомбага тотканнар булса кирәк. Озатып баручылар, медперсонал күренми, менә өченче тәүлек инде, хәлебезне белүче, ашарга түгел, су бирүче дә, яраларны караучы да юк. Вагоныбызда өч авыр ялы җан бирде, башкалары сыкрана, өзгәләнә, ярдәм сорап кычкыра, сүгенә. Нервлану ахыр чиккә җитеп бара, кайберәүләр яраларын бәйләгән, бозлана барган юеш марляларын сүтеп ташлый башладылар, ишек уемына якынрак ятканнарның өстенә кар сибәли, ыңгырашу тавышлары алдагы һәм артыбыздагы вагоннардан да ишетелә—кыскасы, эшелон ду килә.

Кинәт эшелон тынып калды: өстебезгә «Хейнкель» килә! Без, фронтовиклар, аны ерактан ук, тавышыннан таныйбыз. Аның гүелдәве тигез, бер ритмда булмый, ә дулкынлы-дулкынлы булып, бер көчәеп, бер әкренәеп ишетелә. Күренгәч тә белеп була—аның канат очлары түгәрәкләнгән формада... Тиздән якында гына бомба гөрселдәде, вагоныбыз әз генә чайкалып куйды. Йөри алганнар вагоннан сикереп төшеп тирә-якка сибелделәр. Ә без, аяксызлар? Менә шулчак инде мин белдем: сугышта иң ачы, иң аяныч өметсезлек, гаҗизлек—штыкка-штык атакага бару да, йөзгә-йөз, якага-яка килеп дошман белән алышу да түгел икән! Чөнки андый очракларда өмет сине ташламый, йөздән бер кәррә булса да шанс бар! Ә кыймылдый алмый чалкан яткан ялыга күзен йомып, менә бу бомба «минеке» дип, берни эшли алмый көтүдән дә газаплы кичереш бармы икән!

«Хейнкель»нең икенче борылып килүендә ташлаган бер бомбасы безнен артта гына шартлады, бу юлы вагоныбыз чайкалды гына түгел, бераз алга шуышкандай да булды. Бераздан «Хейнкель» бөтен йөген (аның гадәти нормасы 11-16 авыр бомба) бушатып китеп барды. Соңыннан белдек: безнең арттагы икенче вагоннан соңгы, койрык яктагы ялылар белән тулы алты вагон тәкмәрләгән икән, ә алдагы вагоннар һәм паровоз исән калган. Әҗәл ике вагон калгач кына... Җитә алмады.

* * *

ЭШЕЛОНЫБЫЗ тормозларын шыгырдатып бер станциягә килеп туктады. Безнең вагон нәкъ вокзал турысында. «Ст. Энгельс» дип язылган. Йә Хода! Сталинградтан 200 чакрым араны дүрт тәүлек үткәнбез! Әллә инде килеп тә җиттекме икән тиешле урынга? Алай дисән, менә инде өч-дүрт сәгать торабыз, ә вагоннарны бушатучылар күренми. Караңгы да төште... Соңыннан белдек: бу станциягә бер-бер артлы әллә ничә ялылар эшелоны килеп туктаган да, аларны бушатырга шәһәр халкын мобилизацияләү бара икән. Төн узды, безгә чират әле дә килеп җитми, ялылар тагын дау күтәрә башладылар. Ниһаять, ишек уемы алдына носилка тоткан ике хатын килеп басты. Сорыйлар:

—Поносники есть? (ягъни—эче китүчеләр). Юк. Тагын киләләр:

—Башы яраланганнар бармы?

—Эче яраланганнар?

—Аңладык, димәк, яраларга карап аералар да, тиешле госпитальләргә алып китәләр икән. Түземе ахырына җиткән кайберәүләр үзләрен «мин поносник» дип әйтергә мәҗбүр булдылар.

Икенче көн иртән (юлга чыкканның бишенче көнендә) чират, ниһаять,

безнен вагонга да житте. Минем хәлем дә авырайганнан-авырая бара. Тышта—кыш, салкын үзәккә үтә, калтырата, биш тәүлек инде бер тәгам ризык капмагач, эчтә җылы юк, хәл бетүдән күзләр йомыла.

Теге ике хатын, тирән кар ярып, ял итә-итә күтәреп баргач, бер зур гына, дүрт катлы кирпеч йортның капкасы алдына мине носилкада яткан килеш калдырып киттеләр. Димәк, безнең вагоннан мин иң соңгысы булганмын.

Күрәм, башка яралылар карда аунап ята, алар бик күп—ишегалды, капка алды тулган, кайберләре урам уртасында ук ята. Яшәү, тере калу өчен көрәш бара, берәүнен дә шундый газаплардан соң, инде котылдым дигәндә генә, үләсе килми. Хәлсезләре ярдәм сорап кычкыра, бераз хәллерәкләре йөзтүбән, яисә чалкан, яки кырын яткан килеш, кулларына, терсәкләренә таянып алга үрмәли, шуыша, этәренә—ишеккә якынаерга маташа. Чөнки ишек төбенә килеп житкәннәрне санитарлар эчкәрегә алып кереп китәләр... Бөтен өмет, үлемнән котылу—әнә шул ишек бусагасына килеп житү!

Юк, мин бу араны үтә алмаячакмын... миндә урынымнан кузгалырлык та көч-хәл калмаган... Туңа башладым, тәнемне ниндидер авырлык баса, гажизлектән, ачы үкенечтән күземнән яшьләр ага: инде котылдым, әҗәлдән качтым дигәндә генә шулай мәгънәсез үләрмен микәнни?! Бәләкәй чакта олылардан, «кеше юлда, чатнама суыкта катып үләр алдыннан тәнендә ниндидер рәхәт җылылык сизә, утырып, бияләйләрен салып, учак алдында кызынгандай кулларын сузып, рәхәтләнеп җылына-җылына үлеп китә, имеш» дигәннәрен ишеткәнем бар иде. Бу, чыннан да, шулай икән. Менә мин дә тәнемдә—ниндидер оета торган талгын, рәхәт җылы сизәм, ул аяктан күкрәккә таба җәелеп бара, күз кабакларым йомылалар. Янымда әнием басып тора кебек. Көч-хәл белән күзләремне ачам. Тагын, нәкъ Идел яры буенда ятканымдагы картина: әнкәем түгел, бер чибәр кыз баш өстемә иелгән дә, йомшак куллары белән битемне сыйпый, колакларымны ышкый. Ул шинелемнең төймәләрен ычкындырып, изүемне ачты да, күкрәгемә массаж ясый. Янибызга тагын бер кыз килеп басты.

—Тамара, бу капитан безнеке, ул суынып бара. Йөгер операционныйга, ике йотым спирт табып алып кил. Тиз!

Ике йотым спирттан күзләрем бөтенләй ачылды, инде ачык итеп күрәм—бу кызлар икесе дә зәңгәр петлицалы шинельдән. Алар мине носилкам белән күтәреп, башка яралылар аркылы атлый-атлый, госпитальгә алып керделәр һәм югары катка ук мендереп, операция бүлегенә китереп куйдылар. Ә операциядән соң тәгәрмәчле бәләкәй тимер арбада палатага кадәр озаттылар. Әнә шулай итеп, әҗәл кочагыннан тартып алды мине бу ике кыз!

Төскә чибәр, буйга килешле бу ике кыз мина, үлеп яткан әлләни матур да булмаган егеткә нигә карадылар икән? Бу кызлар икесе дә шушы Энгельс шәһәрендәге Хәрби һава училищесенең курсантлары булып чыкты. «Бу капитан безнеке» дигәннең дә серен дә аңладым: минем өстә дә, нәкъ аларныкы шикелле зәңгәр петлицалы шинель иде. Шулай итеп, без хәрби хезмәт буенча кардәшләр булып чыктык. Ә сугышта, хәрбиләрдә, бер уставта да язылмаган какшамас закон бар иде: «Сам умри, но своего выручай!» Ягъни бер төрле хәрби хезмәттәгеләр—очучы очучыга, танкист танкистка, сапер саперга һәрвакыт ярдәмгә килергә, аны бәладән араларга тиеш! Кызлар шул традицияне намуслы үтәделәр. Алар соныннан да, палатага килеп, хәл-әхвәлемне белеп йөрделәр. Бу ике чибәр кызның берсе (мине күреп алганы) Таня—Энгельстән ерак түгел урнашкан Базарлы Караболак исемле башкорт авылыннан Тәнзилә, ә икенчесе, шул ук Энгельс шәһәреннән урыс кызы Тамара иде. Онытмыйм мин сезне, гүргә кергәнче онытачак та түгелмен, гүзәл кызлар!

* * *

**КАЙБЕР** укучылар, гажәпләнеп, бу Сафаровка гел шундый бәхетле мизгелләр генә очрап торган икән, дип уйларлар. Юк, кардәшләрем! Мондый хәлләр, үлем, әҗәл белән йөзгә-йөз очрашулар сугыш эчендә булган, аның утларын-суларын кичкән меннәрчә фронтовикларның башыннан узды. Без, утлы җәһәннәм аша үтеп исән калдык, җиңү алып килдек. Без ул көннәрне, ул сәгатьләрне, ул мизгелләрне мәңге онытачак түгелбез—шуңа күрә җиңү көне безгә кадерле!

# ШИГЪРИЯТ



## Рифә Рахман

### И Кешем!

Өметләрең сүнсә,
　　　　килер нинди көннәр?
Кайсы комлы ярга
　　　　борнын төртер көймәң?
Авыр томан басар
　　　　ишкәгеңне ишсәң.
Ашыгып йөзеп китмә,
　　　　кемдер исеңә төшсә.

Көтмә аннан ярдәм,
　　　　Кеше—ялгыз юлчы.
Дулкыннарга ятса
　　　　өметеңнең кошы,
Хәлсезләнгән кулың
　　　　үзе алсын аны!
Сулык-сулык дулкын,
　　　　ул бит—елга тәне.

Гомер елгасының
　　　　шадра—дулкыннары,
Комлы, ташлы, сазлы,
　　　　сөзгәк, текә яры.
Һәркем соңгы шул яр
　　　　өчен яши өркеп:
Булмый дөньялыктан
　　　　җиңел генә китеп.

Нинди дулкыннарда
　　　　чыгар көймә ярга(?),
Бер өметсез итеп,
　　　　бер өметсез итеп...

*

Иелсен дә этсен таллар сине миннән,
Ишелсен таш, сине ярдан тәгәрәтеп.
Карашыңнан качар өчен эзлим чара:
Карагансың күзләреңне ядрәләтеп.

Сыдырылып чыгар үлән, син тотынсаң.
Кубар тамыр, бөтен суты киткән сыман.
Карашыңнан качар өчен эзлим чара:
Карагансың күз читләрең кипкән сыман.

Ялгыш ярга сикергән бер дулкын булып,
Үрелсен дә алсын елга сине ярдан.
Карашыңнан качар чара уйлап тапкач,
Калырмын мин—инде синнән югарыда.

## Гөл һәм былбыл

Гөлдә генә торган былбыл буламыни,
Авыр түгел, сөйгән ярлар читкә китсә.
Былбыл икән, сайлый белми кунамыни?!
Авыр икән шул гөленә хыянәт итсә.

Мәңге кипми торган гөлләр буламыни,
Яшь үсенте булып шытар, дымнар типсә.
Сайлый белми кунган кош соң—былбылмыни?!
Авыр түгел андый гына хыянәт итсә.

Гөлдән башка җиргә былбыл кунадыр ла.
Ә гөлгә соң былбыл гына кунамыни?
Телидер дә, телидер дә аны гына...
Гөлдә генә торган былбыл буламыни...

*

Почтальоннар тартмаларга салган хатта
Кем хушлаша, кемгә сөю сүзе бара.
Гасабилык җанга үткән бер таңымда
Хатлар элеп чыгармын мин ботакларга.

Укыр бер кош, куеп кояш яктысына,
Укыр бер кош, томшыклары белән чукып.
Болдырымда аңа оя ясармын мин.
Ташыр сиңа, агачымнан хатлар йолкып.

Илтер сөю—минем хатның юлларында
Гасабилык җанга үткән һәр таңымда.
Ясармын мин оя—салмас хатларымнан;
Үпкә сүзе йокымсырар болдырымда.

*

Син кайда?
Мин бик гаепле:
Утырам башка белән.
Ул менә нидер сөйли дә,
Мин башны ташлап көләм.
Мин көләм.
Күңелдә яшь бит.
Ирендә тамчысы бар.
Син киттең
Сөю калдырып,—
Кулында камчысы бар.

## Үрмәкүч

Тәрәзәдән аклык өйгә кергән.
Жетеләнеп киткән һәрбер төс.
Шундый суыкмы соң?—бүлмәбезнең
Почмагында туңа үрмәкүч.

Ул да минем кебек, исе китми,
Жылы булса, башка һич нигә.
Үзәгенә салкын үткән саен,
Йорт күчереп мескен интегә.

Почмак саен пәрәвезләр үреп
Арып бетте инде бу елда...
Тәрәзәдән аклык күчкән—аңа
Суык кергән сыман тоела.

# ШИГЪРИЯТ



## Иделбикә

### ДҮРТЪЮЛЛЫКЛАР

#### Масайма

Ник масаю? Тышкы күркен Ходай биреп,
гүзәллегең булса да әгәр күз тиярлек,
Асыл җан син—җыйсаң асыл сыйфатлар тик,
булып чын яр—гомер юлыңны гизәрлек.

#### Каның бозма

Беркем белми: ни китерер иртәгә...
бүген каның бозма гаута-үпкәгә.
Икенче бер гомердә Син булмассың,
җаның—ташлап, башка сынга күчсә дә.

#### Мирас

Ни ул—мирас? Мирасның да төре—мең.
Әйтик, туган йортта алган фәһемең...
Ата малы, бала, озакка бармас,—
аң-белемгә таянып яшәр көнең!

#### Уйла

Көндәшеңне яманлаудан ни файда,
ул юлдан кем үрләгән үргә? Кайда?
Камиллегең ачыкланыр гамәлдә...
Мактанудан кем уңган—ятса сайда?

## Кайтырмы?

Ничә акыл күккә чөйгән сөюне,
Таһир-Зөһрә, яки Фәрһад-Ширинне.
«Секс-бомбалар» куркыткан Мәхәббәт,
Кайтырмы ул асылына бер көнне?!.

## Кол Галигә

Кол Гали, иҗатың үлмәс, югалмас.
Йосыфыңны бер «күргән»—күз алалмас,
рухы-изгелеге булгач—чын алмаз!
... Җәл, Зөләйхаң андый ук яшь түгел имди...

## Шопен васыяте

Читтә—Парижда сагынып туган илне,
халкы моңын—полонез иткән иде!
Васыятен әйтте: «Тәнем калса да монда...
Ватанымда күмегез йөрәгемне!»

## Марина Цветаевага

Искитмәле аң-сәләтең иҗатта,
рух дөньясын яулагансың син хәтта.
Тик, заманга ачынып, «үч алгансың»
без-татардан... Ни дияргә бу хакта!?

## Шулайдыр...

Пакъләргә дип дөньяны кулым сузам—
бар тарафка һәркөнне куна тузан...
Җир-Әнкәнең кочар вакыты, бәлки?—
Ә мин һаман яшәүгә ызан сызам!



# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## "СӘФӘРЛӘРГӘ ЧЫКСАҢ БЕЛЕРСЕҢ..."

### ШАГЫЙРЬ ЗИННУР МАНСУРОВ ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Үзенчәлекле талант иясе булган әлеге шагыйребезгә карата минем күңелемдә күптәннән саклап килгән җылы сүзем, әйбәт хисем бар. Житмешенче еллар башыннан ук килә бу хис—әле университет буенча чордашлары Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин, Марсель Галиевләр белән бергә «Беренче карлыгачлар» китабында басылган шигырьләрен укыганнан алып, төгәлрәк әйткәндә, 1970 елдан бирле... Чыннан да, «Энекәшләр үсә», дип шигырь язарга этәргән сөенечле очрашу иде ул: бер-берсенә һич тә охшамаган кызыклы дүрт каләм иясе; төрле шигъри алымнар, тел-эслүб, төрле холык-фигыль белән күренде алар. Инде һәммәсе шигърияттә үз урынын тапкан (берәүләре инде бакый дөньяга да күчте — урыннары ожмахта булсын!). Әлеге буын шагыйрьләре яшь буенча энекәшләр булса да, алар дәрт-егәр белән безгә бик тиз арада якын сердәш, дус каләмдәш—сафташлар булып әверелде. Әйе, Фәннурыбыз «ак канатлы егет» булуы белән горурланып, яшьлек романтикасында янып, «йөрәгендә музей ачкан» иде — безне дә шунда чакырды юл башында. Башкортстаннан килгән якташым Робертта да туган җир җылысын, уртак остазыбыз Атнабай шаукымын — җорлык һәм күңел хөрлеген, халыкчан фикер һәм сүзгә тартымлыкны күреп сөендем. Марсель исә яңа гына Азнакайдан килгән—ул Равил Фәйзуллин шәкерте иде — әле ирекле шигырь стихиясендә янып, әле классик үлчәмнәргә күчеп, туктаусыз эзләнүдә булды. Ә Зиннур Мансуров бөтенләй башкача, һичкемгә дә охшамаганча бер стильдә яза кебек тоелды. Мәсәлән, әлеге күмәк җыентыктагы «Казлар авазы» шигыре фольклор белән классика калыбын бик матур куша алу үрнәге иде. (Бәлки, ул чакта безнең буыннан Рәшит Әхмәтҗан гына шулай язгандыр...). Һәм без Зиннурда бик яратып укыган Лорканың татарча бер чагылышын да күргәндәй булдык.

Күктә таныш авазлар...
Таныдым:
былтыр озаткан казлар!

Һәм әлеге шигырь менә ничек тәмамлана:

Болытларга кагылыймчы,
зәңгәрлеккә манчылыймчы;
сине күрми миңа читен —
нинди микән син, күк чите?..

Күктә тавыш, авазлар...
Таныдым...
Быелгы
бала казлар...

Йә, яшь күңелнең, зур хыяллар, максатлар белән шигырьгә килгән авыл малаеның омтылышларын, очу, биеклек турында уен — димәк, Олуг Шигърияткә юл башын моннан да матуррак итеп әйтеп буламы? Бу исә шигырьдә, үз кордашымның бераз элегрәк «кош канатлары орынгач, болытларның күңеле тулды» дип язганы кебек үк, төрле фикри ассоциацияләр тудырырга, нечкә штрих-буяуларда зур тормыш

картинасын ясарга сәләт-осталыкны раслый иде. Һәм бу үзенчәлеге аны беркайчан да ташламады. Ә инде очу, канатлы булу турында шик-борчылулар һәр шагыйрьне гомер буе озата килгән кебек, Зиннурны да газаплап, азакта төшенә дә кергән икән:

Оча алмый калган канат
авырайта моң-зарны.
...Каз мамыгы көн дә иртән
тишеп чыга мендәрне...

Хәзер дә шундый хисләрне тоеп яши микән — инде киң танылган, күп китаплары дөнья күргән, милләтнең күренекле хадиме, җәмәгать эшлеклесе саналган, илле яшендә — димәк, төсе дөнья гаме, миллилек белән баглы «яшел бүрке башында» булган Зиннур дустыбыз Мансуров?!



*Зиннур Мансуров (сулда), Ислам Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Наҗар Нәҗми, Марсель Галиев. Тукай-Кырлай, апрель, 1996 ел.*

Укучыларыбыз дикъкатенә беркадәр биобиблиографик мәгълүматлар биреп китү дә зыян итмәс дип уйлыйбыз... Шагыйрь— Мамадыш районының Түбән Ушмы авылыннан. Шунда урта мәктәп тәмамлаган. 1967—1972 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган (ул чорда университетта әдәби түгәрәкләр дә гөрләп эшли, анда кырыклап яшь әдәбиятчы дәртләнеп иҗат итә иде), аннары ике ел армия хезмәтендә була.Танк частьларында офицер — рота командиры урынбасары. 1975—1986 елларда «Социалистик Татарстан» газетасында, «Казан утлары» журналында әдәби хезмәткәр (шулай: бездә эшләп, чыныгу алган егетләр ким-хур булмый; Туфаннардан, Хәкимнәрдән башланган бу традиция; журналыбыз — чын мәгънәсендә зур шагыйрьләргә үсү мәктәбе ул), 1986 елдан— Татарстан радиосының әдәбият һәм сәнгать тапшырулары буенча баш редакторы. Ә инде 1990—1995 елларда ул — Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшли. Һәм менә бишенче ел инде — абруйлы газетабыз "Мәдәни җомга"ның баш редакторы. Сүз дә юк, олпат, саллы хезмәт юлы. Ә иҗаты? Беренче шигырь китабы «Кул бирәм» 1979 елда дөнья күрә. Аннары 1983 елда «Йөз суы», 1988 елда «Ваем», 1998 елда «Яшәү үзәне» китаплары басылган. Урыс телендә дә ике китабы бар: «Тысячелистник» («Меңъяфрак», М.1983) һәм «Душицы белый запах» (1991).

Хуш, ә шагыйрь турында—китаплары хакында кемнәр язган соң? Беренче мәҗмугасенә яшь тәнкыйтьчеләр Мансур Вәли, Салих Маннаповлар газеталарда рецензия бастырып чыгарган. Талантын танып, үзенчәлеген билгеләп... Аннары үзе остаз санаган, күп иҗат серләрен, шатлык, көенечләрен бүлешкән каләмдәш дусты, шагыйрь Равил Фәйзуллин, ышанып, җитди сүзен әйткән. «Яшәү үзәне» китабында исә әдип Тәлгат Галиуллинның әтрафлы, саллы мәкаләсе бирелгән. Ниһаять, узган елда шагыйрьгә илле яшь тулу уңае белән матбугатта эреле-ваклы төрле язмалар дөнья күрде (үзем дә газеталарда кечерәк ике мәкалә чыгардым). Барсында да Зиннур Мансуровның әдәбиятыбызда үз урыны булуы әйтелә, аның яхшы мәгънәдә акыл-фикер шагыйре икәнлеге ассызыкланып, эрудит, дөнья әдәбияты, мәдәниятенә гашыйк булып яшәүче бу шагыйрьнең чын милли рухына да соклану сизелә, осталык ягы, форма-стиль, лексиконының аерымлыклары күрсәтелә. Иң мөһиме: үз мәсләге, әлеге «Карлыгачлар»дан ук килә торган поэтик дөньясы, үз юлы бар, дибез аның

турында. Ә инде күп каләмдәшләре, остазлары, чордашлары турында үзенчәлекле итеп яза белгән (С.Хәким, Н.Арслан, Р.Фәйзуллин, Рәш. Әхмәтҗановлар иҗаты хакында һәр җәһәттән ныклы уйланып эшләнгән эссе-портретларын искә төшерик), әдәбият, сәнгать мәсьәләләрендә кыю, иркен йөзгән шагыйрь, китабының исеме искәрткәнчә («Юлын белгән арымас»), сайлап алган үз юлын арымыйча дәвам итәр, сәфәрләргә дә еш чыгар.

Сәфәр, дигәннән, бу язмама «Мәгариф» атлы нәшриятыбызның яңа, затлы басмасы — Зиннур Мансуровның «Күңел сәфәре» исемле китабы — һәйбәт сайланмасы сәбәпче булды. Бу урында «Мәгариф» нәшрияты эшчәнлегенә соклану һәм рәхмәт хисләремне әйтеп китсәм, аңлашылыр, шаять. Нинди генә матур басмалар чыгармый ул! Тукайның татарча һәм урысча (тәрҗемә) шигырьләре, Пушкинның оригиналда һәм татар шагыйрьләре тәрҗемә иткән шигырьләр сайланмасы... Һәр берсе уникаль, матур китаплар. Әле өч телдә Байрон китабы да әзерләнә дип ишеттек. Бүгенге шагыйрьләрне нәшер итү матур, затлы басма — Равил Фәйзуллинның «Җил — вакыт ул» исемле кыска шигырьләре, лирик-фәлсәфи сайланмасы белән башланган иде. Әлеге китап күпләрнең кулында һәм телендә, дип беләм. Яшьрәкләрдән Җәүдәт Сөләйман, Рифә Рахманнар да бу нәшриятыбыз чыгарган китаплары өчен сөенәдер. Өлкәннәрдән Роберт Әхмәтҗан иҗаты үрнәкләре дә күптән түгел генә шундый бер шәп басмада дөнья күрде. Тәбрик һәм котлау аларның барчасына!.. Зиннур Мансуровның «Күңел сәфәре» дә матур сувенир китап булып, офсет кәгазьдә басылган. Тышлык та, китап үзе дә танылган рәссам Надир Әлмиев тарафыннан иллюстрацияләнгән. Нур өстенә нур! Безләргә дә шундый басмаларда укучылар хозурына сәфәр чыгарга язсын. Ә халык җыры ни дигән әле?

Бәхетеңнең нинди икәнлеген
Сәфәрләргә чыккач белерсең...

Ә шагыйрь, китабына ачкыч итеп, «Чистару» исемле шигырен тәкъдим итә:

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?
Терекөмеш туңар җилдә
катып-өшеп агара...
Кар эчендә, көртлек сыман,
туңа-уңа агара...
Бәләк һәм таш арасында
мең кыйналып агара...

Һәм, инде шигырь ахырында:

Бер тапланган күңел, әйтче,
кабат ничек агара? —

дип сорый шагыйрь.

Менә шулай безне китабына кертеп җибәрә шагыйрь — укучысын алдан ук күңел, җан белән агарырга, пакьләнергә чакыра, «җанга — мунча» вәгъдә иткәндәй, күңел сәфәренә юлдаш итә. Ә анда — дүрт «кәрван» белән утыз еллык сәяхәттән, халык күңеленнән, милли хәзинәләр иленнән, ерак гасырлар төпкелләреннән алып кайткан рухи байлыклар икән ләбаса! Шигъри йөкләр, асыл сүзләр... Менә беренче «кәрван»да кайткан хәзинә — яшьлекне сагыну, туган җир, нигез-зәмин белән бәйле хыял — мәңгелек Моң авазы:

...Яшьлек кайтавазы:
«Хыялларга итмә хыянәт!..»

...Хыялларын барлап,
«Кем булдың?!» — дип
әйтер күк ул бәреп маңгайга.
Ул чак кояш якынрак булган
каен башындагы малайга...

Яки менә шушы моңның, яктылык белән өртелгән хыялның яңа өзгәләнүләре:

Ничек булса да калырга
кош очар биеклектә!
...Жир белән күк арасында
илаһи бөек нокта!..

Соңгы еллар поэзия тәнкыйтендә без бер нәрсәгә еш юлыгабыз: шагыйрьләрнең төп хасиятен ачуда критерий булырлык сыйфатны — фольклор аша килгән мәңгелек сурәтләр дәвамлылыгын, яки шигъри код, мифологик символларны эзлиләр (Ф.Урманчиев, Г.Гыйльманов мәкаләләре). Бу җәһәттән Зиннур Мансуров шигырьләре бай жирлек була ала, мөгаен. Анда әлеге шартлы алымымнар, символик милли ишарәләр, сыналган сүз-сурәт тәгъбирләре, халыкчан фикерләү һәм хикәяләү (кыйсса, притча) ысуллары — үзләре үк бер системага салынган кебек. Анда Коръән мифологиясе дә, халык ырымнары-ышанулары да, риваять-легендалар да. Кыскасы, дастани һәм язма әдәбият сурәтләре белән ныгытылган үзе бер шигъри олы дөнья бу! Гүяки, борынгы Мамадыш жирләре —элекке ханнар, биләр, карачылар яшәгән олыс, бүгенге кабер ташларында гына түгел, һавасы, суы, борынгы дога сүзе белән сакланып, гомерен дәвам итәдер төсле. Югыйсә, каян ул бу төбәкнең фәрештәләргә хас күңел изгелеге — тере шигърият?

Кардәшләрем рәхмәт юлларынын
томанына кереп күмелә.
Бәхетлеме шулай фәрештәгә
әверелгән халык — кем белә?

Биредә киная дә, борчылып уйлану да бардыр. Аннары бу уй безне кардәш халык язмышына — кырым татар халкы тарихына юнәлтә: «жиде тишекле тукмак» хәлен аңлата шагыйрь, «ишетмәгән ишекләргә әйтеп кан-яшьле такмак», «кагылудан-сугылудан житмеш тишекле тукмак» булган горур кавемгә игътибарыбызны юнәлтә. Раббым, үзең көч-түзем бир!.. «Татар бугазы» турындагы фәлсәфәне дә географик атама гына тудырмаган, әлбәттә. Биредә Нажар Нәжми шигыре белән аваздашлык та сизелә. Тарихилык... Чор-вакытларны үзара бәйләү хас шагыйрьгә. Бер шигырендә «Болгар. Савыт ватыкларын төзәм чирәм өстенә», дип язса, икенчесендә, нигезне, өйне яңарту турында әйтеп, «иманымны шулай кайта-кайта кабат төзәтергә язмасын», дип нәтижә ясый. Һәм янәшәдә үк — иманнарын сатмаган бөек Сәйдәшләр, Тукайлар...

Пычранмаган соңгы пәйгамбәрдәй,
килә Сәйдәш кара еллардан...

«Күңел гамәле» шигырендә дә бөекләребезнең вакыт, дөнья, ил-халык каршында үлемсезлеккә илткән эшләре янәшәсендә хобби-шөгыльләре — аларның тарихтагы йөзен тагы да тулыландыручы чара кебек кабул ителә: К.Насыйри, әйтик, күзгә ясарга яраткан, ә Туфаныбыз буш вакытында сәгать төзәткән. Шул гади детальләрдән мәңгелек турында зур мәгънәләр чыгара шагыйрь. (Юкка гына үзе житәкләгән газетаның да шигарен, «Каләм изгегә тартыр» дип, нәкъ менә К.Насыйридан алмаган бит Зиннур!). Ә аның бик еш Тукай образына, аның шигъри дөньясына, холык-гамәленә, хәтта стиленә таянуы? Гомумән, цитаталар да, төрле чор әдәби ядкарьләре дә, исем-атамалар, сурәт-сүзләр дә шагыйрьнең бүгенге халәтендә, язу һәм фикерләү рәвешендә табигый, ятышлы урын алган, диясем килә. Шуңа да, милләттәше Фуат Мансуров турында язгач, нишләп әле Пушкинның шигырь багышлаган Мансуровы — «закадычный друг» белән дә сөйләшмәскә? «Бөек туңучы» Тукайга битараф булган мохит белән бүгенге татар дөньясы арасында охшашлык юкмыни? Яки Толстой үлеме турында уйланып:

Астапово.
Никтер искә алам
читкә китеп үлгән филләрне,—

дип язу Зиннур Мансуров каләме өчен бик табигый. Севилья матадорының дәртле, кыю рәвештә үлем белән көрәшен ул тәжрибә, зирәклек белән иң гаярь атны да егып салучы татар картында күрә һәм икенче шигырендә инде киләчәкне дә барлый: «Туп кадәрле генә малай ат тышаулый яланда»...

Дөньяны иңләгән уй сәфәре милли атрибутлардан аерылмый, алар — шигырь

«каны»нда. Мондый байлык икенче, өченче «кәрван»нарга да мул төялгән.

Буразнадан бүз тургайлар итеп
күккә күтәрәсе җырым бар...

Ягез, менә бу сурәткә игътибар итик: нинди милли, җанлы, төгәл образ:

Йөзенә салкын тир чыгарып
уянды авылның чалгысы...

«Урман булмый киексез», дип тәкърарлаучы халык бүгенге экологик катастрофалар чорынданиләр кичерә, ниләр уйлый? Күрә бит ул һәм үз-үзенә сорау бирә: «шүрәлеле урманнарда бүген киек аз нигә?»

Мәкальләрне үтерәбез –
менә нинди фаҗига, –

ди шагыйрь.

Нәни генә детальләр, күренешләрдән, хискә, күңелгә аз гына кагылып алудан зур гомумиләштерүләр, фикерләр кузгала шагыйрьдә: әйтик, мәтрүшкә исе анда балачакта күргән Коръән-кәримне искә төшерә, әхлакый һәм рухи тетрәнү китерә. Ә мәхәббәт хисе? «Әй, Мәхәббәт хиссиятем! Йөрәк тулы җәрәхәт!». Шулай яза шагыйрь сөйгән ярына:

Сине әнкәң дә белмидер,
тик мин генә беләм, –

дип, шактый кыю эндәшә – бу өлкәдә бераз «ат уйнаткан» мосафир-җайдак буларак, сөенеч һәм матур көнләшү уята әлеге юллар миндә!

Сөю сукмаклары озын –
барасы да барасы.
Ничек кулга иятәштең,
ах син, болан баласы...

Нәкъ шундый рифмалар, шул җыр үлчәвендә минем дә бер шигырем бар («Зөлфәткә»). Әмма миңа Зиннурныкы шәбрәк төсле тоела.

Шагыйрьнең үзен мин шактый аз сүзле, уйчан, сабыр, хәтта беркадәр йомыкый—«мыштым» дип беләм. Артык ачылып китми – минем кебек шаталак, «җиңел» дә түгел бугай. Акыл кешесе, уйлы зат.

...Бу күңелнең
бар яшерен төше дә;
үзе белән җиргә китәр
сер дә була кешедә...

Була шул, нигә булмасын ди ул Сер шагыйрьдә! Ул Сер әле – илһам алиһәсе, Муза, мәңгелек шигъри идеалдыр, бәлки? Шигърияттәге яшерен Ярыдыр? Ә хәләл җефете аңлармы бу Серне? Әнә бит шагыйрь ничек искәртә:

Тик, өчәүләп яши алмый торган
шагыйрь хатыннары азмы соң?

Дүртенче «кәрван»да – каршылыклы уйлар, шагыйрьне борчып, газаплап торган хисләр, тойгылар авыр йөк булып килә. «Югалмаска кирәк миңа, югалмаска ничек тә!» Чөнки ул күрә: мәкер-хөсетлек, Тукай язган «татарлык» әле һаман «төяб, илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык!» Һәм шагыйрь, каләмен яшенә манчып, сыкрап яза:

Менеп татар «җеназасы-аты»на,
әләк белән(!) китә Аллаһ катына...

Һәм лирик каһарман үзен дә «хаталардан хали» санамый, күрәсең:

Ай-яй ерак, Хак Тәгаләм, ай-яй якын
Хәрам – хәләл, хәләл – хәрам арасы.

Җан, вөҗдан кичерешләре кайсы шагыйрьгә ят тоелыр? Әле бит «Тәкъдир искәртүе» дә бар: «Ничә күбәләк гомерен яшәдең?» – дип сорап тора ул, һәм «Шөкер ит, шөкер ит!» – дип искәртә. Хәер, үлгәч тә кайту бар дип ышана шагыйрь: тал

булып кайту, камыш булып, үлән булып... Бу — мәгълүм пантеистик йә мәҗүси фәлсәфә генә түгел, бу — борынгылар инануы! Бу, бәлки, күпне кичергән, хәтта фаталист була язган халкыбыз өметләреннәндер? Һәм әхлакый акланувы ул, бәлки, безнең гомерләрнең — Мәңгелектә тик кыска мизгелләрнең? Әлеге бабта Зиннурда фәлсәфи-моралист акылы өстенлек итә, әмма ул салкын уй, үгет-нәсихәт түгел. Бу җәһәттән ул, яшьлектәге остазы Равил Фәйзуллинга хас булганча, дөнья белән берлекне нык сизгән хәлдә, гөл касәсендә — дөньяны, бер тамчыда — дәрьяны, һәр мизгел-даимдә — Мәңгелекне һәм, Зөлфәтебез әйткәнчә, «Ходай сулышы»н тоя белә. Әмма пәйгамбәребезнең Ходайдан вәхи рәвешендә алынган сүрәләре кебек үк, Зиннур дуста да шигырьләрнең авыррак укыла, озынлык тәэсире калдырганнары да, кыска, димәк, төгәл, оста, ювелирларча эшләгәннәре дә бар. Ышанып әйтәм: җиңел генә укыла, өстән генә күз йөртеп аңлашыла торган шигырьләр түгел алар. Бу хакта университет студентлары — яшь шагыйрьләр белән дә сөйләшкәнем бар: яраталар, аерым гыйбарә, мисрагларын яттан сөйлиләр, әмма «Берьюлы берничәне укуы авыр, сеңдерергә, уйланырга кирәк», диләр. Ә бу — кимчелекме? Махсус шулай авырайтмаган бит ул аларны: димәк, дөньяны күзаллавы, фикерләве, хис-тойгылары, яшәү ысулы — стиле шундый! Бу төр шигъриятькә күнегергә, М.Цветаева әйткәнчә, «соучастник» булырга, аңлап, ягъни иҗади укырга, яратырга кирәк! Ә яратырлык яклар бик күп бу иҗатта... Китергән мисалларыбыз да моңа дәлилдер. Әйдәгез, һәр шагыйрьнең үзенчәлекле, кабатланмас дөньясына сәфәр чыгып, сәяхәт итә белик әле — белмәгән нәрсәләрне, әнә җырдагыдай, «сәфәрләргә чыксак белербез». Ә бүгенге күп кенә кызыклы шагыйрьләребез үзләренең өр-яңадан ачылуын көтә булыр.

...Бу юлларны язып утырганда, өстәлемдә яткан басмага — яңарак кына Татарстан китап нәшрияты чыгарган бер китапка күз салам: Гамиржан Дәүләтшинның «Төрки-татар рухи мәдәнияте» исемле бик кызыклы һәм, ышанып әйтәм, милләтебез өчен кыйммәте зур булачак, күп тарихи катламнарны эченә алган олуг хезмәте ул. Аның аннотациясендә үк менә ни диелгән: «Һун, Бөек Төрки, Хәзәр каһанлыклары, Болгар, Җучи олысы, Казан ханлыкларының (димәк, халкыбызның бөтен тарихы!—Р. Г.) рухи культурасы тарихы — миф, ышанулары, дөньяга карашлары, халык авыз иҗаты, диннәре... язма мәдәнияты, һөнәри һәм фәнни казанышлары»... Менә нинди киңлек, байлык безнең рухи дөньябызда! Шундый ук колачлылык, бай мәдәният рухы классик шигъриятебездә дә — элгәрләрдән башлап, бүгенгенең җитди, зур шагыйрьләрендә дә сизелмимени? Тукаебызда ул, мөгаен, безнең бәхеткә, күңеленә, теленә Ходай үзе салган дәвамлылык, чорларның рухи синтезы була алырлык пәйгамбәрләр рухыдыр. Ә бит бу мәктәпне дәвам итү — иң изге бурычыбыз! Менә шушы уй-максат яктылыгында мин Зиннур Мансуровта да милли рухыбызның—мәдәниятыбызның өзелмәгән кылларын тоям, сизәм һәм сөенәм. Чыннан да, бүгенге каһәрле чорлар, денсез, динсез еллар тәрбиясе, урысча уйлау, өйрәнү, «Аурупа авангардизмы», хәтта ки сюрреализмы да, һәм үзебезнең татарча эзләнүләрнең «бәрәкәтле» йогынтысы сизелсә дә, үзенең нигез-зәмине белән Зиннурыбыз — югарыда әйтелгән әнә шул милли рухи мәдәниятыбыз вәкиле.

Күренә ки, Зиннур Мансуров элгәрләрнең бөек рухына, олуг сүз-васыятьләренә сыгынып яши, китаби һәм дастани дөньяны иңләрдәй олы фикерләргә омтыла. (Биредә мин аның дастан—кыйсса—миф—риваять традицияләренә таянган оригиналь кыса-композицияле поэмаларын да күздә тотам). Аңарда кыпчак Әтрәк йә мәмлүк Бейбарсларны ераклардан, әрнетеп, үзенә чакырган дала әреме — кылган исе дә, Болгар чоры шәһәрләре культурасы да, борынгы Казан турында тере хәтер дә, бүгенгебез турында ярсулы уйлар да үзара кушыла кебек. Кайта-кайта Тукай пәйгамбәргә дә килеп егыла ул, Хозыр Ильясны да эзли, ярдәмгә чакыра, Җәлил, Мөҗәй кебек шәһит киткән халык улларын да изгеләр рәтеннән санап, каһарманнар рухына таяна, халкының үлемсезлегенә дә ышана. Юкка гына шагыйрь үзенең калын китабы исемен «Яшәү үзе» дип куймагандыр: монда да тарихи аң, тере хәтер белән сугарылган гомер — яшәү кыры. Ул гаять киң, ул мәңгелек милли озон, фикри, рухи, мәдәни кислород белән тулы. Менә нинди ул шигъри сурәт — Яшәү үзе!

Яза торгач, үзем дә уй сәфәрендә шактый ерак, озак йөреп кайттым бугай, гафу итәсезләр! Әмма бу юлларны язучы инанып, хаклылыгына ышанып, сезне дә әлеге замандаш шагыйрьнең иҗат дөньясына сәяхәткә, матур сәфәргә чыгарга чакыра. Чынлап әйтәм, үкенмәссез: бик кызыклы, бай, милли шигъри дөнья ул!

**Рәдиф ГАТАШ.**

ПУБЛИЦИСТИКА

# ФИДАКАРЬЛӘР ВӨҖДАНСЫЗ БУЛМЫЙ

«ТУКАЙЛАР РУХЫ» ИСЕМЛЕ КИТАПНЫ УКЫГАЧ

Татар халкы, бигрәк тә Казани мәркәздәге татарлар, чираттагы мәртәбә үзләренең кайчандыр иректе милләт, дәүләтле халык икәнлекләрен исләренә төшереп, «ләхетләрен» күтәреп, урамнарга, мәйданнарга чыгып кычкыра башлаган 1989 еллардан бирле мин Казандагы тәнкыйтьчеләргә яки кайчандыр, күпмедер әдәби тәнкыйть мәкаләләре, очерклары язган Фәез Зөлкарнәй, Равил Рахман, Мансур Вәлиләрнең тенкәләренә тиеп беттем: ник сез андый жанрны алга сөрмисез? Ник сез әдәби процессны этәреп җибәрердәй мәкалә, очерклар язмыйсыз? Әллә сезгә Брежнев тәрбиясе шулкадәр дә нык сеңдеме дә, сез уңай мисаллар һәм мактау белән генә әдәбиятны алга, киләчәккә алып барырга җыенасызмы?

Җавап та юк, мәкаләләр дә. Әдәбият исә тәгәрәп түгел, үзенчәләй мәтәлә-мәтәлә алга бара. Тик аның юнәлешен дә, кыйбласы-максатын да аеру шулкадәр авыр. Әйе, авыр. Әле әдәбият дөньясына керергә тырышып тарткалашкан яшь кешегә түгел, хәтта буын утырткан әдәбиятчыга да. Ә яшь кешегә андый мәкаләләрнең ничек кирәклеген мин үз тәҗрибәмнән бик нык аңлаган идем инде. Чөнки әдәбият, әдәби процесс, әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйть сыман төшенчәләрне аңларга тырышып эзләнгән чакларымда авыл клубы төбәсенә ташланган иске китапларга тап булган идем. Ә алар арасында В. Плеханов томнары да бар иде. Шуларның X томын авызыма кабып, почмактан үрмәләп төшеп килгәндә безнең «Ленин юлы» колхозы рәисе Зарипов агай күреп алмасынмы үземне. Куркуымнан авызымны ачып катып калганмын күрәсең, китап җиргә үк төшеп китте. Рәис китапны күтәреп алды, актарып карады. Ә мин бүрәнә почмагына песи баласы кебек тотынып торам. Нидер укыштыргач, бу миңа таба карамыйча гына: «Төш, төш, ал китабыңны, моның белән кызыксынгач, син почмактан гына егылмыйсың инде»,—диде дә үз юлы белән китеп барды.

Төштем. Китап нәкъ 135 нче битендә ачылган килеш калган. «Пессимизм как отражение экономической действительности» дип аталган мәкаләнең эпиграфы астына каләм белән калын итеп сызылган. Һәм карасы әле кибеп тә өлгермәгән иде. Димәк, персидәтел сызган булгандыр. Ә эпиграф мондый иде: «Не оттого ли мы довольствуемся сенями, что история наша еще стучится в ворота». Менә шушы сорауга җавап эзли-эзли В. Плехановның калган томнарын да укып чыктым. Адашыплар беттем. Тик инде барыбер дә әдәби процесс, әдәби алым һәм шуларның кешелек тарихына, рухына тәэсир итүен аңларлык хәлгә килдем шикелле.

Бу әле урта мәктәптә укыган дәвер һәм шул чордан башлап инде мин «Вопросы литературы», «Литературная газета» кебек матбагалардан аерылмадым. Һәм боларның миңа тигән иң зур файдасы шул булды—унбиш ел буе әдәбият дөньясында дәшми тордым. Чөнки бу гәзит-журналлар өстенә «С кем вы, мастера культуры?» сериясендәге китаплар да өстәлде. Шулчак мин инде сәясәт халык мәнфәгатенә каршы эшли башлый икәнен, җинаять дип атала башларга тиеш икәнен дә аңладым. Монысы инде минем уема, телемә коточкыч богау булып та салынды. Инде әйтәм генә дисең, медальнең икенче ягы ялтырап китә. Һәм дәшәргә теләүне дәшмәү алыштыра. Бераздан инде мин чукракларга «көнләшеп яши башладым».

Әмма дәшми калу мөмкин түгел иде. Чөнки мин: «Ни өчен без—Кеше кадәр Кеше—тарихнын капка төбендә генә торырга тиеш? Тарихны кемнәр тәшкил итә?» кебек сораулардан арына алмый озак газапландым.

Кичә дә, бүген дә бик күпләр шушы сораугa җавап эзли. Иртәгә дә эзләрләр. Болар һәм башка бик күп төрле сорау һәм уйлар миндә нәкъ менә шушы мәкаләне язу теләген тудырды да инде.

Мәкалә! Олуг язучыбыз Әмирхан ага Еники Мансур Вәли белән әңгәмә барышында мондый фикер әйтә: «Мин инде мәкаләләрнең кабат укылмавын, тиз онытылуын, китап булып чыга алмавын әйтеп тә тормыйм»—ди. Нәкъ менә шушы фикернең киресен исбатлагандай, Мансур Вәли әңгәмәләрдән һәм мәкаләләрдән торган китап бастырып чыгарган. Әйе, мәкалә китап булып басылган һәм мин инде бу китапны бер генә кат укып чыкмадым. Димәк, мәкалә кабат та укыла икән ләбаса. Ә гасыр үткәч тә, Чернышевский, Плеханов, Ибраһимов, Тукай мәкаләләренең укылуы үзе үк Әмирхан аганың фикеренә каршы килмимени?

Дөресен әйткәндә, Мансур Вәлинең «Тукайлар рухы» дип аталган китабын мин шушы әңгәмәдән укый башладым. Шуннан соң күренекле галим һәм әдәбият тәнкыйтьчесе Ибраһим ага Нуруллин белән әңгәмәгә күчтем. Кирәк бит! Мансур Вәли галимгә беренче итеп шундый сорау куя: «...Ә беренче соравыбыз менә мондый. Әдәби тәнкыйть өлкәсенә килүегез ничек булды? Мона этәргеч ни иде?— Һәм менә мондый җавап ала:—1942 елның ноябреннән 1943 елның октябренә кадәр бик күп әсәр укыдым. Шулар арасында Д. Писаревның «Реалисты» исемле зур мәкаләсен һәм В. Белинскийның мәкаләләрен яратып укыган идем. Әнә шул мәкаләләр миндә тәнкыйтьче булу хыялының яралуына сәбәп булды инде».

Димәк, галим Ибраһим Нуруллин да мәкалә жанрына унай караштa торган икән, аны югары бәяләгән. «Кыскасы, халык файдасына булган эш-гамәл әхлаклылык билгесе итеп каралырга, халык зарарына булганнары әхлаксызлык итеп тамгаланырга тиеш»,—ди ул бер урында.

Әйе, инде ничә гасырлар тәкрарлап киләләр шушы хакта. Кече Сенака әйтмешли: «Философы пишут о том, как должны жить другие, а не о том, как живут сами». Шушы ук китапта олуг проза остасы Нурихан ага Фәттах сүзләреннән дә шул аңлашыла: Тукайлар заманы белән чагыштырганда берни үзгәрмәгән. Алга китеш түгел, чигенү бар.

Шулаймы икән, шулай була аламы икән соң бу? Ә фидакарь Батулла: «Тукай ни язар иде икән бүген?» дигән сораугa: «Шуны ук» дигән җавапны бирә.

Хикмәт нидә? Ник болай сөйли соң бу затлар? Нинди җавап бирелүенә карамастан, шәхесләр белән алып барылган әлеге әңгәмәләрдә чорның колориты чагыла, мәсьәләләрнең ни дәрәҗәдә кискенлеге нәкъ тарихи чынлыгы белән ышандырырлык бәян ителә. Ахырзаман гына килмәсә, киләчәктә дә тарих, әдәбият белән кызыксынучылар булыр һәм чын хакыйкатьне бар булганы белән белү, аңлау өчен нәкъ менә шул мәкаләләргә дә мөрәҗәгать итәрләр. Мондый әсәрләргә генә түгел, кискен зарурлык булганда, хөкем-тикшерү рәсми кәгазьләрен дә кабат-кабат укып өйрәнәләр. Ә болар, мондый шәхесләрнең сүзе, тарихның тере язмасы инде ул.

Китапны укуымны дәвам итәм. Янә китаптагы беренче әңгәмәгә әйләнеп кайттым да... мине бөтенләй башка уйлар өермәсе биләп алды. Әллә Әмирхан ага да Такташ кебек, анкеталарында алдаша микән? Һәм шуңа күрә Мансур Вәли куйган сорауларга да вөҗданы кушканча җавап бирмәде микән? Менә тыңлап карагыз әле. «...Дөрес, намус бирәүдә күбрәк, бирәүдә кимрәк булырга мөмкин, ләкин аның үлчәвен кем белә, кем үлчәп карый ала? Әйтик, намуслыны намуссыздан ничек аерырга?... Намуссыз дип әйтергә мөмкиндер бәлки чеп-чи ялган язучыны, кешегә нахак яла ягучыны, яки үзеннән өстеннәргә ачыктан-ачык ялагайланучыны... Ләкин моны да исбат итәргә кирәк бит әле»—ди дә шундый нәтиҗә ясый: «...Әмма иҗат эше ул—асылда намус эше...»

Ахыр чиктә өлкән язучыбыз әйткәннәрдән мин шуны аңлыйм: чын иҗат намус булганда гына була ала икән. Ә инде намусыннан тайпылгач, иҗат иҗат булмый, ул ялганга әверелә. Димәк, ялган язган язучы намуссыз калган буладыр. Ник соң ул намусны тегe яки бу иҗатчыда процентлап үлчәп булырга мөмкин ди әле? Мина калса, бу мантыйкка туры килми. Намусны да нәкъ иҗат кебек үк йә бар, йә юк кына дип беләм мин. Шулай булмаса, иҗат итү өчен язучы ике йөзле булырга, ике яшәештә матавыкланырга, алдарга һәм алданырга, ялагайланырга, яраклашырга тиеш. Юк инде! Халык җанының лакмусын тәшкил иткән шагыйре,

язучысы да шундый булса, халкы нинди булырга тиеш соң аның? Бәлки намусны шулай процентлап үлчи торгач, милләтне адаштырып бетергәннәрдер дә? Әллә нинди ялган, ясалма кампанияләргә ышанып, дөрләпләр яна бит халкыбыз. Шул ышануы аркасында күпме «гулаг», «суслонгерларга», нинди богау, элмәкләргә башын салды ул. Ничекләр генә өшегән сыныннан «оттепельләр» белән җанын алырга тырышмадылар аның. Ничәмә ничә тапкыр богауларны бушаттылар да кыстылар һәм тагы да ныграк кыстылар. Мин исә үскәндә үк шул кысулар хакында әби-бабалар, әткәй-әнкәйләрдән бик күп адәм ышанмаслык хикәятләр тыңладым. Ышанмадым, еладым, аларны ялганда фаш итмәкче булып бәхәсләштем дә әле. Тик дәлилләр... Кеше барыбер бөтенләй дә эзсез югалмый бит ул. Гасырдан артык яшәп киткән әбиемнең сүзләре тел очыма килә: «Бер Аллага вә үз-үзенә ышан. Кеше рухының алтын үзәге шулдыр. Андый үзәге булган Кеше янына кешеләр җыела. Шуларга таян. Сатсалар, елама! Сине сатканнарның язмышы сатылу». Шушы сүзләрне дога китабына язып куйдым. Һәм дөнья авырлыгы бәгыремне сава башлаган саен кулыма шул китапны алдым, шул сүзләрне догадай кабатладым. Ышанмаска һәм ышанырга өйрәндем.

Минем гомергә тигән «оттепель»нең икенчесе 1985 елда башланды. Ләкин мин аның ихлас күңелдән эшләнгән мәсләк икәненә ышанмыйм. Чөнки мин аңа империянең богауларын вакытлыча бушатып, кемнең кая таба бара икәнлеген сынап каравы дип карыйм.

...Мәхәббәт һәм Ирек. Мәхәббәт ясалмалылыкны кабул итә алмаган кебек, җан да ясалма ирекне, асылда тулы булмаган ирекне кабул итә алмый. Безнең бүгенге «ирегебез» дә шул сынау гына сыман тоела миңа. Кемнең кем икәнен төгәл белүгә богаулар тагы кысылмаячак та, тарих тагы кабатланмас дип кем генә әйтә ала соң? Миңа буыннан-буынга шушы хакта тәкрарлап торалар икән, минем ышанмаска ни хакым бар. Мисал эзләп ерак китәсе түгел. Моннан дүрт буын элек яшәгән Фәүхетдин бабам әткәйгә: «Үтәр җиде буын, миссионерлар татар авыллары буйлап нәсел агачларын күтәреп йөрерләр вә татарларны башкорт дип исбатларга тырышырлар»,—дип язып калдырган булган. Һәм бүген башкорт шовинистлары—башкорт милләтен ясалма арттырырга тырышучылар—татар авыллары буйлап шәҗәрә күтәреп йөри икән, ата-бабам сүзе хак булып чыга түгелме соң?

Мансур Вәли Әмирхан агага тагы шундый сорау да куя: «Ә менә хәзер кино һәм телевидение (бигрәк тә Россиянеке) яшь кешене эчтән җимерү өчен үтә актив эш алып бара. Экранда минут саен үтереш, талау, көчләү, секс. Бу инде хәзерге балаларны «менә дигән» бандитлар итеп үстерү дигән сүз. Массакүләм тәрбия менә шундый. Биредә язучы нишли ала? Безнең татар зыялылары милләтнең киләчәген саклап калу өчен мондый очракларда нәрсә эшләргә тиешләр? Ә безнең җитәкчеләр, хөкүмәт?»

Бөтен татар дөньясын газаплый торган сорау бу. Әйе, Әмирхан ага да Мансур Вәли әйткәннәрнең хаклы икәнлеген таный.

Һай рәхмәтләр төшкере: Мансур Вәли, әйтерсең, уйларымны ишетеп торган да, мин әйтергә теләгәнне—ипле генә сораулар белән Әмирхан аганың авызыннан өзеп үк ала: «...Шул ук вакытта бик күпләрне җан саклар өчен эчке уйларын яшерергә, ике йөзле булырга, яраклашырга мәҗбүр итәләр»—ди әдип. Аннары: «Г. Исхакый, Г. Тукай—бу ике шәхеснең гражданлык батырлыгы барыннан да бигрәк нәрсәгә нигезләнгән», дигән сорауга җавап биргәндә ул тагын шундый нәтиҗә ясый: «...була һич үзгәрми торган кешеләр... Үзгәрә тарихи вакыйгалар, үзгәрә тормыш шартлары, ә ул үҗәт кеше, һич кенә дә үзгәрмичә үзенең төп мәсләгендә кала бирә. Хәтта вакытлы мавыгып китүләре булса да, андый кеше, барыбер үзенең баштагы иманына кайтып төшә. Исхакый белән Тукай, минемчә, әнә шундый үзгәрә белми торганнардан... Әгәр алар безнең заманда яшәсәләр, кичә большевик, бүген милләтче, иртәгә демократ була алмаслар иде... Чөнки вөҗдан бар, вөҗдан кушмый төрле кыяфәткә керергә... Андый кешеләр, гадәттә, сирәк очрыйлар.

...Нәкъ менә мәсләк, иманнары какшамас, үзгәрмәс булуы өчен дә заман аларны сайлап алды һәм кул җитмәс «биеклеккә күтәрде». Вөҗдан кушканны гына эшләгән кеше, янарак сүз белән әйтсәк, намуслы да буладыр инде ул. Урысчага икесен дә бер үк «совесть» сүзе белән тәрҗемә итәләр. Тик намус ул пионерныкы, комсомолныкы, коммунистныкы, депутатныкы һәм башка төрлеләр дә була бугай. Ә менә вөҗдан һәм иман фәкать кешенеке генә була ала. Һәм алар рухны билгеләүче,

мина билгеле булган, абсолют төшенчәләр. Ә инде шул вөҗдан һәм иманга ия булмаган затларның башкаларга рух җырчысы булырга хаккы юктыр. Һәм менә шуна күрә дә әзрәк иманлы, әзрәк намуслы гына булганнарны тарих үз битләреннән юып ташлыйдыр да, Тукайлар, Исхакыйлар гына каладыр. Әйе, милләт өчен фидакарь хезмәт иткәннәр генә һәм бүген әдәбиятта Тукайлар аз булганга күрә яшәешебез сәер салулап бара, фаҗигаи төс вә эчтәлек алалыр.

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов «Нәрсә ул Тукайлар рухы?» дигән сорауга турыдан-туры фидакарьлек, дип җавап бирә. Ә безнен заманның фидакарь әдибе дип Нурихан ага Фәттахны атый.

Җен туе дәверендә дә үз тавышларын ишеттерә алган Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалим, Кадыйр Сибгатуллин, Зөлфәт, Эдуард Мостафин, Ләис Зөлкарнәевләрне дә аерып күрсәтә.

Ә менә язучы Фәнзаман Баттал үзенең җавабын шундый сүзләр белән тәмамлый: «Соңгы сулышта: «Гомерем иртә өзелә, шуна күрә иҗатым да кыска булды»—дип үкенә алмаячакбыз. Шулай дисәк, Тукай көләчәк»...»

Карагыз әле, әдәбиятка килүче яшьләр өчен нинди олы фикер, шигарь бу! Эх, мин бу фикерне егерме генә ел элек укыган булсам иде... Минем үз тизлегем барлыкка килгән булыр иде дә... Әйе, яктылык үз тизлеге булганга күрә яктылык дип атала шул..

Беләсезме кардәшләр, минем бу «Тукайлар рухы» китабын кулыма тоткан килеш барлык яшьләргә ишетелерлек итеп сөрән саласым килә: тугыз гына татар әдибенен биш-алты гына сорауга биргән җавабын укып карагыз әле! Анда аксакаллар да, урта буын вәкилләре дә, хатын-кыз язучы да, шагыйрь һәм прозаиклар да, юморист һәм тәнкыйтьчеләр дә—барысы да заман хакында фикерләрен әйтә. Бер китапка никадәр байлык тупланган! Никадәр рухи хәзинә җыелган анда!

Тик хөрмәтле әдәбият сөючегә, әдәбият дөньясына керергә омтылучыга аерым сүзем дә бар: берәүнең дә хаталардан хали була алмаганы кебек, бу китапны әзерләгән һәм дөньяга чыгарган затларның да хаталары, җитешсезлекләре бар. Бу китапның кыйммәтлелеген, әһәмиятен тагы бер кат таныганнан соң, кортлы чикләвек кебек авызны-телне пычраткан берничә вак җитешсезлекләрне генә күрсәтеп узарга кирәк дип саныйм. Ә калганнарын игътибарлы укучы үзе дә күрер.

Халык язучысы Аяз ага Гыйләҗев китапка кергән икенче әңгәмә барышында шундый гыйбарә куллана: «Әмма зур кызганычка каршы, әдәбият белән халык арасы елдан-ел ераклаша бара». «Әмма зур кызганычка каршы» дигәннәре шул урысның «к великому сожалению» дигәннәредер инде ул. Бигрәкләр чит сөйләм икәне колакны ярa. Шуны Аяз абый язып куйган. Мансур Вәли редакциясләми китапка кертеп җибәргән дисәм, әле тагы бер редакторы—Наилә Вәлитова да булган икән әле. Бу гыйбарә нәкъ татар теле һәм аны белмәүчеләр хакында сөйләгәндә кулланыла бит әле. Шундый чит ямаулыклар белән ямап язсан, халык белән әдәбият арасы ераклашмый нишләсен соң.

Ә Айдар Хәлим исә урысның сүз байлыгыннан болайрак файдалана: «Аларның иң авыры һәм гафу ителмәслеге—кичә генә синең ышанычка кереп, популярлык яуларга тырышкан, синең аша халыкка хезмәт эшенә тәкъдим ителгән, бүген инде нииндидер вазифага ия булып, сине дарга мендерергә әзер торган көчләр белән рухи коррупциягә кереп, югары органнарга чапкан һәм сина, синең вөҗданына каршы турыдан-туры һөҗүмгә күчкән сатлык җаннар авызыннан ишетелүе». Лев Толстой үзе «көнләшер» иде, билләһи.

Шушындый да кирәкле китап чыгарган, татар дөньясы өчен олы хезмәт күрсәткән әдипләр күнеленә авыр алмасыннар, мона охшаш галәмәтләр очраштыргалый шул китапта. Ә бит олуг затлардан килгән кимчелекләр, «зур кызганычка каршы» уртак хәзинәгә әверелеп китүчән була. Аннан соң нәрсә җитми соң безнең әдәбиятыбыздагы бүгенге геройга, дибез. Еш кына җанлы татар теле дә җитмидер инде.

Мин шәхсән, әңгәмәләрнең урнаштырылу тәртибе белән дә риза түгелмен. Шуна күрә Аяз Гыйләҗевкә бирелгән «Нәрсә җитми соң безнең әдәбиятыбыздагы бүгенге геройга, ни өчен аерым әсәрләрне укыгач, геройдан канәгатьсезлек хисе кала әле?» дигән сорауны ахырга тартып чыгардым. Бу сорауга Аяз ага болай дип җавап бирә: «Мин аларга заман катлаулыгы һәм заман ялкыны җитми дияр идем.»

Ә Мансур Вәли исә Аяз ага белән күпмедер дәрәҗә килешмичә түбәндәгечә фикер йөртә. «Ә мин, күрәсен, болайрак дияр идем: безнең геройларга бүгенге укучының акыл дәрәҗәсенә күтәрелергә һәм, аңа нинди дә булса сабак бирә алырлык булу өчен аны узып та китәргә кирәк...»

Аяз ага моңа каршы да килми, хуплап та бер сүз дә әйтми. Тик мин боларның икесе белән дә килешә алмыйм. Чөнки мин болайрак фикер йөртәм: Татар әдәби процессы инде рус әдәби процессыннан 100 ел чамасы артта калып бармый. Ул аралык бетте. Татар әдәбияты инде күптәннән үз-үзен узып китте һәм үз-үзен кабатлый да кабатлый. Чөнки безнең тормышыбыз, җаныбыз тоткында, торгынлыкта, зинданда. Андый дөньяда киләчәк буыннар кызыгып шәхесләр табып сурәтләү кеше ышанмаслык дәрәҗәдә авыр. Шуңа күрә аңа төрләнү, үсү авыр. Кабатланган нәрсәнең кызыгы бетә. Ярый әле фантастикага күчә башладылар. Әдәби процессның торгынлык чорында фантастикага күчүе башка әдәбиятларда да күзәтелгән. Фантастика жанры үскән, алга киткән барлык әдәбиятлар да таптану чорын үткәргәннәр. Әмма аерма шунда: ул әдәбиятларда фантастикага егерме-егерме биш яшьлекләр мөрәҗәгать итсә, бездә илле яшьлекләр фантастик әсәрләр яза башлады. Әмма бу соңга калу түгел, ә киресенчә, ярты гасыр чамасы, әле киләсе буын яшьләр яза башлаячак вакыт сызыгына керү галәмәте дияр идем. Флүс Латыйфиның «Тамга» китабын шундый беренче карлыгач дип атыйсым килә.

Мәкаләмнең ахырына якынлашам. Әмма үземнең дә кимчелегемне әйтеп китми булдыра алмыйм. Һәркем аңласын өчен, ни турында, нинди күләмдәге әсәр хакында сүз әйтмәкче икән бу бәндә дип, укучы аптырап калмасын өчен, бу язманы болайрак башларга тиеш булганмындыр: «Әле күптән түгел, Татарстан китап нәшрияты инде татар китабы чыгудан туктау хәленә килгән бер мәлдә, Мансур Вәлинең «Тукайлар рухы» дип аталган яшел тышлы, 286 битле әңгәмәләр вә мәкаләләр китабын чыгарды. Әдәбият дөньясы, икътисад, сәясәт белән кызыксынган кеше бу китаптан бихисап сорауларына җавап таба ала. Әмма һәр үз фикерле кеше өчен бәхәсле урыннар да аз түгел. Минем өчен шунысы белән дә бик кыйммәт бу китап.»

Ләкин «Тукайлар рухы»ның кыйммәте аның белән генә дә бетми икән бит әле. Кыйммәтлелек турында сөйләгәндә китапның яртысыннан аз гына кимрәк өлешен тәшкил иткән «Идел» өчен көрәш бүлегенә, һичшиксез, аерым игътибар итәргә кирәк. Биредә хәзерге заманда да зыялы татар яшьләренең тәхет әһелләре тарафыннан корылган үтә нечкә богаулары аша үтеп чыгарга мәҗбүр ителүләре бик тә ышандырырлык итеп сурәтләнгән. Китапның бу «көрәш» өлеше мине янә көрәшле Башкортстанга кайтарып төшерде. Шул рәвешле ун ел дәвамында үзем яшәгән Нефтекама шәһәрендә нәни-нәни генә рухи таләпләр куйган татарларның хәле күз алдыма килеп басты. Ә таләпләр гадинең дә гадие иде: мәктәпләрдә туган телдә белем алу, туган телдә матбага булдыру, иҗат итү, театр булдыру, радио-телевидениедә татар телендә тапшырулар оештыру. Ә түрәләр моңа каршы, чөнки шушы гади генә таләпләр үтәлсә дә, кеше туган теле, туган халкы, милләтенең киләчәге хакына яши ала. Ул—үлми, рухи җиңелми. Ә кешене аны җиңү өчен иң беренче аның рухын сындырырга кирәк. Әнә бит олуг әдипләребез дә шуны тәкрарлап тора: радио-телевидениедә азгынлык, сугыш-үтереш, диләр. Өстәвенә, алар үтерү юлы белән генә килеп туган мәсьәләләрне «хәл итә белә» торган «зат»лар уйлап чыгарган, әзер рецептлар бирүче фильмнар. Кеше җаны бик нәзберек. Ул бер адымга гына үз теленнән, үз җиреннән, үз җырыннан читләшсә дә башка халәткә керә. Җаны—тәнен саклап калу өчен яраклашырга мәҗбүр була. Адәми затның нәкъ шушы сыйфатыннан үз җире, үз теле, үз иманыннан инде күптән тайпылганнар кабахәтләрчә файдалана, калганнардан да үзенә охшаш затлар ясарга омтыла. Үз-үзләреннән китмәгәннәрдән шулай үч алмакчы булалар. «Идел» журналын чыгартмаска тырышу да нәкъ шушы максатны тормышка ашыруның ачык бер мисалы. Башкортстан хакимиятчелегенең татар милләтеннән башкорт ясамакчы булып тарткалашуын да шуның белән аңлатырга кирәк.

Әйе, Мансур Вәли детальле сурәтләр аша хакыйкать җебенең очын эләктергән: шәхесләрне адаштыру, өметен өзү, сабырлыгын сындыру юлы белән көрәштән читләштерү өчен үз-үзләреннән киткәннәрнең нинди вак, мәкерле адымнар белән эш итүен күрсәтеп биргән. Юкса хакыйкать гади иң: әдәбиятның яшәве һәм үсүе өчен, беренче чиратта, әдәби әсәрнең язылуы һәм басылып чыгуы шарт. Һәм бу

ике фактор бер-берсенең алшартлары да булып торалар. Нәкъ шуларны булдырмас өчен барган көрәшнең татар яшьләренең рухын сындыру өчен барган сугыш икәнен аңлап укыган укучы бу зур мәкаләдән тарихи гыйбрәт алачак, олы нәтиҗәләр ясый алачак. Чөнки автор иҗат итүнең шартларын һәм төп факторларын шулкадәр зур төгәллек белән күрсәткән һәм язучылар оешмасының да бу эштәге ролен анык дәлилләр белән сурәтли алган.

«Әлеге дә баягы Тукайлар, Әмирханнар чорын алыйк. Ул чагында татар телендә гәзит-журналлар күп чыккан, Язучылар берлеге бөтенләй дә булмаган. Ләкин бит безнең бик күбебез белеп тора: бу дәвер, Тукайлар чоры—татар әдәбиятының алтын чоры! Үз үсешендә иң зур күтәрелеш кичергән дәверләрнең берсе ич ул! Ул чакта матбугат күп булу сәбәпле, әдипләр үзләре язганны тиз арада бастыра алганнар. Йөрәкләрендә кайнаган хисне, кичерешне шундук укучыга, халыкка җиткерә алганнар. Димәк, тормыштагы теге яисә бу вакыйга, күренеш уңаеннан әдип күңеленең, әдип йөрәгенең дулкынлануы тиз арада киң массага ирешкән. Димәк, бу дулкынлану тормышка да тәэсир иткән. Күпмедер дәрәҗәдә аны үзгәрткән дә»,—ди Мансур Вәли.

Әлбәттә, шулай. Тормышта торгынлык ул кибеттә колбаса бетүдән башланмый, ә җандагы торгынлыктан башлана. Ә без инде кайчаннардан бирле «Брежнев чоры, торгынлык чоры» дип ыгы-зыгы киләбез, кайчаннан бирле көнләп түгел, айлап түгел, әллә дистә еллар буе язучы үз әсәрләрен дөньяга чыгара алмый иң тегә. Үзе акча түләп чыгарырга да тырышып карый. Әмма юк. Алай да булмый. Чөнки акчасызлыкка китереп терәделәр. Чөнки беләләр: иманы исән халык соңгы тиенен дә тәнен асрарга түгел, рухын саклап калырга тотачак.

Ә шулай да алда китерелгән өзектә авторның бер фикере белән килешеп бетмим бит әле. Чөнки матбугат бүген дә аз түгел дә бит, әмма язылган әсәрләр һич кенә дә вакытында укучыга, халыкка барып ирешә алмый. Күрәсең, матбугатның күп булуыннан бигрәк, аның хөр күңелле кешеләр карамагында булуы беренчел шарттыр. «Күп матбугат» хәзерге рухта әллә ни озакка бара алмаячак. Үзеннән-үзе сүнәчәк, ябылачак. Рух газраилләре монысын да бик яхшы күреп торалар, әлбәттә.

Әйе, әсәр басылып чыгу иҗатның, әлбәттә, төп шарты. «Үзе язган әсәрләренең кешегә, укучыга, халыкка тәэсир итүләрен күреп, тоеп, аңлап торган әдип исә тагын да дәртләнеп һәм илһамланып икенче, өченче әсәрләрен язарга тотына. Чөнки аның үз чоры хакында, үзен уйландырган яна вакыйгалар турында әле тагын әйтәсе сүзләре бар!»

Ә бүгенге көндә исә язучы булу кретерие Язучылар берлеге әгъзасы булу белән билгеләнә шикелле. Ләкин Язучылар берлеге язучыларның басмаларын арттырамы да, аны халыкка җиткерүне җиңеләйтәме соң? Шулай булса икән лә ул... 1910 елда Рәсәй территориясендәге 13 типографиядә мөселман китаплары йөзәр мең данә булып басылып чыккан, утызлап исемдә гәзит-журналлар дөнья күргән. Бүген исә ничә типография нинди тираж белән татар китаплары чыгара? Чагыштырып кына карау да өметләрне өзәрлек. Болай барса, татар китабы бер мең, йөз данә тиражга ук төшеп калырга мөмкин. Ә инде гәзит-журналларның—көндәлек булудан инде күптән туктавы, махсус киртәләр куелу халык белән матбугат арасын бөтенләй бозды, җимерде. Җимерүче көчләр бүгенге көндә куйган максатларының апогеена ирештеләр шикелле. Без һаман нидер өмет итеп карап торабыз: боздан ботка тамганны көтәбез. Хатлар язабыз, җыелабыз, таралабыз, таркалабыз... Ә шулай да ничектер, нидәндер шөкер итәбез. Ни тырышлык белән гамәлгә куелган милли журналларыбызның да хәле аяныч бүген. Яшь иҗатчылар дәшә алмаслык хәлгә килделәр, күрәсең. Хокуклар бөтенләй киселеп беткәч, кабаттан яулавы бик авыр бит ул. «Идел»егезгә янә күз салыгыз, яшьләр, дип кычкырасым килә. Аның агымы буылмаганмы, юлларын чистартырга, аңа коючы нәни елга-чишмәләрнең юлларын ачарга кирәкмиме икән? Чишмәләребезнең суларын тәти шешәләргә салып, сатып кына биреп эчерәләр бит безгә хәзер. Акча юк. Чишмәләр йозакта...

Китапның соңгы бу сәхифәсе миндә шундый зур сораулар тудырды.

«Тукайлар рухы»—тыгыз фикерле китап, милли яшәеш өчен фидакарьләрчә көрәш үрнәген дә эченә алган яңа басма. Ходай кушып, ул Тукайлар рухына, тәнкыйть әдәбиятына юл ачучы, әдәби тәнкыйть журналы булдыру өчен дә көрәш байрагына әверелсә иде.

**Нәҗибә САФИНА.**

*Җинүнең 55 еллыгына*

# ШИГЪРИ ҖАНЛЫ ГАЛИМ

Надиров. Жыр. Финляндия. Артык кыска һәм абстракт бу сүзләрне бераз шәрехли төшкәч, болайрак чыга: Илбарис Нурислам улы Надиров— фольклорчы, фронтовик; татар халык жырларын фәнни өйрәнеп, жыйнап, бастырып халыкка ирештергән галим; Финляндиядә яшәүче татарларны совет чорында янәдән Ана-Йортка тартып, тарихи уртак мөнәсәбәтләрне урнаштыруга зур өлеш керткән шәхес.

Ышануы кыен булса да, ана да 75 яшь тулган икән. Чыннан да, ышану кыен: әле ел ахырында гына редакциябезгә кергәч, уртак эшләр турында сөйләшкәндә сүз унаенда гына «минем дә юбилей сыман нәрсә якынлаша» дигәч, ихлас сорап куйган идем—әллә 70 кә якынлашасызмы? «Әзрәк күбрәк...» дип жавап бирде ул. Әйе, шактый гомер үтелгән. Бу яшьтә төп эшләр, нигездә, эшләнгән була инде. Энциклопедиядә И. Надиров турында ничек язылгандыр, карарга өлгермәдем, әмма мин белгәне шул: ул—рухи дөньябыз тарихында шанлы бер сәхифә булып калган татар халык ижаты әсәрләренен 12 томлыгын дөньяга китерүне оештырган (жыр томнарын үзе төзегән) галим. Бу фундаменталь хезмәт ижтимагый-рәсми яктан югары бәяләнде дә. 1989 елны И. Надиров житәкләгән галимнәр төркеме Х. Мәхмүтов, Ф. Әхмәтова, Л. Жамалетдинов, Х. Ярми (үлгәннән сон) Татарстан-нын Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

Фольклор—үзе бер зур дөнья, әдәбиятнын, сәнгатьнен нигезе. Илбарис ага гомерен халык ижаты дигән әнә шул олуг мирасның бер тармагын—жыр жанрын өйрәнүгә багышлаган. «Мина жан рәхәте биргән фәнни дөнья—ул халкыбызнын жыр поэзиясе. Халык жыры—бөек шигърият әсәре ул. Анда иксез-чиксез хисси байлык, мон, хикмәтле, сурәтле фикерләр, тел бизәкләре тулып ята...» ди ул үзенен бер язмасында. Шунда ук өстәп тә куя: «фольклор әсәрләренен төрлесен язып алсам да, мина нигәдер жыр жанры якын булды. Жырнын үзенә гашыйк итә торган ниндидер тылсымы бар, күрәсен». Тәкъдир кушуы буенча гомер юлы дөрес сайланган булган. Ир жырны күтәргән, Жыр ирне күтәргән.

Ә Финляндиягә килгәндә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне «ачу», алар белән ныклап аралашу буенча бу ил—беренче ил булды шикелле. Төркия, Германия, Америка кебек илләргә юл сонрак ачылды... Моннан 40 еллар элек гади кеше өчен чит илләргә чыгып йөрү гайре табигый, сирәк хәл иде. Сәяхәтчеләр өчен, кем генә булмасын, сынау-таләпләр бик көчле иде. Чит ил татарлары белән аралашасы да килә, тоталитар режим куйган тәртип-кысаларны да бозарга ярамый. Дипломатик акылга ия булсан гына нәрсәдер майтарып була. И. Надиров бу яктан егет кеше булып чыкты. Казан татарларынын гыйлем иялəренә, сәнгать осталарына Финляндиягә юл яруда анын өлеше зур булды. Хельсинкидагы Тукай жәмгыяте житәкчеләре (Г. Таһир һ. б.) дә Казанга килә башлады. 1968 елда безнен олуг затлар—Р. Яхин, И. Шакиров, А. Арсланов, В. Шәрипова һ. б.ларнын Финляндиядәге гастрольләре, аларнын Суоми иле президенты У. Кекконен белән очрашулары ул заман өчен олы вакыйга иде. Аннан сонгы елларда күпләр булды ул якларда. Финляндия татарларынын байтак рухи хәзинәсе илебезгә кайтты. И. Надиров тырышлыгы аркасында, мәсәлән, Хәсән ага Хәмидулла ижаты белән безнен укучыларыбыз ныклап таныша алды. Хельсинкида 1980 елда чыккан «Безнен жырлар» дигән жыелма китапка да без белмәгән байтак татар жырлары тупланган иде. Сонгы дистә елда И. Надировнын бу юнәлештәге эшчәнлеге Финляндия белән генә чикләнмичә, дөньянын

татарлар яши торган бүтән кыйтгаларына да күчте. Җөмләдән, Төркиядә яшәгән милләтпәрвәр шәхесләребез—Ә. Мәнгәр, С. Имре, М. Алукай, Швециядәге—Төркәр Соуккан һ.б. турында ул кызыклы мәгълүматләр белән матбугатыбызда чыгышлар ясады. Күрәсең, берара аның «Ватан» җәмгыятендә хезмәт итүдә бу эшчәнлеккә этәргәндер.

И. Надиров, халкыбызның төп журналы дип саналган «Казан утлары» белән тыгыз бәйләнештә. Нәкъ 50 ел язышa. 40 тан артык хезмәте басылган. Ел саен диярлек катнашкан дигән сүз. Алга таба да активлык кимемәс дип ышанабыз. Чит илләрдә гомер кичереп бакый дөньяга күчкән һәм бүген исән-сау яшәп ятучы мәшһүр милләттәшләребез турында язмалар циклы язмакчы ул безнең журналга. Иншалла, теләкләр тормышка ашсын!

Һай, гомерләр! Илбарис ага белән танышып, аралашып яши башлаганга да 30 еллап гомер үткән. Еш күрешеп тордык дип әйтә алмыйм. Әмма һәр очрашу үзенчә истә, үзенчә кадерле. Шигырьгә, шигырь язучы затка гаять ихтирамлы ул. Шәхсән, үзем моны һәрчак тоеп яшим. Хәер, ул үзе дә гомер буе шигырь язган кеше. Үсмерегет чакта да, сугыш-фронтта булганда да, олпат ир-аксакал булганда да. Шигъри җан дигәндә тагын бер күркәм зат—безнең уртак дустыбыз—Рим Кәримов искә төшә (ул озак еллар Татарстан радиосында баш мөхәррир булып эшләде). Кайчакта, бигрәк тә күңеле нечкәргән чакларда, «әйдә, Илбарис абый янына кереп чыгыйк әле!» ди торган иде. Галим өенә, көтелмәгәндә, өермәдәй килеп керәбез. Итагатьле каршылар, өстәленә затлы сыен куяр, яхшы якларыбызны мактар, хезмәтләребез хакында сорашыр... Гадәттә, андый очракларда, яна чыккан китабыма автограф та язып бирәм, ул да, шундук, җавап итеп берәр бүләк-истәлек бирер... Гомумән, канатланып, баеп чыга идек без Илбарис абыйлар өеннән! Ниндидер бер затлылык, иплелек бар анарда. Нәселдән-каннан киләдер инде. Холык дигәннәренә тагын гомер буе халык иҗаты белән яшәү хикмәте дә өстәлгәндер. Халык сүзе, халык уе, халык моңы сеңгәндер аның җанына дип уйлыйсы килә.

Кайчак, бик сирәк, радиодан бер мишәр халык җыры яңгырап ала (Аны композитор Ш. Шәрифуллин эшкәрткән, башкаручысы—консерватория хоры.).

Үлән арасында үләннәр күп.
Ат кузгалагыннан да биеге юк!..
Хәсрәт арасында хәсрәтләр күп
Гыйшык хәсрәтеннән авыры юк...

Үзәк өзгеч җыр. Заманында бу җырны Илбарис ага белән Рим абый Пенза якларында ишетеп язып алганнар. Җырны тыңлыйм һәм күз алдыма китерәм. Моннан 40 еллар элек ике егет әллә кайдагы матур табигатьле татар авылында әллә нинди бөек хыяллар белән рух хәзинәсе җыеп йөриләр... Берсе инде менә байтак еллар гүрдә. Уртак дустыбызның урыны оҗмахта, рухы шат булсын...

Заманында, Илбарис ага тарафыннан әзерләнеп, 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» дигән зәңгәр тышлы бер китап белән «яшәп» алган идем. Анда халкыбызның 450 гә якын җыры басылган. Галимнәр теле белән әйткәндә, үз көйләре булган «сюжетлы» җырлар. Аларның бик күбесе борынгы һәм әлегә билгесез булып калган җырлар. Чөнки алар бу гасырның илленче-алтмышынчы елларында гына язып алынганнар. Кызыксынып санап карадым, Татарстаннан тыш татарлар яшәгән унга якын өлкәдән җыелганнар икән алар. Менә кайда сурәтле сүз хәзинәсе! Нинди генә ритмик формалар, бормалар, кушымталар, нинди генә тел-бизәкләр, шигъри сурәтләр юк анда! Үз вакытында ул китапны кат-кат укып, өйрәнеп үзем өчен шактый яңалык ачтым шикелле... Монда шунсын да әйтми калалмыйм, күрше өлкәләрдә җыелган ул җырларның байтагы Илбарис абый кулы белән язып алынган. Олы ихтирамга лаек бер эш бит бу!

Галимнең хөрмәткә лаек тагын бер эшчәнлеген телгә алып үтәсем килә. Халык җырларын җыю, өйрәнү белән бер үк вакытта ул татар шагыйрьләренең халыклашкан җырларын өйрәнү буенча да мавыгып эшләгән кеше. Хәтерлим, моннан утыз еллар әүвәл Язучыларның Тукай клубында шагыйрьләр һәм композиторлар язган җырлар турында зур сөйләшү булган иде. Анда төп докладны Илбарис абый ясады, фикер алышулар да кайнар гына булды. Соңыннан бу доклады нигезендә озын гына мәкалә язып, аны журналыбызда бастырды да. Янә шунсын да әйтү артык булмас, Илбарис

абый татар халкының иң матур җырларын һәм шагыйрьләрнең халкыбыз арасында уныш казанган әйбәт җырларын туплап берничә популяр җыентык та төзеп чыгарды. Шул елларда И. Надировны безнең Язучылар берлегенә әгъза буларак тәкъдим иткәннәре истә калган. Ул утырышта Сибгат ага Хәким дә Илбарис абый хезмәтләре хакында җылы сүзләр әйткән иде. Шунсы гаҗәп булды, Илбарис абый берлеккә керүдән нигәдер тыелып калды...

Сүзем ахырында шунсын да әйтеп узыйм. СССР Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында кайчандыр мин дә аспирант идем. Фәнни эшем: «Хәзерге татар поэзиясендә халык иҗаты поэтикасы». Исеме бераз үзгәрергә дә мөмкин иде. Җитәкчем—Илбарис ага Надиров. Кандидатлык имтиханнарын әйбәт кенә биреп бетердем. Шактый күп фәнни китап укылды, татар поэзиясе тарихын яңа бер яктан өйрәнә башладым. Рухымны баету күзлегеннән аспирантура елларының файдасы булмады дип әйтергә телем әйләнми. Әмма оештыру эшенә, дөресрәге Язучылар берлегенең җитәкчелек эшенә күчү сәбәпле фәнни эшем бүленеп калды. Диссертация якламадым. Җитәкчемне беркадәр авыр хәлгә дә куйганмындыр, бәлки. Хәер, үткәнгә бик үк үкенмим. Хәзер фән кандидатларыннан да бигрәк, «академиклар» күбәйде.

Академиклармы?
Бездә дә бар. Байтак алар:
хакыйкый да әгъза,
әгъза да хакыйкый...

Тик нишләптер юк арада
берәр Нәкый,
йәки Бакый,
йә Исхакый...

И. Надиров 1959 елда ук кандидатлык диссертациясен яклаган. Ул һаман да фәннәр кандидаты. Халык танырлык хезмәтләрең булганда чын мәгънәсендәге Фәннәр Кандидаты булу да аз түгел бу дөньяда!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*январь, 2000*



# Илбарис Надиров

## ИСКӘ ТӨШӘ СУГЫШ ЕЛЛАРЫ

Хәрби хезмәттә мин 1943 елның көзеннән 1948 елның язына хәтле булдым. Армияга Уфа авиация институтыннан киттем. Сугыш башлангач, Рыбинск шәһәреннән күчерелгән бу институтка мине Ютазы районы комсомол комитеты юлламасы белән җибәргәннәр иде. Әмма анда уку насыйп булмады, матди кыенлыклар басымы астында без төрле авыллардан килгән дүрт фәкыйрь студент институтта бирелгән «бронь»нан баш тартып армияга китүне кулай күрдек. Чкалов өлкәсенең (хәзер Оренбург) Колтубанка исемле авылы янындагы кара урманда урнашкан снайперлар

мәктәбендә ярты ел укыгач, безне фронтка озаттылар. 1944 елның августыннан башлап сугыш беткәнче мин Балтик буе фронтында булдым, ике кат яраландым... Җиңү бәйрәмен үзйөрешле артиллерия полкында радиотелегра-фист сыйфатында каршыладым. 1943 елның 1 гыйнварыннан 1959 елның җәенә хәтле мин куен дәфтәрләренә һәм калын дәфтәрләргә көндәлекләр язып баруга хирыс идем. Аларда гомернең артта калган шактый озын вә бормалы юллары уелган. Ул сәхифә-ләрне мин хәзер йә көлемсерәп, йә гаҗәпләнебрәк (кара инде, шундый хәлләр дә булган икән диебрәк) укыйм. Көндәлекләрдә аерым бер кешенең шәхси карашлары, кичерешләре аша бу катлаулы дөньяның кайбер гомум яклары да ачылган шикелле. Шуны истә тотып, мин сугыш елларындагы көндәлекләрдән өземтәләр бирүне урынлы булыр дип санадым.

Сугыш чорына караган ике куен дәфтәрем саклана. Бу дәфтәрләр—трофей. Аларны 1944 елның октябрендә безнең полк Балтик диңгезе буенда оборонада торганда качып китәргә өлгермәгән немец солдатларыннан алган иделәр. Дәфтәрләрнең берсендә шул елларда Германиядә чыккан почта маркалары әле дә булса саклананалар. Аның титул битенә «Борис Надиров. Госпиталь 3829 г. Двинск, XII. 1944» дип язылган (армияда чакта Борис дип атауларына күнеккән идем инде). Шунда ук әлеге госпитальдә чакта язылган озын гына тәрҗемәи хәлем бар. Ул «Идел егете» дип исемләнгән һәм дәфтәрнең 7-64 битләрен алып тора. Сабый чак, яшьлек еллары, армияга китү, сугышта беренче яралану—болар һәммәсе дә тасвирланган анда. Шул дәфтәрдән снайперлар мәктәбендә уку һәм фронтка китү белән бәйле хатирәләрдән кыскартыбрак өзекләр китерим. Бу «трофей» дәфтәргә аларны кечкенә иске блокноттан күчереп язган идем.

**28 ноябрь 1943.** Моннан ун көн элек безне «карантин» дип аталган бер казармага китерделәр. Башкортстан авылларыннан җыелган авыл малайлары, Уфа, Бөре, Стәрлетамак кебек шәһәрләрдән килгән усал шәһәр малайлары бар иде монда. Менә шулар барсы бергә өйләреннән алып чыккан юл капчыклары, чабаталары белән казарманың өч катлы нарларына таралдылар. Ун көн узды бу карантинда, капчык яру, урлашу, сугышулар гел булып торды. Столовойга барулар юк, алай да барысы да тук, капчыктагы азыклар бетмәгән иде әле. Менә бүген безне роталарга аерулар башланды. Институттагы иптәшләремне каядыр икенче җиргә алып киттеләр, берүзем калдым. Бераздан Уфа малайлары янына куштылар, мунча керү башланды. Өс-баш киемнәрен, азыкларны солдаттан алалар да мунча почмагына ыргыталар. Авылым истәлеге булган кыска пальтомны, яшел чалбарымны да шунда ыргыттылар. Үзем белән кечкенә капчыкта шигырьләр дәфтәрем, берничә фото куелган альбом, ике китап, бер бит яулыгы гына калды. Безне яңа шинель, гимнастерка, чалбар, ботинка һәм обмотка белән киендереп яңа казармага китерделәр. Бу казарма җылы, нарларда постельләр бар, безне старшина урнаштырып йөрде. Ә кичен ул ротаны тезеп столовойга алып китте. Шулай итеп снайперлар мәктәбендә чын солдатлык гомере башланды...

**16 январь 1944.** Без укырга тиеш снайперлар мәктәбе тирә-якка унар чакрымга сузылган кара урман эчендә таралып утырган булып чыкты. Аны лагерь дип йөртәләр. Монда тимер тәртипкә, уставка буйсынып яшәргә туры килә. Нормасыз ашарга, приказсыз яшәргә күнеккән авыл малайлары бирелә ябыгып беттеләр. Ни өчен дисәң, тамак туймый, көненә сигезәр сәгать занятиедә йөрү, суык кырда окоп казу, «һөҗүмгә» барулар бик ардыра. Шуңа күрә курсантлар столовойда комсызланып ашарга тотыналар, берничә минуттан өстәлдә бер ни дә калмый. Җитмәсә, кышы да яман салкын башланды. «Строевая подготовка», «Тактика» дип аталган занятиеләргә «Заготовка дров» өстәлде. Лагерьга, землянкаларга, кухняга, пекарняга без баштарак өч-дүрт чакрымдагы урманнан җилкәләргә салып утын ташый башладык, аннары безне ун-унике чакрымга куа башладылар... Биш минутта киенеп, стройга чыгып басарга кирәк. Соңга калсаң, төнлә идән юарга җибәрәләр. Лагерьда кая карама соры шинельле солдатлар, кая карама—команда тавышы. Столовойга җыр белән, занятиегә җыр белән, әгәр җырламасаң, көчләп йөгертәләр. Бер чакрым булыр. Монда кино да, музыка да, китаплар да юк. Хәрби белем бирәләр, тик элек алган белемнәрең юкка чыга. Нишлисең, аяусыз сугыш бара, буйсынмыйча булмый...

**19 февраль 1944.** Менә монда өч ай гомер узып та киткән. Бу айлар эчендә хатлар алышуым рәтләнде. Әткәй-әнкәйгә, Зөлхиҗәгә, Сәгъдәгә хатлар язгалап, алардан да хатлар алып тора башладым. Хат алу солдат өчен чын бәйрәм... Без өч айлык укчы-сугышчы программасы буенча сынаулар биргәннән соң, снайпер винтовкасын, оптик прицельне өйрәнә башладык...

**20 апрель 1944.** Яз килде. Кышкы зар-моңнар тарала, табигать матурлыгына карап

күнелләр күтәрелә торган вакытлар килде. Алай да мондагы сорылыктан туйган солдатларның күз карашларында «Тизме безне озатырлар, тизме моннан котылыр-быз» дигән сорауны сизүе авыр түгел иде...

**24 май 1944.** Мин каравылда идем. Постны биреп казармага кайту белән егетләрнең ниндидер яңалыктан тынгысыз дулкынлануын сизеп алдым. Әйе, безне якын арада фронтка җибәрәчәкләр икән. Алты айдан артык яшәгән бу казармаларны калдырып сугышка китүне барысы да көтә иде...

**25 май 1944.** Көн бик җылы, һава саф бүген. Шулай итеп безне көтмәгәндә ерак юлга әзерли башладылар. Баштанаяк өр-яңа киемнәр бирелде. Төштән соң шул яңа киемнәрне киеп, без гарнизон мәйданына җыелдык. Озату парадына. Солдатлар баскан урыннарында тора алмый, тыпырдашалар, шаулашалар. Менә гарнизон начальнигы полковник Кулаков трибунага менеп «Поздравляю вас, товарищи, с отправкой на фронт» дип кычкырды. Бөтен солдат халкы бар тавышка «Ура» кычкыра башлады. Без бу төнне урамда, ачык һавада йокларга тиешбез, иртәгә безне станциягә озатачаклар икән...

**26 май 1944.** Безне Колтубанка станциясенә китерделәр. Акчасы булганнар базарга йөгерде һәм туйганчы ашарга тотынды... Вагоннарга төялгәч, безнең янга рота командиры лейтенант Нохрин саубуллашырга керде. Ул акыллы, мәрхәмәтле командир иде. «Миңа үпкәләп китмәгез, ачуыгыз килгән чаклар булса, гафу итегез, балаларым» диде ул. Аның күзләре яшьле иде, безнең дә күңелләр тулды... Колтубанкага килгән командирлар туган илнең бәйсезлеген сакларга өндәп озатып калдылар. Бу минутларда күнелне биләгән хисләрне анлату мөмкин түгел кебек. Вагонда җыр, шау-шу, күтәренкелек. Поезд кузгалды...

**24 июнь 1944.** Запас полкта язам бу юлларны. Безне монда расформировать итәчәкләр икән. Үткән көннәрне искә төшерим әле. 26 майдан 13 июньгә хәтле юлда булдык без. Куйбышев шәһәрен узгач Идел күпере аша чыгып Сызраньга килдек. Аннан Пенза-Тула-Кинзяк-Ряжск-Сухиничи-Брянск-Гомель-Городня... Менә безнең 16 көнлек маршрутыбыз. Вагон тәрәзәсеннән һәм яртылаш ачык ишектән карап бардык без узасы юлларны. Чиксез кырлар, урманнарны узгач сугышны искә төшерә торган ватык юллар, җимерек йортлар, траншеялар, окоплар күренә башлады. Брянскида, нигәдер, озак тоттылар. Мин әткәй-әнкәйгә, берничә кызга үземнең сугышка китүем турында хатлар язып җибәрдем. Базарда очсызлык: ипинең килосы 40 сум, онның поты 400. Безгә биргән сухой паеклардан үзебезнең котелокларда ботка, аш пешерергә өйрәнеп беттек. Городняда вагоннардан төшеп тезелгәч, безне каядыр алып киттеләр. Бер ун чакрымнар баргач урман янында туктадык. Каядыр шушы тирәдә запас полкта безне төрле якка таратачаклар икән, диделәр. Менә көтәбез.

**18 июль 1944.** Теге вакыт «запасной»дан мине йөздән артык солдат белән 52 нче армиянең базасына җибәрделәр. Вакытлыча, диделәр. Снайперлар мәктәбендә бергә укыган Тимер Абдуллин (Башкортстаннан) һәм Саша Шатилов (Чкалов өлкәсеннән) белән бергә туры килдек. Бергә булырга сүз бирештек. Шунсы кызганыч булды, мәктәптәге якын дустым Хәләф Усмановны икенче якка җибәрделәр (монда җәя эчендә шуны әйтәсем килә, Хәләф илгә исән-сау кайтып, Октябрьский шәһәрендә эшкә урнашты, гаилә корды, хәзер дә шунда яши. Без баштарак күрешкә-ләп тордык, соңгы елларда хатлар алышып торабыз. Мин аның турында «Ватаным Татарстан» газетасында «Мәргән дустым Хәләф» дигән мәкалә бастырдым. 1991, 2 август).

Менә ике атнадан артык инде без шул базада эшлибез. Безнең бурыч вагоннардан, машиналардан боеприпас, кием-салым, азык-төлек, дарулар бушату, урнаштыру, озатудан гыйбарәт. Эш авыр, йокы эләкмәгән төннәр дә була, ашау-эчүдән зарланып булмый... База белән күченеп йөри-йөри без менә Белоруссиягә килеп җиттек. Бу араларда эшебез Алеша дигән станциядә бара...

**21 сентябрь 1944.** База белән саубуллашып кабат «запасной»га юл тоттык. 35 чакрым араны өч көн буе бардык. Анда безне таркаттылар. Кемне кая? Саша, Тимер белән өчебез дә бергә туры килдек. Шатланыштык. Өчебезне дә автоматчы иттеләр. Снайперлар икәнебезне белсәләр дә. Кирәгебез булмады. 5 сентябрьдә сугышка киттек. Алда атыш тавышлары, әнә ерак түгел йортлар яна, ияләрен җуйган маллар кырда буталышып йөри. Без «боевой порядок» алып цепь белән алга атлыйбыз... Шул төнне урманда фрицләр белән очраштык. Тәртипсез генә сугыш булып алды. Алар күп түгел иде, күрәсең. Качтылар.

... Менә фрицләрне куу башланды. Алар машиналарда кача, без җәяүләп кенә куабыз. Көне-төне походта. Дөресрәге, төне буе юлда булсак, көндезләрен берәр урманда

ятабыз. Дошман самолетлары бомбить итмәс өчен шулай кирәк. Стройда барганда төнен Саша, Тимер белән чиратлашып аяк өстеннән генә йоклап барабыз. Йоклыйсы кешене уртага алабыз да, култыклап атлый бирәбез. Файдасы бар. Бу походта 6 көн, 6 төн узды. 280 чакрым юл узганбыз, диделәр. Поход дигәнең хәлне бик алды. Юлда егылып калучылар да булды. Андыйларны санбатка озаттылар... Бара-бара без Пруссия чикләрен дүрт чакрым артта калдырып, сугышсыз-нисез диярлек зур, яшькелт Балтик диңгезенә килеп чыктык. Береговой охрана килгәнче дип безне шунда диңгез буйларын сакларга дип калдырдылар. Бу Паланга дигән шәһәрдән ерак түгел бер урын. Яңгырлар гел явып тора, салкын, мин аякны кузгаттым, бу араларда аксап йөрим. Ротаның комсоргы булгач, миңа якын-тирәдәге солдатлар янына баргаларга да туры килә бит. Монда күпме булырбыз, төгәл берәү дә белми, аны әйтмиләр дә...

*Беренче «трофейный» дәфтәрдән.*

Икенче «трофейный» дәфтәрнең титул битенә «Борис Надиров. Фронтовые записки, стихи, важные даты. С октября 1944 г.» дип язылган. Дәфтәрнең беренче битендә әтием-әнием яшәгән авыл адресы күрсәтелгән. Шунда ук түбәндәге язма да бар.

**19 октябрь 1944.** Балтик диңгезе буенда комнан казылган окопта языла бу сүзләр. Оборонада ятабыз. Диңгез ярларын саклау бурычы йөкләнгән безнең өскә. Күп көннәр узды, ләкин диңгезнең бүгенге кебек дәһшәт белән үкергәнен күргәнем юк иде әле. 18 октябрьдә бөтен төн буена яуган яңгыр безнең «өчлек» окобына да үтте. Төнен торып икенче землянка казырга, шунда күчәргә мәҗбүр булдык. Яңгыр һаман ява, көзге җил улый, ком бөртекләре яңгыр белән кушылып очалар да очалар. Кичә мин «Әниемә хат» дигән лирик шигырь язып, аны шушы дәфтәргә фрицлардан кулга төшергән кара һәм каләм белән теркәп куярга булдым.

### Әниемә хат

Көзге җилләр, көзге кичләр сиңа
Хәтерләтер газиз улыңны,
Тиздән, әнием, туар җиңү таңы,
Улың кайтыр, кысар кулыңны.

Дошман киртәләрен узып, алга
Атакага китте танклар,
Аннан китте батыр сугышчылар,
Анда, әнием, синең улың бар.

Үтә алмаслык хәтәр киртәләр дә
Солдат каршысында юк була;
Дошман кача, дошман чыдый алмый,
Шул чак безгә шатлык кушыла.

Өметләрең тиздән кабынырлар,
Җиңү таңы тиздән сызылыр,
Дан яңгырар бөтен туган илдә
Улың кайтыр, әнием, көтеп тор.

***Моннан соңгы язмалар төрле госпитальләрдә яткан вакытларга карый. Баштагы битләрдә яшьлек уйлануларына күп урын бирелгән. «Шигырьләр турында», «Бәхет турында уйлар», «Мәхәббәт турында» дигән аерым бүлекләр дәфтәрнең шактый өлешен алганнар. Шундый бүлекләрнең берсе «Йөрәк әрни» дип аталган.***

## Йөрәк әрни

«Бала—газиз ул, бала—күз нуры ул. Ул бәхет алып килүче, гаилә мәхәббәт саклаучы, ул тормыш таянычы» диләр сабый балалары туган кешеләр. Болар дөрес сүзләр. Менә мин дә тудым бу дөньяга, иркә булып, теләсәм нишләп үстем мин. Әтием-әнием мине укыттылар, кеше итәргә, киләчәкләре өчен таяныч булырга әзерләделәр... Тик кинәт сугыш килде, үзе белән кара болыт кебек кайгы, диңгез хәтле күз яше, ачлык, михнәт, тоткынлык алып килде... Мин дә армиягә киттем, шул

көннән башлап йөрәк киләчәктәге авырлыклар өчен чыныга башлады. Күп юллар уздым мин, бик күп яшь егетләрне, таза ирләрне үз кочагына суырып алган сугыш театрында катнашырга туры килде миңа. Барысын да күрдем. Күз алдымда кешеләр үлде, аяксыз-кулсыз калды. Үлемнең үзләреннән көчлерәк икәнен белсәләр дә, кешеләр аның белән аяусыз көрәшәләр... Сугыш театрында булган кешеләр тормышны икеләтә ныграк сөяләр, тормыш алар өчен тагы да матуррак булып күренә башлый. Әйе, солдат күңелендә мәхәббәт һәм нәфрәт бергә яши. Берничә минутлык йокы арасында ул үзенең сөйгән кызын төшендә күрә. Тик татлы минутлар тиз узалар, солдатны якында гына ярылган мина тавышы уята. Тирә-якта салкын булса да солдат төшенә ялганган мәхәббәт җылысында хәрәкәтсез генә утыра бирә... Менә шунда аларга командирлары һөҗүмгә күчү турында приказ бирә. Егет шулчак сөйгәненә гүя: «Кайгырма, иркәм, мин исән һәм исән булырмын»—дип һөҗүмгә кузгала. Берничә минут элек аның күңелен каплаган сагышлы мәхәббәт кырында нәфрәт хисе кабына... Бу хис дошманга нәфрәт хисе һәм егет автомат, гранат һәм нәфрәте белән коралланып сугышка юнәлә. Арслан кук сугыша ул, чөнки аның мәхәббәте дошманга булган нәфрәтен көчле итте, аны үчле итте. Шуңа ул сугышта бер зыян күрми җиңеп чыкты. Менә нинди ул сугыш романтикасы, яшәү белән үлем арасындагы хисләр көче...

Яшәү һәм үлем, караңгылык һәм яктылык, мәхәббәт һәм нәфрәт, кайгы һәм шатлык—менә алар мәңгелек каршылыклар. Кеше шулар арасында гына яши, кеше шулар аша гына чын тормышны таный... Кешеләр арасында яхшы күңелле, саф йөрәкле булганнары да, вакчыл, усал, мәкерле булганнары да бар. Мин үзем бер вакытта да кешеләргә авыр сүз әйтмәскә тырышып яшәдем, мин аларның бәхетсез булуларын теләми идем, кешеләргә ярдәм итүне, аларның күңелен күтәрүне, алардан рәхмәт сүзе ишетүне үземнең изге бурычым дип саный идем...


*И. Надиров сугышчан дусты белән. 1946 ел. Эстония.*

Үлмәү—кешенең бөек идеалы ул. Синең алдагы тормышың кара пәрдәгә төренгән булса да, син үлем турында уйламыйсың. Юк, яшәү искиткеч матур, диңгездәй тирән ул...

Мин менә Двинский шәһәрендә, таш коймалар белән уратып алынган крепость эчендәге госпитальда ятам. 19 ноябрьдә (1944) китерделәр безне бирегә. Бу крепость ничектер җимерелми калган һәм аның эчендә тагын әллә ничә госпиталь урнашкан. Мин менә хәзер тәрәзә кырындагы нарда ятам һәм язам. Берничә көн инде кузгалмыйча диярлек, саф һава да суларга чыкмыйча язам да, язам. Чөнки ЙӨРӘК ӘРНИ. Әле тормышны юньләп күрмәгән, ярлы семьяда үскән егетнең йөрәге әрни... Тиздән бу госпитальдән мине «выздоравливающийлар» командасына күчерәчәкләр. Анда озак тотмыйлар, запасной полкка, ә аннан передовойга. Йә Раббем, алда тагын ниләр булыр, бәлкем мине үлем көтә торгандыр. Юк, юк, мин тормышны бөтен тулылыгы белән сөям һәм үлемгә чирканып карыйм...

Мин тормышны сөям, чөнки тормыш
Минем өчен шундый сөйкемле.
Мин яшәргә телим, уй-моң белән
Үткәрсәм дә һәрбер көнемне.

Мин исәнлек, башка саулык сорыйм
Мине тудыручы Аллаһдан,
Бир ярдәмен, рәхмәтле бул миңа,
Сакла мине бәла-казадан...

*Икенче дәфтәрдән.*
*Госпиталь, 20-23 XII. 1944.*

Бу араларда Америка язучысы Эптон Синклернын «Джимми Хиггинс» дигән романын укып яттым. Роман мина бик ошады. Бу юлларны шуннан күчерәм: «... И так, целыми днями, зимой и летом, во всякую погоду люди учились убивать своих ближних, исполняя это механически, как обыкновенную фабричную работу... Таким образом, Джимми изо дня в день жил с мыслью о братоубийствах и видел перед собою суровый, жестокий лик войны... Война—это зло, война—это зло, раздавалось в его душе. Люди не должны прибегать к такому грубому способу для улажения своих споров... Да, войны есть величайшее зло! Но война в данное время происходит, и ее никак нельзя остановить. Так что же, чорт возьми, должен делать человек!..»

*Икенче дәфтәрдән.*

**7 гыйнвар 1945.** Двинский госпитале артта калды. Яралары төзәлгән бер төркем солдатларны (арада мин дә бар) кичә 6.01.45 запасной полкка озаттылар. Шаляй тирәсендәге Перевенчай разъездына китерделәр. Мондагы солдатның иге-чиге юк. Көнетөне обучение бара. Бу юлы мин пехотадан китеп артиллериягә языларга булдым. Якташым Фатхулов Яхъя белән шулай сөйләштек. Самоходный полктан килгән майор минем белән дә сөйләште, «мин сине заряжающий итеп алам» диде. Безне—сигез солдатны «Студебеккер»га төяп алып киттеләр. Мин бу сүзләрне буш калган литовец өендә язып утырам. Берничә көннән безне передовойга җибәрерләр дип сөйлиләр. Сугышта кичерәчәк авыр минутларны, кайгы-михнәтләрне кабат татырга туры киләчәк икән...

**5 февраль 1945.** Менә мин кабат госпитальдә. Литва җире, Грушлаутис дигән местечко. Госпиталь легкораненых. Номеры 3541. Монда килгәнче күргән хәлләр, дошманның каршылыгы бу юлы узганда булган сугыш вакытындагыдан икеләтә көчлерәк, канлырак булды. Безнең самоходка кырында ук шартлаган мина мине дә, наводчикны да яралады. Сул кулым бәйләнгән. Уңы белән яза алам. Мине кичә перевязочныйга берничә көнгә регистратор итеп куйдылар. Мин анда авыр яралы солдатларның әрнешеп, ыңгырашып операция өстәлендә ятуларын, аларның аяккулларын кискәндәге хәлләрен күреп тетрәнә идем. Кайгылы, кызганыч күренешләргә күнегергә туры килер, күрәсең... Мондагы климат әллә нинди. Февраль булса да кар эри башлады, сазлыклар, чокырлар, тар юллар, бер-берсеннән берәр чакрым торган хуторлар, вак этләр, ябык хатыннар, каты тәмәке тартучы ирләр...


**23 февраль 1945.** *(Боларны мин урысча язып куйганмын).* Вот уже почти 20 дней, как я попал в этот госпиталь. За это время через него прошли, наверное, тысячи фронтовиков, раненых, обмороженных. 20 февраля с раннего утра началась артподготовка, она длилась около двух часов. В тот день началась наступление наших войск, ведь был приказ к 23 февраля очистить Прибалтику от фашистов, и вот с того дня безперерывно к нам в госпиталь поступают раненные. Уже трое суток подряд без отдыха, без сна хирурги оперируют, отрезают где надо, перевязывают и отправлют в тыл сотни больных.

**22 март 1945.** Без «самоходчиклар» эзләп килгән бер капитанга язылдык. Обедтан соң 12 кеше отправкага әзер иде инде. Йөк машинасы белән киттек. Скоудас артта калды. Тар тактaлар түшәлгән ниндидер сазлыктан барабыз. Саперларга, ай-һай, кыен булгандыр. Сазлык өстенә ун километрлап юл сузу уен эш түгел бит. Менә Громздас дигән местечко, бирәдән бер чакрымда без билгеләнгән часть тора. Килдек шунда. Жылы гына кабул иттеләр. Мине боепитание взводына билгеләделәр. Начальник артснабжения ст. тех. лейтенант Яков Дунец 1923 елгы Москва егете икән, ул инде үлем кырларында булган, сугышның тизрәк бетүен көтә. Безнекеләр бүген Кенисбергны алганнар дигән хәбәр бар. Яхшы хәбәр бу.

**8 май 1945.** Нәкъ бер ел дигәндә туган илдән хат алдым. Минем нинди хәлдә калганымны кем генә аңлый алыр икән? Калтыранган кулларым белән туган энем Әмир язган кечкенә, борчылып беткән хатны ашыгып ачтым. Нинди шатлык! Әти-әнием дә, энеләрем дә барысы да исәннәр, бер көйгә тыныч кына яшәп яталар. Алар миннән бик күп хатлар алганнар, һәрбер хатыма җавап та язып барганнар, ә мин аларның соңгы хатын узган ел май башында алган идем. Күпмедер вакыттан безне фронтка озаттылар, шуннан башлап минем тормышта күчenүләр, сугышлар, госпитальләр, тагын әлләниләр алмашынып торды. Мине аларның хатлары ничек эзләп тапсын инде! Үткән бер ел эчендә мин тормыш мәктәбенең күп кенә фәннәреннән сынау биреп, яшәүнең төрле якларын аңладым шикелле. Русча сөйләшүем көннән-көн шомарды, язуым да дөресләнә барды, хәзер мин рус солдатлары белән бәхәсләшә алырлык хәлгә килдем... Бу хатта туган якның йомшак җилләре, кечкенә энеләремнең шаян авазлары, әниемнең авыр

сулап утырган сагышлы минутлары, авылым халкының кайгылы кичерешләре—барысы да җанланган шикелле булды. Әйе, тиздән сугыш туктар дип өметләнәбез. Тик менә безнең бу тирәдә әле башланмаган хәлиткеч сугышлар булачак дип сөйлиләр. Язмыш миңа тагын ниләр әзерләгән икән?

... Радиотелеграфист дустым Анатолий Шикунов белән без гел бергә. Ул 1923 елгы, бик белемле. Мин аңа сокланам. Ул бөтен фәннәр буенча да әллә ниләр белә. Мине еш кына тәнкыйтьли. Шаяртыбрак сөйли үзе. Кичә әйтә: «Иптәш Надиров, синдә мактану чаткылары күренгәли, син белгәнем җитәр дип туктарга уйлыйсың кебек. Бу—эгоизм. Син әлегә вак дилетант кына. Төпле белем алыр өчен университет бетерергә кирәк...» ди. Дөрестән дә шулай бит. Без аның белән төннәрен приемниктан музыка тыңлыйбыз, китаплар укыйбыз, бәхәсләшәбез...




*Галимнең сугыш елларындагы куен дәфтәреннән. 1945 ел.*

**10 май 1945.** 8 май төнендә мине радиотелефон бүлмәсендә дежурить итәргә куштылар. Мин аны-моны уйламыйча шунда утырам. Бервакыт кайсыдыр сәгатьтә Мәскәүдән сугышның басылу турындагы хәбәрне тапшырдылар. Бу сүзләрне беренче булып үз колагым белән ишетүгә мин, әлбәттә, чиксез куандым, шул минутта ук бу изге хәбәрне барысына да җиткерергә тырыштым... Менә тиздән тын, караңгы урман эченнән, куе болытлар белән капланган күк йөзенә фронтның шатлык йолдызы—җиңүгә охшаган кызыл ракета атылды. Ә аннан соң бөтен урман шау-шу, гөрелдәү астында калды, пулеметлар, автоматлар, зениткалар такылдавы, ракеталарның гаҗәеп матур яктылыгы тирә-якка әллә нинди серле төс бирде. Шулай узды ул төн... Сугыш бетү хәбәрен берәү дә тыныч кан белән тыңламагандыр, бигрәк тә солдатлар. Алар бу сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәрделәр, үз җаннары аша үткәрделәр. Менә шуңа күрә аларның шатлыгы берни белән дә чагыштырмаслык иде. Күпләр еладылар бу хәбәрне ишеткәч, кочаклаштылар, котлаштылар. Ә иртәгәсен урманга сибелгән бөтен гаскәрләр тантаналы митингка җыелды, кабат бер кат салют бирелде. Аннан барыбызны да ял итәргә тараттылар. Ул көнне безгә американский фильм китергәннәр иде. Исеме «Северная звезда». Бу исем Украинадагы бер колхоз исеме булып чыкты. Шул авылны фашистлар басып алгач, анда булган хәлләр турында сүз бара. Сугыш туктаган көнне бу сугыш башланган беренче көннәрне кинодан карап утыруы кызык тоелды. Әйе, хәзер күп еллар буена бу сугыш турында кинолар эшләнер, романнар, пьесалар, шигырьләр языла әле. Ә төнгә табан Сталинның җиңү уңае белән халыкка мөрәҗәгате һәм приказы укылгач, кабат кичәгедән дә көчлерәк булып салют яңгырады. Бу юлы салютка авыр туплар, «Катюша»лар, минометлардан аткан тавышлар да кушылды. Ә ракеталарның яктылыган карый-карый күзләр талып бетте. Шулай матур булып, шау-гөр килеп үтте җиңү бәйрәме...

**20 июнь 1945.** Менә бүген мин хезмәт итә торган 1489 нчы самоходно-артиллерийский Митаский полк үзенең бер еллык бәйрәмен уздырды. Көн кояшлы иде. Солдатларга бәйрәм хөрмәтенә 100 грамм аракы бирделәр. Күңел ачылып китте. Тантаналы митингтан соң полкның ал байрагы янында офицерларга, солдатларга орденнар, медальләр тапшырдылар. Мин дә «За отвагу» («Батырлык өчен») медале белән бүләкләндем. Ни дисәң дә, сугышларда катнашып ике мәртәбә яраланган солдат бит. Тагын шундый хәбәр дә йөри. Безнең бу полкны икегә аерып ике самоходный дивизион оештыралар икән. Ни булса да исән-сау булып, тизрәк илгә кайтасы иде...

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## «УТЫРЫП УЙЛАР УЙЛАДЫМ»

Көндәлек дигән жанр (әгәр аны аерым бер жанр ук дип әйтергә яраса) кызыклы һәм авторның рухи дөньясын шактый ачык чагылдыра. Ул кешенең үз-үзе белән сөйләшүе, бәхәсләшүе, эчке диалогы, дөньяга карашы, һәм дә ки, жыйган тәжрибәсе. Юкка гына түгелдер, Туфан Миңнуллин да, әлеге «көндәлекләр»ендә* үзе генә уйлаган уйларын, хис-кичерешләрен язасы иткән. Күрәсең, үтелгән еллар, гомер баскычлары ана байтак гыйбрәтләр, уртаклашыр хәлләр, күңел тулы бәхәсле хисләр биргәндер.

«Кыска хикәя» дигән атама бар әдәбият теориясендә. Хикәя никадәр кыска булса, аның фикер үткенлеге дә шуңа нисбәтән дияр идем. Әгәр бу кече жанрга ярыш оештырсаң, мөгаен, Т. Миңнуллинның көндәлегендәге һәр язма алдынгы урынны алыр иде. Халык әйтмешли, дөрестән дә: «үзе кечкенә, эче төш кенә». Бередәге акыл үткенлеге, фикер тирәнлеге күңелгә хуш килә һәм син аны аерыла алмый укыйсың да, укыйсың. Юкса, автор прозаик та түгел, драматург бит! Ә бәлки драма әсәре проза белән поэзия арасында торгангадыр, осталыкның бер ябе шулдыр?

Нигездә, әдипнең уйланулары кеше турында. Ә кеше турында язу, ул, яхшылык белән явызлык, бәхет һәм бәхетсезлек, чын вә ялган, яктылык һәм караңгылык, куаныч һәм сагышлар, тагын әллә никадәр бер-берсенә капма-каршы төшенчәләрне үз эченә ала. Чөнки адәм балаларындагы сыйфатлар шуңа нигезләнә ич! Кеше холкын гына алып, бераз уена салып карасаң, ул бит тумыштан килә торган сыйфат икән ләбаса: «Холык», «Холык һәм онык», «Кайда ул дөреслек», «Татарлар һәм дуңгызлар», тагын башка истәлекләр моңар ачык дәлил. Димәк, кешенең холкы үзе белән бергә туа, бергә гомер кичерә, бергә фани дөньядан китә. Шуңлыктан, һәр адәми затны өйрәнеп, аның холкын, фигылен белеп кенә жайлы һәм жайсыз мөнәсәбәтләрне ачыкларга мөмкин.

Авторның истәлекләре «Әти» белән «Әни» бүлекләреннән башланып китә. Әтисе бик намуслы, тирән хисле, үз эченә бикләнгән, авыр тормышка, чынбарлыкка бигүк сыешмаган кеше булган, ахрысы. Мондый затларны мәшәкатьле хәят кабул итеп бетерми, аны башкалар алдында бер кадәр «сәер» итеп күрсәтә.

Әни булганы исә, бераз башкачарак—гайяр авыл хатыны. «Әниләр бары тиеш кенә»,—дип яза автор. Дөрес сүзгә җавап юк, бу—тормыш кануны. Шулай да, анага булган олуг мәхәббәт автор язган бөтен уйлар эченнән агылып килә. Чөнки ул күпләрнең йөрәк кылларын тибрәтмичә, үткәннәрне искә төшермичә калмый.

Язучының истәлекләре язылу вакыты белән түгел, бәлки вакыйгалар хронологиясе буенча бара. Ул—балачак, үсмер чакның кайбер мизгелләре, Мәскәүдәге студент еллары... Аеруча истәлеклесе—пәһлеван Алексей Николаевич. Ул—ихлас ярдәмчел, олы җанлы, акыл иясе, саф рус токымыннан килә торган, рухи гарипләнмәгән җан.

Әдипнең йөрәге сак, кешеләрне үзенчә кабул итә, үз бәясен чыгара. «Мәргән» дигән кыска гына истәлектә Ватан сугышында снайпер булган 19 яшьлек кызның

---

* Туфан МИҢНУЛЛИН. **Утырып уйлар уйладым**. Татарстан китап нәшрияты. 1997.

(хәзер инде өлкән ханым) унбер немецны үтереп, жиңүгә өлеш кертүен, исән калып, бәхетле булуын укыйсын. Шулай да, кеше үтереп, «кешенең жаны имгәнә», дип дәвам итә әдип. Әйе, фронтовикларның күкрәгендә балкыган күпсанлы орден-медальләргә үз ихтыярыңнан тыш сагаюлы караш ташлыйсың. Башкача аны кабул итеп булмый, ахрысы: «сугышның төп сере—үзең үлмичә, дошманны үтерү», бу да яшәү кануны бит!

Язучының беррәт язмалары туган телгә, милли мәсьәләгә мөнәсәбәт турында уйланырлык, чигенмәс хаклык булып, төп юнәлешне алып тора. Мәгълүм булганча, тел—милләтнең көзгесе, рухына бәйле әхлагы; чит телдә сөйләшкәндә, синең сүзләрең яныңнан шуышып баралар шикелле. Үз ана телен белмәгән кешенең, минемчә, шәфкате дә чамалы, чөнки аның жаны китек була. «Туган тел нигә кирәк?» кыйссасы укучыны әнә шундый уйларга этәрә. «Татарлар турында ике кыйсса» да исә авыр гыйбрәтле хәлгә тарыйсың. Биредә инде милли мәсьәләнең кайбер караңгы яклары ачылып китә. Калмык шагыйре Давыт Көгелтиновның үз балалары үзеннән читләшүен (аның хатыны маржа) борчылып сөйләве көендерә. Малае дәреслектә язылган «поганий татарин» сүзләре нәтиҗәсендә әтисеннән бизсә, кечкенә кызчыгы, «татарка» дип мыскыллаучыларга күрсәтү өчен, кулына тәре учлап йөри икән.

Милли мәсьәләнең тамырлары тарихта. Рус тарихын дөрес язмыйча, державачылык ысулы белән ясалган дәреслекләр, хаталы фәнни гариплек Рәсәй кебек күпмилләтле дәүләтнең бары тик таркалуына, җимерелүенә генә китерергә мөмкин. Бу күренеш тарихтан ук янап килә торган олуг сәбәпләрнең берсе. «Татар кулы белән үз дошманнарын юк итү Ленинның иң мәкерле уе булган,—дип дәвам итә автор.—Бик акыллы кеше булган Ленинныбыз. Татар сугышчылары басмачыларга каршы һөҗүмгә барганда: «Аллаһ әкбәр! Аллаһ әкбәр!»—дип барганнар икән. Бу изге сүзләрне ишетеп каушап калган мөселман үзбәкләрне кырганнар гына безнекеләр! Бу имансызлыкны без таныырга һәм ялгышкан, алданган бабаларыбыз өчен үзбәк халкыннан гафу үтенергә тиешбез». Автор әле Кавказдагы сугыш чорын да бик урынлы искә ала. Шуңа өстәп Ватан сугышы чорында (1944 елның мае) Кырым татарларын туган илләреннән аерып, Себер, Казакъстан якларына куунның татар дивизиясен кертеп эшләнгән эш икәнен искә алсак, аз санлы милләтләргә каршы алып барылган мәкерле сәясәткә, тарих буйлап килә торган фаҗигале рәхимсезлеккә тәмам аптырап калырлык!

Тормышта һәркем диярлек милли каршылыкларга сөртенеп яши. Шунадыр ахрысы, әдипнең язмаларында да милли низагларны еш очратырга туры килә. Мәскәү гидларының нәфрәтләнеп, монгол татар явы турында ярсып сөйләүләре әнә шул державачылыкның кара ялганы булып күңелгә суга («Константиновкага сәяхәт һәм Сәмәркандта экскурсия»). Бу инде бөтен мәктәп дәреслекләрендә яшь буынның җанын тетрәтә торган гасыр тилчәсенә әверелде. Әмма шунысы хак: татарның бирешмичә килә алган милли аңы бар! Ни генә булмасын, торып-торып чын татарның уяна, үз хокукын яулап баруы сизелә түгелме?

Олуг әдипнең язмасын, мөгаен, гади укучы куанып, кызыксынып укыр. Чөнки Т. Миннуллин үзе татар җанлы, горур һәм баш имәс шәхес булып, рус язучылары арасында милләтен күрсәтә белә. «Кая гына барсаң да», «Безнеке түгел» кебек язмаларын аласыңмы, һәммәсендә горур сыйфатлары белән татар кешесе таудай калкып тора.

Русияне хәерчелектән чыгару өчен нишләргә кирәк? («Идея») Бу сорауга кем генә уйламый да, кем генә җавап эзләп баш ватмый икән? Югыйсә, табигать без яшәгән, урыс басып алган территорияләрне казылма байлыгы ягыннан да, үсемлек вә җәнлекләр төркеме ягыннан да кыерсытмаган икән ләбаса. Әмма «Сәбәп шунда—русиядә ил белән идарә итәрлек акыл юк».

Бу фикер белән килешмичә булмый. Еракка китәсе түгел, «Кешеләр кешене яратмый?» истәлегендә яхшылык белән явызлык фәлсәфәсе милли фаҗига булып килеп керә. «Нигә урысны бөтен җирдән, милли республикалардан куалар?»—дигән сорауга көндәлекләрдәге хакыйкый җавап, хак дәлилләр җитеп арткан. «Штык өстендә генә утырырга көйләнгән урысның әхлаксызлыгы, котсыз тупаслыгы һәм наданлыгы» (тарихчы галим Н. Фирсов сүзләре) аны үз хәлен аңларлык дәреслектән мәхрүм иткән, күрәсең. Кайчакны гаделсезлек үзе гаделсез кешене хаким итә. Моны тарих юлы гел күрсәтеп килә шикелле. Әгәр «старший брат» шуннан гыйбрәт алмаса, аның харап булуы ихтимал. Әмма урыс туганның замана хөкеменә дучар булып, нәселен, балаларын адәм рәтле итәр өчен чынлыкка килеп егылганнары да, ягъни уяна башлаганнары да бар икән. Воронеж ягына дулап кайтып киткән бер

урыс гаиләсе (ул элек Үзбәкстанда яшәгән булган) тагын үзбәккә кире кайтып, үзбәк телен өйрәнергә, шунда төпләнеп яшәргә керешкән. Чөнки кайчандыр туган иле булган Воронеж ягында бер генә аек кешене дә очрата алмаган, бу бахыр. («Кысалармы?»). Соң булса да, ун булсын, ди акыллы халык, бирсен ходай... Мондый күренешне хупламыйча мөмкин түгел, минемчә.

Ничек кин уйлансан да, милләтара гаделсезлеккә, милли мәсьәләнен Рәсәй шартларында хәл ителмәс караңгы күгенә барып төртеләсен. Чыннан да, ни өчен милли мәсьәлә җанга тиеп, кешенең бөтен хәятен чолгап ала соң? Кайчагында ул чынлыкнын, чиксез галәмнен үзе кебек тә тоела. Аның нигезендә ирешә алмаслык гаделлек вә иза чигеп, көрәшеп алалмаслык азатлык ятканга күрәдер, тәгаен. Менә монысы инде безнен чын тарих, татарнын бүгенгесе. Авторнын сүз сөреше бик саллы, «без татарлар әле Рәсәйнең бозаулары»,—ди ул. Әйе, мона кем гаепле? Аның җавабын үзебездән дә эзләргә кирәктер. Ул—милләтнен таркаулыгы, сатлыкларнын артуы, куштанлыкнын үсүе—ачык вә чигенмәс хаклык булып бергә укмашып бара. «Көтүчеләр һәм бозаулар»—милли мәсьәләгә бик гади, ачык җавап булып төшә торган мәгълүм язма. Үзенен мөстәкыйльлегенә ирешү өчен сугышкан чечен халкын автор дөрес исбатлама итеп карый. Ә бит Чечня үз җире өчен, гасырлар буе яшәгән Ватанын яклап кан коя. Әле хәзергә кадәр (1955 елдан алып) суверенитет алып, халыкара мөстәкыйль илләргә кушыла алганы юк анын («Көтүчеләр һәм бозаулар»). Көтүче булып чыбыркы тоткан Рәсәйнең башка милләтләрне ничек «бозау» итмәкче икәне бик ачык күренеп тора ич!

Милли мәсьәләгә авторнын латыш драматургы Пауль Путникыш белән диалогына тукталып («Чибәрлек») нокта куясым килә. Әлеге латыш бер ямьсез кешегә күрсәтеп (Мәскәүдә семинар вакытында була бу хәл) «Коллар беркайчан да чибәр булмыйлар. Аларнын мескенлеге, изелгәнлеге йөзләренә чыга»,—ди. «Мин үзебезнең кешеләргә карыйм да, дип дәвам итә Туфан Миннуллин,—һәрвакыт сөенеп куям. Без чибәр, димәк әле без кол дәрәҗәсенә үк төшмәгән. Әлегә буйсынырга мәҗбүр булсак та, җаныбызда ирекә омтылу уты сүнмәгән... Сүнә генә күрмәсен иде, Ходаем...». Амин, шуны телик барыбыз да!

«Көндәлекләр»дә иҗат эшенен характеры, авторнын уй-хис дөньясы да ачылып китә. Хосусан, аерым әсәрләренең язылу тарихы, минемчә, шул турыда искәртә сыман. Т. Миннуллиннын Тукай тормышына кагылышлы әсәре («Без китәбез, сез каласыз» драмасы) «Байлар, байлар бал эчә» исталегән дә хуплауга лаек димичә булмый. Чөнки ул әсәр шагыйрьнен тормышы күгендәге ачылмаган бер якны күрсәтә, шунын өстәвенә байларга мөнәсәбәт, үзәк геройнын (Тукайнын) реаль бирелешен раслый. Әгәр Тукай дустанә серләшеп үзенен байларына исә-бөгелә рәхмәт әйтсә, бу дөреслеккә хилафлык булыр, мәрхүм шагыйрь рухын рәнҗетү булыр иде. Әйе, хәзерге сәясәтчеләр, тарихчы галимнәр, шул исәптән кайбер язучылар да, татар байларын барлап, аларнын эшчәнлеге, кешелеге турында күпләгән хезмәтләр язарга керештеләр. Бу, әлбәттә, кирәкле эш. Әмма мәсьәлә бер яклы гына яктыртылмаска (бигрәк тә аерым шәхес турында сүз барса), гаделрәк кыйбланы алырга тиеш иде. Нигә соң Тукайны Питердан көчкә билет табып озатып җибәрәләр? Әллә анда татар байлары, хәлле зыялылар аз булганмы? Җитмәсә, олуг талант булу белән бергә, мөхтәрәм шагыйрьнен авырган чагы да ич! Шулай, кайсы заманда да байлар катламы өстенлек символы булып килә...

Тагын автор үзенен өч пьесасы турында язасы иткән. Анын берсе—«Диләфрүзгә дүрт кияү»—әлләни катлаулы әсәр түгел. Хәтта дүрт кияүнең берсе автор үзе икән. Җинелчә, матур, яшьлекнен үзе кебек якты, комик әсәр ул.

«Бозау» һәм «Гаеп» кебек язмалар ихлас елмайтып, авторнын тапкырлыгын, күзәтүчән күнеленен зирәклеген тоярга ярдәм итәләр. Язучынын икенче пьесасы—«Әниләр һәм бәбиләр»—хатын-кыз турында, анын тормыш даирәсе турында күптөрле сорауларга, байтак уйлануларга дучар итә. Бу проблема һәр заманны дулкынландырган, җанга тигән проблема булып кала ахрысы. Аның белән Такташ заманы да шаулаган, әмма һәр заман өчен хатын-кызнын абруе, ул гына башкара алган табигый гаделлеге, җәмгыятьнен әхлагын төзегән җитди куәте һаман да мөһим булып кала бирә. Биредә әдипнен фикерләре белән килешмичә булмый сыман: «Хатын-кыз—гаилә үзәге, ул үзе закон, парламентларда ялкынлы чыгышлар ясап түгел, спорт мәйданнарында хоккей уйнап түгел, ат урынына эшләп түгел, өйдә балаларын кочагына җыеп, башыннан сыйпап, аркасыннан сөеп, һәр баланың язмышы өчен көрәшкән хатын-кыз гына киләчәккә мәрхәмәтле кеше тәрбияли ала» («Хатын-кыз үзе закон ул»).

Әдипнең «Әлдермештән Әлмәндәр» язмасы да укучыны битараф калдырмый. Чөнки милләтнең тереге, иманы вә моң тулы 91 яшьлек татар карты үзенчә яшәп, үзенең карашлары вә сабыр холкы белән безгә якын. Әҗәл белән алышта сыналып, Илаһиятнең, Табигатьнең котылгысыз канунын кабул итә икән, шунда гына ул тамашачыга тәэсирле. Әлмәндәр, шуңа күрә, язучыга асыл таш куя, үлемсезлекнең эчтәлеген анларга ярдәм итеп, ничек яшәргә дигән сораугa бер мисал булып тора. Драматург беррәттән «Тамашачыбыз»ны да читтә калдырмый.

Иҗади эш унаеннан авторның язучы һәм җәмгыять арасындагы конфликтлы һәм күнелгә суга торган хаксыз хәлләрне дә яшереп тормавын кызыксынып укыйсың. Мондый хәлләрнең берсе «Сибгат абый» истәлегендә чагылыш таба. «Бервакыт иҗат интеллигенциясе белән очрашуында обком секретаре Табеев, язучыларны «Сез—иждевенецлар» дип мыскыл итте,—дип яза автор бу турыда. Анда С. Хәким, Н. Җиһановлар бар иде. Алар трибунага чыгып берни әйтмәделәр... С. Хәким күнеле белән саф кеше иде. Әмма шул сафлыгын трибунадан торып якларга егетлеге җитмәде». Гаҗәп түгел, әле бу вакытта яшь каләм иясе Т. Миңнуллинның җанга тигән гаделсезлекне кабул итә алмавы бик инандыра. Ләкин талантларны кырыс заманның үзенә буйсындыруын да истән чыгарырга кирәкмәс, минемчә.

Демократия еллары да безгә (язмада 1986-1990 еллар күздә тотыла) хаксызлыкны, казна караклыгын, җинаятьчелекне, әхлакый тотрыксызлык белән хәерчелекне генә алып килде бит. Боларны бары тик язмыш кына итеп карап булмыйдыр. «Авыл кызы» (язылуы 1990 ел) тетрәндерерлек яра калдыра торган истәлек. Шәһәрдә фахишә булып, сифилитик бәндәгә әверелүе—әллә җинаять, әллә хаталык, әллә язмышнын төзәлмәс фаҗигасе. Бүгенге көндә бу хәлләрнең ишәеп китүен таркалган һәм хәшәрәт җәмгыятьнең аерым шәхескә, кешегә карата рәхимсез һөҗүме дип кенә кабул итәсең. Тормыш, әхлак турында сүз бара икән, ул инде җәмгыятьнең мөһим катламы. Нинди җәмгыятен, шундый әхлагын, ди халык. Авторның бу турыда уйланулары («Колхоз председателе») авылның ярты гасырлык социаль-икъдисади вә иҗтимагый җирлеген ачып сала. Сугыш чоры председательләре, аннан соңгылары, һәм ниһаять, бүгенләре искә алына. Колхоз дигәне таралып, Рәсәй тоташтан фермер хуҗалыкларына күчсә (бу мәсьәләдә президент Ельцинның гайрәтле итеп, колхозларны таратуга бер җилкенүе булып алган иде. Әле ярый, республика һәм өлкәләрдәге акыллар аны күтәреп алмадылар), болай да экономик егылган ил бөтенләй күтәрәмгә каласы иде.

«Стриптиз», «Диссидент» янә дә башка истәлекләрне аласыңмы—һәммәсендә сәясәткә һәм тарихтан агылып килә торган яшәешкә кагылмаган язма юк диярлек. Автор зур булмаган бер вакыйганы ала да, укучыны уйлар кочагына ташлый. Бу исә, без кичергән җуелмас яра булып, җан әрнүен уятып җибәрә.

Тагын бер кызыклы мәсьәләгә кагылмыйча фикеремне тәмамлый алмыйм. Ул—төш, һәркемне уйлата торган газиз күренеш—авторның истәлекләрендә аерым урынны алып тора, дияр идем. («Төш», «Бер мин генә түгел»... һ. б.) Уйлана китсәң, төш дин белән дә, фән белән дә бик бәйләнештә түгел, ахрысы. Югыйсә, инде гасырлар буена аңа төгәл генә эчтәлекле аныклама бирелгән булыр иде. Әмма, чигенеш ясап шуны әйтим, үзе бик серле чишелешле булып, синең юравыңны көтеп тормыйча, алдыңа килә дә баса. Т. Миңнуллин да төшендә «Хушыгыз!» драмасының баш герое—Миләүшәнең ап-ак киемнән булырга тиешлеген («Көндәлекләр») күргән. Чөнки ул беренче тапкыр сәхнәгә ак күлмәк киеп чыккан икән. Күрәсең, героиняның гомере белән саубуллашу алдыннан да, аның рәнҗешле җаны, шундый табигый чишелеш белән китәргә тиеш булып чыга.

Туфан Миңнуллинның көндәлек язмалары мине уйлар кочагына, тирән хис-кичерешләргә этәрде. Тол хатыннар да, юлдан язган авыл кызлары да, бала психологиясендәге авыр газаплар да, ниһаять исерекнең әрнегән йөрәге дә, үзенең урыс агаеннан алдануы да, милләтне мыскыллаган урыска манкорт булып киткән татар мәхлуклары да—әдипнең күңел ярасы, борчулы уйлануларының җуелмас эзләре булып калалар. Мөгаен, кеше өчен янып-көеп яшәгән каләм иясенең үз милләтенә, туган халкына тугры булуы шулдыр!

**Миләүшә ХАҖИЕВА,**
*Казан Дәүләт Педагогия университеты аспиранты.*

*Әдәбият тарихына*

# ТУКАЙ ҺӘМ ВӘЛИДИ

Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү һәм бәяләүнең бер гасырлык бай, үзенчәлекле, вакыты белән хәтта каршылыклы тарихы бар. Шагыйрьнең лирикасы милли әдәбиятыбызның, әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйтьнең үсеш юлын һәм дәрәҗәсен билгеләүче ориентир, бизмән дә булып торды. Совет чорында исә әдәбият фәне, кайбер идеологик-сәяси кысаларга, чикләүләргә карамастан, Тукай турындагы фәнне тудырды. Һәм, әйтергә кирәк, бу фән җитди генә уңышларга да иреште. Ә бит аның юлбашында шагыйрьнең замандашлары булды! Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Т. Галиуллин Тукай иҗатының XX гасыр татар поэзиясенә йогынтысын тулыландыру һәм фәннилеген тирәнәйтү максатыннан «шагыйрь иҗатына замандашлары биргән бәягә» игътибар итү кирәклеген әйтеп чыккан иде. *(«Тукай һәм XX гасыр татар мәдәнияте»—Казан, 1997).*

XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә Г. Тукай шигъриятенең, тормыш сукмакларының төрле якларын яктырткан авторлар аз булмады. Шагыйрь бу яктан бик тә бәхетле. Шулай да, алар арасында Җамал Вәлиди мәртәбәле урын алып тора. Бездә аның тәнкыйди эшчәнлеген өйрәнүне башлап җибәргән тәнкыйтьче һәм язучы Р.Мөхәммәдиев Җ. Вәлидине бик хаклы рәвештә «тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләребездән «беренче тукайчы» дип атый *(«Әгәр без янмасак...»—Казан, 1980).*

Мәгълүм булганча, Җ. Вәлиди әдәби тәнкыйтькә унынчы елларда килә. «Вакыт» газетасында, «Шура» (Оренбург), «Аң» (Казан) журналларында басылган беренче мәкаләләре белән үк ул үзен әдәбият-сәнгать әсәрләрен тирән аңлаган, аларга төпле бәя бирергә сәләтле тәнкыйтьче итеп таныта. Шул чорның күренекле язучылары иҗатына һәм әдәби хәрәкәтнең гомуми торышына багышланган мәкаләләрендә, «Татар әдәбиятының барышы» (Оренбург, 1912), «Милләт вә миллият» (Оренбург, 1914) исемле монографик хезмәтләрендә ул, конкрет әсәрләре һәм язучылар иҗатын анализлаудан тыш, әдәбият-сәнгатьнең специфик хасияте, иҗтимагый тормыш һәм тарихи чынбарлык белән бәйләнеше, иҗтимагый-фикри хәрәкәттәге роле кебек әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә. Җ. Вәлидинең башка хезмәтләре дә күп. Ә 1923 елда Петроград дәүләт нәшриятында басылган «Очерк истории образованности и литературы татар» дигән русча хезмәте В. И. Ленинның шәхси китапханәсендә саклана.

Тәнкыйтьченең беренче мәкаләләре үк Г. Тукай иҗатына багышланганнар. Бу мәкаләләрдә Г. Тукай шигъриятенең төп сыйфатлары, аны чорларга бүлү мәсьәләсе, әдәби әсәрләренең теле һәм өслүбе, шагыйрь иҗатының татар әдәбиятында тоткан урыны, вакытсыз үлеменә мөнәсәбәт кебек мәсьәләләр күтәрелә. Монысы—берьяктан. Икенчедән шагыйрь поэзиясенә нисбәтле милли әдәбиятның үсеш-үзгәреш закончалыклары, ориентациясе, әдәби мираска мөнәсәбәт, әдәбиятның милли характеры һәм халыкчанлыгы кебек татар әдәбиятыдай олы, бай тарихлы әдәбиятның яшәеше белән бәйле зур, хәлиткеч проблемалар да карала.

Җ. Вәлидинең Г. Тукай иҗатын тирәнтен аңлап, дөрес һәм объектив бәяләвенең сере, күрәсең, аны бәяләү критерийларында. Унынчы елларда бүген исемнәрен зур горурлану, хөрмәт белән искә алган Г. Ибраһимов, Р. Фәхретдинов, М. Бигиев, Н.Думави кебек әдипләрнең дә шагыйрь иҗатына мөнәсәбәте шактый катлаулы, каршылыклы булды. Ә Вәлиди, тәнкыйтькә яңа гына килүгә карамастан, шушы могътәбәр шәхесләр арасында Тукайны яклап чыкты, аларның бәяләрен дәлилле итеп кире кага алды. Тәнкыйтьче шагыйрь иҗатын үзебезнең милли җирлектә, татар чынбарлыгы, татар әдәбиятының үсеш закончалыклары, милли үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә карауны һәм бәяләүне һәрвакыт үзенең эшчәнлегендә төп бизмән, үлчәү итеп алды һәм аны эзлекле рәвештә тормышка ашырды: «Тукайның татар шагыйре икәнлеген, үзебезнең дә татарның зур кешеләреннән булып йөрүебезне онытабыз. Һичбер кеше, үзенең халкының тарихыннан узып, әллә кая китә алмый; моның хикмәте нәрсәдәдер, ләкин бу факт. Менә шуның өчен дә Тукайны үлчәгәндә, Лондон белән, Нью-Йорк

белән түгел, бәлки үзебезнең Казаныбыз белән үлчәргә туры килә» *(«Тукай турында замандашлары»—Казан, 1960).*

Билгеле булганча, Г. Тукай иҗатының төп сыйфатлары—халыкчанлык һәм миллилек. Җ. Вәлиди шагыйрь поэзиясенең һәр ягын, һәр үзенчәлеген шушы принциплар яктылыгында бәяли. Алар—тәнкыйтьче язмаларында әйдәп баручы мотивлар. Дөрес, ул аерым бер мәкаләләрендә Тукайда «бер система, бер мәсләк юк иде» дигән фикер уздыра. Күрәсең, автор биредә әдип яки философның гомер буе бары тик бер юнәлештә эш итүен, бер төрле теоретик караш тәэсире астында булуын күздә тота. Тукай бит—күпкырлы талант, иҗат, хезмәт кешесе. Шулай да аның тарафыннан шагыйрь әсәрләренең үзәгендә торган төп идея бер урында «әхлакый, иҗтимагый түбәнлекләргә, хаксызлыкларга каршылык», ә икенче урында «аның һәрвакыт мәзлүм (изелгән) халык кайгысын чигүе, андагы хәб инсаният (гуманность)» дип күрсәтелә. Шушы үзәк идеягә бәйле рәвештә Җ. Вәлиди милләтче, инсаниятче, халыкчы Г. Тукай турында уйлана. Мәсәлән, Г. Тукай иҗатында халыкчылык идеяләренең тамырлары хакында болай ди: «Безнең язучыларның күбесе халык эчендә һәм мәдрәсәдә житешкәннәр. Шуның өчен алар йә хәсән (бик гүзәл) вә йә фикран (уй-фикер) буенча азмы-күпме халыкчы. Матбугатымызга, әдәбиятымызга бу тупаслык, бу простойлык халыкчылык илә бергә гайре ихтыяри сурәттә килеп керә» («Вакыт» газетасы, 1913 ел, 25-26 июль). Димәк, автор халыкчылыкны әдипнең яшәү-көнкүреш шартлары, гомуми мәктәп-мәдрәсәләрдә, гади халык арасында яшәве һәм белем алуы белән дә бәйләп карый. Шушы сыйфатка бәйле рәвештә Җ. Вәлиди унынчы еллар эстетик фикерендә бәхәс уяткан «сәнгать—сәнгать өченме» дигән сораугa килеп чыга. Аңа катгый рәвештә тискәре мөнәсәбәт белдермәсә дә, Тукай иҗатына таянып, сәнгатьнең халыкка хезмәт итәргә тиешлеген ассызыклый: «Тукаев шигырьне Аполлон вә аның жирдәге табынучылары өчен сөйләми иде. Ул халык илә бергә, халык өчен, халык йөрәгеннән сөйли иде» (шунда ук, 20 июль). Аның фикеренчә, Тукай «татар милләте кебек төрле вә яшәү өчен тыпырчынып ята торган вә үзенең талантларыннан «хис»тән бигрәк хезмәт көтә торган халыкка» фидакарь хезмәт итүнең югары үрнәген күрсәтте.

Тукайчы галим, беренчеләрдән, шагыйрьнең фәнни тәрҗемәи хәлен булдыруга омтылыш ясый. Иҗат юлында үсеш баскычларын аерып чыгарып, чорларга бүленешне тәкъдим итә. Шагыйрь вафат булып, өч көн үткәч дөнья күргән «Габдулла Тукаев» дигән тәнкыйди язмасында Җаек һәм Казан чорларын күрсәтә. Ә инде Г. Тукайның мәҗмугаи әсәренә нисбәтле дөнья күргән сүз башында шагыйрьнең иҗатын өч дәвергә бүлеп карый: 1905—1907; 1907—1910; 1910—1913. Җ. Вәлиди тарафыннан язылган «Тукайның тәрҗемәи хәле һәм шигырьләре хакында бер мөляхазә» (1913) дип аталган язманы Г. Тукайның тормыш сукмакларын һәм шигърияттен өйрәнүдәге беренче күләмле фәнни хезмәт дип атарга тулы нигез бар. Беренче дәвердә шагыйрьнең теләк-омтылышлары, фикер ягыннан үсеше, тормышка мөнәсәбәте, тарихи вакыйгаларны, заман агышын аңлавы, бәясе күрсәтелә. Шигырьләренең идея-эчтәлеге, форма төзелеше кебек якларына да хезмәт авторы игътибар итә. Шагыйрьнең беренче әсәрләрендә «татар шәкертләренең аң вә тойгысы» гәүдәләнү, «һәр тараф мөселманнары»ның бәхетен кайгырту; «караңгылыкка, хокук, хөррият, хакыйкать кебиләрне буып торган чылбырларга каршы рәнҗү һәм нәфрәт хисен сурәтләү», «Бакырган, Мөхәммәдия кебек классик әдәбиятның өслүб вә аһәңе тәэсирендә язылу» кебек сыйфатлар билгеләнә.

Уральскида вакытта язган шигырьләренең мәүзугъ (тема) вә мәфһүм (эчтәлек) җәһәтеннән төрлелеге Җ. Вәлиди тарафыннан образлы тел белән түбәндәгечә билгеләнә: «Бакчага яңа килгән сандугач кеби, бертуктаусыз бер ботактан икенче ботакка кунып, әле бер чәчкә, әле икенче чәчкә каршында сайрыйдыр» (Шунда ук, 6 апрель). Шагыйрь әсәрләрендәге хис-кичерешләрнең байлыгы, тирәнлеге, төрлелеге һәм аларның хәрәкәте тәнкыйтьчене сокландыра да, уйландыра да. «Ул шатлана да, кайгыра да, сөя дә, күрә дә алмый. Мактый да, ямanлый да, нәсихәт тә итә, кинәш тә бирә»,—дип, Җ. Вәлиди лирик геройның катлаулы, вакыты белән драматик рухи халәтен, аның аша татар чынбарлыгына, иҗтимагый тирәлеккә каршылыклы мөнәсәбәтен дә чагылдыра. 1905—1907 еллар лирикасында мәхәббәт лирикасында мәхәббәт хисләренең калкулана баруын күрсәтә: «Шулай ук ул вакытта хөррият, дин, милләт хисләреннән кала шагыйрь өчен иң табигый күрелгән бер хис гыйшык вә мәхәббәт хисе иде».

Казан чорының беренче елларында язылган әдәби әсәрләрендә, тәнкыйтьче карашынча, идея-эчтәлек ягыннан үзгәреш күзәтелми, тәрҗемәчелек эшендә аеруча

осталык, талант, аның төрләреннән иркен файдалану, халык авыз иҗаты белән бәйләнеш көчәю билгеләнә: «Бу дәвер бигрәк тә Тукайның уйный, көлә-шаяра торган вакыты булды» *(«Габдулла Тукаев мәҗмугаи әсәре»—Казан, 1913)*—дип, Җ. Вәлиди шагыйрьдәге сатираның көчен, үткенлеген, татар тормышындагы искелек, наданлыкны, уртагасырчылык торгынлыкны, тәкълидчелекне фаш итү сәләтен ассызыклый. Авторның бу карашы Тукайның шагыйрьлеге (1923) дигән мәкаләсендә тагын бер кат искәртелә.

«1910 елда Тукайның рухында алмашыну сизелә... Хәзер исә ул үзенә өмет вә ышанычы кимегән төсле карый» дип, шагыйрь иҗатында өченче дәверне аерып чыгара хезмәт авторы. Гомеренең соңгы елларында иҗат ителгән әсәрләрендәге лирик геройның күңел дөньясы тагын да катлаулана, аның газаплы кичерешләре, драматик психологизмы көчәя. Тукай яшәешенең ике чиге—яшәү һәм үлем турында уйлана. Җ. Вәлиди, нечкә сиземле тәнкыйтьче буларак, шагыйрь күңелендәге капма-каршы хисләр көчешен, аларның һәрдаим үзгәреп, алмашып торуын тотып ала: «Тукаев соңгы елларда бөтенләй хәстә бер лирик булып килде. Ул әүвәлдән үк инде дөньяда тормаска кинәш бирә иде. Ләкин болар сөйләнгән бер вәгазь генә иделәр. Шуның артыннан ук өмет вә сөю шигырьләре килә иде. Соңгы елларда исә шул дөньяны бөтенләй чит күрә вә аннан китәргә бөтен рухы илә ашкына башлады» *(«Вакыт», 6 апрель)*. Бу, һичшиксез, Тукайның хәле, ана иҗтимагый-милли мохитнең тәэсире белән бәйле була. Җ. Вәлиди әлеге сыйфат үзгәрешенә шушы ноктадан якын килә дә. Өченче дәвер әдәби әсәрләрен шушы рәвештә бәяләп, тәнкыйтьче берьяклылыкка бирелми. Анда шигъри куәтнең кимемәве, сәнгати камиллек, лиризм көчәю, һәрдаим шагыйрьне әхлакый, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләр борчып торуы, вакыты белән «саф вәгазь вә нәсыйхәт әсәрләре» язылу искәртелә.

Г. Ибраһимов тарафыннан Г. Тукайның мәхәббәт лирикасына бирелгән берьяклы бәяне йомшарту, кире кагу рухында, бу юнәлештә дә шагыйрьнең уңышлы эшләп килүен, талантлы, матур әсәрләр язуын раслап, Җ. Вәлиди һәрбер мәкаләсендә дәлилле чыгыш ясый. 1905-1907 еллар лирикасында ук мәхәббәт хисләренең калкулана баруын чираттагы бер мәкаләсендә күрсәтеп уза: «Шулай ук ул вакытта хөррият, дин, милләт хисләреннән кала шагыйрь өчен иң табигый күрелгән бер хис «гыйшык вә мәхәббәт» хисе иде». Алга таба мондый характердагы әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешен, бизәкләү чараларының камиллеген, сүзләренең урынлы кулланышын болай дип бәяли: «Тукаевның сөю шигырьләре башка шигырьләреннән бер дә калыш түгел. Галимҗан әфәнде әйткәнчә, мәхәббәт шигырьләре арасында бәгъзе бер уен сүзләре булыр да, аның самимилегенә зур игътибар бирмәскә кирәк. Чөнки мондый сүзләр гашыйкның мәгъшукасына булган мөнәсәбәтен төрләләндерә генә» (...).

Мәхәббәт темасына язылган шигырьләрендә һәм, гомумән, шагыйрьнең тулаем иҗатында күзәтелгән үзенчәлекләрне автор Тукайның шәхси сыйфатлары, тормышының аерым яклары белән дә бәйләргә омтыла: «Тукаев бу турыда шундый хиссият кешесе булып, аның күгенең бер ягында кояш нурларын чәчеп көлеп торса, икенче ягында болытлар арасында яшеннәр яшьни вә күкләр күкридер».

Җ. Вәлидинең тәнкыйте күптармаклы, аның каләме әдип иҗатындагы бер генә якны да игътибарсыз калдырмый. Тукайдагы сатираның көче, үткенлеге, каләменең татар тормышындагы бозыклыкны, артталыкны, искелекне, наданлыкны, җәмгыятьтәге гаделсезлекне фаш итү сәләте ассызыклана. Аннан соң Вәлидинең Октябрь борылышларына кадәр Тукай иҗатының матбугатта яктыртылышына күзәтү ясап чыгуы, басылып чыккан шигырь җыентыкларын укучылар арасында пропагандалавы, шагыйрьнең гыйльми тәрҗемәи хәлен тудыруда җитди адымнар ясавы, һичшиксез, игътибарга лаек.

Җ. Вәлидинең тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Тукай шигъриятенең тел һәм өслүбе мәсьәләсе мөстәкыйль сызык булып бара. Аны аңлау, кабул итү һәм бәяләү ягыннан Вәлиди үз чорының тәнкыйтьчеләре һәм галимнәреннән күпкә өстен тора. Тәнкыйтьче шагыйрь әсәрләренең теле мәсьәләсен аның иҗат эволюциясе яктылыгында, халыкчанлашу ноктасыннан торып өйрәнә. Г. Тукайның башлангыч чорда язылган шигырьләрендә күзәтелгән тел чуарлыгы, өслүбе каршылыклы бәя алган вакытта, Җ. Вәлиди, мәсьәләнең иҗтимагый-милли асылын аңлап, җитди якын килә. Ул шагыйрь яшәгән вакыт, урын, чор үзенчәлегенә таянып эш итә; аны XX гасыр башында татар теленең формалашу процессы белән тыгыз бәйләнештә карый. Җ. Вәлиди Тукайның

Җаек чорында язылган әсәрләренең телен «сай госманлыча яки бераз татарчалашкан» тел дип бәяли һәм заманы өчен табигый, канунлы күренеш булуын ассызыклый: «Бездә хәзерге татар теле тәкрир иткәнчә (барлыкка килгәнче) кадәр күбрәк әдип вә шагыйрьләрнең теле татарчалашкан бозык госманлыча булып, моңа бәгъзе казах вә сарт нәсире (чәчмә телдә язучы) катыша иде. Шуның өчен Тукаев шивәсе (диалекты) вакытына күрә бик табигый иде» *(«Вакыт», 28 июль).*

Тукайның 1905-1907 еллар арасында язылган шигырьләре тупланып, бер җыентык рәвешендә дөнья күргәч, Ф. Әмирхан да тәнкыйди язма белән чыгыш ясый. Ул анда саф татарча әсәрләре белән беррәттән, иске «төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, әзербайҗанча телләреннән корылган шигырьләре» булуын әйтә. Дөрес, автор бу чор Тукай теленә тискәре мөнәсәбәтен сиздереп тә куя: «Габдулла әфәнде кеби табигате шигъриясе кешеләрнең иске вә яңа төрек әдәбияты тәхте тәэсиренә төшеп тә, татар шагыйре урынына—үзләреннән мәтәкәллиф (кирәксез) төрекләшкән шагыйрьләр ясап чыгарулары татар теле һәм әдәбияты ноктаи нәзарыннан (караш ноктасыннан) гөнаһтыр» *(«Әсәрләр», 4 том, Казан, 1986).*

Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында язылган шигырьләренең теле милли тел формалашу хәрәкәтендәге бер үзенчәлекне—Җаек төбәге урынчылыгы телен—чагылдыра. Соңрак бу фикер Г. Сәгъди тарафыннан да куәтләнә, фактлар белән нигезле расланa. Галим инкыйлаб һәм реакция көннәрендә телдә ике агым—төрекчелек һәм татарчылык агымнарының көрәшен билгеләп уза, аларның территориаль чикләрен күрсәтә: «Казан газет-журналларында (монда да бәгъзе бер истисна—(чыгарма бар) каюмчылык, татарчылык кыздырылса, Петроградта («Өлфәт» кебек) һәм Урта Азия чикләрендә *(Оренбургта «Вакыт», «Шура», Уральскида «Әлгасрелҗәдит» кебек)* төрекчелек белән сугарылып баралар иде. Боларда язылган мәкаләләрдә, хәбәрләрдә дә, шигырь вә хикәятләрдә дә шулар иде» *(«Татар әдәбияты тарихы», Казан, 1926).*

Вакытлар үтү белән, шагыйрь әсәрләренең теле үзгәрә, камилләшә, тагын да халыкның җанлы сөйләм теленә якынлаша, татарлашу процессы кичерә. Һәм, әйтергә кирәк, Тукай бу юлда үз замандашлары М. Гафури, Н. Думави, З. Бәшири h. б. белән чагыштырганда алдарак бара. Казан чорында язылган әсәрләре бу юнәлештә камилләшүнең югары үрнәген күрсәтә. Г. Тукай поэзиясенең тел һәм өслүбе өлкәсендәге сыйфат үзгәреше тәнкыйтьчеләр, бигрәк тә Җ. Вәлиди тарафыннан «... тел вә өслүб җәһәтеннән җитди һәм әсаслы (нигезле) бер үзгәреш сизелүе» билгеләп үтелә. Автор: «Ул хәзер чын-чын татар шагыйре» дигән олы бәяне бирә.

Г. Тукай поэзиясенең тел һәм өслүбенә үтә дә таләпчән һәм вакыты белән берьяклы, субъектив мөнәсәбәт белдергән Г. Ибраһимов та шагыйрьнең бу өлкәдә сыйфат үзгәрешен, тел-сүз байлыгын, өслүб гадилеген билгеләп, соклануын белдерә: «Һәм аның теле, өслүбе һәм берәүнең әдәби зәүкын рәнҗетерлек булмый, оста күренә, максатны да гавамга табигый вә ачык һәм матур аңлата, хәтта кешесенә күрә ятларлык та була иде» *(«Әсәрләр», 5 том).*

Камилләшү, татарчалашу процессының иң югары ноктасы буларак, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлидиләр шагыйрьнең «Шүрәле», «Су анасы», «Мияубикә» әсәрләрен билгелиләр. Билгеле булганча, Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» китабында Тукай шигъриятенең тел һәм өслүб үсешендә өч чорны аерып чыгара: госманчылык, күчеш чоры һәм татарлык.

1923 елда шагыйрь иҗатына гомуми бәя бирү юнәлешендә язылган «Тукайның шагыйрьлеге» мәкаләсендә тәнкыйтьче шагыйрь әсәрләренең теле һәм өслүбендәге үзенчәлекләргә, төп сыйфатларга үтә нечкә сизем белән югары бәя бирә: «Тукайның иң сөйдергән ягы, шөбһәсез, аның тел вә өслүбедер. Тукай кадәр җиңел вә тәкәллефсез табигый, шуның белән бергә аһәңле вә сәлис язучы шагыйрь әле һаңүз татарда килгәне юк».

Аннан соң Җ. Вәлиди шагыйрь әсәрләрендә форма һәм өслүб күренешенең аерым якларына да тукталa. Башта Г. Тукай тарафыннан урта гасыр әдәби, дини-әхлакый һәм ярымдөньяви әсәрләренең формалары, аларга хас өслүб файдалану билгеләп үтелә: «Ул шигырьләрен, халыкның электән ияләшкән бер форма вә өслүб илә тәркиб итеп, аны күптәннән өйрәнгән көенә биетә», «Шүрәле» әкият-поэма уңаеннан татар теленең мөмкинлекләре турында һәм аларның шагыйрь иҗатында исбатлануы искәртелә: «...аз гына бер мәйдан шигъри куәт аркасында нинди зур хезмәт тудырырга мөмкин улуы, ифадә вә тасвир өчен татар телендә куәт һәм кабилият булганлыгы вә Тукайның лирик

улдыгы кадәр бер кыйсса... язучы була алачагы аңлашыладыр». Өслүбенең гадилеген, ачыклыгын, табигыйлеген тәнкыйтьче кат-кат ассызыклый: «... нәзымнарда (шигырьләрдә) зәвык вә сәләхият (сәләт), шунын илә бәрабәр садәлек (гадилек) вә табигыйлек Тукаевка сүзләрен ни дәрәҗәдә мәсхүр (сихерләнгән) булганлыгын күрсәтсә кирәк».

Өслүб күренешенең тагын бер сыйфаты—сүзләрне урынлы, үз мәгънәсенә туры китереп файдалану, аларның автор әйтергә теләгән фикерне бөтен тулылыгы белән бирү үзенчәлеге Тукай шигъриятендә ачык күренә. Әйтерсең, шагыйрь сүзләрне куллануда сихри көчкә ия, тылсым таягы белән эш итә. Аның бу осталыгы, Җ. Вәлиди хезмәтләрендә Давыт галәйһиссәләмнең тимер эретү сәләтенә тиңләштерелеп, югары бәяләнә: «Тукаевта сүзләр шулкадәр урынлы вә җайлы тезелгән, гүя гади кешеләрнең каләме чыныга алмаган сүзләрне ул әллә нинди бер сихер куәте белән тота. Ул бик каты вә тупас күренгән татар сүзләреннән дә... теләгән нәзымнар яза».

Шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләләреннән күренгәнчә, Җ. Вәлиди Тукай әсәрләренең теле һәм өслүбенә бәя бирүне тәнкыйтьнең иң мөһим таләпләреннән берсе дип саный һәм аның иҗаты үрнәгендә XX йөз башында милли телнең формалашу тарихын, ул үткән катлаулы юлны да яктырта. Шагыйрь әсәрләренең телен анализлау, бәяләү аша татар теленең олылыгын, байлыгын, аһәңлеген раслый.

Мәгълүм булганча, Җ. Вәлиди—татар әдәбиятының үсеш юнәлешен, татар чынбарлыгы, мохит, иҗтимагый тормыш хәрәкәте, тарихи фактлар белән тыгыз бәйләнештә карап, житди, төпле фикерләр белән чыгыш ясаган галим. Ул милли әдәбиятның Шәрыктан Гаребкә борылуын Тукайның тәҗрибәсенә дә таянып дәлилли. Шагыйрь үзенең башлангыч чор иҗатында урта гасыр суфыйчылык, дини-әхлакый, мәгърифәтчелек һәм госманлы-төрек әдәбиятларының традицияләрен дәвам иттерде. Шуна күрә бу чорда иҗат ителгән әсәрләренең идея-эчтәлек, форма ягыннан Шәрык йогынтысында булуын күрергә мөмкин. Әлеге үзенчәлек Җ. Вәлиди тарафыннан да күрсәтелә: «Тукаевның иң элек телен ачкан шигырьләре форма ягыннан гына түгел, хис вә мәгънә игътибары илә дә шәркый бер характердадыр. Аның авызы мәдех белән ачылды». Әмма шагыйрьнең торган саен Аурупа, рус әдәбиятына ныграк йөз тотуы татар эстетик фикере тарафыннан бертөрле генә бәяләнми. Мәсәлән, Н. Думави шагыйрьнең Гареб тәэсире астына төшүен хупламый, аның аркасында шигъри таланты тулысынча ачылмый калды дигән фикергә килә: «Мәрхүм шагыйребез, чын үзебезнең шагыйребез Тукаев, белмим, бер үлчәүченең куәтеннән куркыпмы, баштарак язган шәркыйлыгын югалтты. Лермонтов, Пушкиннар аша Байрон школасына кереп китә язды. Ләкин мескен барып чыккан бер нәзыйм һәм әгәр шәркыйлыгында дәвам итсә, зур шагыйрь булырлык барып чыккан бер шәрык кабилияте иде *(«Йолдыз», 1915 ел, 22 октябрь)*. Җ. Вәлидинең «Шәрыктан-Гаребкә» мәкаләсенә җавап рәвешендә язылган хезмәтендә ул үз фикерен тагын да ачыклап, шәрехләп китә. Җаек чорында язылган әсәрләре «чын шигырь иделәр» дигән фикер үткәрә, чөнки «ул вакытларда анарда нииндидер фән үлчәвеннән куркулар юк иде», ди. Гареб тәэсиренә төшкәч, аның фикеренчә, соңгы шигырьләрендә мәгънәдәге, хыялындагы хөрлек әзәйде, рифмоплетлык белән тел гармониясе генә калды. Дөрес, шигърият бөтенләй югалып бетмәде. Ул һаман бар иде, ләкин куәтсез, зәгыйфь иделәр *(«Аң», 1916 ел, № 9)*. Җ. Вәлиди исә Тукайның Гареб тәэсиренә бирелүен татар әдәбиятының гомум үсеш тенденциясе яктылыгында, тарихи барышка нисбәтле бәяли: «Ул башта шагыйрь наменә фәкать төрек диваннарын гына күрә вә аларга тәкълид (иярү) итә иде. Соңрак рус әдәбиятын аңлау, Гареб тәэсиренә бирелде. Бу бер Тукаевта гына түгел, безнең бөтән язучыларыбызга гомум булган бер хәл. Безнең соңгы 10-15 еллык бөтен тарихыбыз шул: Шәрык тәэсиреннән Гареб тәэсиренә авышудан гыйбарәттер» *(«Аң», № 3, 4)*.

Шагыйрь иҗатында совет чоры әдәбият галимнәре тарафыннан, безнең карашка, максатлы рәвештә арткы планга калдырган һәм бер ягы белән татар әдәбиятының Гаребкә борылуы белән бәйләнгән Г. Тукайның тәрҗемәчелек эше бар. Тәрҗемәчелек үзе үк татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнеше турында сөйли. Шагыйрьнең замандашлары Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һәм бераз соңрак Г. Сәгъдиләр, Г. Тукай иҗатының бу ягын объектив яктыртып, шактый җентекле, әтрафлы өйрәнгәннәр һәм бу эш, нигездә, барлык тәнкыйтьчеләр тарафыннан да унай, югары бәя ала. Мәкаләләрдә тәрҗемәчелек, тәкълидчелек, нәзыйрәчелек, икътибас (файдаланып язу) кебек сүзләр файдаланыла. Күрәсең, алар Тукай заманында синоним рәвешендә генә кулланылмаганнар, бер-берсеннән беркадәр мәгънәви төсмерләр белән

дә аерылганнар. Аерым алганда, Җ. Вәлидинең тәнкыйди язмаларында бу мәсьәлә эзлекле рәвештә күзәтеп барыла. Ул чираттагы бер мәкаләсендә: «Тәкълидтә без Тукай дәрәҗәсенә ирешкән һичбер шагыйрьне белмибез, хәтта Бабич та аннан бик күп түбән тора. Тукайның читтән алган тәрҗемә һәм икътибаслары тәмам үзенеке булып чыга. Үзебезнең иске әдәбиятка һәм халык әдәбиятына тәкълид аның аерым сөйгән бер нәрсәседер».

Алда әйтелгәнчә, Җ. Вәлидинең шагыйрь иҗатына багышлап язылган мәкаләләре ул вафат булгач дөнья күргән. Автор Г. Тукайның вакытсыз вафатын татар әдәбияты һәм мәдәнияте өчен зур югалту буларак бәяли: «... татар әдәбияты тәсбихендә иң зур төймәләрдән берсе өзелеп төште». Алга таба шагыйрьнең кыска гомере эчендә халыкка, милләткә иткән хезмәте турында уйлана. Тукайның кыска гомерен «күпер аркылы чыгып китү» белән чагыштырып, аның әсәрләрен «күпернең иң нык бер жирендәге нәкышкә (рәсем)» тиңли. Шагыйрь иҗатының үлемсезлеге, халык күңелендә мәңге яшәве турында фикер йөртә: «Аның ул бөек канатлары *(берсе кыйный торган, икенчесе сыйпый, сөя торган,—Г. Т.)* һаман калды. Алар һәнүз (һаман) әүвәлге мәһабәт, вә газамәт илә (бөеклек белән) безнең әдәбият күгебездә кагынып йөриләр, берәүгә мәдех вә сәна (мактау) укыйлар, берәүләрдән һаман көләләр, жәрых (кире кагу) вә һөжүм итәләр». Тәнкыйтьче Г. Тукай шигъриятенә нисбәтле егерменче еллар татар әдәби тәнкыйтендә бөтен зурлыгы белән куелган үзәк мәсьәләгә—әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләсенә үз карашын белдерә. Шунысы кызыклы: Вәлидинең «Тукайның шагыйрьлеге» дигән мәкаләсе Г. Ибраһимов белән икесе арасында әдәби мираска мөнәсәбәт хакында булып узган бәхәстән соң языла. Билгеле булганча, Г. Ибраһимов Октябрь инкыйлабына кадәрге татар әдәбиятының гомумкешелек кыйммәтен, фикри-мәгънәви әһәмиятен инкарь итеп, «тарихи бер дәвернең тарихи материаллары буларак кына» бәяли. *(Әсәрләр, 5 том).* Җ. Вәлиди исә, киресенчә, әдәби мирасның, шул исәптән Г. Тукай иҗатының да, һәр дәвер яңа буын укучылары өчен мәгънәви кыйммәтен, гомумкешелек яңгырашын яклап тавыш бирә: «Тукайның әһәмияте безнең өчен тарихи гына түгел, ул һаман укылачак; руслар Некрасовны укыган вакытта, татарлар да Тукайны укыячак». Ибраһимов белән шундый кискен әдәби бәрелешләрдән соң да Җ. Вәлидинең үз фикерендә калуы, позициясенең, карашының ныклыгы укучыны бүген дә сокландыра.

Димәк, Җ. Вәлидинең Г. Тукайга багышланган тәнкыйди мирасын өйрәнүгә нигезләнеп, төп нәтиҗәләр рәвешендә шуларны әйтергә мөмкин. Аның тәнкыйди эшчәнлегендә Тукай иҗатын бәяләүгә махсус язылган мәкаләләре бар, ә инде еллык хисап рәвешендә язылган күзәтүләрдә тәнкыйтьче шагыйрьнең мәжмугаи әсәрен бәяләүгә, аны укучылар арасында пропагандалауга урын бирә. Татар әдәбиятының үсеш законлалыклары турында сүз алып барган язмаларда исә үз нәзари карашларын нигезләү өчен шагыйрь иҗатына мөрәҗәгать итә. Аларда ул Г. Тукайның татар әдәбияты, татар милләте тормышында тоткан урыны, шагыйрь иҗатын чорларга бүлү, һәр дәвернең идея-эстетик үзенчәлекләре, шагыйрьлек таланты, тел һәм өслүб, шагыйрь иҗатында халыкчанлык һәм миллилек, сатира, тәрҗемәчелек кебек мәсьәләләргә зур игътибар бирә, аларны аңлау юлында житди адымнар ясый. Мәкаләләренең күбесе бәхәс рухында язылган, һәрберсе диярлек Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» һәм башка тәнкыйди язмаларда Тукайга бирелгән берьяклы бәягә каршы юнәлдерелгән. Ә инде аерым бер мәкаләләрдә Ибраһимовның исеме махсус яңгырамаса да, сүз сөреше, фикер агышы, шул хакта сиздереп тора. Җ. Вәлиди шагыйрь иҗатын үз шөһрәте, бөеклегенә бәрабәр югарылыкка, биеклеккә күтәреп, фәнни нигездә өйрәнүне башлап жибәрә һәм ул Тукай турындагы фәннең, беренчеләрдән булып, нигез ташларын салучы галим дип бәяләүгә, һичшиксез, лаек.

**Таһир ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*КДУ доценты.*

*Юмор-сатира*

**Азиз Нәсин,**
төрек язучысы

## Бакча карачкысы

Шулай бервакыт ял көнне йөреп керергә булдым. Ада, Мода һәм башка шундый купшы-матур урыннарны байларга күңел ачарга калдырып, Төпкапы капкасыннан чыктым да, туп-туры җимерек йортлар аша китеп барган идем, озакламый яшелчә бакчаларына килеп кергәнмен.

Кинәт арттан тавыш ишетәм:

—Тыңлагыз әле!

Борылып карадым—бакча карачкысыннан башка беркем юк. Ул җилдә селкенеп тик тора. Эшләпә урынына башында кыршылып беткән тишек төнге чүлмәк. Кием-салымы—таякка эленгән сәләмәләр. Мин куркып артыма чигендем, әмма шунда карачкы телгә килде:

—Курыкма, балакаем!

Куркудан тез буыннарым йомшарып, калтырана ук башладым.

—Исәнмесез, карачкы әфәнде...—дип бытылдап куйдым.

—Йә, безнең туганнар ничек яшәп ята анда?

—Сезнең туганнарыгыз да бармыни?

Карачкының бөтен гәүдәсе — ногыт борчагын бәйләп үстерә торган таягы шыгырдап алды, миңа ул хихылдап көлә шикелле тоелды.

—Әлбәттә, бар! Булмыйча соң!

—Гаҗәп... Юкса, мин яшь кеше дә түгел...

—Шулай, син бу дөньяның бөек кешеләренең бакча карачкылары ыруыннан икәнлеген белмисең, димәк?

—Дөресен әйткәндә, белми идем.

—Йа хода! Соң, без булмасак—тарих та булмас иде бит. Безнең арадан күпме корольләр, патшалар, вәзирләр, министрлар чыккан!

—Кемнәр, мәсәлән?

—Тс-с-с! Авызыңны йом! Берәүләрен әйтергә яраса да, башкаларын хәзергә ярамый.

—Шулай итеп, сезнең туганнарыгыз—бөек кешеләр. Ә ни өчен сезне монда җибәрделәр?

—Вакытында минем дә үз кәнәфием бар иде, үз машинам, үз әрәмтамак ялагайларым.

—Нәрсә булды соң?

—Булмады ла! Үземнең карачкы икәнемне онытып җибәргәнмен дә, хуҗалык эшләренә тыкшына башлаганмын.

—Нинди эшләргә?

—Ә менә син тыңла. Бервакыт ничектер шикәргә, иткә бәяләрне төшерергә, эшчеләр өчен социаль яклау системасы кертергә, эшсезлекне бетерергә, салымнарны киметергә теләдем. Акыллыбаш булып, тормышка ашмас хыялларга биреләдем.

—Соң, шуннан?

—Шуннан шул. Безнең хуҗа андыйларга түзеп тора алмый. Тотты да мине шушында чыгарып ыргытты. Нәкъ мәкальдәгечә килеп чыкты: «Сүзең көмеш булса, дәшмәвең—алтын».

—Әй-әй-әй!

—Менә шулай килеп чыга да: башкалар өчен тамагың карлыкканчы кычкырма, утыр да тәмәкеңне тарт...

—Һем-һем...

—Ә мин өметемне өзмим. Минем якты көннәрем алда әле.

—Аңлап ук бетермим...

—Нәрсәсен аңламыйсың аның? Нindидер аңгыра син. Без, карачкылар, еллар буе шулай карачкы булып тырпаеп тора алабыз. Ә аннары карыйсың—барысы да үзгәрә. Хакимият башындагы карачкылардан кайсысыдыр ялгышып эш турында сөйләнә башлый—аны шунда ук төшерәләр дә аның урынына безнең беребезне куялар, яңа түрә күптән көтеп алынган кәнәфигә тиз генә менеп утыра. —Карачкы бик мәгънәле генә итеп тамак кырып алды, түрә кәнәфиенә үзе менеп утырган, диярсең!—Менә шул чагында сөйләшүебез дә башкача булыр! Бәлки, син дә зур кеше булырга телисеңдер?—дип сорап куйды ул кинәт кенә.

—Теләмичә соң?!

—Бас минем янга, үзебезнеке булырсың.

Мин шулай эшләдем дә. Пинжәгемнең эчен тышка әйләндереп кидем дә, кулларымны як-якка җәеп җибәрдем, карачкыдай басып тик торам. Үз чиратымны көтәм.

Карагыз аны, менә-менә яңа түрә булып сезнең башка килеп төшәрмен әле!

## Гаебеңне таныйсыңмы—юкмы?

Кешелекне йокы дигән коточкыч бәладән коткара алырлык берәр адәм табылса, дөнья цивилизациясе алдында аның бу игелеге бәһаләп бетермәслек булыр иде.

Асылда, нәрсә инде ул кеше гомере? Аның ким дигәндә өчтән берен йоклап үткәрәсең. Дөрес, минем үземнең йокларга бик вакытым юк, ләкин кайчакларда мин дә ул афәттән котылып кала алмыйм. Бераз гына черем итә башладыңмы, күр-кара—сине инде берәр партиягә язып та куйганнар.

Шулай бервакыт, йокының зарары турында тирән фәлсәфи уйларга батып утырганда, кинәт кенә үземне нindидер сәер бер залда күрдем. Нәкъ минем каршымда утлы мөнбәрдә, янып-ялкынланып торган кәнәфидә Зобани утыра. Сорый бу миннән:

—Нәрсә белән шөгыльләнәсең?—ди.

Авыр сорау.

—Төрмәләрдә утырам. Төрмәләрдән арынган араларда аз-маз язгалаштырам, —дим.

—Нәрсәләр язасың?

—Тормыш ваклыклары шунда. Тегесе-монысы. Җыен юк-бар.

—Теркәп куябыз: гаепләнүче үзенең «юк» белән «бар» турында язуын таный.

—Мин бит әле язмадым, язарга җыенам гына...

—Анысы мөһим түгел. Язгансыңмы, язарга җыенгансыңмы—безгә барыбер. Шундый теләгең булдымы?

—Булуын-булды. Ләкин җыен юк-бар турында гына бит.

—Судка барысы да ачык. «Юк» дигән булып, син дәүләт сәүдәсенә ишарә ясыйсың, ә дәүләт сәүдәсе сәүдә министрлыгына бәйле, ә сәүдә министры—хөкүмәт вәкиле. Дөрес сөйлимме?

—Дөрес.

—Димәк, син безнең хөкүмәтне мәсхәрәлисең.

—Шулай булып чыгадыр инде.

—Бу җинаятең өчен—биш ел төрмә. Хәзер «бар» турында сөйләшеп алыйк.

—Сөйләшик...

—Нәрсә соң ул «бар»? Бар ул—шәрабләр су кебек ага торган урын. Ә бездә тагын кайда, ни-нәрсә су кебек ага? Бары тик парламентта гына. Бары тик

сөйләнгән нотыклар гына. Ә аларны кемнәр сөйли? Депутатлар. Ә кемнәр ул депутатлар? Рәсми хакимият вәкилләре. Шулай итеп, гаепләнүче хакимиятнең абруен какшата! Гаебеңне танныйсыңмы-юкмы?

—Какшатам булып чыгадыр инде...

—Теркәп куябыз: ихлас тану. Тагын биш ел. Җәмгысе була ун. Димәк, ун елны истә тотабыз. Инде башка җинаятьләреңә күчик. Гаепләнүче «тегесен-монысын язам» диде. Кем ул «тегесе»? Әлбәттә, безнең гади төрек гражданы. Димәк, гаепләнүче безнең бөтен милләтебезне мәсхәрәләгән. Гаебеңне танныйсыңмы-юкмы?

—Мәсхәрәлим булып чыгадыр инде...

—Монысы өчен дә биш ел, җәмгысе унбиш. Санап бар. Тагын нәрсәләр язасың?

—Язмыйм мин!

—Язасың, язасың, яшерми сөйләп бир.

—Хатлар язам...

—Дәвам итмәсәң дә була. Теркәп куябыз: гаепләнүче кемнәргәдер хатлар аша нииндидер мәгълүматлар бирә. Гаебеңне танныйсыңмы?

—Кемнәргәдер...

—Тагын биш ел, җәмгысе егерме.

—Ә күпме җыярга кирәк?

—Теркәп куябыз: мондый сорау эш вазифаларын башкарганда мәсхәрәләү була. Гаебеңне танныйсыңмы?

Нәрсә әйтергә белмим, дәшмим.

—Әйт, танныйсыңмы?

—Танымыйм!

—Таны!

—Таныйм.

Хөкемдарлар чышын-пышын сөйләшеп-киңәшеп алдылар.

—Анысы шулай, әмма чыш-пыш... пыш-чыш...

—Шуның өстенә чыш-паш, паш-пош, нәтиҗәдә тагын чыш-пыш...

—Катгый карар—чыш-пыш!

—Суд бертавыштан мондый карар чыгара: «Гаепләнүченең гаебе тулысынча исбатлана, әмма, җинаятьнең җинаятьчел уй-теләк рәвешендә генә булуы нәтиҗәсендә, ягъни тулы җинаять составы булмау сәбәпле, җәза срогы ике көн ярымга кимителә. Гаепләнүче егерме елга түгел, ә унтугыз ел һәм дә йөз алтмыш ике көн ярым төрмәдә утыртылуга вә җәһәннәм артына ун елга сөрелүгә хөкем ителә. Гаепләнүченең гомере җәза срогы тулганчы өзелгән очракта, бу җәзаны аның варисларына күчерергә. Әгәр гаепләнүче җәза срогы тулгач та тәүбәгә килмәсә, аны сират күперендәге казыкка утыртырга».

Җәзалаучы фәрештәләр үземне күтәреп алганда гына, салкын тиргә батып уянып киттем.

Ә шулай да төшләрне кирегә юраулары әйбәт бит!

**Марс ШАБАЕВ** *тәрҗемәсе*

*Beznen̡ kalendar'*

## Kin̡ qolaçlı ədip wə ğalim

ĞƏMƏR TOLIMBAYNIN̡ TUUINA 100 YIL

20-30 yıllarda ədəbiat məydanında aktiv eşləgən yazuçı həm tənqitçe Ğəmər Tolımbay (Ğəbdelxaq Cələletdin ulı Şahiəxmətov) 1900 yılnın̡ 14 aprelendə Sember gubernasının̡ Bua øyəze (xəzer Tatarstannın̡ Bua rayonı) Tolımbay awılında tua. Başta ul üz awıllarında, annan Bua mədrəsəsendə uqıy. Annarı Petrogradqa kitə, tuğan yaqlarına kire qaytıp cir dawlaw kərəşlərendə qatnaşa, ə 1918 yılda uqıtuçı bulıp eşli. Qələm tibrətə başlawı da şuşı çorğa turı kilə: şiğerlər yaza, dramaturgiədə kəçen sınap qarıy.

Ğ. Tolımbay grajdannar suğışında qatnaşa. Fronttan qaytkaç, Qazan waqitlı matbuğatında, «Beznen̡ yul» jurnalında bastırğan suğışçan ruxlı məqələləre həm agitatsion xarakterdağı ədəbi əsərləre anı tiz arada yəş ədəbi kəçlərnen̡ berse itep tanıta. Ul şulay uq bu yıllarda nıq cəyelep kitkən ədəbi ağımnar kərəşendə də aktiv qatnaşa.

Ğ. Tolımbay belemen kütərü øçen 1924-1927 yıllarda Tatar kommunistlar universitetında uqıy, «Fatix Əmirxan icatı» digən temağa dissertatsiə yaqlıy, professor digən ğilmi dərəcə ala. Ğømerenen̡ son̡ğı yıllarında pedagogiə institutında uqıta həm Tatarstan dəwlət nəşriatının̡ matur ədəbiat sektorına citəkçelek itə.

Ğ. Tolımbaynın̡ yegerme yılğa yaqın suzılğan icat ğømerendə utız kitabı basılıp çığa. Ədip qaldırğan tørle janrdağı ədəbi mirasnın̡ qiymmətle øleşe— xikəyələr həm fol'klorğa qarağan xezmətlər. Xikəyəçe bularaq, Ğ. Tolımbay 20—30 yıllardağı awıl, krəstiən tormışına bağışlanğan həm andağı üzgəreşlərne, sıynfıy qarşılıqlarnı, kolxozlaşu çorı küreneşləren taswirlağan əsərləre belən qızıqlı.

Ul—tatar mədəniəte xaqındağı küp sanlı məqələlər avtorı da. Ğ. Tolımbay 1939 yılda wafat bula.

## Ğibrətle tormış yulı...

ƏNƏS ĞƏLİEVNEN̡ TUUINA 80 YIL

İcat keşese øçen Xoday birgən talant nurınnan tış, anın̡ tormış yulı ğıybrətle waqiğalarğa bay, kün̡el dəryasının̡ tirən wə kin̡ qolaçlı buluı zarurdır, kürəsen̡. Mon̡a tağın ədipnen̡ tormışnı, Cirdəge barlıq can iələren ixlas yaratuın, xolqının̡ qızıqsınuçan, fikerləwenen̡ fəlsəfi buluın da østərgə kirəkter. Hərxəldə, əsərləren xalıq yaratıp uqıy torğan qələm əhellərenen̡ yazmışları ənə şunı kürsətə.

Ənəs Qasim ulı Ğəliev tə ənə şundıy, əsərləren üze kiçergənnərdən, qaynap torğan tormıştan çumırıp alıp icat itkən yazuçılarıbıznın̡ berse ide. Ul

1920 yılnın 3 aprelendə Arça rayonının dənyaǵa bəyek Tuqayıbıznı birgən Quşlawıç awılında tuǵan. Ətise mulla bulǵanlıqtan, dəhri xakimiətnen cəberzolımnarın balaçaqtan uq kürep üskən...

Ber kilgəngə gel kilə, kürəsen, bəla digənen. Watan suǵışında awır yaralanıp, doşman qulına eləgə. 1942 yıldan 1945 yılǵaça—faşistlar totqınlıǵındaǵı adəm çıdamaslıq ǵazaplar, açlıq-yalanǵaçlıq, qollarça awır xezmət... Suǵış betep, əsirlektən qotılıp qaytqannan son da, üz ilendəge kimsetelülər, qaǵılu-suǵılular... Yəşüsmer çaǵınnan uq şiǵerlər yaza başlaǵan Ənəs Ĝəlievne, elekkege əsir bularaq, ədəbi məydanǵa yaqın da cibərmilər. Ul üzenen yərək qanı belən yazǵan əsərləren 1956 yıldan son ǵına matbuǵatta çıǵara alu bəxetenə ireşə. Anın ber-ber artlı ike şiǵri cıyıntıǵı həm «Yoldızlar şahit», «Namus quşqança», «Tuǵrılıq saǵında», «Hər soldatnın üz yazmışı», «Awıldaşlar», «Cimerelgən xıyallar» digən proza əsərləre dənya kürə. Ul üzenen roman həm povest'larında, Nəbi Dəwli, Xisam Kamalov h. b. frontovik ədiplər şikelle ük, açı front xaqiqəten taswirlıy. Şuna kürəder, əlege əsərlərne uquçılar, ədəbi cəməǵətçelek zur qızıqsınu belən qabul itə, yaratıp uqıy.

Bu urında şunı əytep uzu da urınlı bulır: Ənəs Ĝəlievnen üz icatında üsep, kütərelep kitüendə icattaş dustı, Tatarstannın xalıq yazuçısı Ayaz Ĝiləcevnen ixlas yərdəme də sizelerlek rol' uynaǵandır. Hərxəldə, frontovik ədipnen hər əsəre diərlek «Qazan utları» redaksiəsenə jurnalnın redkollegiə əǵzası Ayaz Ĝiləcevnen xəyer-fatixası belən kilep kerə ide. Ənəs Ĝəlievnen wafatınnan son, anın «Çigengəndə...» digən povesten yazuçı arxivınnan alıp, jurnalǵa təqdim itüçe də Ayaz Ĝiləcev buldı. Bu əsər «Qazan utları»nın uzǵan yılǵı 12 sanında anın kereş süze belən basılıp çıqtı. «Tormıştaǵı açı xaqiqətne tanıǵan, xaq belən xaqsızını cete küz belən ayıra alǵan talantlı zamandaşıbız... emotsional' keçkə iə bulǵan roman-povest'lar yazıp, tatar ədəbiatında batırlıq eşləde... Ənəs Ĝəliev «tuǵrılıq saǵında» torıp, «namus quşqança» yəşəgən çın tatar, tatarnın da zatlısı, çın keşe ide»—dielə əlege kereş məqələdə. Bez də bu fiker belən tulısınça kileşəbez həm Ənəs Ĝəlievnen tormıştan alıp yazılǵan ixlas əsərlərenen uquçılarıbız künelen haman dulqınlandırıp, keşelekle bulırǵa əndəp toraçaǵına ışanabız.

❖

## Çın ədəbiatçı ide...

ILDUS AXUNCANOVNIN TUUINA 70 YIL

Tumıştan uq digəndəy, icat dənyası əçen, ədəbiat əçen yaratılǵan talantlı zatlar bula. Alar sonraq ədəbiatnın qaysı ǵına tarmaǵında at uynatsalar da uquçılarnın xəterendə ozaq saqlanıp qalırday ər-yana fikerlər əytələr, üzençəlekle şəxes bularaq yaqtı yoldız sıman balqıp yəşilər.

Bu ayda üzenen 70 yəşen tutırırǵa tieşle Ildus Axuncanov ta ənə şundıy çın ədəbiat keşese—kürenekle ədəbi tənqitçe ide. Çaǵıştırmaça az sanlı, ləkin yuǵarı sıyfatlı xezmətlər belən ul tatar ədəbi tənqite əlkəsendə onıtılmaslıq ez qaldırdı.

Ildus Ĝəbdelgani ulı Axuncanov 1930 yılnın 23 aprelendə Ijaw şəhərendə tua. Ildusnın bala çaǵı Watan suǵışının qırıs yıllarına turı kilə, ul keçkenədən ük tormış awırlıǵın kürep üsə. Ə 1948 yılda Ijawda urta məktəp təmamlaǵaç ul Qazanǵa kilə həm universitetnın tarix-filologiə fakul'tetına uqırǵa kerə. Sonǵa taba üze də qələm tibrətə başlıy. Biredə uqıtqan kürenekle tənqitçe Ĝazi Kaşşaf yəş yegetnen yazu sələten tiz kürə həm anı «Sovet ədəbiatı»

(xəzerge «Qazan utları») jurnalının ədəbi tənqit bülegenə eşkə ala. Jurnal redaksiəsendə eşləw yəş tənqitçe əçen çın təcribə məktəbe bula. Monda ul tatar ədəbiatının olı zatları N. İsənbət, M. Cəlil, F. Kərim, Ə. Fəyzi, S. Xəkim h. b. lar turında qızıqlı məqələlər yazıp çığa. Ber ük waqıtta uquçılarnı dənya həm urıs ədəbiatı klassikları belən də tanıştıra.

1958-1964 yıllarda İldus Axuncanov Tatarstan radiosında, televideniedə həm Qazan xronikal' fil'mnar studiəsendə ədəbi xezmətkər bulıp eşli. Annarı citdi səbəplər arqasında anın iseme matbuğattan şaqtıy waqıt yuğalıp tora. Ə inde citmeşençe yıllarda İldus Axuncanov iseme Tatarstanda ğına tügel, ə üzək jurnallarda da şaqtıy kürenə. Bu məqələlər anın yuğarı professional' ostalığı, kin qarașı həm fiker tirənlege turında səyli. 1978 yılda Tatarstan kitap nəşriatında tənqitçenen «Xudojnik həm anın süze» digən kitabı da basılıp çığa. Biredə ike teldə də unışlı icat itüçe ədiplər M. Rafikov, Ş. Anak, R. Mostafin, Y. Mostafin, M. Zaripov h. b. lar turında qızıqlı məqələlər urın alğan.

Siksənençe yıllar axırında İldus Axuncanov qatı awırdı həm üzenen 60 yəşlek yubileyın ütkərgənnən son küp tə ütməstən bu dənya belən xuşlaştı da. Əmmə tatar yazuçıları həm küp sanlı uquçılar yaqtı künelle həm ğədel bu keşene sağınıp iskə alalar, anın yazğannarın yaratıp uqıylar.

❖

## Tərcemə ostası

TAHİR NURMƏXƏMMƏTOVNIN TUUINA 70 YIL

Tahir Mirzağəlləm ulı Nurməxəmmətov 1930 yılnın 14 aprelendə Kazaqstannın Semipalatinsk şəhərendə dənyağa kilə. Biregə anın əti-ənise 1921 yılğı açlıq waqıtında Qazan artı təbəgennən küçenep kilgən bula, dənyalar beraz rətləngəç alar kire Qazanğa qaytalar. Monda Tahir urta belem ala, 1949-1953 yıllarda Qazan dəwlət pedagogiə institutının tatar tele həm ədəbiatı bülegendə uqıy, anı təmamlağaç Tatarstan kitap nəşriatının matur ədəbiat redaksiəsendə redaktor bulıp eşli. 1966 yıldan ul nəşriatnın yəşlər-balalar ədəbiatı bülegendə əlkən redaktor həm bülek mədire urınbasarı xezməten başqara. Sonğı yıllarda «Şəhri Qazan» redaksiəsendə eşləde.

Tahir Nurməxəmmətov—tərcemə ostası. A. Kuprinnın ul tərcemə itkən «Sıyırçıq» isemle xikəyələr cıyıntığı 1955 yılda dənya kürə. A. Rıbakovnın «Кортик», «Бронзовая птица» («Xəncər», «Baqır qoş») povest'ları, ğərəp yazuçısı Səxip Camalnın «Qara çəçəklər», tərek yazuçısı Rişad Nuri Güntekinnın «Çalı qoşı» romannarı, R. Frayermannın «Дикая собака Динго, или повесть о первой любви» («Qırğıy et, yəki berençe məxəbbət turında xikəyət) h. b. kürenekle rus həm başqa tuğandaş xalıqlar, çit il yazuçılarının əsərləre tatar uquçısına osta itep taswirlap birelep, uquçılar tarafınnan yaratıp qabul itelde.

Redaktor bularaq ta, T. Nurməxəmmətov tatar ədəbiatının üseşenə, anı propagandalauğa üzennən zur əleş kertte. Matbuğat əlkəsendəge küp yıllıq xezmətləre əçen 1980 yılda Tatarstannın atqazanğan mədəniət xezmətkəre digən maqtaulı isemgə layıq bula. Ul—1973 yıldan Yazuçılar berlege əğzası ide.

1999 yılda wafat buldı.

❖

*Котлыйбыз!*

## Заһирә Гомәровага 70 яшь



Заһирә Гомәрова Арча районы Чөмә-Елга авылында 1930 елның 12 апрелендә дөньяга килә. Башлангыч һәм җидееллык белемне авыл мәктәбендә алганнан соң Арча укытучылар хәзерләү училищесында укый. Аннан Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, химия укытучысы дигән диплом ала. Саба районы, Эзмә авылында химия һәм биология укытучысы булып эшли. Берүк вакытта читтән торып Казан музыка институты каршындагы курсларны тәмамлап музыкаль белем дә ала. Авыл Культура йорты каршында үз укучылары белән оркестр оештырып балаларны музыка серләренә төшендерә. Шулай ук шахмат-шашка белән мавыгуы да аңа уңышлар китерә, берничә ел рәттән республикада уздырылган ярышларда чемпион исеменә лаек була.

Заһирә Гомәрова нигездә балалар өчен иҗат итә. Укытучылык хезмәте аның иҗатында да чагыла, ул балалар күңелен тирән аңлап, аларны яратып яза. Бу темага караган хикәяләр һәм пьесалары да бар. Китаплары шулай ук рус телендә дә дөнья күргән. Ул 17 китап авторы. Шулардан «Яшьлек таңы»—1964, «Иске ел кая китә»—1965. «Мәктәп юлы»—1966, «Нәни врач»—1970 һ. б. балаларның яраткан китабына әйләнде. Заһирә Гомәрова 1990 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

Бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яши. «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлый, иҗат эшендә уңышлар, бәхет һәм сәламәтлек тели.

---

### Хөрмәтле укучыларыбыз!

«Казан утлары»ның быелгы 3 санында «1552 елны Казанны саклаганда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзү фонды» рәисе—Туфан Миңнуллинның мөрәҗәгатен бастырган идек. Бу изге эшкә ярдәм итәргә теләге булган кешеләр өчен әлеге фондның исәп-хисап мәгълүматларын хәбәр итәбез.

ИНН 1654036144
Расчетный счет 40703810900000000103
В КИТБ «Казанский» г. Казань
БИК 049205806
К/с 30101810300000000806

Үзләре килеп иганә кертергә теләгәннәр өчен Фондның адресы:
*Казан, Кремль урамы, 9 йорт, 13 бүлмә.*

*Котлыйбыз!*

# Артист һәм шагыйрь



Хәлим Җәләл - язучылары һәм артистлары белән мәшһүр Балык Бистәсе төбәгеннән. Хәлим укыган Олы Солтан мәктәбеннән генә дә язучы-шагыйрьләр - Роберт Әхмәтҗанов, Вакыйф Нуруллин, Кадыйр Сибгатуллин, Әхәт Гаффар, Рәшит Гарипов, Мидхәт Миншин, Әхәт Сафиуллин, Мансур Шиһапов, Мансур Шаһимәрдән, Фәүзия Солтан..., артистлардан - Рауза Хәйретдинова, Равил Шәрәфи һәм... Хәлим Җәләлләр чыккан. Ул бу мәктәпне 1957 елда көмеш медаль алып тәмамлый. Башта ул авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Әмма, яшьтән үк сәнгать белән мавыккан Хәлим, берничә ел бу институтта укыганнан соң, аны ташлап, Казан театр училищесына укырга керә. Күренекле шәхесләр - Ш. Сарымсаков, Г. Шамуков, Х. Уразиковлардан осталык мәктәбе узып, 1961 елны училищены тәмамлагач, аның бөтен иҗат гомере Г. Камал театры белән бәйле. Артист 40 елга якын хезмәт дәверендә театр сәхнәсендә дистәләгән онытылмаслык образлар иҗат итте. Шүрәле (Н. Исәнбәт. «Кырлай егете»), Гайфи (Х. Вахит. «Күк капусы ачылса»), Шәкүр (Т. Миңнуллин. «Диләфрүзгә дүрт кияү»), Ильяс (М. Әмир. «Агыйдел»), Прометей-Гермес (М. Кәрим. «Ташлама утны, Прометей!»), Шәвәли (Г. Ибраһимов. «Татар хатыны нилләр күрми»), Ахун (Н. Исәнбәт. «Хуҗа Насретдин»), Гата (З. Хәким. «Көрәзәче») образлары әнә шундыйлардан.

Ул, шулай ук, татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен телевидение һәм радио аша халыкка җиткерү буенча да зур хезмәт куйган артист. Бүгенге татар поэзиясен, аерым алганда, Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләм, Зөлфәт әсәрләрен пропагандалауда аның роле зур булды.

Хәлим Җәләл—җәмәгатьчелеккә шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак та билгеле. Бу яктан кабатланмас талант Габдулла Шамуков традициясен дәвам итүче ул. Аерым китаплары «Корчаңгы тай һәм таз малай» (1997), «Шәрә бүре» (1999) бүгенге татар балалар поэзиясенең уңышлы әсәрләре дип бәя алды.

Ул—1998 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.

Күренекле артист һәм шагыйрьне 60 еллык юбилее белән котлыйбыз, исәнлек-саулык һәм яңа иҗат уңышлары телибез!

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### БАШКАЛА ЮБИЛЕЕНА ӘЗЕРЛЕК

Татарстан Республикасы Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча республика комиссиясенең утырышын үткәрде. Очрашуда Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Илгиз Хәйруллинның тәкъдимнәре каралды һәм Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаковның «Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын үткәрүгә әзерлек концепциясенең төп нигезләмәләре турында»гы доклады тыңланды. Программа барышында Казан хакимиятенең һәм промышленность предприятиеләренең байтак кына эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, башкаланың архитектура һәйкәлләрен төзекләндерү һәм реконструкцияләү планлаштырыла.

### БӘЙГЕ-КОНКУРС

Татарстан Язучылар берлеге, уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыятенең республика советы уйлап табу һәм рационализаторлык эшчәнлеге турында иң яхшы очеркка, зарисовкага бәйге-конкурс игълан иттеләр.

Бәйгедә язучылар, журналистлар, башка авторлар катнаша ала. Газета-журнал битләрендә басылган һәм радиода яңгыраган, телеэфирга чыккан материаллар 2000 елның 20 декабренә хәтле тәкъдим ителергә тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата премияләр көтә. Беренче урынга—биш мең, ике икенче урын өчен—өчәр мең, өч өченче урынга—икешәр мең сум.

### ОЧРАШУЛАР

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, аның урынбасары Шаһинур Мостафин, шагыйрә Резеда Вәлиева, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев Әгерҗе районының Иж-Бубый, Кырынды, Кичкетаң авылларында булып, әдәбият сөючеләр белән очраштылар. Район үзәгендә шәһәр мәктәпләре укытучылары һәм укучылары белән очрашу барышында яшь иҗатчыларның яна әсәрләре тикшерелде, уңышлылары матбугатка тәкъдим ителде.

### КҮЗ УҢЫНДА— ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

24 февраль көнне Татарстан Язучылар берлегендә тәнкыйть һәм поэзия остаханәләренең берләштерелгән утырышында «Бүгенге вакытлы матбугатта язучыларның иҗат портретлары» дигән темага эшлекле сөйләшү булып узды. Утырышта катнашучылар язучының иҗат портреты турында бәхәсле әңгәмә кордылар. Сүз, әлбәттә, иҗат эшчәнлеген җанландыру, тәнкыйтьнең куәтен арттыру турында да барды.

### МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ ЮЛЫНДА

28 февраль көнне татар әдәбияты классигы Нәкый Исәнбәт исемен мәңгеләштерү максатыннан 1931—1957 елларда ул яшәгән йортка (Мөштәри урамы, 13 йорт) мемориаль такта беркетелде. Барельефның авторы— М. Гасыймов. Мемориаль тактаны ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, мәдәният министры урынбасары Р. Вәлиев, галим Ф. Ганиев, артистка Н. Ихсанова һ. б. чыгыш ясады.

### МӘГЪРИФӘТЧЕ ГАЛИМГӘ БАГЫШЛАП

Танылган татар мәгърифәтчесе, галим Каюм Насыйриның 175 еллыгы уңаеннан Милли китапханә үзенчәлекле күргәзмә оештырды. Анда бу кабатланмас шәхеснең язучы, мәгърифәтче, тарихчы-этнограф, тел белгече буларак язган китаплары һәм язмалары куелды. Шунда ук галимнең төрле елларда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр», «Әкиятләр», «Китап-әт-тәрбия», «Дару үләннәре» һ. б. китаплары бар.

### ИСКӘ АЛУ

Г. Тукай музеенда күренекле шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең 120 еллыгы уңаеннан конференция узды. Анда шагыйрьнең иҗаты хакында галимнәр Н. Хисамов, З. Рәмиев, Н. Ханзафаров, Р. Ганиева, М. Гайнетдин, язучылар Р. Батулла, Г. Гыйльманов, Ш. Мостафин, Р. Әхмәт һ. б. чыгыш ясады. Шагыйрьнең әсәрләрен Россиянең һәм Татарстанның халык артисты А. Арсланов укыды. Татар гимназиясе укучылары Сәгыйть Рәмиевнең шигырьләрен сөйләделәр. Җыенны Г.Тукай музее директоры М. Низамиев алып барды.

### ЯЗУЧЫ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Лениногорск шәһәрендә шушында яшәп иҗат иткән язучы Җәмит Рәхимовны искә алу кичәсе булып узды. Әгәр исән булса, аңа 65 яшь тулыр иде. Кичәне район һәм шәһәр хакимияте, «Чишмә» иҗат берләшмәсе оештырды.

Шулай ук шагыйрь яшәгән йортка истәлек тактасы куелды һәм шәһәрнең бер матур яңа урамына Җәмит Рәхимов исеме бирелде.

### МӘКТӘПТӘ МУЗЕЙ

Дәрвишләр бистәсендәге 58 нче мәктәптә танылган композитор Фасил Әхмәтов иҗатына багышланган музей ачылды. Тантанада бер төркем мәдәниятсәнгать әһелләре, композиторның туганнары һәм дуслары катнашты.

### КИРӘКЛЕ БЕЛЕШМӘ

Милли архив һәм Үзәк дәүләт тарихисәяси документлар архивының белешмәкүрсәткечләре дөнья күрде. Әлеге басмаларда саклагычларда җыелган рәсми кәгазьләрнең исемлеге хронологик тәртиптә төзелгән. Эчтәлеге, күләме һәм бүтән мәгълүматлар да язылган белешмә архив белгечләре һәм бүтән кызыксынучылар өчен кирәкле.

### ЯКТАШЛАРЫН ДАНЛЫЙ

«Татарстан» журналы редакциясе каршында оештырылган нәшрият Рифат Фәттаховның «Рәшит Ваһапов» дигән китабын бастырып чыгарды. Анда халкыбызның мәшһүр җырчысы узган иҗат һәм тормыш юлы тасвирлана. Автор бу хезмәтен моңарчы билгеле булмаган архив материалларына, җырчы турында замандашлары истәлекләренә таянып язган. Ә үткән ел шушы ук нәшриятта Р. Фәттахов нәширлегендә Хәйдәр Бигичев турында истәлекләр китабы дөнья күргән иде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар драма сәнгатен үстерүдәге зур уңышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **Әзһәр Шәфыйк улы Шакировка** «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

### КАЛӘМДӘШЕБЕЗ— ДӘРӘҖӘЛЕ ГАЛИМ

10 мартта журналыбызның даими авторы, Казан дәүләт университеты доценты, танылган шагыйрь **Сөләйман** (Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы) Туполев исемдәгә Казан техник университеты гыйльми советы утырышында «Гамәли юнәлешле лингвистик модельләр нигезендә табигый тел текстларын эшкәртүнең системалары һәм информатик технологияләре» дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Утырышта катнашучы Мәскәү һәм Казан галимнәре каләмдәшебезнең гыйльми эшен югары бәяләделәр.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Язгы ташу.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы—публицист Мәгъсүм Гәрәев.

# ЯҢА КИТАПЛАР


Дилбәр САИНОВА-ӘХМӘРОВА. **Салих Сәйдәшев** *(рус телендә)*.—Казан: Татарстан китап нәшрияты.—1999.—212 б. Тиражы—3000 данә.



Мәгълүм булганча, бу елның декабрь аенда бөек композитор Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тула. Шул унай белән Республикакүләм юбилей комиссиясе төзелде һәм аның эш планында композиторның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә байтак игелекле эшләр каралган. Бу монография—әлеге юбилей мөнәсәбәте белән нәшер ителгән басма. Күп кенә архив материаллары тупланган һәм фотоматериаллар белән иллюстрацияләнгән бу китапта Салих Сәйдәшевнең тормыш һәм иҗат юлы шактый тулы яктыртылган.

Китапның редакторлары—Үзбәк Әхмәров һәм Булат Хәмидуллин.

Хуҗи МӘХМҮТОВ. **Канатлы сүз—хикмәтле сүз** (Ни өчен болай әйтәбез?).—Казан: «Мәгариф» нәшрияты.—1999.—174 бит. Тиражы—1000 данә.



Туган телебездәге күп кенә мәкаль, әйтем һәм башка сурәтле тәгъбирләрнең барлыкка килүе төрле тарихи вакыйгалар, көнкүрештәге гыйбрәтле хәлләр, борынгы йола-ышанулар, гореф-гадәтләр, миф, риваять, легенда, кыйсса, әкият, мәзәк кебек фольклор әсәрләре белән бәйләнгән. Филология фәннәре докторы Х. Ш. Мәхмүтовның бу китабында әнә шундый 150 дән артык гыйбарәнең килеп чыгу тарихлары яктыртыла, аларның мәгънәләре, әдәби телебездә кулланылыш үзенчәлекләре күрсәтелә.

Китап тел-әдәбият укытучылары, фән һәм матбугат әһелләре, студентлар, мәктәп балалары һәм туган телебезне ихлас яратучы, аны тирәнрәк өйрәнергә омтылучы күпсанлы укучылар өчен кызыклы һәм файдалы бер кулланма.

Индекс 73210



Мәгъсүм Гәрәев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)